# Казан утлары

9.1995



## Тәвәккәл булыйк, милләттәшләр!

*(Россия, БДБ һәм Балтыйк буе илләрендәге татар газета-журналлары, телерадиотапшырулар мөхәррирләре семинары һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты утырышында катнашучыларның татар халкына мөрәҗәгате)*

**Тарих безнең өчен мәрхәмәтсез булган. Язмыш җилләре безне күп гасырлар дәвамында дөнья киңлекләренә сипкән. Милләтебез дәүләтен югалту, басып алучы кул астында сыкранып яшәү фаҗигаларын кичергән. Хәзер, дүрт йөз елдан артык колония шартларында яшәгәннән соң, халкыбыз, Россиянең башка милләтләре белән берлектә, үзен саклап калу өчен көрәш, дәүләтчелеген торгызу юлына басты. Бу көрәштә аерым җиңүләр булса да, соңгы вакыйгалардан күренгәнчә, империячел көчләрнең үз позициясеннән ваз кичәргә исәбе юк. Шулай ук милләтнең дә үзаңы тиешле дәрәҗәдә булмавы, шунлыктан азатлык хәрәкәтенең дә әле озакка сузылачагы билгеле булды. Бу хәл милли көчләрнең дә хәрәкәт тактикасын үзгәртүне таләп итә. Шулардан чыгып, сезгә түбәндәгеләрне җиткермәкче булабыз, милләттәшләр!**

**Рухыгызны төшермәгез! Дәүләтле булу, дөньяның алга киткән милләтләре белән тигезләшү уе сезне ташламасын. Без аңа ирешербез. Тик аның өчен безгә фаҗигале тарихыбызга әйләнеп карарга, аннан гыйбрәт алырга, милли бердәмлегебезне ныгытырга кирәк.**

**Әгәр дә без чыннан да шундый уй белән яшибез икән, түбәндәге фикерләрне күңелгә беркетеп кую фарыз, милләттәшләр:**

**— Кайда яшәвеңә карамастан, Татарстанның мөстәкыйль дәүләт булып әверелүенә ярдәм ит. Бары тик ул чын дәүләт булып оеша алса гына, синең саклаучың һәм яклаучың булачак. Дәүләтле милләтнең генә җир йөзендә кадере бар.**

**— Татар, Татарстан исеменә яла ягуларга каршы көрәш, алар турында җәмәгатьчелектә дөрес фикер урнаштыру өчен тырыш.**

**— Һәркайда милли гаделсезлеккә каршы чык, татар мәдәниятен һәм мәгарифен үстерү эшендә башка милләтләр белән тигез мөнәсәбәт күрсәтелүенә иреш.**

**— Кайда яшәвеңә карамастан, гореф-гадәтеңне, динеңне тот; милли бәйрәмнәреңне уздыр.**

**— Гаиләңне башка милләт вәкиле белән бәйләмәкче булсаң, ыру-милләтеңнең алга таба дәвам ителү-ителмәвен уйла.**

**— Милләтеңнең киләчәге булсын дисәң, гаиләң ишле булсын һәм балаларыңны милли традицияләрдә тәрбиялә; һәркайда ана телендә тәрбия бирелә һәм укытыла торган бакча, мәктәпләр булуын кайгырт.**

**— Башка милләтләргә карата ихтирамлы бул. Ә татар кешесен үзеңнең туганың дип уйла, аңа ярдәм ит.**

**Бары тик шулай яшәгәндә генә без морадыбызга ирешербез, дәүләтле һәм озын гомерле милләт булырбыз. Бердәм булыйк, түземле һәм тәвәккәл булыйк, туганнар!**

*Мөрәҗәгать 1995 елның 20 июнендә кабул ителде.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**9**

**(875)**

**1995**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Н. НӘҖМИ. Көтүчеләр. *Шигырьләр* .......... 3
Р. НИЗАМИЕВ. Татарстан турында моңсу жыр. *Шигырьләр* .......... 66
Р. РАХМАН. Кояшлы җәй. *Шигырьләр* .......... 73
Т. ӘЙДИ. Кечкенә дә төш кенә. *Эстониягә сәяхәт* .......... 78
К. ЛАТЫЙП. Җиденче сәяркә. *Новелла* .......... 141

ГАРИФ АХУНОВКА 70 ЯШЬ

Г. АХУНОВ. Йолдызлар калка. *(Автобиографик повестьның икенче китабыннан)* .......... 8

ФИРАЯ ЗЫЯТДИНОВАГА 50 ЯШЬ

Ф. ЗЫЯТДИНОВА. Дулкыннар. *Шигырьләр* .......... 132

ПУБЛИЦИСТИКА

М. АБДУЛЛИН. «Колхоз тарала микән?» .......... 145
Р. ХИСАМЕТДИНОВ. Дусларымның васыятен үтәдем .......... 151

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

К. ГЫЙЗЗӘТ. Тажи Гыйззәтнең реализмы *(Тууына 100 ел тулу уңаеннан)* .......... 173
Гасырлар авазы .......... 182

КАРДӘШ ӘДӘБИЯТЛАР

Җәнгиз Дагҗыга 75 яшь .......... 187

Безнең календарь .......... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнен адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повествование о путешествии в Эстонию Т. АЙДИ «Маленькая да удаленькая», новелла К. ЛАТЫЙПОВА «Седьмая любовница»; стихи Н. НАДЖМИ, Р. НИЗАМИЕВА, Р. РАХМАН, Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ.
«К 70-летию Гарифа Ахунова»: автобиографическая повесть Г. АХУНОВА «Когда зажигаются звезды».
«Публицистика»: статья М. АБДУЛЛИНА посвящена острым проблемам колхозов; статья Р. ХИСАМУТДИНОВА «Я выполнил завещание друзей».
«Литературная критика»: статья К. ГИЗЗАТА «Реализм Тази Гиззата».
Эхо веков.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: День Памяти в Казани; известный писатель, публицист, общественный деятель Айдар Халим.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: T. Aidi's narration about the journey around Estonig «Stall but daring», K. Latipov's short story «The seventh lover», the verses of N. Najmi, R. Nizamiev, R. Rakhman, Ph. Ziyatdinova.
«To the 70 th anniversary of Gariph Akhunov»: G. Akhunov's autobiographical novel «When the stars gatch fire».
«Publicism»: M. Abdullin's article devoted to the sharp problem of collective farms; R. Khisamutdinov's article «I did my duty».
«Literary gritique»: K. Gizzat's article «Tazi Gizzat's realism».
«Echo of the past years».
«Our Calendar».
«The diary of the social and cultural life».
In our corvers: Memory day in Kazan, the well-known writer, publicist, public figure Aidar Khalim.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.


*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Марсель Гали, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 2.08.95 ел. Басарга кул куелды 11.09.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 7 981. Заказ Д-396.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Нажар Нәҗми

### Көтүчеләр

Аполлонны, шигърият алласын
Дуңгыз көткән, диләр, заманында.
Безгә мәгълүм хәзер: Мөхәммәт тә
Көтү көткән Мәккә яланында.

Алланың һәм пәйгамбәребезнең
Күз алдына басса үткәннәре,
Искә төшә Хәсән Туфанның да
Себерләрдә көтү көткәннәре.

### Телләр

*Рәшит Әхмәтҗан истәлегенә*

Акыл теле, йөрәк теле —
Шагыйрьнең корал көче,
Шул коралы белән чыга
Сугышка шагыйрь кеше.
Бәйле илнең теле икәү,
Бер телле була бәйсез.
Бәйсез урыска, ахыры,
Бер телле булу җайсыз.
Пушкин һәм пушка теләндә
Сөйләшә урыс һаман.
Барлык бәйле халык өчен
Ике теле дә яман.
Берсе бәйле халыкларның
Телләрен онлый, йота.
Икенчесе бер гаепсез
Җирләрне утка тота.

Пушка теле — ул ут теле,
Кан һәм кыйралыш теле.
Ул ут-тел кешеләрне дә,
Җирне дә итә үле.
Атышлар ерак барса да
Җан өчен юктыр ара,
Ут йөрәккә килеп тия,
Ул ут йөрәкне яра.
Ярылу да һәм шартлау да
Хас ул чын йөрәк өчен.
Шартлауларга каршы шартлау
Ул чын йөрәкнең көче.
Кан, ут, кыйралыш Рәсәйнең
Бөтен тарихи йөзе.
Шулар белән горурланып
Ул яши һаман үзе.
Шартлады шагыйрь йөрәге
Ул бомба булып гүя.
Кайчан юар канлы йөзен
«Юылмаган Русия»?

* * *

Быелгы кыш шундый озын булды,
Яз дигәнең иртә килсә дә.
Февраль ае җитмеш җиде яшьне
Бүләк итеп миңа китсә дә.
Яңа елы — яңа ел булмады.
Кан коелгангамы Чәчәндә.
Әлеге шул: көчең барда акыл
Һич кирәкми, дигән мәсьәлә.
Әлеге шул: барын бүлгәлә дә
Хакимлек ит дигән ерткычлык.
Җиребездә, шушы ерткычлыкта
Яшәп ята ялган тынычлык.
Пушка тавышлары телгәләргә
Әзер торган чакта җиреңне,
Без җыр, бию, курай моңы белән
Каршы тормакчыбыз шикелле.
Әйе, сөрән без салмадык түгел,
Ә канкоеш барды, бетмәде.
Ул сөрән дә Уфа мәйданыннан
Ары китә алмады... Китмәде!
Көенечем кысыр көек кебек,
Авыр үткәнгәме һәр көнем.
Язлар үтеп, җылы җәйләр килгәч,
Эрер бәлки туңган күңелем.

Быелгы кыш шундый озын булды...

## Зәки Вәлиди кабере янында

Ак мәрмәр таш... Мәрмәр ташта — язу.
Ә ул язу төрек теләндә.
Мәрмәр таштан «башкорт» дигән сүз дә
Карый миңа төрек җиреннән.
Тынлык монда... Кипарислар да тын...
Якты тынлык кабер өстендә.
Ә күпме соң давыл һәм гарасат
Бу кабердә яткан җисемдә,
Гарасаты да бит, давылы да
Ут төсендә һәм кан төсендә:
Күпме язмыш, күпме кеше гомере
Килеп бәрелә шушы исемгә.
Күпме тартыш, хәтта милли тартыш,—
Аңлап бетергесез күпләргә.
Сөрән салган хәтта Ходайбердин:
«Зәки башкорт түгел, башкорт ул — мин.
Ышанмагыз сез ул типтәргә».[1]
Күпме еллар шушы шәхес белән
Үлчәнде аң һәм җан, күп җисем.
Бер Бабичның гомерен генәме
Фаҗигале итте бу исем?
Кан коешка, бөтен буталышка
Гаепледер сыман ул гына.
Азатлык дип, җанын фида кылган —
Бар «гаебе» аның шул гына.
Еллар узгач, әй, ул күз ачылу.—
Барысы бит булган нахакка.
Ләгънәт төшсен милли азатлыкны
Милләтчелек дигән ахмакка!
Мәрмәр ташта язу... Рухына, дип,
Фатиха, дип, анда язылган.
Рухы әле һаман аның тере,
Фатихасын бирә хәр заман.

## Истанбул

Бөек кала, син зур базар кебек,
Әгәр сиңа тыштан карасаң.
Син күк белән сөйләшәсең кебек,
Азан әйтүләрен тыңласаң.
Син илеңнең милли йөзек кашы,
Халкың горурлыгы, байлыгы.
Аңкып тора синдә төрек иле —
Чын мөстәкыйль илнең барлыгы.
Ничәмә ел урыс белән сугыш,
Йә җиңә ул, йә ул җиңелә.
Нишләр идең, әгәр урыс җиңеп,
Калсаң син дә Казан көненә?

---

[1] Шаһит Ходайбердинның 1919 елның 19 февралендә «Кызыл яу» газитендә татарча басылган «Башкорт ярлыларына» дигән чакыруы күздә тотыла.

Нишләр идең, Петр Беренченең
Хыяллары ашса тормышка?[1]
Яшәр идең микән бүгенгедәй
Якты, горур, иркен сулышта?
Тугрылыгың синең искитмәле
Телгә, денгә, гореф-гадәткә.
Синнәндер ул мөмкин өйрәнергә
Кешелеклеккә, әдәпкә.
Кешелеклелек... Юкка гынамыни
Сиңа якын башкорт, татарлар.
Аларның бит бөек улларының
Сөякләре синдә яталар.
Әйтерсең лә Ходай үзе сиңа
Сайлап биргән шушы урынны.
Балкый-балкый син өстисең кебек
Ходай нурына үз нурыңны.
Базарларың, азаннарың белән
Син каласың истә, Истанбул.
Бу дөньяда безнең барлыкны да
Онытмасаң иде... Исән бул!

*1994*



[1] Петр Беренче үзенең яшерен васыятендә Истанбул каласын Русиянең башкаласы итәргә куша.

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**



# ГАРИФ АХУНОВКА 70 ЯШЬ

# ТЫНГЫСЫЗ ИҖАТЧЫ

Танылган әдип, җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахунов Татарстанның Арча районы Өчиле авылында 1925 елның 18 сентябрендә игенче гаиләсендә туа. Арча педагогия училищесен (1947), Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген (1952) тәмамлый. Студент елларында әдәби иҗаты да башланып китә — «Галләм сорау бирә» дигән беренче хикәясе матбугатта (1951) басылып чыга.

Г. Ахуновның тормыш юлы тулаем татар әдәбияты үсешеннән аерылгысыз: «Совет әдәбияты» журналының әдәби хезмәткәре, проза бүлеге мөдире, җаваплы секретаре, баш редакторы, Татарстан язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җитәкчесе, Татарстан язучылар берлеге рәисе (1974—1984) булып эшли. Шушы дәвердә ул ике тапкыр Әлмәт шәһәр советына, ике мәртәбә (1974—1984) СССР Югары Советына сайлана, күп еллар буе РСФСР ЯБ идарәсе әгъзасы, РСФСР һәм СССР Язучылар берлекләре секретаре, төрле басмаларның редколлегияләре әгъзасы вазифаларын да башкара. Аның җәмәгать эшчәнлеге монда саналганнар белән генә чикләнми, ул кайда да үз шөгыленә җаваплы каравы, берсенә дә сәләтен һәм көчен кызганмавы белән таныла.

Җаваплы вазифалар башкару бик күп вакытны һәм дәрманны алганлыктан, кайберәүләрнең, гадәттә, иҗаты сүлпәнләнә һәм тоныклана. Г. Ахунов каләме исә әнә шундый киеренке эшчәнлек барышында үткенәя һәм житезләнә генә төшә — ул берничә тармакта бәрәкәтле иҗат итүгә ирешә: йөзләгән мәкаләләр, очерклар бастыра, докладлар сөйли, радио-телевидениедә чыгышлар ясый. Татар укучылары В. Закруткинның «Йөзмә станица», А. Макаренконың «Педагогик поэма», М. Шолоховның «Тын Дон» (2, 4 китаплар), Н. Шундикның «Боланнар илендә» романнарын, Р. Тагор хикәяләрен аның тәрҗемәсендә укый, Н. Погодин һәм А. Островский пьесаларын аның тәрҗемәсендә тамаша кыла. Берәүгә гомер буена житәрлек эшләр бу! Әмма Г. Ахунов театрларыбызда «Чулпы жыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк», «Кичләвек төше», «Ардуан батыр», «Икәүдән икәү генә» пьесаларын куйдыруга да өлгерә, Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен сәхнәләштерүгә зур өлеш кертә.

Оста тәрҗемәче, кайнар рухлы публицист, танылган драматург... Ләкин Г. Ахуновның әдәби шөһрәтен хикәяләре, повестьлары һәм романнары чыгарды. «Яшьлек яме», «Артышлы тау буенда», «Канатлар кая илтә»,

**«Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Олы язга сәяхәт», «Без бит Арча яклары», «Йолдызлар калка», «Этләр патшасы», «Тимерханның яшьлеге», «Акча күктән яумый» һ. б. повестьлары, «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы», «Гомер юлы» романнары инде күпләрнең яратып укый торган әсәрләренә әйләнде. Автор «Чикләвек төше» һәм «Хәзинә» өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде, аның «Хәзинә» романын Свердловск киностудиясе экранлаштырды һәм шул исемдәге нәфис фильм бөтен СССРда күрсәтелде.**

**Г. Ахунов әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителгән, аның әдәбиятыбызны үстерүдәге тырышлыгы, матур казанышлары СССР орденнарына, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булды. 1993 елны Президентыбыз М. Шәймиев Указы белән Гариф Ахуновка — иң дәрәҗәле исем — «Татарстан Республикасының халык язучысы» исеме бирелде.**

**1957 елдан Язучылар берлеге әгъзасы Гариф Ахуновны — хөрмәтле каләмдәшебезне — без олы юбилее белән котлыйбыз һәм киләчәктә дә «Казан утлары» журналы редакциясен, барлык укучыларны яңа әсәрләре белән сөендерүен телибез. Аның «Йолдызлар калка» әсәренең икенче китабыннан күләмле өзекне укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.**

# Гариф Ахунов

# ЙОЛДЫЗЛАР КАЛКА

(АВТОБИОГРАФИК ПОВЕСТЬНЫҢ ИКЕНЧЕ КИТАБЫННАН)

## Тәүге хисләр

Арча педучилищесында мин ике мәртәбә укыдым. Моның бик җитди сәбәпләре бар, аны укучы дусларыма җентекләп аңлатып бирмичә булмас.

Беренче мәртәбә минем Арча педучилищесында укый башлавым 1940 елның сентябрендә булды. Чабатасыз студент икәнемне инде сөйләп биргән идем. Безгә утыз сум стипендия бирәләр, дәресрәге — аны кулга бирмиләр, тулай торакта торган өчен һәм бер мәртәбә ашханәдә көндезге ашны ашаган өчен тотып калалар иде. Шул ел балалары хәтерли: авылларда колхозчылар «тишекле сутыйга» эшлиләр, хезмәт көненә ике-өч йөз граммнан артык ашлык бирелми иде. Күрше-тирә авыллар барысы да пешкән ипине Казаннан капчык күтәреп ташыйлар иде. Моның өчен авыл агае ике-өч көн Казанда ятарга, төннәрен йокламыйча ипи чиратында торырга тиеш, тагын әллә ниләр эшләргә тиеш. Сугышка кадәр дә, сугыштан соң да байтак еллар колхозчының тамагы ипигә туеп тормады.

Безгә, педучилище студентларына, ипине норма белән ашханә буфетында сатып бирәләр, иртән без ашханәдән кайнар суны шешәгә тутырып алып чыгабыз да шуның белән ипине чылатып ашап, дәрескә йөгерәбез. Мин, Арчаның кулланучылар җәмгыяте һәм кайбер учреждениеләре белән танышып, бәйрәмнәрдә алар өчен кызыл материягә кләйле акбур белән плакатлар яза идем, балалар бакчаларына әкият рәсемнәре ясый идем, шуның белән тамак туйдырып бара идем.

Ел азагындарак безнең өскә күкләр күкрәп, яшеннәр атылды: педучилищеда укыган өчен акча түләргә дигән карар килеп чыкты. Стипендияне дә бер дә «икеле» алмаганнарга гына бирергә булдылар. Минем акча түләү ягы җайланды: әти юклыкка һәм кулаклар кулыннан вафат булган әти өчен алган пенсиягә карата Казанбаш авыл советыннан белешмә китереп тоттыргач, мине укыган өчен акча түләүдән азат иттеләр. Татарча фәннәрне — телне, әдәбиятны, тарихны, географияне мин бик яхшы билгеләренә генә укый идем, минем математика ягы сайрак та, урыс теленнән диктант бик барып чыкмый иде. Тырыша торгач, математика да рәтләнде, ә менә диктантка Гали ага Халит тартып-сузып булса да «өчле» куеп килә, димәк, стипендия алырга хакым бар.

Шул елны Кукмара, Саба ягы авылларыннан килгән студентлар, укуны ташлап, вагон-вагон төялеп өйләренә кайтып киттеләр. Минем ише стипендия алучылар да укыган өчен түләргә кирәк булмаган студентлар гына торып калды. Шулар янына тагын Арчага якын авыллардан килеп укучылар. Арчаның үз балалары калды. Сирәкләнде укучылар, училище бинасының күкрәп-гөрләп торган чаклары юкка чыкты. Спорт уеннары бөтенләй кимеде. Мин сентябрьдә килгән чакта биредә футболдыр, волейболдыр уйнаучылардан ишегаллары гөрләп тора торган иде.

Шул елны бик күп балаларны, ФЗӨ мәктәпләренә җыеп алып, шахталарга озаттылар. Ихтимал, укытучы булырга тиешле кешеләр, шуның өчен генә яратылган булачак педагоглар шахта забойларында күмер чапканнардыр.

Җан биргәнгә ходай җүн бирә, дигән бик мәгънәле халык мәкале бар. Бер ел буена тырышып-тырмашып дигәндәй, җан-фәрманга чәрәшеп, беренче курсны тәмамладык.

Җәйге каникулларга таралуыбыз булды, сугыш башланды. Авыл урамнары сугышка китүчеләрнең җырлары, озатып калучыларның күз яшьләре белән тулды.

Сугышны тиз бетәр дип юрадылар. Ләкин аның очы-кырые күренми иде әле. Күрше Каенлык авылында бик данлыклы ике егет бар иде. Берсе — Нәкыйпь, үзенә утыз сумга үсмерләр гармуны сатып алып, бер ай эчендә шул гармунда өздереп уйнарга өйрәнгән иде. Икенчесе — аның туганнан туганы Шәйдулла, җырлап та карый иде соң ул! Таңнар калырдай моңлы җырларны үзәкләрне өзеп җырлаганын әйткән дә юк инде. Нәкыйпьнең гармунын булып та уйный иде ул, тавышы белән гармун тавышын чыгара ала иде:

Кәр-кир, кәр-кир кәллалла,
Кәр-кир, кәр-кир кәллалла...

Шәйдулла гармун булып уйный башладымы — Нәкыйпь чыккан икән, дип егетләр урамга агыла торган иде.

Менә шул дөнья бәһасе ике егет сугышның беренче көннәреннән үк фронтка киттеләр дә хәбәрсез югалдылар. Нәкыйпьнең абыйсы Шәйхи бар иде, скрипкәче иде, үзе ясаган скрипкәдә кешеләрне жылатырлык көйләр уйный иде. Ул да сугышка китте һәм тиздән аның үле хәбәре килде. Әниләре дөм сукыр карчык кияүсез кызы Рәбига апа белән торып калды. Ә Рәбига апаның ире сугыш алдыннан Арча стансасына ашлык илткән җирдән поездга тапталып үлгән иде. Бер Каенлыктан, тугыз йортлы бәләкәй авылдан, сугышның беренче елында ук фронтка киткән алты-җиде әзмәвердәй егетләр яу кырында ятып калдылар. Өчиле тегермәнчесе Константин Павлов, чеп-чиста татарча сөйләшә, татар егетләре белән урам әйләнеп татар җырларын җырлап йөри торган, авыл мәҗлесләренең даны булган, алтын куллы Күчте абзый да, тагын башкалар да сугышта һәлак булдылар.

Әйе, сугышның очы-кырые күренми иде әле, сугыш бер-бер артлы Өчиленең һәм Каенлыкның егетләрен йотып кына тора иде.

Авылда карт-коры, карчык-корчык, бала-чага җыелып калды. Җәйге каникул вакытында безнең кебек үсмерләр колхозның төп көченә әйләнде. Мин кырык бернең җәендә лабогрейка тартучы атларны әйдәдем, атка атланып шыбын белән салам тарттырдым, безнең Өчиледә сугыш алдыннан тегермәнчебез Константин Павлов сугу машиналарын Казан суына көйләгән иде, урылган ашлыкны су көче белән суктыралар, саламын эскертләргә өя баралар, минем әни Бибинур эскерт түбәсендә салам алып, аны тырма белән таратып торучы иде. Бакча сукаларга ат бирмиләр, язын, укудан бушаган базар көннәрендә егерме биш сутый бакчаны без үзебез — Гайшә апа, мин, Сәҗидә көрәк белән казып чыктык, көрәк белән бәрәңгесен утырттык, өчәүләп чүбен утадык, көрәк-китмән белән бәрәңгенең төбенә өеп чыктык. Шуның өстәвенә әле Каенлык белән Өчиленең көтүен бер генә көтүче көтә, ә без, үсмерләр, атна саен диярлек көтү чиратына чыга торган идек. Сугыш безнең балачак уеннарыбызны уйнап бетерергә ирек бирмәде, без ундүрт-унбиш яшеннән җәйге каникул вакытларында колхоз арбасын төпкә җигелеп тарттык.

Заманында әтием Ахунҗанның якын дусты булган Салих абзый, инде илле биш яшьләрендәге кеше, капка төбенә чыгып, үсмерләр белән кичләрен сөйләшеп утырырга ярата иде.

— Менә, балалар, шулай, сугышның азагы күренми бит әле. Фашистларны әнә гәзиттә дуңгыз дип атыйлар. Ә бит, беләсезме, дуңгыз бит ул шундый хәйван, бәрәңге бакчасына килеп кердеме, бөтен бакчаны актарып бетермичә чыкмый ул...— диде.

Салих абзый урман умарталыгыннан кайткан, ул хәзер Каенлык белән Өчиледә бригадир булып эшли, ә бу авыллар «Кызыл Көтек» колхозының өченче бригадасы иде.

Август аенда миңа Арча педучилищесыннан, дирекциядән хат килеп төште: педучилище Арчадан «Үрнәк» совхозына күчә, укырга «Үрнәк»кә барырга тиеш булып чыгам мин.

Сөенергә дә, көенергә дә белмәдем. Бер уйлаганда, моңа, әлбәттә, сөенергә кирәк иде. Арча безгә унике чакрым булса, «Үрнәк» безгә нибарысы алты чакрым гына. Мин аннан Өчилегә көн аралаш кайтып йөри алам, бигрәк тә сентябрь аенда «әбиләр чуагы» дип аталган җылы көннәрдә. Тик Арчадан шундый данлы, Татарстандагы өч училищеның берсен райүзәктән гади бер авылга күчерү миңа аңлашылып бетми, бу, мөгаен, сугыш белән бәйледер инде...

Ярый, хуш, укый башладык. Педучилище студентдарын, 20—30 үсмерне, шыксыз берничә баракка китереп тутырдылар. Дәресләр бара торган класслар да әллә кем түгел, каралып, күкшәеп беткән агач бүрәнәле бер йорт иде. Әмма бу якларның табигате бик гүзәл, тау астындагы наратлыкта Арча районының участок шифаханәсе урнашкан. «Үрнәк» совхозы үзе әле Ленин исән чакта ук үрнәк хуҗалык булып оешкан, дип сөйлиләр иде.

Казан елгасы монда тар бер инеш булып кына ага, аның башланган урыны бер-ике чакрым гына ары иде. Студентларның байтагын совхозга терәлеп үк торган Тылангыр авылына урнаштырдылар — фатирларга. Укытучыларыбыз Рәмзия апа, Гали Халит, педагогия укытучысы керәшен Николай Иванович «Үрнәк» совхозы белән янәшәдәге зур карурмандагы йортларга — лесхоз поселогына фатирга куелдылар.

«Үрнәк»тәге тораклар да, укыту бинасы да миңа ошамады. Сентябрь ае буена мин үзебезнең Өчилегә кайтып йөрдем.

Шулай бер кайтуымда адәм баласының кайчан да булса бер башыннан уза, күңелләрен кузгата, азактан гомер буе оныта алмый торган нәрсәгә тап булдым. Күршебез Шәйхи абыйларның өендә аулак өй икән, үсмерләр шунда җыелганнар: Казан каласыннан кунак кызы кайткан, ә йорт хуҗасы Камилә җиңги Казанга кунакка китеп барган иде. Чәй эзләргәдер инде, чәйсез ул бер генә минут та тора алмый иде.

Кунак кызы Рәйсә җаннарны айкап алырлык чибәр иде. Аны күргәч, минем бөтен җаным тетрәде. Кич буе мин аңардан күземне ала алмадым. Аулак өйдә була торганниндидер уеннар уйнадылар, шаян сүз әйтеп көлештеләр, мин аларның берсенә дә игътибар итмәдем. Гел Рәйсәгә генә карап утырдым. Ул үзе дә кыйгач кара кашлары астыннан, керфекләрен сирпеп миңа карап ала һәм шундук аның ак чиста битенә, шәфәкъ нурыдай, алсулык кабына, андый чакта ул мин әкиятләрдән укып белгән хур кызларыннан да гүзәлрәк булып күренә иде. Шәйхи абзыйларның Шамилдән соңгы ун яшьлек малайлары Дәүли чамадан тыш кыю, усал малай иде. Менә хәзер мин аны үз ягыма аударырга тиешмен. «Тиешмен» дип шуңа әйтәм, мин бүген Рәйсә белән булырга ният кылдым, шул ниятем тәндә калтырау-каушау тудыра иде, мин ул ниятемнең барып чыгарына ышанып бетми идем. Төнге сәгать уннар тирәсендә Дәүли аулак өйгә җыелган үсмер малайларны һәм кызларны куып чыгарды. Мин дә чыктым, тик азакзы булып. Караңгы чоланда, ишектән чыгып китәр алдыннан Дәүлигә әйттем:

— Менә сиңа өч тәңкә акча, бизәкле букча алырсың, мин бүген сездә куныйм әле,— дидем.

— Хәзер чык, килерсең, тәрәзә чиертерсең, ачармын,— диде миңа Дәүли. Безнең як авылларында кунак кыз янында куну дигән йола бар иде. Куну — йоклау дигән сүз түгел, янәшәдә йокысыз, сөйләшеп яту иде. Әгәр берәр әрсез егет кунак кызны борчырга теләсә, аның даны иртәгә үк бөтен авылга тарала һәм ул бозык егетне кызлар егет чутыннан алып ташлыйлар, аның белән берәү дә дуслашмый, ул инде беткән башка санала иде.

Дәүли мине ишек ачып кертте.

Мин, йөрәгем дөп-дөп типкән хәлдә, кунак кызы янына барып яттым. Минем сүз әйтерлек хәлем юк иде әле, кызның тетрәнгән тәнен һәм кайнарлыгын гына тойдым. Ул бераздан миңа таба борылып ятты, шыпырт тавыш белән: «Синме?» — диде. «Мин»,— дидем. Ул минем кулымны эзләп тапты һәм караңгыда минем кулны җылы кулында кысып, исәнләшкән сыман, селкеп куйды.

Өй бик тын иде, караңгы иде, мич артында мунча сиерчыгы сайрый иде. Без, бер-беребезнең йөрәк тибешләрен тыңлап, сүзсез ята идек.

Тәрәзә кактылар. Рәйсә белән мин урыныбызга сеңдек.

Дәүли урыныннан торды, каты итеп:

— Кем йөри анда? — дип кычкырды.

— Мин бу, Дәүли, ишекне ач әле.

— Нәрсә кирәк? — диде Дәүли усал итеп.

— Дәүли, дим, ач инде, буш итмәм,— диде тәрәзә артындагы тавыш.

— Кем син? — диде Дәүли.

— Сөнгать мин, Сөнгать.

— Йөрмә, ачмыйм,— диде Дәүли.

Шуннан соң беркавым тын торгач, ишек дөбердәткән тавыш ишетелде. Дәүли мич буеннан юынтык сулы чиләкне капшанып тапты, шуны күтәреп чоланга чыкты, тышкы ишекнең келәсе чылтырап ачылганы ишетелде, аннары кемдер ачы тавыш белән: «Ах!» — дип кычкырып җибәрде.

Үз дигәнен итми туктамый торган Дәүли Сөнгатькә юынтык суны чиләге белән сибеп җибәрде бугай. Ишек артында катлы-катлы итеп сүгенгәннәре ишетелде.

— Шул кирәк сезгә, йөрмәссез йокы бүлдереп,— дип сөйләнде Дәүли.

Аннары дөнья тынды.

Бүтән тәрәзә чиертүче дә, ишек кагучы да булмады.

Без кулларыбызны-кулга тотынып, бер-беребезнең шашып типкән йөрәк тавышларын тыңлап, тын гына яттык.

Тагын бераздан өйдәгеләр барысы да йоклый иде инде. Тик без генә йокламый идек. Бездән йокы качкан, безнең җаннарны ут биләп алган иде...

Тәрәзәдә таң яктысы беленә башлагач, мин тордым, чоланга чыктым, Рәйсә дә чоланга чыкты, калтыранып торган җылы тәне белән миңа килеп сарылды:

— Мин сине сагынырмын,— диде.

— Мин дә,— дип пышылдадым.

Иртән иртүк мин «Үрнәк»кә китеп бардым. Әмма укуым уку булмады. Укытучыларның сөйләгән сүзләре колакка кермәде. Мин гел Рәйсәне генә уйлап утырдым. Аның кыйгач кара кашлары, озын кара керфекләрен күтәреп караган чакта алсуланып киткән ак чиста бите, уймак чаклы гына алсу иреннәре, кара чәченең колак янындагы бөдрәләре, ике озын толымы — күңелемнән һич китми, йөрәкне нәрсәдер кысып, авырттырып тора иде.

Дәресләр беткәнне дә көтмичә, соңгы музыка дәресеннән мин өйгә — Өчилегә элдерттем. Үзебезгә дә кереп тормастан, Шәйхи абыйларга киттем. Аларның ишеге бикле, ишек тоткасына уклау тыгып куйганнар иде.

Үзебезгә кайттым. Әни ишегалдына таратып салган бәрәңгенең эресен — эрегә, вагын — вакка аерып утыра иде. Кояш баемаган иде әле, ишегалдында чуар тавыклар кыт-кыт килеп йөри, әни өзеп ташлаган бәрәңге сабакларын томшыклары белән эләктереп, лапас астына йөгерәләр иде.

Әни мине аптырап та, сөенеп тә каршылады. Аның чырае гел балкып, күзләре нурланып күренә, ул нигәдер мин моңарчы күрмәгәнчә матур, ягымлы, гүзәл иде. Бәрәңге таратырга дип җәйгән капчыклар өстендә утырып, аяклары оеган бугай, ул авыраеп кына урыннан күтәрелде дә:

— Әй, улым, кайтып бик әйбәт иттең әле, апаң Гайшә белән сеңлең Сажидә басуда, миңа Салих абый кәнүшни лапасына бәрәңге чүпләргә төшәргә кушканые, әллә син генә төшәсеңме шунда?— диде, аннары ашыгып: — Әй, аллам, ни сөйлим соң әле мин, син бит әле тамагыңа да ашамагансыңдыр?— дип, миңа ашарга бирергә өтәләнә башлады.

— Юк, әни, борчылма, ашадым мин... педучилищеда...— дип ялганладым. Ашамаган идем, бер тамчы да ашыйсым килми иде.— Киттем мин алайса кәнүшни лапасына.

Безнең Кечкенә Өчиледә, Каенлык белән бергә, егермедән артык ат бар иде, мөгаен, алар арасында Кызыл Армиягә яраклы атлар да булгандыр, сугыш башлану белән аларын җыеп алдылар, шулай да атлар байтак калды әле, авыл егетләре, үсмерләр дип әйтергә дә телим, өстән коеп яуган яңгырда да, кышкы суыкларда да әнә шул атлар белән түләү бәрәңгесе, түләү ашлыгын Арча стансасына ташыйлар, стансада көннәр буе чират торып, төнлә генә өйгә кайтып керәләр, иртәгесен алар тагын, Көтекнеке белән кушкач, егермешәр олау булып, юл чыгып китәләр иде.

Өчиледә, минем әти рәис чагында ук, ике рәт итеп ат абзарлары, лапаслар салганнар, ат абзарларында атлар тора, егерме-утыз метрлар озынлыгындагы бик дәү лапаста арба-чаналарны, ат дирбияләрен саклыйлар иде.

Менә хәзер шул дәү лапаска, арбалар арасына ике-өч метр калынлыгында итеп колхоз басуыннан бәрәңге кайтарып аударганнар, Өчиле һәм Каенлыкның җиңгәләр, тол хатыннары, үсмер кызлар һәм малайлары шул бәрәңгене чүпләп, түләүгә кирәклесен аралыйлар икән.

Лапаска килеп керү белән мин монда чуар киемле кешеләрнең бәрәңге өеме өстенә чүмәшеп, гел кыймылдап торуларын күрдем: өстенә юл кожаны, аягына керза итек, башына ямышаеп беткән иске эшләпә кигән Салих абзый алар белән командалык итә, ул әле лапасның бер башына, әле икенче башына килеп, гел йөреп тора иде.

Баштарак мин, йөрәгем дөп-дөп типкән хәлдә, Рәйсәне эзләсәм дә, тиз генә таба алмадым, Салих абый янына килеп, үземнең әни урынына эшләргә килгәнемне әйттем.

— Чүгәлә шунда, башкалар ни эшләсә, шуны эшлә,— диде Салих абзый, аның чырае борчулы, мыеклары тырпайган иде.

Чүгәләдем, башкалар ни эшләсә шуны эшли башладым: үзем белән алып төшкән чиләгемә бәрәңгенең эрерәген тутырам да арбага илтеп салам. Арба кырыйларына ярты метр биеклегендә итеп тактадан яшьнек ясалган, задание бәрәңгесен, димәк, шул яшьнекләргә тутырып ташыйлар, капчыклар ашлык тутыру өчен кирәктер, күрәсең.

Дүрт чиләк бәрәңгене арба яшьнегенә илтеп салгач, минем аркага шап итеп зур бер бәрәңге килеп төште, мин, үзем дә сизмәстән: ай! — дип кычкырып җибәрдем.

Бәрәңге чүпләүче хатыннар кычкырып көлеп җибәрделәр.

Мин башымны күтәрдем. Йөзенә бәхет иңгән Рәйсә, зәңгәр башлыктан, телогрейкадан, биленә япкан нindидер иске алъяпкычтан, Шәйхи абзый малайлары һәм аларның кызлары Мәрьям арасында утыра, миңа карап, рәхәтләнеп елмая иде.

Нишләгәнемне белештермичә, мин дә аңа бәрәңге алып ыргыттым, ләкин тидерә алмадым.

Өчиле-Каенлык хатыннары лапасны яңгыратып тагын бер мәртәбә көлештеләр. Шунда мин җанымда кабынган беренче сөю-ярату хисләре белән бергә, авыл хатыннарының безнең тойгыларыбызны аңлауларын, аны хуплауларын, безгә бәхет теләүләрен төшенеп алдым. Сугыш чорында, ут эчендә ирләре һәлак булып ятып калган чакта, үсмерләрдә кабынган беренче яшьлек кайнарлыгы, саф тойгылар авыл хатыннары өчен, кайберләре сөекле ирләре белән берәр ай гына торып калган яшь киленнәр өчен аеруча кадерле булгандыр дип беләм. Мин ул көнне башымны күтәрми, туры карарга кыймыйча, кич буе эшләдем, булдыклылыгымны күрсәтер өчен, Рәйсә алдында ялкау булып калмас өчен, бәрәңге таулары белән арба арасында гел йөгереп йөрдем, минем чиләгем, гүя, үзеннән-үзе тула, үзеннән-үзе яшьнекле арба янына йөгереп баруымны таләп итә иде. Ә чиләк илтә барган чакта мин Рәйсә эшләгән якка ихтыярсыз күз салам, аның да, минем кебек, баш күтәрми бәрәңге чүпләвен күрә идем...

Иртәгесен иртүк тагын «Үрнәк»кә китәргә, тагын мең газап белән дәрестә утырырга тиеш идем. Мин бит, Рәйсәне үлепләр дә күрәсем килә дип, Шәйхи абзыйларга кабат барып керә алмый идем. Әгәр аулак өй булса, минем дустым Дәүли шул аулак өйгә баш булса, ихтимал, барып та кергән булыр идем, Дәүлине бәхилләтеп, Рәйсә бәгырькәем белән янә бер мәртәбә көзге озын төн буена сөйләшеп чыгар идем, ут кебек кайнар кулы белән ул минем кулны тотар иде, ихтимал, мин аңа дөньяларымның яктырганын, аңардан башка тора алмавымны да әйткән булыр идем, тик Шәйхи абзыйларда аулак өй беткән. Камилә җиңги Казаннан кайтып төшкән, Рәйсә инде алардан китеп барырга тиеш иде.

Шулай да ул көнне дә мин дәресләрне бик начар тыңладым. Соңгы дәрестән чыгып ычкынмакчы, Рәйсәне Казанга киткәнче соңгы мәртәбә күреп калмакчы булып ашкынган идем, тик мин дигәнчә барып чыкмады, соңгы практика дәресендә безне совхоз бәрәңгесен чүпләргә дип барлык студентны да кырга кудылар, кем дә кем койрык тайдыра, аның практика дәресенә «икеле» куелачагын әйтеп, бик хәтәр янадылар.

Йөрәктән кан тамган хәлдә, мин, башка студентлар белән бергә, лесхоз буендагы басудан «Үрнәк» совхозының бәрәңгесен чүпләп йөрдем. Икенче көнне студентларның ялы иде, әмма безне кичтән үк кисәтеп куеп, тагын кырга — бәрәңге чүпләргә алып чыктылар. Өченче көнне мин, айга-вайга карамыйча, авылга элдерттем, тик мин кайтканда, Рәйсәдән җилләр искән иде инде.

Аны мин ул елны бүтән күрә алмадым.

Ул арада минем эшләр педучилищеда да кәегеп китте. Хикмәт шундадыр ки, училищеның уку бинасы кышын бик суык булды, без өскә бишмәтләрне, башка бүрекне, кулларга бияләйне киеп утыра торган идек. Ә бит ярты чакрым гына ары өскә аварга торган чыршы урманы бар иде. Заманында ул Габдрахман Ишморатов дигән алпавытныкы булган. Себер якларында алтын приискалары, Казанда һәм Санкт-Петербургта мануфактура фабрикалары булган әлеге алпавыт хәзерге «Үрнәк» совхозы урнашкан урында ат заводы тоткан. Әнием Бибинур исләре китеп сөйли торган иде: «Ишморат байның атлары Өчиле урамыннан ярты сәгать буе узып торалары, аның такта яру заводы кычкырткан чакта без урак өстендә төшке ашка кайта торганыек, ул алпавыт бик тә юмарт булган, тапкан малын үзенә генә тотмаган, җәйләрен үз урманындагы йортларына ял итәргә кайткан чакта үзе янындагы авылларның ярлы-ябагаена зәкят өләшкән» — ди иде.

Әйе, алпавыт булган, аның урманында да, ат заводында да, башка урыннарында да тәртип сакланган, ә менә безнең уку йортыбызны җылытырлык утын да әзерли алмыйлар хәзер. Без, торактагы малайлар, кичләрен урманнан ботак-сатак ташып, бүлмәбезне җылытабыз, өйдән алып килгән бәрәңге-мазарны да пешереп ашыйбыз, иртән тагын, күнелдән генә сукрана-сукрана, китап букчаларыбызны күтәреп, боз кебек салкын бинага җыелабыз.

«Күңелдән сукрана-сукрана» дип әйттем дә әйтүен, кайберәүләр күңелдән сукранып калмаганнар, педучилищедагы тәртипсезлекләр турында Мәгариф халык комиссариятына Казанга да язып җибәргән булып чыктылар.

Көннәрдән бер көнне педучилищега комиссия килеп төште. Барыбызны диярлек берәм-берәм чакырып сөйләштеләр. Кече яшьтән үк безнең өйдә гаделлекне сөйләргә өйрәтә иде әниебез, ялганны ул күрә алмый иде, шуңа күрә мин, бер дә яшермичә, чын дөресен әйтеп бирдем. Башкалар да әйткәннәрдер дип уйлыйм, озак та тормый, кайсыдыр бер гәзиттә Арча педагогия училищесындагы тәртипләрне Мәгариф халык комиссариятының рәсми комиссиясе тикшерүе, тәртипсезлекләргә юл куйганы һәм студентларны суык баракларда яшәтүе, салкын биналарда уку-укыту эшенең алып барылуы, шул сәбәпле салкын тиеп авыручы студентларның һәм педколлективның көннән-көн артуына юл куйганы өчен училище директорына каты шелтә бирелүе бәян ителгән иде.

Мин ул чакта педучилище күләмендә чыга торган стена гәзитенең редакторы идем. Анда безнең «Чаян» почмагы бар иде, шул көлке почмагына без, гәзитне чыгаручылар, шаян бер мәзәк бастырып чыгардык.

«— Әй, үскәнем, әйт әле, безнең директор нигә бик каты йөгереп йөри башлады икән?

— Йөгереп йөрми хәле юк, аңа бит каты шелтә биреп киттеләр».

Бу гади генә ике җөмлә шул ук көнне бөтен училищега таралды, студентларның да, педагогларның да телендә гел шул иде. Иртәгесен дәрескә килгәндә инде стена гәзите алынган, ул урын бөтенләй буш калган иде. Алмаган булсалар, бер атна эчендә, хәтта бер-ике көннән ул вакыйга, бәлки, онытылган да булыр иде, әнә шул алып ташлаулары эшне бозып куйды. Җепшек карны тәгәрәтеп бик зур шар ясаган кебек, вакыйга зурайды, инде аны сөйләмәгән бер генә кеше дә юк иде. Моңардан нәтиҗә чыгаручылар да табылды:

— Ахунов башсыз икән. Нигә шуны стенгәзиткә язып торырга иде инде? Менә директор аңа күрмәгәнен күрсәтер әле...

«Күрмәгәнне күрсәтү» көне әлләни озак көттермәде. Башта укытучылар миңа кырын карый башладылар, сәламемә җүнле сәлам бирмәделәр, аннары минем исем-фамилиям турысына «өчле»ләр тезелеп китте.

Моңарчы гел «бишле»гә укыган студентка бу инде гарьлек иде, гаделсезлек иде. Педучилище укытучыларыннан мине яклаучы, ихтимал, Гали Халит белән Сәләй Вәгыйз генә булгандыр. Алар икесе дә әдәбиятчы, берсе тәнкыйтьче, берсе шагыйрь иде. Ул арада Сәләй Вәгыйз фронтка китеп барды, Гали Халитны Казанга эшкә алдылар, минем белән тел укытучыбыз Рәмзия апа гына торып калды. Телгә мин чатырдап ябышып ятканлыктан, өстәвенә барлык кагыйдәләрне төн уртасында уятып сорасалар да гел яттан белгәнлектән, ул миңа берничек тә «өчле» куя алмый, аннары без бит икәүдән-икәү генә түгел, мин аның сорауларына дәрестә җавап бирәм, моны башка студентлар ишетеп тора, ә башка дәресләрдән, әйтик, тарихтан, географиядән, яки математикадан мине теләсә кайчан, теләсә нинди четерекле сорау белән тота алалар, чөнки укытучы хәтле белә алмый бит инде укучы, әгәр укытучы этлек эшләргә, сине батырырга теләсә, батыра ала...

Җан борчуы белән мин гамьсез яши алмый идем. Кече яшьтән шулай. Гайшә апалар җиләкләрен ашап бетереп төшкәндә, мин савыт тулы җиләгемне исән-сау килеш әнигә алып кайтып тапшырдым. Бакча казыган чакта да, бакча чүбен утаганда да, бәрәңге төбенә өйгәндә дә, мин егерме биш сутыйлык бакчаны өчебезгә бүлеп куям, үземнең өлешне беренче булып эшләп бетерәм, минем өчен һәркайда тәртип булырга тиеш иде. Әйткән, вәгъдә куйган эшемне вакытында башкарып чыкмасам, яки үземә карата башкаларның гаделсезлеген сизсәм, мин инде йоклый алмыйм, бу хәл мине кара кайгыга сала иде. Шунлыктан, укучы дусларыбыз аңлыйлар булыр, «өчле»ләр мине упкын кырыена китереп куйды, упкынга очмас өчен мин ниндидер көтелмәгән бер борылыш ясарга тиеш идем.

Апрель урталарында, кискен бер карарга килеп, мин укуны ташлап кайтып киттем. Башта моны әни сизмәде. Атна буе укуга бармагач, ул аптырый төшеп, миннән сорады:

— Улым Гарифҗан, әллә сезнең каникулыгызмы?

— Юк, әни, каникул түгел,— дидем.

— Ник соң, алайса, син укырга бармыйсың?

Әнинең күзләренә туп-туры карап:

— Мин укуны ташладым, әни,— дидем.

Башта аның шомырт кара күзләренә хәвеф, курку, аптырау билгеләре чыкты, аннары күзе мөлдерәмә яшь белән тулды, аннары ул хәлсезләнеп сәке йөзлегенә утырды да кычкырып җылап җибәрде. «Бар икән күрәселәрем, йарабби, мин бит син булса да укысын дип җир тырмашам, әллә миңа үпкәләп ташладыңмы укуыңны?» Мин аңа бер сүз белән дә җавап кайтармадым, тавышсыз-өнсез сәке йөзлегендә тып-тын утырдым. Минем аны юатасым килә, җилкәләреннән сыпырасым килә, тик кулым күтәрелми иде.

Монысының да үз сәбәпләре бар иде. Алтымы-җидеме ел тол хатын булып торганнан соң, тормышлар аеруча авырайгач, әни Каенлык авылының иң ярлы кешеләре булган, әмма чисталык-пөхтәлекләре белән дан тоткан Хәйруллаиыкылардан сазаган егет Нурулла абыйны йортка кертте. Авыл советына Казанбашка төшеп язылышып тормадылар алар, Каенлык мулласына никах укыттылар да тормыш арбасын бергә тарта башладылар. Гайшә апа да, сеңлебез Сәҗидә дә әнинең бу эшен хупламадылар. Сәҗидә дәшмәде, кара янып кына йөрде, ә Гайшә апа үзенең протестын бик тә аңлаешлы итеп белдерде: төне буе бүлмә тактасына аягын бәреп чыкты.

Малай кешегә әти кирәк, мин Нурулла абый белән чынлап торып дуслаштым. Ул Казанга инигә барган чакларда мин аны безнең авылдан ярты чакрымнар ары булган Каенлык елгасына тикле йөгереп барып

каршылый идем, ә ул мине, үзен яратканга күрәдер, аркасына капчык аскан булуга карамастан, кулларына күтәреп ала торган иде.

Хәйрулланыкыларның Өчиле-Каенлыкта һәм Көтектә дан итеп сөйләнелә торган ике бик яхшы сыйфатлары бар иде: беренчедән, алар барысы да бик матур тавышлы, көчле һәм моңлы тавышлы иде, халык җыелып капка төпләрендә утырган чакта бер җырлап җибәрсәләр, офыклар киңәеп, дөньялар матурланып киткәндәй була торган иде. Аларның икенче сыйфатлары — өйдә, ягъни Каенлык авылында гына бикләнеп ятарга теләмәүләре иде. Кышны ничек кирәк алай уздырып җибәрәләр дә, язга чыгу белән, Байкал күле буйларына, хәтта Сахалин утравына тикле язылып китеп баралар. Нурулла, Ярулла, Зиннәтулла, Маһибәдәр апа — барысы да язылып китә, бер ел тимер юлында, нәкъ менә тимер юлда, бүтән бер кайда да түгел,— эшләп, бер елдан соң сандык-сандык ситсы төяп, үзләре иң затлы киемнәр киенеп, туган якларына кайтып төшәләр, баеп кайтулары белән тирә-як авылларны шаккатыралар иде. Кунакка барган чакта — биш метр ситсы бирү сугышка кадәрге елларда иң зур бүләк санала иде.

Нурулла абый да безгә кышын йортка кергән иде, язын Чита шәһәренә язылып китте, бер елдан соң мал-мөлкәт төяп, авылга кайтты. Миңа ул бик матур кара костюм, ак күлмәк, ботинка, кепка, майка, күз явынны алырдай кыска җиңле джемпер алып кайткан иде. Минем үз гомеремдә беренче тапкыр шундый да матур киемнәр киюем иде әле, баш пешәрлек эссе җәй көнендә мин аларны киеп, тугыз чакрым ераклыктагы Югары Пошалым авылына Алма апай янына бардым. Аркамнан шыбырдап су акса да, маңгайны әледән-әле яңа пинҗәгемнең җиңе белән сөртеп торсам да түздем, ничек итсәм иттем, яңа киемнәремне Югары Пошалым авылына, андагы малайларга, Алма апайга күрсәтеп кайттым.

Аннары мине Нурулла абый безнең Өчиледән егерме биш чакрым ераклыктагы Кызыл Байрак авылына алып китте. Ул авыл Теләче районында иде, анда, соңгы елларда гына оешкан ул авылда, Каенлыкның кулак дип сөрелгән Хаҗи малайлары, Өчиледән кулак дип сөрелгән Хашим абый малайлары яши иде. Алар бик яхшы йортлар корганнар, ул авыл урманга терәлеп үк тора, Читадан баеп кайткан Нурулла абый аларга бармый булдыра алмый иде, әлбәттә!

Башта без Арчага бардык. Нурулла абый Арча кибетеннән Кызыл Байрактагы туганнарның балаларына дип ун прәннек сатып алды, ул перәннекләрне минем кесәгә тутырды. Арчадан соң Кызыл Байракка тикле уникеме-унөчме чакрым барасы бар иде әле. Мин бара-бара арыдым, өстәвенә бик нык ачыктым, ә кесәдә минем төшемә дә кермәгән перәннекләр ята, кулны кесәгә тыгып карыйм, җаннар әллә нишләп китә. Мин шул перәннекләрнең берсен ипләп кенә алам, юрамалый Нурулла абыйдан арткарак калып, кырыеннан кимереп чыгам — тәмле каһәр! Тагын арткарак калам — икенчесен кырыеннан кимереп, кесәгә кире салам. Шул рәвешле ун перәннекнең унысының да кырыен кимереп чыктым, Нурулла абый сизмәс әле дип уйладым.

Перәннек белән мәш килгән арада юл мәшәкатьләре, ару-ачыгулар да онытылып киткән иде.

Туганнар йортына килеп кергәч, Нурулла абый миннән перәннекләрне сорап алды, аларның кырыйлары һәммәсенең кимерелеп чыкканын күргәч, күзе маңгаена менде.

— Ыңңң! — диде ул авыз эченнән сузып кына, аннары йомарланган йодрыгының урта бармагын өчпочмаклап озайтты да минем башка җиңелчә генә төртеп алды:

— Аның икесен-өчесен ашасаң ни була инде, нигә аның бөтенесен кимереп чыгарга кирәк?!

Прәннекләрне ул күчтәнәч итеп бирергә оялды һәм алар минем кесәдә ятып калдылар.

Прәннек дигән ризыкка мин әле дә битараф карый алмыйм, күргән бер жиремдә аларны сатып алырга тырышам, ихтимал, прәннек яратуым минем әнә шул сабый чак истәлекләре белән бәйледер...

Нурулла абый сугышка кадәр бездә дүрт ел чамасы булды, тик аның ике елдан артыгы читтә — Чита ягында, Байкал күле тирәләрендә узды. Нурулла абыйдан әни ике бала тапты — Рамазан белән Ризуан. Рамазан уникe яшьләрендә суык тиюдән терелә алмыйча вафат булды, Ризуан әнебез үсте, өйләнде, үз йортларын корды. Хәзер дә Арчада яши, хатыны да, балалары да бик булдыклы.

Нурулла абыйлар нәселе турында тагын бер өстәмә мәгълүмат бирмәсәм, язганнарым тулы булмас шикелле тоела. Бу йортта бик сәер кешеләр яши: Ярулла абый да, Нурулла һәм Зиннәтулла абый да, ни хәтле генә читтә йөрмәсеннәр, тәмәке тартырга да, аракы эчәргә дә өйрәнмәгән булып чыктылар. Аның каравы Хәйрулланыкыларның ике кызы — Маһибәдәр апа белән Хәерниса тәмәкене убалар гына иде. Хәер, «уба» дигәнем Хәерниса апага туры килә, ул Каенлык белән Өчиле атларын карый, ярты гомере кәнүшни йортында уза, гәзит кәгазенә тәмәкене бүрәнә чаклы итеп төрә иде. Маһибәдәр апа да тәмәке тарта, тик ул нәзберек, үзе әйтмешли, хуш исле «лүвкәвәй» тәмәке белән генә хозурлана иде. Соңгы елларында ул да Каенлык белән Өчиленең көтүен көтте, ул бик яшьләй иреннән калган, аның ике малае инде үсеп житкәннәр иде, берсе сугыштан кайтмады, икенчесе бөкре иде. Әнә шул бөкре улы Корбый белән ул гомеренең азаккы көннәренә чаклы көтү көтеп, үзен-үзе кайгыртып яшәде.

Алар барысы да чибәрләр, арада Фәрзәнә апа аеруча чибәр иде, ул кияүгә чыкмады, өч мәртәбә зинадан бала табып, шуларны кайгыртып яшәде. Әшкә чамасыз уңган иде, зинадан тапкан балалары да үсеп житеп, затлы кияүләргә тап булдылар, азактан әниләренә бик булыштылар.

Унбиш яшькә житкәнче минем тормыш баскычларым әнә шундый булды, унбиш яшьтән соң бик кинәт үзгәреп китте...

## Яланаяклы бригадир һәм күрәзәче

Мин педучилищены ташлап авылга кайтканда, сугышның инде бер елы тулып килә иде. Авылда тормышлар бик авырайган. Гайшә апаны окоп казырга жибәргәннәр, әниебез Бибинур колхозда төрле эштә йөри, авыргалап та ала, салам эскерте төбәсендә тору, жәйләрен урак уру кебек авыр эшләрнең барысын да ул ых та итмичә эшләп бара иде.

Укуны ташлап торган бер атна эчендә мин әнине утын вату, салам алып кайту кебек өстәмә эшләрдән азат итәргә тырыштым. Сажидә белән икәүләп без кырдагы салам эскертенең карын казып, аркабызга бер чүмәлә хәтле салам күтәреп кайттык, аны сыер абзарына, сыер астына таратып салдык, иртәгесен без аны кабат җыеп алып, көлтә итеп бәйләрбез, шул көлтәләрне ягып, өйне жылытырбыз.

Минем инде атна буе өйдә ятканымны, «Үрнәк»кә укырга бармавымны ишетеп, безгә бригадир Салих абзый керде. Мәзәк сүзләргә оста булса да, ул бик усал, аның хатыны Фатыйматтәйгә кычкырганы бездән өч чакрым ары Казанбашка тикле ишетелә, диләр иде. Каты әрәкле һәм тимер куллы бу кеше елына бер мәртәбә телчән хатыны Фатыйматтәйне кара яндырып кыйный, ә тегесе аңа үч итеп, тагын бер елга тикле аңа ачу китерә алырлык сүзләр жыйный иде. Салих абзый белән Фатыйматтәй — минем якын дусларым Шәкүр, Мансур, Гарифларның әти-әниләре иде.

Салих абый кергәндә, мин чабата үреп утыра идем, ул миңа кырыс кына карап алды да, исәнләшеп-нитеп тә тормастан:

— Гарифҗан, син ялга кайттыңмы, әллә укудан качып дуракка вәлэйт итеп ятасыңмы? — диде.

— Дуракка вәләйт итеп ятам,— дидем.

— Ул эш хәзергесе көндә, немеч фашистлары илнең җелеген суырган настаяшный вакытта, ярап бетмәс. Син миңа, Ахун малае, дөресен әйт: укуыңны ташлаган булсаң, калхуз эшенә чыгарга туры килер!

— Нинди эшкә?

— Шәйхи малае Шамил, минем малайлар Мансур, Гариф сукага чыгарсыз. Бүген мин сезне кәнүшни өенә чакырам, штубыты хәзер үк тамагыгызга капкалап алыгыз да шунда төшегез.

— Ә анда нишләргә?

— Һәркайсыгызга атлар беркетербез, икешәр ат, ике төрәнле сука белән җир сукаларсыз. Ел коры килә, яз иртә, ат ызбруйларын тикшерерсез, камыт баулары өзелсә, шорниктан тектербез, йөгәннәрегезне, дилбегәне барларсыз, бәлки тимерчелектә сука калакларын да кайратып алырга туры килер.

Менә шулай итеп, мин авыл кешеләре башкара торган төп эш-гамәлемә килеп тоташтым.

Урамнардан язгы сулар ага иде инде. Салих абзыйлар белән ике арадагы бушлыкка Мансур ермак ерып куйган, Шәкүр инде әллә кайлардагы фронтта сугыша, аның апасы Зәйнәп «Кызыл Көтек» колхозының амбарчысы булып урнашкан иде.

Мин, язгы сукага чыкканчы, әнигә бик нык булышырга тиеш идем. Ул миңа хәзер тегенди-мондый юк-бар эш кушмый, минем укуны ташлап кайтуыма риза булмыйча, караңгырак чырай белән, дәшәр-дәшмәс йөри, мин аның күңелен күтәрергә, укуны ташлавым аңа булышыр өчен кирәк икәнен аңлатырга тиеш идем.

Авылда безнең йорт иң биеге һәм иң төзеге иде. Әтинең туганнары Хашим абый белән Әсәт абый, бүленеп чыккан чакта, энеләре Ахунҗанга койрыксыз сыер белән сукыр ат калдырганнар — әниебез боларны, мин Казанбаш мәктәбендә укып йөргән чакта, төннәр буе сөйли торган иде. Тик аларга Галимҗан бай йортыннан берни дә бирмәгәннәр, кара-каршы ике йорт, келәт, ике амбар, мунча, алты торыклы лапас, сыер һәм ат асрар өчен бурабзарлар, сарыклар араны шул килеш торып калган. Күмәк хуҗалыкка берләшәсе елларны әти каралты-кураны кечерәйткән, югары бакча яныннан түбәнгәрәк төшергән, шулай да әле безнең йорт мин үскәндә дә авылда иң биек йорт иде. Шулай булгач, табигый, кар көртләре безнең йорт янына бик күп өелә, ишегалды да кар белән тула, мин хәзер, бер көн дә соңармыйча, шул карны ишегалдыннан базга салырга, калганын урамга чыгарып ыргытырга, абзарларга, өй асларына су кермәсен өчен, каралты-кура тирәсенә канаулар казып чыгарга тиеш идем. Көннең көн буе баш күтәрми эшләдем, урман-кырлардан зур су килеп төшкәнче йорт-җиребезне хәвеф-хәтәр булмаслык итеп әзерләп куйдым.

Әниебез моңа бик риза булды, аның кычкырып сөенә торган гадәте юк иде, көндез ул мин эшләп бетерешкә дип кыстыбый пешереп куйган, чырае да болытлы көн төсле караңгы түгел, шулай булгач, канәгатьтер дигән фикергә килдем.

Апрельнең егермеләрендә елгалар шаулап тынды, Өчиле һәм Төрнәле болыннарына җәелгән су Казан елгасына кайтып төште, кар инде чокыр-чакырларда, кояш күзенә эләкмәгән урыннарда гына сакланып калган иде.

Тагын бер атнадан без сукага, җир сөрергә чыктык. Алты пар ат. Мансур, Гариф, Шәйхи абзый малае Шамил, Каенлыкның Әфләтун малае Рәхимҗан, Өчиленең Сибгать абый малае Сөнгать һәм мин. Бригадир Салих абзый безнең белән кырга чыкты, сукаларыбызны көйләде, атларны чыбыркыламаска киңәш итте, чөнки алар болай да бик бетәшкән, берәр сәгать сукалаганнан соң, атларны тугарып, ызанда чирәм утлатып алырсыз, борын төртеп кенә чыккан булсалар да, атларга ул чирәм бик тансык, диде.

Безгә әле атларга ашатырга дип берәр кило солы да биргәннәр иде. Шул солыны да ашатып, чирәмнәрдә дә йөртеп, ничек кирәк алай, без суканы сукалап, тырманы тырмалап бетердек. Минем белән Шамилне Салих абзый чәчкечкә күчерде, Шамил ат тота, ә мин сошникларның дөрес эшлиме, бөртекне тигез төшерәме икәнен барлап-тикшереп йөрергә тиеш идем. Бу шактый ук авыр эш, сукалаган, тырмалаган җир өстеннән барган чакта чабата эченә туфрак тула, әнә шул туфрак аякның хәлен ала иде.

Ашау ягын бригадир Салих абзый көйләде. Язгы чәчүдә эшләгәннәргә — сукачыларга, чәчүчеләргә, амбардан ашлык ташучыларга ул көн саен берәр кило пешкән ипи һәм кайнар аш бирүне сугышып алды. Аш пешерүне минем әнигә йөкләделәр. Без, иртән басуга чыгар алдыннан, дүртәр-бишәр тәлинкә умачлы, сөтле ашны аударып куябыз да, ходайга шөкерана кылып, басу юлына кузгалабыз. Баштарак атларга атланып, тезелешеп чыга идек, әмма атлар ябык булганга, аларның сырты пычак сырты кебек чыгып калган, бер-ике көн атлануга ук безнең арт шәрифләр суелып чыкты һәм без инде атларны йөгән тезгененнән тотып кына, җәяүләп кенә теркелди башладык.

Май азакларында без чәчкән уҗымнар ямь-яшел булып тишелде, шифалы җылы яңгырлар явып узды, кояш нурына сөенгән тургайлар баш өстендә сайрап тордылар.

Мин, авыл малае, ялан кырда эшләвемә, педучилище педагогларының гаделсезлеген күрмәвемә бик шат идем, гомеремне сука сукалап, чәчү чәчеп, болын тугайларында печән чабып уздырырга да риза идем. Ләкин дөнья син дигәнчә генә бармый икән шул.

1942 елның июнь аенда Салих абзый бригадирлыктан баш тартты.

— Минем эш — умарта карау. Олыгайган көнемдә кешеләргә гозерләнеп, кеше көтүчесе булып йөрү миңа бер дә килешми. Рөхсәт итегез миңа урманыма кайтырга, бал кортлары белән сөйләшеп гомеремне уздырырга,— диде ул колхоз рәисе Гомәр абыйга.

Боларны мин колхоз кәнсәләрендә ишеттем. Шул көнне мине дә кәнсәләргә чакырганнар иде. Баштарак, Салих абзый сөйләгән чакта, мин аның гозере дөрес дип уйлап утырдым, ул чакта миңа 55 яшендәге кеше бик карт булып күренә иде инде. Салих абзыйның чал төшә башлаган куе кара сакалы да аны миңа карт итеп күрсәтә иде. Мин аларны уйлаганда, җил-давылның үземә борыласын белми идем.

Гомәр абый Ганиев, идарә әгъзаларын кул күтәртеп, Салих Ибәтуллинны үз үтенече белән бригадирлык вазифасыннан азат итәргә кушты.

Азат иттеләр.

Гомәр абый да шактый олы яшьтәге кеше иде инде, тәмәкене бик күп тарта, авызыннан чыгарган төтенне борынына кабул итеп, берничә мәртәбә әйләндерә ала иде. Мин аның әлеге гамәленә исем китеп, фокусник бу, дип уйлый идем. Менә хәзер дә ул авызыннан чыккан төтенне борыны аша берничә мәртәбә әйләндергәч, кулындагы карандашы белән өстәлгә каты итеп төртте:

— Тә-әәк, Салих абый Ибәтуллинны бригадирлыктан азат кылдык. Инде бригадирга кеше сайларга кирәк — Өчиле белән Каенлыкка, ягъни өченче бригадага. Кемдә нинди тәкъдимнәр бар? Дәшмисезме? Беренче бригада бригадиры Гөлсәхра, синдә нинди уй бар? Тә-әәк, дәшмисең? Икенче бригада бригадиры? Син дә дәшмисең? Минемчә, өченче бригадага бригадирны йә Каенлыктан, йә Өчиледән куярга кирәк.

Тәмәке төтене белән тулган кәнсәләрдә утыручылар барысы берьюлы минем якка башларын бордылар, мин ишек буендагы ук эскәмиядә гамьсез генә утыра идем.

— Башны дөрес якка бордыгыз,— дип, Гомәр абый, колхоз председателе, тәмәке төтенен авыздан борынга тутырып, ике-өч мәртәбә әйләндереп алды.— Мин уйлыйм, Ахунов Гарифҗан — бу эшкә иң кулай кеше.

Әтисе Ахун абый — Өчиле белән Каенлыкта колхоз оештырган, шул юлда кулаклар тарафыннан үтерелгән кеше. Кем дә кем Ахунов Гарифҗан «Кызыл Көтек» колхозының өченче бригадасында кырчылык бригадасы бригадиры булсын ди — шулар рәхим итеп кулларын күтәрсеннәр... Рәхмәт, бертавыштан. Гарифҗан энем, сине бригадир булуың белән котлыйм, хәзер нәрәт бирү башлана, идарә әгъзаларына кайтып китәргә мөмкин, ә син, Гарифҗан, иртәгәсе көн өчен нәрәт алырга каласың.

— Туктагыз әле, ничек була инде бу? Миннән сорау юк, киңәштабыш юк, бәлки, минем бригадир булып бөтенләй дә эшлисем килми торгандыр,— дип, мин урынымнан сикереп тордым.— Нигә минем ризалыкны сорамадыгыз?

— Энем Гарифҗан, хәзер мирный заманнар түгел, сугыш вакыты, әгәренки бик беләсең килсә! Синең пачти тугыз сыйныф белемең бар, сүзне җиренә җиткереп сөйли беләсең, эшкә дә җәптәш син, әниең дә әйбәт кеше, карышып торудан мәгънә юк,— дип кырт кисте колхоз рәисе.

— Юк,— дидем мин.— Сез, Гомәр абый, уйламыйчарак хәл итәсез, мине бит тагын ике елдан армиягә алачаклар...

Сүзне кискен итеп әйттем, болар шуннан соң, минем уемча, аптырашта калырга тиешләр иде.

— У-һу-уу! — диде Гомәр абый, сүнгән тәмәкесен кабызып.— Ике елда кем бар, кем юк әле. Сугыш вакытында, немеч фашистлары өскә килгәндә, алай сөйләшмиләр, энем. Мин инде иллене узган кеше, әгәр дә иптәш Сталин фронтка бар, Ганиев, кулыңа корал ал, дип әйтә икән, ике дә уйлап тормыйча...

— Егетләр, эшне озакка сузмыйк әле, сайладык бит инде Ахуновны,— дип, күршебез Салих абзый мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Шуннан соң минем идарә карарына буйсынмый хәлем калмады.

Иртәгәсен иртүк караңгылы-яктылыда Өчиле белән Каенлыкның сирәгәеп калган йортларын, алай да унике-унбиш йортны йөреп, нәрәт буенча кая эшкә барырга икәнен әйтеп чыккач, өйгә кайтып уйга калдым. Күп булса, тагын ике атнадан печәнгә төшәчәкләр. Чалгылар бармы? Тырмалар? Печән чабар өчен кулына чалгы тотардайлар — үсмерләр белән картлар гына түгел, хатын-кызлар да, печән кабартырга чыгардай бала-чага да...

Мин шунда сугышка кадәрге елларны исемә төшердем. Печәнгә төшәр алдыннан авылларда тәкә симертеп суялар, мич башларына мичкә белән бал куя торганнар иде. Болынга шлеяле-чуклы атлар җигелгән җиңел сиртмәләргә төялеп, гармуннар белән җырлап бара торганнар иде. Колхоз печән өстендә үгез симертеп суя, печәнчеләргә болын тугаенда зур кара казанда аш пешерәләр иде. Күкрәп тора торган иде авыл. Ә иң бәхетле баланы ат белән шыбын тарттырырга куялар иде. Минем дә бер мәртәбә шыбын тарттырырга чыкканым булды. Ул болындагы уен-көлкене, яшь киленнәрнең, кияүгә барасы кызларның киенүләрен күрсәң, исләрең китәр, тугызлы итеп үргән сап-сары чабатадан, сарык йонынннан бәйләгән ап-ак оекбаштан, чигүле алъяпкыч, чытыр ак яулыклардан, бизәкле тырмалардан һәм арыслandай егетләрнең яңгыратып чалгы янауларыннан Казан суы буйлары гү килә иде, моны эш итеп карамыйлар, моны бәйрәм итеп саныйлар иде. Кемнең булдыклы, кемнең булдыксыз булуы әнә шунда күренә дә инде. Өчиле тегермәненең ике ягында җәелеп яткан, печәне билгә җиткән ике болынны ике көн эчендә ялмап чыгып, әллә ничә кибән өеп куялар иде.

Мин боларның барысын карт-коры, бала-чага, солдат хатыннары белән ничек башкарып чыгармын? Менә сиңа авыртмаган башка тимер тарак! Нигә кайттым соң әле мин педучилищены калдырып? «Өчле» куйсалар куйсыннар иде, тырышлыгым аркасында мин ул фәннәрне барыбер «бишле» билгесенә күтәрер идем әле.

«Күз куркак, кул батыр»,— ди халык. Печәнгә төшәр алдыннан хәсрәт эчендә янсам да, печәнне яңгырсыз торган дүрт көн эчендә ерып чыктык.

Дөрес, сугышка кадәрге төсле печән өстенә дип колхозда үгез суелмады, Казан елгасы тугаенда, таллар арасында кара казанны быгырдатып аш та пешмәде. Аның каравы, печән эшендә катнашучыларга көн саен икешәр кило ипи, шул чор өчен дип бераәр кило шикәр бүлеп бирделәр.

Оныта язганмын, Өчиле белән Каенлыкка, Көтеккә һәм тирә-яктагы башка авылларга Мәскәүдән, Ленинградтан, Украинадан эвакуацияләнгән кешеләр кайткан иде. Безнең авылга чит-ят кеше кайтмады. Сибгат абзыйның армиягә яраксыз улы Сәет белән укымышлы хатыны кайттылар, гомер буе читтә йөргән Шәйхи Апушы тал чыбыгы төсле нәзек хатыны белән кайтып төште, кыргый үскән бер шомырт төбенә бәләкәй генә, әмма курчак өе төсле матур йорт салып керде, аларга аның хатыны Мәрзия апаның кайчандыр алу-сату эшендә йөргән апасы кайтты, ул апасының исемен инде оныткынмын, әмма безнең өченче бригадага гаять дәрәҗәдә кирәкле кеше булып чыкты ул. Бик тиз арада ул ат җигәргә, ирләр кия торган киемне кияргә, чыбыркы тотып, сызгыра-сызгыра ат куаларга өйрәнде. Аңардан, аның усал теленнән үсмер егетләр дә куркып тора торганнар иде.

Башта әнә шул усал шәһәр хатыны ат җигеп, су ындырына басудан көлтә ташыды, көзен түләү ашлыгы илтүчеләрнең бригадиры булды, председатель Гомәр абый да, бригадир мин дә аны бик үз иттек, аңа гел якты күз белән карап, эшләгән эшләрен дә, үзен дә гел мактап кына тора торган идек. Апушның хатыны Мәрзия апа колхоз эшенә чыкмый, апасына һәм ире Апушка аларның эштән кайтышларына аш пешереп, өен гөл кебек итеп тота иде. Эшче кулларга никадәрле кытлык чакта да, без Мәрзия апага, ник эшкә чыкмыйсың, дип бәйләнмәдек. Чөнки аның каладан кайткан апасы олаучыларның башлыгы булса, Апуш суга көйләгән сугу машинасында кыш буе ашлык суктыра иде.

Сибгать абыйның олы улы Сәет мәсьәләсенә килгәндә, ул мине бик тә аптыраштa калдыра, ука-чуктан киенгән укымышлы хатыны белән ул кәнүшни өендә тора, атлар карый (Хәерниса апа ул эштән туеп, кәнүшнидән киткән иде инде), аларның өенә килеп керсәң, анда һәрчак тәртипсезлек була, урын-җир җыелмаган, чүп чиләкләре түгелмәгән, самавырлары бер илле каткан, чәй чокырлары, чынаяклары танымаслык булып каралган иде.

Миндә шагыйрьлек, нәзберекләлек ул чакта ук булган, күрәсең, кәнүшни өенә керүдән мин бик чирканам, әмма керми дә булдыра алмыйм, чөнки атлы эштә йөрүчеләр әнә шул кәнүшни өендә тулып яталар, аларны тиргәп йә юмалап чыгарып җибәрергә кирәк була иде.

Мин Көтеккә нәрәт алырга кичке сәгать сигезләрдә төшә идем. Ул елны бураннар бик көчле булды. Авыр үрәчәле чана белән юл салулары-на төшә-төшә Көтеккә берничә мәртәбә барырга кирәк булгач, мин үземә бер остадан чыпталы чана ясатып алдым, өч яшьлек кырыкмышны үземә ияләндердем, шунлыктан Көтеккә мин күз ачып йомганчы барып җитә идем. Гомәр абыйның да тәрәкле чанасы, урысчалап әйтсәк, кошовкасы бар иде, тик ул зур иде, авыр иде, ул җигеп йөри торган ат та авыррак сөякле иде. Мин үзем ярата торган ат-кырыкмыш белән, җилләр уйнатып, ат тоякларыннан һавага кар аттырып китеп барган чакта Гомәр абый миннән көнләшеп карап кала торган иде. Йолдыз кашка кырыкмышны мин бик тәрбияләп, бер дә күздән ычкындырмый саклыйм, аны беркемгә дә бирми идем.

Минем карамакта җилләр уйнатып йөри торган кырыкмыш булу ул әле һәммә нәрсә дә ал да гөл икән дигән сүз түгел. Язга таба эшләр бик хөртиләнеп китте: атларның печәне апрель башында бетте, саламны да эскертләрдән Өчиле-Каенлык халкы җилкәсенә күтәреп, мал-туарына һәм мичкә ягарга ташып бетерә язган, салам булса да, башак болгатырга оны юк иде. Олырак яшьтәге атлар берәм-берәм күтәрәмгә калды, утызар ел яшәгән атлар үлде, без аларны кәнүшни артындагы үләксә

чокырына илтеп күмдек, аларга бүреләр ияләнде, март аенда төннәрен урамга чыксаң, үләксә чокыры ягыннан бүреләр улаганы ишетелә иде.

Бер бүренең хәтта Мансур белән без, төн уртасында Шәйхи абзыйлардан чыгып, капка төбендә сөйләшеп торган чакта, абзарлар артында чабулап йөргәнен күрдек. Салих абзыйларның мылтыгы бар иде, Мансур мылтыкка йөгерде, ул арада инде бүре абзар артыннан китеп, Салих абзыйлар белән безнең арадагы бушлыктан менеп бара иде, тик аңа атлавы авыр, ул яңа гына бурап-бурап яуган карга бата, чабып китә алмый иде. Мансур, ау мылтыгын иңенә терәп атып җибәрде, бүре чүгеп куйды, без инде: «Булды бу! Нәкъ савырына эләкте!» — дип кычкырып сөенергә дә өлгермәдек, бүре тирән карны ашыга-ашыга ерып, урман ягына китеп югалды.

Кайдадыр еракта туплар гөрселди, без авылда ач утырабыз. Ипи юк, хезмәт көненә бирелгән өч йөз грамм ашлык җәй көне үк инде ашалып беткән, сарык ите салымга түләнгән, сыер әле бозауламаган — без, балалар, кырдан коелып калган борчакны җыйган идек, шуннан атнага бер мәртәбә әни борчак эштие пешерә, калган көннәрдә — бәрәңге, бик тә саклап, кадерләп кенә тоткан оннан арыш умачы...

Ашка туң май кыздырып салынган көн безнең өчен бәйрәм була. Гайшә апа окоп казудан кайтты. Без хәзер ишле: әни, Гайшә апа, мин, Саҗидә, Нурулла абый балалары Рамазан белән Ризуан — төп-төгәл алты кашык.

Нурулла абый сугыш башланган елны Читада иде, шуннан бирле аның хәбәре юк, сугышка китеп, гүр иясе булганмы — берни белмибез. Аның абыйсы Ярулла сугыштан кулы яраланып кайтты, тик эшкә ярамый әле. Энесе Зиннәтулланың үлгән хәбәре килде.

Кәнсәләрдә нәрәт алган чакта Өчиле белән Каенлыктан Илләт ягына урман кисәргә ике кеше табарга кушты миңа Гомәр абый. Ике авылны бер итеп йөреп чыктым — берәүнең дә кышкы суыкларда урман кисәргә барасы килми. Шул хакта Гайшә апага әйткән идем, ул әнә җылап утыра, әни, аны яклап, минем белән тиргәшә:

— Син нәрсә, Гарифҗан, акылыңнан яздыңмы әллә, апаң бит әле генә окоп казудан кайтты, чыкмаганнар чыксыннар — Кайнык Әскадуллаларда Гөлчирә бар, Өчиле Шәйхинекеләрдә — Мәрьям. Нәрсә син гел шул бер апаңа каныгасың...

Кешеләрне эшкә чыгару авырлашты. «Үзең чык!» — дип кенә җибәрәләр, «тишекле сутыйга» берәүнең дә эшлисе килми, сугыш заманы икәнен исләренә төшерергә туры килә, закон белән куркытырга.

Язга таба атларның күбесе күтәрәмгә калды. Үсмерләрне чакырып, атларны корсак асларыннан бау тарттырып күтәрергә туры килә. «Бар икән күрәселәр, юк икән үләселәр»,— дип уйлыйм, укуны ташлап кайтканыма тора-тора үкенәм.

Әҗәткә он сорап язган гаризаларны Гомәр абыйга — колхоз рәисенә китереп торам. Бер пот, ярты пот ашлык сорыйлар, умач уарга да бер кашык та оныбыз калмады, диләр.

Гомәр абый кашларын җыера, ике куллап башына тотына:

— Каян алыйм? Юк бит, юк, көзен бит бар булганын себереп алып, фронтка дип җибәрделәр. Упалнамученный үзе карап торып амбардан алып китте бит. Әле бит ашлык симәнәгә дә җитми, Арча элеваторыннан бәләкәй чаналар белән симәнә ташырга туры киләчәк.

Атлар күтәрәмгә калгач, колхозчыларның сыерын көчләп җиктерә башладылар. Алар өчен, мөгезле тискәреләр өчен, махсус камытлар ясарга туры килде, аларны тәртә арасына кертә алмыйча җаннар чыкты.

Адәм балалары бер җирдә дә бер төсле булмаганнар. Берәүләре үткен, берәүләре җебегән. Безнең күршебез Салих абзыйлар ипигә дә, итле ашка да аптырап тормыйлар, ат бирмиләр икән колхоздан, утынны үгез белән ташыйлар; сыерларны колхоз эшенә җиктерәсен әллә алдан ук белгәннәр инде, үгез бозауларын ике елда үстереп җиткереп, шуның

белән урман ташый башладылар. Сыерларын колхоз эшенә бирмәделәр, үгезләрен бирделәр. Үзләренең бәйдә торган тана чаклы этләре бар иде, үгезне колхоз алгач, тагын каяндыр бер эт ияртеп кайттылар да, шул ике этне ат чанасының яртысы чаклы чанага җигеп (ул чананы Салих абзый үз кулы белән ясады), урманнан янә дә этләр белән утын ташырга керештеләр. Эвакуация белән кайтканнар, ачтан үлмәс өчен, затлы киемнәрен саталар, дөресрәге, ипигә, онга алыштыралар иде, ул затлы киемнәр озак та тормый Салих абзый кызы Зәйнәп өстендә булып чыкты.

Педучилищеда укыган чакта мин гаделлек таба алмагач, үз авылыбызга кайткан идем, инде ул гаделлекнең авылда да булмавын күреп, киредән училищега китәргә булдым. Гаделсезлек дигән коточкыч чир миңа Салих абзыйлар тормышында аеруча зур булып күренде. Салих абзыйның бригадирлыктан китеп, урманга кайтырга теләве юкка гына булмаган икән, тиздән ул үзләренең бакчасына биш-алты умарта куйды, ул умарталар бер елдан сигез башка, аннары ун башка кадәрле үскән. Белмим, алар күпме бал биргәннәрдер, әмма Салих абзый белән Фатыйматтәйләрнең балы әллә кемнәрнең дә авызын капларлык күп иде. Алардан гомер буе бал өзелмәде, килгән-киткән түгел, район башлыклары да, милиционерлар да, урман каравылчыларының атлары да алар капка төбенә еш килеп туктый иде. Бу түрәләр, түрә кисәкләре Салих абзыйлардан бик озак утыргач кына чыгалар, капка төбендә бик хәтәр җанланып сөйләшәләр иде.

Бригадир чакта мин тәмәке тартырга өйрәндем. Салих абзыйлар зур бер түтәл итеп тәмәке дә үстерәләр, ул тәмәкедән миңа да өлеш чыгаралар иде (ни генә дисәң дә, бригадир бит, бер ялынычың төшмәсә, бер төшүе бар).

Тиздән Шәкүр армиягә алынды, Фатыйматтәй бер чиләк бал күтәреп, хәрби комиссар янына да барып караган, диделәр, тик ул юлы файдасы тимәгән, ахрысы, безнең район үзәге сугыш вакытында Арчадан Яңа Чүрилегә күчкән, ул Гөберчәктән алты чакрымнар ары, Шәмәрдән ягындарак иде, Салих абзыйларның, күрәсең, яңа районда әле танышлары булып җитмәгән.

Шәкүр шулай итеп фронтка китеп барды.

Күтәрәмгә калган атлар, хуҗалыкларны мәҗбүр итеп кырга чыгарган сыерлар белән язгы чәчүне тәмамлап чыккач, мин «Үрнәк»кә кабат барып карарга булдым. Вакыт уздырырга ярамый, минем моңарчы укыганнарым коелып бетәчәк, шуңа тикле аякны киенеп өлгерергә кирәк иде.

Тик минем педучилищега барыр көнем кителмәгәндә тагын өч көнгә сузылды. Барлык нәрәт кенәгәләренә өченче бригада колхозчыларының һәм эвакуация белән кайткан авылдашларыбызның хезмәт көннәрен язып чыгарга дип тәрәзә буена утырган идем, әниләр басу чүбенә киткәннәр иде, көн бик җылы, кояшлы иде, капка түбәсенә чыпчыклар кунып чыркылдый иде,— тәрәзәне ачып җибәрдем дә, күлмәк якаларын чишеп, колхозчыларның кенәгәләрен тәрәзә төбенә тезеп куеп, язу эшенә чумдым.

Исемем белән дәшкән тавышка сискәнеп, башны күтәрсәм, минем ачык тәрәзәм каршында түбәтәйле, сакал-мыеклы бер карт басып тора. Аның сәламен алдым, исәнләштем:

— Сез кем буласыз?— дип сорадым.

Ул миңа исемен әйтергә ашыкмады, өйгә керергә рөхсәт сорады. Түбәтәйле кеше өйгә керде, минем белән ике куллап күреште, морҗа буенда торган сандык өстенә утырып, дога кылды, тик шуннан соң гына кем икәнен әйтеп бирде:

— Мин үзем Гөберчәкнеке. Анда күрәзәче бар икән дип ишетмәгән идеңме, Гарифҗан?

— Ишеткән идем. Көтек хатыннары өчәү сезгә сугыштагы ирләренең хәлен белергә дип барганнар, имеш. Сез аларның икесен баккансыз, өченчесен бакмагансыз, имеш. Шул хәл булдымы?

— Булды. Ник бакмаганымны беләсезме соң?

— Имеш, сез әйткәнсез: «Син, кодача, юлда килгәндә күнеленнән уйлап килдең, өч сум бирсәм аз була, биш сум бирсәм, күп була, дип.

— Шуннан соң ул жылап җибәрдеме?

— Нәкъ шулай. Ә син каян беләсең?

— Шуннан соң сез аны бактыгызмы?

— Әйе, бактым, сиңа ул каян билгеле?

— Ә миңа Көтек хатыннары сөйләде.

— Болар барысы дөрес. Сине дә багыйммы? Әниең бит синең безнең Гөберчәкнеке, Ногман абзыйларның туганы.

— Ногман абзыйның бертуган сеңлесе,— дидем мин.

— Ногман абзый булыщамы соң сезгә?

— Булыша. Итекләрне бушлай басып бирә. Әтисез балаларны кызгана.

— Син бит әтисез түгел.

— Кем соң минем әтием?

— Синең әтиең Кайныкныкы.

— Аның бит сугыш башланганнан бирле хәбәре юк.

— Хәбәре юк, әмма ул исән. Сине дә багыйммы?

Мин икеләндем. Мин комсомолга язылган идем. Казанбаш мәктәбенең җиденче сыйныфында укыганда ук әле.

— Абзый, без чәй эчеп алыйк әле,— дидем мин.

Чәй эчәргә минем бер сынык ипием бар иде, мин шуны урталай бүлеп куйдым. Абзый үзенең юл капчыгыннан бер бөтен ипи, ике шакмак шикәр чыгарды, без икәү озаклап чәй эчтек. Чәй эчеп бетергәч, ул тагын миннән сорады:

— Йә, энем Гарифҗан, багыйммы инде сине?

Ни булса да булыр, минем янда кеше-кара юк бит әле, аның мине бакканын берәү дә күрми дип, мин риза булдым.

Аның мине сискәндереп әйткән беренче сүзе:

— Энем, син язучы буласың,— дигән сүз иде.

Беренче мәлгә сискәнеп китсәм дә, тиз айныдым. Ул бит минем язу язганымны күреп калды. Туктале, белешик, «язучы» дигән сүзгә ул нинди мәгънә сала икән?

— Китаплар язучы,— диде ул ике генә сүз белән.

Бу мине кызыксындырып җибәрде.

— Алга таба,— дидем мин дулкынланып,— алга таба мин нишлим?

— Син бик югары дәрәҗәләргә ирешәсең. Тик аңарчы сине әле казна йорты көтә. Синең үз авылыгыз Өчиледә ике-өч дошманың бар. Алар сине шөпшә кебек чагарлар. Сиңа көн күрсәтмәскә тырышырлар...

— Шуннан, шуннан?— дидем мин сабырсызланып.

— Шуннан шул: син казна йортыннан чыккач, котылгач дип сөйләшик инде, син бер кара кызга өйләнерсең, сезнең ике балагыз булыр, сез гомер буе бәхетле яшәрсез...

Күрәзәче картның сүзләре мине бөтенләй чыгырымнан чыгарып ташлады. Колхозчыларның хезмәт көнәгәләренә эшләгән эшләрен язып, ике көн, ике төн булаштым мин. Бу миңа эшләп бетермәгәнне бетерү өчен кирәк иде.

Күрәзәче картның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Әмма аның беренчесе минем каршыма бер атнадан соң ук килеп басты.

Укуымны алга таба дәвам иттерү теләге белән мин «Үрнәк» совхозына — педучилищега бардым. Ниятем — гафу үтенеп, үз белдегем белән киткәнемә үкенеп училищега кабат кайтаруларын сорау иде. Директор өйдә юк икән, буш кул белән кайтырга туры килде.

Өйгә кайтып керсәм, әни җылап утыра. Аны көч-хәл белән тынычландырып, ни булганын сорадым.

— Шәйхи Гаптерие белән Сибәгать Сөнгатен милитсе Төрнәлегә алып менеп япкан,— диде ул, бите буйлап аккан күз яшьләрен кулы белән яңагына сылап.

— Ни өчен япканнар соң?

— Чүк Төрнәлесендә бер кешеләрнең сарыгы югалган. Милитсе шуны эзләп безнең авылга килгән. Күршеләр әйткән булырга тиеш. Шәйхи Гаптерие белән Сибәгать Сөнгатенең эшедер, дигәннәр, милитсе сине дә эзләткән.

Шунда минем күңелдән казна йорты дигән сүз — Гөберчәк күрәзәчесе әйткән сүз яшен кебек ялтырап узды.

— Минем бит бер гаебем дә юк, әни,— дидем мин аны юату өчен.

— Мин синең чиста бала икәнеңне беләм, ләкин бит ул кайгы агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри. Син бит Гаптериләр, Сөнгатьләр белән йөрдең, аларга урманнан утын алып кайтырга ат бирә торганыең, алар үзләре генә буялып калмас өчен сине дә кыстырсалар...

Мин Гаптеринең дә, Сөнгатьнең дә сарык урлаган булуларына ышанмый идем, әмма минем күңелемә шөр төште, алар фронтка китми калган ике чирле, үз өянәкле кешеләр быел язын бәрәңге утырткан чакта бер капчык бәрәңге урлап тотылганнар иде. Ә аларга урманга барырга дип мин ат биргән идем. Председатель, колхозда эшче куллар кирәк, дип ул эшне зурга җибәрмәде, менә хәзер шуны казып чыгарсалар? Ат биргән өчен мине дә гаепле итсәләр?

Әнигә шик төшермәс өчен мин өйдә йокысыз ята алмый идем, Көтеккә кичке уеннарга йөрергә дип алган кара постау чалбарымны, ак күлмәгемне, яңа ботинкамны, кепкамны кидем дә, әнигә кая барганымны әйтеп, үз юлыма юнәлдем.

Күңел һаман тынычсыз, йөрәк чәнчеп тора иде.

Кибеттә мичкә белән кайтартылган аракы-сырец саталар иде. Минем белән дус кеше, миннән унбиш-егерме яшькә олырак булса да, мине ихтирам итә торган шаукымлы Һидият абый туры килде. Аның белән бергә аракы алып, аларга кайттык. Ул еш кына хатыны белән дәгъвалаша, ә хатыны, дәгъвалашкан саен, бирнәгә дип алып килгән ястыгын күтәреп, әниләре йортына кайтып китә торган иде. Моны бөтен Көтек белә. Бу юлы да Һидият абыйның хатыны киткән вакыт булып чыкты. Һидият абыйның да борчуы бар, минем дә, моңарчы, бригадир булып эшли башлагач, бер дә авызга капмаган нәрсә түгел аракы, Һидият абый белән әкрен генә сыйланып сөйләшеп утырдык. Мин озак утыру бәрабәренә ярты стакан чамасы аракы эчкәнмендер, Һидият абый стакан белән генә туктамады бугай, аның башына китте, һәм ул миңа бик тә якын итеп, Өчиленең Ахун малае итеп, күңелендә утырган төенне чиште:

— Син, энем, нык бул. Анда сине дә чакыртулары мөмкин. Сибәгать абый малае Сөнгать белән Шәйхи абзый Гаптериеннән сарык таптыралар, милитсе аларны кыйный икән,— диде.

Халык арасында йөргән бик тә гыйбрәтле бер сүз бар: белмәгән дә күрмәгән — мең бәладән котылган. Мин күңелемә беркетеп куйдым: әгәр милиционер мине чакыртса, бер сүз дә әйтмәскә. Шул уй белән, өсне дә чишенмичә, йоклап киткәнмен.

Иртәгесен мине Һидият абый уятты.

— Энем, сине эзләтеп, колхоз персидәтеле Гомәр абыйга язу җибәргәннәр, торырга туры килер. Бик рәхәт йоклыйдырыең да, нишләтим соң, уятырга куштылар.

Һидият абый миңа чәй эчертте, тастымалга төреп, ни өчендер ярты бөтен ипи алды. Аннары без капка төбенә чыктык, анда йөгән сабагыннан капка боҗрасына бәйләп куйган җигүле ат тора иде.

— Утыр, энем. Сине миңа Төрнәлегә апменергә куштылар. Нишлим соң, ләчәнстуа әйткәнне үтәми булмый...— диде ул уфтанып.

Мин эшләрнең хәрти икәнен аңлап алдым. Милиция кулына эләктеңме, тиз генә котылырмын, димә.

Юл буе мин дәшмәдем, Һидият абый да дәшмәде.

«Колхоз идарәсе» дип язылган зур гына бер йорт янына килеп туктадык.

— Энем, син утырып тор, мин белешеп чыгыйм әле,— дип, Һидият абый арбадан төшә башлаган иде, кәнсәләр ишегеннән милиция киеме кигән, билен калын сары каеш белән буган усал чырайлы берәү чыгып:

— Китердегезме? Яхшы. Сез азат. Хәзер ул безнең кулда,— дип, Һидият абыйга честь бирде. Һидият абый ашыгып кына миңа үзе белән алып чыккан ярты бөтен ипине тастымалы-ние белән тоттырмакчы иде, милиционер кырыс тавыш белән, команда биргән кебек итеп әйтеп салды:

— Не положено!

Һидият абый уңайсызланып, үз алдына бөрешеп, миңа күз сирпеде — аның кыяфәте, нишлим соң, дигәнне аңлата иде. Милиционер мине алдан уздырып, икенче катка менгәч, калын бер ишеккә күрсәтте.

Гадәти бер кәнсәләр бүлмәсе икәнен абайлап алдым. Кичтән генә председатель нәрәт биреп утырган булса кирәк, тәрәзә форточкасы ачык булса да, тәмәке исе бетмәгән иде әле анда. Милиционер фуражкасын салып, өстәл өстенә куйды. Баягы кырыс чыраена ягымлылык өстәп:

— Без, Ахунов, монда барысын да белдек. Сибгатуллин Сөнгать тә, Шәйхетдинов Габдрахман да Кечкенә Төрнәледән ничек итеп сарык урлап суйганнарын таныдылар. Анда син дә булгансың. Син, гомумән, үзеңнән өлкән әшнәләрең белән бергәләп, ел буе караклык белән шөгыльләнгәнсең. Әгәр син шуларны ихлас күңелдән, ачыктан-ачык әйтеп бирсәң, җәзаң җиңеләя. Йә, сөйлә,— диде.

— Мин бернәрсә дә белмим, минем бер нәрсә дә урлаганым юк.

— Юк, дисең, алайса,— диде милиционер, кобурына кагылып, ул миңа үзендә корал барлыгын ымлады.— Юк, дисең, димәк. Бәрәңге дә урлаганың юкмы?

Мине иң куркытканы шул иде. Сөнгать белән Гаптеринең бәрәңге урлаганын берәү дә моңарчы белми иде бит әле. Моңа кем әйтте икән моны? Председательме, әллә үзләреме?

Мин дәшмәдем.

Милиционер урыныннан торды, кәгазь тартмадан бармак озынлыгы папирос алып, аны кабызды, тирән итеп эчкә суыргач, өстәл тирәли әрле-бирле йөреп килде.

— Ник дәшмисең, гражданин Ахунов?

— Нигә дәшәргә тиеш мин? Минем гаебем юк.

— Син бит комсомолец, колхозда бригадир булып эшләгәнсең, педучилищеда укыгансың, гаебеңне танырга да теләмисең, ә?

Мин аның сүзләрен ишетмәдем. Хыялымда инде дүртенче сыйныфта чакта ук, җәйләрен, алдынгы пионер булып, кырларда дозор торганымны искә төшердем. Колхоз председателе Гомәр абыйның олы малае Госман белән без Көтек клубында стена газитләре чыгарып йөргән идек. Төсле буяулар белән ясап, кешеләрнең — ялкауларның, колхоз кырыннан ашлык урлаган каракларның карикатуралары төшерелгән газитне мин, «Пүләп» исемле бәләкәй атка атланып, басулар буйлап укып йөри торган идем. Казаннан килгән газитләрне дә укый идем. Минем телем телгә йокмый иде ул чакта. «Кызыл Көтек» колхозында газитне кызу, бик кызу укый алучы, сүзләрне бер дә йотмыйча тыңлаучыларга җиткерүче бер генә кеше бар, ул да булса, минем белән беренче сыйныфтан башлап укыган Шәйдулланың абыйсы бар иде. Аны 1937 елны алып китеп яптылар да шуннан ул күренмәде. Мин һәрвакыт аның уку осталыгына сокланып карый идем. Озакламый үзем дә шулай тиз һәм аңлаешлы итеп укырга өйрәндем. Әллә газитне, китапларны кызу укый торган кешеләрне төрмәгә ябарга дигән закон бар микән?

Милиционер мине хыял дөньясыннан чынбарлыкка кайтарды. Өстәл яныннан торырга кушып җикерде:

— Стенага карап бас! Мин әйтмичә кузгаласы булма. Бәлки, гаебеңне шунда уйлап бетерерсең! — Ишекне дөбердәтеп ябып чыгып китте, ишек артында йозак шалтыраганы ишетелде. Димәк, мине бикләп чыгып киттеләр.

Стенага карап тиктомалдан бер хәрәкәтсез сәгать буе басып торгангадыр, аягымның хәле китте, мин идәнгә сыгылып төштем. Торырлык хәлем юк иде — ач та идем бит әле мин. Сәгать инде күптән төшлектән авышкан иде.

Шалтырап йозак ачылды, шыгырдап — ишек.

Милиционерның беренче сүзе шул булды:

— Стенага!

Мин тормакчы булып карадым, тора алмый идем, идәнгә кабат көлтә кебек аудым. Милиционер мине култыклап торгызды, өстәл янына китереп утыртты, йөзенә тагын ягымлылык, миңа яхшылык теләү битлеге киеп алды.

— Син, гражданин Ахунов, сарык урламадым, дисең инде, ә? Ә бит шайкагыздан Шәйхетдинов Габдрахман белән Сибәгатуллин Сөнгать ул эшне эшләгәннәрен таныйлар.

— Анысы — алар эше. Эшләмәгән эшләрен дә үз өсләренә алалар икән, җәзасын үзләре күрерләр. Мин — кулаклар тарафыннан үтерелгән коммунист Ахунҗан малае, өстәвенә, комсомолец, җиденче сыйныфны Мактау кәгазе белән тәмамладым, мин өстемә ялган бәла ала алмыйм.

— Син, Ахунов, ялган бәла ала алмыйм, дип әйтәсең дә әйтүен, әтине кулаклар үтерде, дисең дә...

— Әйе, кулаклар яллаган бандит үтерде, нәкъ менә шушы Төрнәле авылында. Аны ун елга төрмәгә яптылар. Әтине бандит кулына китереп тапшырган ике кулакны җидешәр елга яптылар...

— Алай икән, алай...— диде милиционер. — Ә менә мин, участок уполномоченные Бикташев, кулымда башка документ иметь итәм. Менә шушыны укып кара әле, караклыкта гаепләнүче Ахунов! — Ул минем алга «Кызыл Көтек» колхозының мөһерен баскан кәгазь китереп салды. Кәгазьгә күз төшереп алу белән мин ярсынып киттем. Бөтен тәнемне ут чолгап алды. Анда акка кара белән: «Гаепләнүче Гариф Ахунҗан улы Ахуновның нәселләрендә явызлык тулып ята. Ул нәсел — кеше үтерүчеләр»,— дип язылган. Характеристикага Казанбаш авыл Советы рәисе кул куймаган, аңа минем белән колхозда җәфа чиккән кеше — Гомәр Ганиев кул куйган иде. Мин тетрәнеп киттем, сикереп урынымнан тордым һәм ачыргаланып:

— Ялган! Чеп-чи ялган! Ничек оят түгел ул Гомәр абыйга? Мине көчли-көчли бригадир итте, анысы гына җитмәгән, инде безнең нәселгә яла яга! — дип кычкырып җибәрдем. — Киресенчә бит, кеше үтерүче — безнең нәсел түгел, безнең нәселнең кешесен үтерделәр.

Минем алга китереп салган кәгазьнең нинди давыл тудырасын участок начальнигы Бикташев белгән, күрәсең, минем холкымны да, ялганны күтәрә алмаганымны да кешеләрдән сорашкан, инде менә шантажга бара: янәсе, әгәр син гаебеңне танымасаң, без сиңа зуррак гаепләр дә тага алабыз!

Мин моңарчы гел дә аңгыра булганмын икән. Мәктәптә укытучылар сөйләгәнгә ышанып яшәгәнмен. Безнең ил — дөньяда иң бәхетле ил, безнең суд — иң гадел суд, бездә гаепсезгә бер генә кешене дә утыртмыйлар.

Бикташев тыныч кына урыныннан торды. Гомәр Ганиев кул куйган кәгазьне урталай бөкләп, портфеленә салды, чамадан тыш гамьсез тавыш белән әйтте:

— Йә, гражданин Ахунов, педучилищеда «отлично» билгеләренә укыган Ахунов, мин синең күзгә карап алдашкан сүзләреңә ышаныйммы, акка кара белән язылган, колхоз пичәте сугылган характеристикага ышаныйммы?

Мин тагын бер мәртәбә хәлсез тавыш белән:

— Болар барысы ялган! Чеп-чи ялган! — дидем.

Бикташев миңа бүтән сүз әйтмәде, ишеккә таба юнәлде, тик ишекне ачар алдыннан, тоткага тотынгач кына:

— Уйла, Ахунов, ныгытып уйла, ихлас күңелдән гаебеңне тану хөкем карарын җиңеләйтер,— диде һәм, ишекне япкач, йозак бикләнгән тавыш ишетелде.

Мин ул чакта әле, беркатлылыгым аркасында, дөньяның мәкерле икәнен, милициянең чинында күтәрелү өчен кешеләрне мөмкин кадәр күбрәк тотарга, гаебе булса да, булмаса да, танырга мәҗбүр иткәннәрен белми идем. Минем өстемә өелгән чүпләрнең сәгать саен, минут саен арта барганын, бу тозактан котылып чыгып булмаячагын аңлап елап җибәрдем.

Кечкә кадәр бүлмәгә керүче дә, бикләнгән ишеккә кагылучы да булмады. Мин колхоз кәнсәләренең бер почмагына барып чүмәштем дә педучилищеда укып йөргән чакларымны, яланаяклы бригадир чорымны күңел күзеннән уздыра башладым. Бервакыт шулай җир үлчәп йөргәндә колхоз председателе Гомәр абый минем янга бик пөхтә киенгән, ак күлмәген һәм кара костюмын балкытып, зәңгәрсу төстәге галстук таккан озын буйлы, тук чырайлы бер кешене алып килде.

— Менә, иптәш райком секретаре, «Кызыл Көтек» колхозының өченче бригада бригадиры Ахунов шушы була инде,— диде.— Мин сезгә аның турында сөйләгән идем. Белемле, намуслы, уйлый белә торган егет. Әтисен кулаклар үтерде — колхоз председателе иде. Өчиле белән Каенлыкны «Ленинчы» дигән колхоз итеп яшәтте. Ахунҗан үлгәч, без ул авылларны «Кызыл Көтек» колхозының өченче бригадасы итеп алдык.

«Иптәш райком секретаре» Гомәр абыйның сүзләрен башын кырынрак салып тыңлады, аннары минем буй-сынымны, сентябрь чебиедәй бәләкәй, йолкыш гәүдәмне күздән үткәрде дә, сынаулы, үткен карашы белән аякларыма тукталды:

— Нигә яланаяк? — дип сорады.

— Җир үлчәгәндә, чабата арасына балчык тула, шуңа күрә яланаяк йөрергә туры килә,— дидем мин уңайсызланып.

— Бригадир — җитәкче кеше. Моннан соң яланаяк йөрмә, Ахунов. Юкса кешеләр алдында, гади колхозчылар каршында авторитетың булмас,— диде райком секретаре.

Теге чакта әллә ни игътибар итмәсәм дә, менә хәзер уйлар өчен бик зур мөмкинлек бирелгәч, ерып чыга алмастай уйларыма баттым. Димәк, кешеләр гадиләргә һәм җитәкчеләргә бүленә. Мин, зур булмасам да, җитәкче. Димәк, мин башкалардан аерылып торырга тиеш. Минем бу уйларым үзен зур җитәкче, кешеләрнең язмышын хәл итәрдәй түрә дип санаган участок начальнигы милиционер Бикташевка барып тоташа иде. Аның карашында мин гади, ул түрә, ягъни начальство, ул минем белән, мәче тычкан белән уйнаган төсле, уйный ала. Теләсә коткара, теләсә — ябып куя. Ул кадәресен мин ачык аңладым. Миңа хәзер моннан котылу юк. Монысы көн кебек ачык. Мин инде ул мәсьәләдә язмышыма буйсына яздым, чын дөреслек кайчан да булса ачылыр әле, дип уйладым. Мине алары гаҗәпләндермәде, мин Бикташевның зуррак түрә булырга омтылганын аңлаганнан башлап үземә-үзем хөкем карары чыгардым, үземне өянәкле, үз чирле кешеләр белән бәйләгәнем өчен гаепләдем. Мин аларга ышанып, урманнан утын алып кайталар икән дип, ат бирдем, ә алар бәрәңге урлап йөргәннәр булып чыкты. Инде менә шуның шаукымы миңа да килеп кагылды. Димәк, бу очракта минем дә гаебем бар, димәк, мин дә җәза алырга тиешмен. Бикташев бәрәңге турында сүз кузгатты, ул, димәк, нәрсәнедер белә, вакыты җиткәнче аның серләрен үзендә саклый, мине нәрсә белән булса да каптырырга исәпли. Тик мин әле һаман Гомәр абыйны аңлап җиткерә алмыйм, райком секретаре алдында ул мине «белемле, намуслы, тырыш» дип сөйләде, мин бригадир чакта да

эшемнән канәгать иде, ә үзе, мин бәлагә тарыгач, әнә нинди характеристика язып биргән. Безнең нәсел кеше үтерүче, имеш! Моннан да зуррак ялган, акны кара дип әйтүче икейөзле кеше бармы икән дөньяда?

Ишек артында йозак шалтырады, ишек шыгырдап ачылды, тәрәзәдән бүлмәгә мул булып төшкән кичке шәфәкъ яктысында участок милиционеры Бикташевның төз гәүдәсе пәйда булды. Керә керешли үк ул миңа: «Встать!» — дип акырды.

Мин торып бастым.

— Ахунов,— диде ул, минем иягемне тотып, башымны югары таба күтәрде: — Синең гаепле булуыңның дәлилләре тулысынча ачылды. Без, пүнәтәйләр белән, Югары Пошалымга, әтиең үлгәч син ике ел яшәгән Фаизә карчыкка барып тентү үткәрдек. Сарыкны сез аңар илтмәгәнсез. «Өчиле егетләре сезгә суйган сарык китерделәрме?» — дип сорадык. Карчык бик туры сүзле булып чыкты. «Китерерләр сиңа бар! Әллә кайчан ашап бетергәннәр инде!» — диде. Димәк, Фаизә Гыйбадуллина сезнең өчәүләп сарык урлаганыгызны белә?

— Минә бу — минем өчен яңалык. Урламаган әйберне ничек белә инде ул? — дидем батыраеп. Бикташев хәзер мине ничек кенә мәсхәрәләсә дә, ничек кенә өскә гаеп ягарга теләсә дә, миңа барыбер иде. «Совет суды — гадел суд»,— дигән уй минем күңелгә кереп утырган иде, аны чөй белән дә сугып чыгарырлык түгел иде. Суд булыр, суд минем гаепсез икәнне күрер, мине Бикташев ялаларыннан йолып алыр, дип өметләндем.

Төз гәүдәле көяз милиционер, участок башлыгы, өстәл буенда иягенә таянып сүзсез генә утыргач, аяк өсте басты, мин дә бастым, ул юкка иренен кысып, мине тишәрдәй булып карады да әйтте:

— Сезнең семья жәл миңа, Ахунов. Әниең Бибинур белән Гайшә апаң биш җан өелеп кала. Ихлас күңелдән гаебеңне танысаң, синең җәзаңны җиңеләйтерләр иде, бәлки, әле хезмәт көне белән штраф кына салырлар иде, инде син әйтергә теләмисең икән, үзеңә үпкәлә, сугыш чоры законнары каты, судья сиңа күзен дә йоммыйча, биш елны чәпәячәк. Групповой дип атала ул, групповой караклык. Син юкка киреләнәсең, судта синең балигъ булмавыңа карап тормаслар. Әйт яхшы чакта, урланган сарыкны кая куйдыгыз?

— Минем сарык урлаганым юк, урларга уйлаганым да юк.

— Бүген, сиңа ашарга бирергә дип, Гайшә апаң килде. Чүлмәк белән аш китергән. Синең, димәк, ашыйсың килми?

— Ялган бәла яккан җирдә ашыйсы килми минем...

Ул кырт кына борылды, миңа бүтән ләм-мим бер сүз әйтмәстән, чыгып китте, ишекне йозак белән бикләп алды.

Мин төн уртасына тикле йоклый алмадым. Безне, ятим балаларны, ач-ялангач итмәс өчен көне-төне иза чиккән әниемне уйлап яттым. Ул кайгырадыр инде, минем өчен күз яше коядыр. Безгә үч итеп, милицияне котырткан күршеләрне каргыйдыр. Мин юкка аның сүзен тыңламадым, укуымны юкка ташлап кайттым. Әнием минем укуымны бик тә теләгән иде бит. Казанбаш мәктәбе укытучылары ел саен кыш урталарында яки яз ахырларында Көтек клубында ата-аналар белән очрашалар, Көтек, Өчиле, Каенлык балаларының йөреш-өлгерешләре турында сөйлиләр, шулар арасында югары сыйныф укучысы Рамазан Салахов, бишенче йә алтынчы сыйныф укучысы без фәкыйрегез була иде. Минем исем чыкканны әнием өзелеп көтә, ул минем алдынгы укучы булуым белән бик горурлана иде. Менә булдым инде, болай булгач, алдынгы укучы, әтинең үлеме генә җитмәгән, мин тагын әниебезнең хәсрәтен арттырдым...

Минем уйларым Югары Пошалымга күчте. Зур кош төсле олы гәүдәле Алма апаны, дәһшәтле вакыйгаларны дәһшәтле итеп сөйли белүчене күз алдына бастырдым. Моңарчы мин аны ярата идем, аңа ияләнгән идем, аның кимчелекләренә, кире якларына күз йома идем. Алма апай бик саран иде. Күршеләре аны дин йолаларын белүче дип

каймак яки сөзмә китерсәләр, ул аны башта идән астына төшереп куя, миннән куйдырта, бер атна узгач, каймак яки сөзмә ачып, өсләре җонлангач кына ашарга бирә иде. Андый ризыкны ничек ашыйсың инде? Кызы Мәликә апага, мин унике яшемдә Казанга алып барган Мәликә апага саранлык шуңардан йоккандыр әле. Саран булса гына бер хәл иде, ул әле кире беткән дә карчык иде. Аның сугыш чыкканчы колхозга кермичә, аерым хуҗалык булып яшәве нәрсәдән дисез? Кирелегеннән. Аңардан сорыйлар: «Гарифҗаннар сезгә сарык китермәделәрме?» «Юк, китермәделәр, андый нәрсәне күргәнем дә юк, ишеткәнем дә юк»,— дип әйтсә, ни була инде, йә? Юк, ул остара, милициягә шик салып: «Китерерләр сиңа бар, әллә кайчан ашап бетергәннәрдер инде...» — ди. И ходаем, мин бит әле ике ел буена, әти үлгәннән соң аларның сыер-сарыкларын көтүгә кудым, көтүдән каршы алдым, алар кырга киткән чакта өй сакладым, чишмәдән бәләкәй чиләк белән су ташыдым. Шуларны да онытты микәнни Алма апай? Хәер, мин аның өчен яшәмәдем Пошалымда, мин анда Хәкимулла абый хакына яшәдем, ул миңа искиткеч матур уенчыклар ясап бирә иде. Уенчыклар... уенчыклар...

Мин как идәндә йоклап киткәнмен.

Иртән, әле таң атып кына килгәндә, ишек ачылганга уянып киттем. Ишектән берьюлы өч кеше керде. Аларның берсе — Сибәгать абый малае Сөнгать, икенчесе — Гаптеринең апасы, кияүдән аерылып кайтып, зинадан бала тапкан Хөмәйрә, өченчесе — милиционер Бикташев иде.

Бикташев үзе белән кәнсәләр бүлмәсенә алып керүчеләрне өстәл янындагы урындыкка утыртты. Миңа аяк өсте басарга кушып җикерде.

Башта ул Хөмәйрә ападан сорау алды.

— Әйтегез әле, Хөмәйрә Шәйхетдинова, дөресен генә әйтегез, юкса, ялган сөйләгән өчен РСФСР җинаятьләр кодексында махсус статья каралган, тимер рәшәткә арасына эләгеп куюыгыз мөмкин... (Пауза ясап торды, мондый хәтәр сүзләрне үз гомерендә дә ишетмәгән, заманында, колхоз чыккан елларны ат караган, аннары кырда бил бөккән Хөмәйрә апа кан калтырап утыра башлады.) Әйтегез әле, Хөмәйрә апа, сезнең энегез Габдрахман төнлә берәр әйбер күтәреп кайтмадымы?

— Кайтты,— диде иреннәре дер-дер килгән Хөмәйрә апа.

— Нәрсә иде ул?

— Бәрәңге.

— Күпме?

— Бер капчык.

— Каян алып кайтты?

— Подвалдан.

— Менә бу егет юк идеме анда?

— Юк, аны күрмәдем.

— Энегез Габдрахман сарык суйдымы?

— Юк, сарык суймады. Сарык юк безнең.

— Читтән алып кайтып суймадымы?

Хөмәйрә апа сүзен әйтә алмас дәрәҗәдә курыкты. Күрәсең, бәрәңге урлауны ул гадәти нәрсә дип белгән, ә сарык чаклы сарык урлау — ул инде җинаять. Ул инде төрмә.

Бикташев аның шул халәтеннән файдаланып, шаһитенә ябырылды:

— Гражданка Шәйхетдинова, дөресен әйтегез. Ялган сөйләгән өчен җинаятьләр кодексында статья бар.

Хөмәйрә апа шулчаклы да курыккан иде, ул сүзен әйтә алмас дәрәҗәгә житте. Аның авызыннан пыты-пыты килгән авазлар чыга башлады. Бикташев эшнең зурга китүен, аның алдында педучилищеда укыган Ахунов түгел, надан бер авыл хатыны утыруын аңлады бугай, Хөмәйрә апаны кайтарып җибәрде. Тегесе, авыз эченнән белгән догаларын укыйукый, үзе белән алып кергән төенчеген күкрәгенә кысып, чыгып китте. Мин ул төенчеккә игътибар иттем, анда ашау ризыгы түгел, анда, мөгаен, чиста күлмәк-ыштан булгандыр, андый-мондый ябып куйсалар,

дип Хөмәйрә апа аны үзе белән алгандыр. Татар хатын-кызлары чисталыкны ярата.

Хөмәйрә апа чыгып киткәч, Төрнәленең кәнсәләр бүлмәсендә бераз тынлык булып торды. Бикташев иренен кысып, миңа карап алды да:

— Гражданин Ахунов, соңгы мәртәбә әйтәм, син Сибгатуллин Сөнгать, Шәйхетдинов Габдрахман белән сарык урларга бардыңмы? Урлаган сарыкны кая куйдыгыз? Язмышыңны җиңеләйтәсең килсә, дөресен әйт,— диде.

— Юк,— дидем мин.— Бу — минем өскә яла ягу.

— Допустим, шулай булсын. Бәрәңге урладыңмы?

Мин, идәндә йокласам да, ял итәргә өлгергән идем инде. Участковый Бикташевның күзенә карадым да дәшмәдем — син мине тәмам туйдырдың инде, дигән мәгънәне аңлатырга тырыштым. Ул — күп төрле җинаять эшләрен тикшергән карт бүре — моны аңлады, Сибгатуллин Сөнгатькә карап ым какты.

Сөнгать, үз өянәкле, чирле булса да, миннән таза, күп өлеш таза, укуын дүртенче сыйныфтан ук ташлаган, әдәбиятның нәрсә икәнен дә белми торган әрсез һәм дә гамьсез бер бәндә булып чыкты. Азактан мәгълүм булганча, Бикташев аны кыйнаган, шуңа күрә ул әйткән: «Минем сарык урлаганым юк, колхоз басуыннан, подвалдан бәрәңге урладым»,— дигән. Участковый Бикташевка шул гына кирәк. Җепнең очы табылды, әнә шул җепкә тотынып, зур җинаятькә барып чыгарга була. «Кемнәр белән урладың?» — дигән Бикташев. «Гаптери белән урладым». «Сарык урладыңмы?» — дип каныккан Бикташев. «Юк, сарык урламадым, бәрәңге урладым»,— дигән Сөнгать. Кабат сораган Бикташев: «Кемнәр белән урладың?» — «Гаптери белән». Бу җавап Бикташевны канәгатьләндермәгән. Безнең күршеләребез, минем әтине үтерүдә катнашы булган кешеләр, мине, нәкъ менә колхоз председателе булган Ахун малаен, утыртып куюны йөкләгәннәр Бикташевка. Ихтимал, ришвәт тә биргәннәрдер. Хәзер менә Бикташев Сөнгатькә ым какты, Сөнгать минем каршыга килеп басты.

— Сибгатуллин Сөнгать, сезнең белән бергә Ахунов Гарифҗан бәрәңге урладымы? — дип сорады.

Сөнгать күзен дә йоммыйча:

— Урлады,— диде.

Шул ук сорауны Бикташев миңа бирде, мин дәшмәдем. Мин, гомумән, күңелемне дәшмәскә, бер сорауга да җавап бирмәскә дип беркеткән идем.

Бикташев Сөнгатькә тагын ым какты, тегесе кизәнеп торып минем яңакка салып җибәрде. Мин, кылчык хәтле ябык малай, идәнгә тәгәрәп киттем, гәүдәм ябык булса да, йөрәгем зур иде минем, котырып ачуым чыкты, идәннән үрмәләп килдем дә Сөнгатьнең ботына тешемне батырдым, ул өйне күтәреп китәрлек итеп акырып җибәрде. Бикташев урыныннан очып чыкты да, мине күлмәк якамнан тотып стенага китереп бәрде. Минем борыным канады, канаган борынымны күлмәк җиңем белән сөртә-сөртә Пошалым башы Алма апай өйрәткән сүзләр белән мин Бикташевны каргарга тотындым:

— Башың бетсен, муеның астына килсен, ятим малайны рәнҗеткән өчен, Ходай тәгалә сиңа иң әшәке җәзаны бирсен!

Бикташевның да инде сабырлыгы төкәнгән иде, шушы җәбәхәер авыл малаен, шушы йолкышны җиңә алмавын белү авыр иде бугай аңа, ул мине тагын күлмәк якамнан умырып тотып күтәрде дә өстәл янына китереп бастырды, аннары баш бармагын тырпайтып, минем колак яфрагы турысына басты. Озак басып торды, мин башта күз алларым караңгыланганны тойдым, аннары аңымны җуйдым. Азактан, күп еллар узгач, медицина энциклопедиясеннән укып белдем, ул минем йокы артериясен томалаган икән.

Аңыма килгәндә, ул өстәл янында утырып тора, папирос тарта иде. Йөзе инде аның усал түгел, талчыккан иде.

Миңа үзенең каршысына, өстәл буена утырырга кушты.

— Менә шулай, Ахунов, әгәр син миңа хәзер дөресен әйтеп бирмәсәң, КПЗда[1] суд тикшерүчесе сине алай гына җәзаламас, эчеңне-бавырыңны сытар, син гомерлек гарип булып калырсың.

Минем гарип булып каласым килми иде. Болай да тормышта күп рәнҗетелдем бит инде. Мин Гаптери белән Сөнгатькә ат бирдем, алар басудан бер капчык бәрәңге урлаганнар, әгәр бер капчыкта өч пот бәрәңге була дип исәпләсәк, димәк, алар урлаган бәрәңгенең бер поты минеке дигән сүз. «Сарык урлауда катнаштыңмы?» — дигәнгә мин, юк, дип җавап бирдем. «Бәрәңге урладыңмы?» — дигәнгә, урладым, дидем. «Каян урладың?» — дигәнгә, подвалдан урладым, дидем. Басудан урладың ни, подвалдан ни — барыбер түгелмени?

Боларның барысын Бикташев бик тырышып ак кәгазьгә — шакмаклы дәфтәр битенә язды, аннары миңа кул куярга кушты.

— Укымыйча кул куймыйм, — дидем мин.

— Укы, син аны, закон буенча, укырга тиеш.

Чорнап-чорнап язылган язуны мин озаклап укыдым. Анда хәреф хаталары да, пунктуация хаталары да байтак иде. Участковый Бикташевның ачуын кабартмас өчен мин аларын әйтеп тормадым. Ул язганнарга кул куйдым.

Бикташев, өстеннән таулар төшкәндәй, җиңел сулады. Миңа таба башын сузып, якын дустына серен әйткәндәй, ягымлы һәм тыныч тавыш белән:

— Син, Гарифҗан, судта шушы ук сүзләрне әйтеп бар. Юкса синнән кабат сорау ала башларлар, кыйнап булса да әйттерерләр, миңа сөйләгәннәрне сөйләсәң, җиңел генә җәза белән котылырсың, — диде.

Мин аңар ышандым, ул чакта аның үз мәнфәгатен кайгыртып сөйләнүен аңламадым. Кешеләргә ышану, беркатлылык минем гомерлек сыйфатым булды.

## Хөкем карары. Колония

Шушы көнгә кадәр миңа аңлашылмаган хәл: безне — Гаптерине, Сөнгатьне, мине — Бикташев үзе дә, мылтыклы конвой да озата бармады. Төрнәлегә, безне алмага, әлеге дә баягы Һидият абый менгән иде.

— Нишлим соң, егетләр, куштылар, — диде ул, кулларын җәеп.

Без Төрнәледән Өчилегә төшмәдек, Олы юл белән Арчага киттек. Юлда сөйләшмәдек. Һәркем үз уен уйлап барды. Минем уй оптимистик иде, мин җәзаның аз биреләчәгенә күңелемнән иман китердем. Әгәр каты җәза бирәсе булсалар, безне Көтек авылының гап-гади бер кешесенә ышанып тапшырмаслар иде, безне кораллы конвой озата барыр иде.

Арчада безне мин педучилищеда укыган чакта көн саен яныннан узып йөри торган ике катлы, тәрәзәләре тимер рәшәткәле йортка китерде Һидият абый, бик озын бер коридорга килеп кергәч, җанга курку төште — бу коридордан әллә нинди күңелгә ятышсыз ачы-төче исләр килә иде.

Майормы, капитанмы киемендәге тәбәнәк бер татар безне Һидият абыйдан кабул итеп, аны кайтарып җибәрде. Озаклап документларны укыды. Һәркайсыбызның исем-фамилиясен сорап чыкты. Ике сакчы чакырып, безне КПЗга ябарга кушты.

---

[1] КПЗ — камера предварительного заключения, татарчасы — хөкем карары чыгарылганчы вакытлыча ябып тору урыны.

Шунда Гаптери абыйның теле ачылды:

— Гражданин начальник,— диде ул,— безне ике көн ашатмады Бикташев, өйдән китергән ризыкны да бирмәде, безне ачка үтерергә уйламыйсыздыр бит?

«Гражданин начальник», аның ягына күз дә салмыйча, сакчыларга дәште:

— КПЗ ишек алдындагы ашханәгә алып кереп ашатыгыз.

Ашаттылар. Бер сынык ипи, бер тимер җамаяк кәбестә шулпасы бирделәр.

«КПЗ» дигәннәре мин укыган педучилище бинасы каршындагы пожар каланчасының аскы каты икән. КПЗга ябар алдыннан безнең чалбар каешларын, чабата киндерәләрен кисеп алып калдылар. Без кергәндә, анда ике-өч кеше бар иде. Алар салам матраска, биек сәкегә тезелеп ятканнар иде. Берсе йоклый, икесе әкрен генә сөйләшеп утыра, битләрен сакал-мыек баскан иде. Сөйләшеп утыручыларның берсен, илле биш яшьләр тирәсендәгесен, чалбар кесәсенә салып, бер кило бодай алып кайткан өчен япканнар, икенчесе колхоз председателен кыйнаган өчен утыра иде.

— Ә сезне нәрсә өчен кулга алдылар? — диде тоткыннарның олы яшьтәгесе.

— Бәрәңге урлаган өчен,— диде Гаптери абый.— Безне менә шушы б..к чүлмәге сатты,— дип ул көтмәгәндә Сөнгатьнең яңагына салып җибәрде. Шундый каты чалтыратып салды, теге дөбердәп идәнгә ауды, акырып җибәрде. Ул акырганга йоклап яткан тоткын уянып, берни аңламый, әсәренде, богаулы ишек ачылып, аннан надзирательнең башы күренде:

— Что за безобразие? — диде ул чыелдавык нечкә тавыш белән.

— Берни дә юк, гражданин начальник, менә бу мөртәт йоклаган җиреннән саташып, идәнгә егылып төште,— диде Гаптери.

— То-то! — диде надзиратель, ишекне ябып, шалтыр-шолтыр бикләде.

Гаптери ярсыган иде, ул Сөнгатьнең артына типте:

— Хәзер үк сәке астына кер, юкса синең ише сатлык җанны буып үтерәм мин,— диде.

Сөнгать атна буе сәке астында йоклады, көн яктыргач кына сәке астыннан чыга торган булды. Судка кадәр Гаптери аны шулай сәке астында йоклатты. Мин аны яклап бер сүз дә әйтмәдем. Сөнгатьнең минем яңакка сукканы күңелдән китмәгән иде әле.

Бер атнадан суд булды. Бикташевка әйткәннәрне без расладык. Ялган бәла итеп ягылган сарык урлауны өстебезгә алмадык. Судка минем әни белән Хөмәйрә апа килгәннәр иде. Мин әнинең чыраена бер генә мәртәбә күз төшердем, ул ябыккан, чырае хәсрәтле, күз читләренә, ирен кырыйларына җыерчыклар тезелгән иде. Ул үзе дә миңа карамады, башын иеп кенә утырды.

Хөкем карары кыска булды:

Миңа, балигъ булмаган үсмергә — өч ел, Гаптери белән Сөнгатькә биш ел биреп, Казанның Кремль асты төрмәсенә озаттылар.

Стансада, вагонга утыртыр алдыннан, безне туганнарыбыз белән күрештерделәр. Әни туктаусыз елады, миңа ул бик-бик кызганыч тоелды.

— Әйттем бит мин сиңа, балам, укуыңны ташлама, дип әйттем бит. Үзеңнең акылың булмаса, олылар сүзен тыңлау да бер һөнәр. Инде балам, тәти йөр, тәтилекнең чиге юк. Үзеңне әйбәт тотсаң, ләчәнстуаның сүзенә каршы килмәсәң, анда алданрак та коткаралар, дип сөйлиләр. Исән-сау бул, балам, хат язып тор безгә. Без инде менә балаларны карарга Гайшә апаң белән икәү генә калабыз...

Паровоз гудок бирде, безне ашыгып вагонга утырттылар. Каравылчы ике солдат безнең ике ягыбызга утырды, вагон буш, анда башка кеше юк иде.

Башта безне япкан Кремль асты күчмә төрмәсе, аннары Казанның Социалистик шәһәрчегендәге — җәһәннәм астындагы Тугызынчы колония һәркайсы бик нык хәтеремә сеңеп калды.

Күчмә төрмәдә, утыз-кырык кешене бергә тутырган камерада, мин коточкыч акырган тавышка куркып уяндым. Бөтен кеше берьюлы акыра, стеналар тетрәп тора иде.

Өч надзиратель керде, хәлне шундук аңладылар, безнең камерага туры килгән өч законный карак тоткыннарның яңарак киемнәрен салдырырга тотынганнар икән, надзирательләр, аларның кулына богау кидертеп, алып чыгып киттеләр.

Тугызынчы колониядә мине аптыраштта калдырган нәрсә — монда чиләктәр, кәстрүлдер ише нәрсәләр ясап маташулары иде.

«Ничек була инде бу? — дип уйладым мин. — Илдә сугыш бара, Ленинград камалышта, СССРның күпме җире фашистлар тарафыннан басып алынган, ә монда калай чиләк, калай кәстрүл ясап чиләнәләр. Бу тоткыннарны, сак астында, берәр заводка яки фабрикага куярга булыр иде.»

Тугызынчы колониядәге яшәү рәвеше миңа бер дә ошамады. Моннан ычкынырга кирәк иде. «Әни килеп йөрсә, үзләренә дә юк ризыкны авызыннан өзеп китерсә, минем бит җанымны борчу биләп алачак.» Мин әлеге тоткынлыгымнан бигрәк, алар өчен кайгыра башлармын дип курыктым. Тормышымда борылыш булуны көтеп яшәргә тотындым. Язмышыммы-ялгышыммы дигәндәй, көннәрдән бер көнне: «Мәскәү ягына ФЗӨга җыялар икән үсмерләрне»,— дигән хәбәр таралды. Кем тели, шул языла ала, имеш. Ике дә уйлап тормастан, бардым да язылдым. Сәламәтлегемне сорадылар, сау-сәламәт, дидем. Юлга әзерләнәсем юк, кара постау чалбар белән ак күлмәгемне ике буханка ипигә алыштырган идем, ник дигәндә, Кремльнең күчмә төрмәсе камерасында бандитларның яхшы киемнәрне барыбер талап алачакларын күрдем.

Язылып кайтканнан соң атна-ун көн уздымы икән, безне җыеп алдылар да тоткыннарны йөртә торган товар вагоннарына илтеп төяделәр. Монда гел үсмерләр генә, алар Тугызынчы колониядән генә түгел, Казанның төрле-төрле төрмәләреннән иде.

Казаннан безне Мәскәү ягына таба алып киткәч, сөенүне күрсәң! Димәк, чынлап та ФЗӨга алып баралар.

Юдинога җиткәч, туктадык. Ул сортировочный станса икән, ике көннән соң тоткыннар белән шыплап тутырылган өч вагонны ниндидер составка тактылар һәм безне бөтенләй кире якка — Себер ягына алып киттеләр.

Арчаны узган чакта, их, каласың бит туган якларым, дип йөрәктән каннар тамды.

Вагоннар, мин уйлаганча, товар вагоннары түгел, тоткыннарны йөртә торган вагоннар булып чыкты. Пассажир поездларындагы төсле, аларда да вагон эче купеларга бүленгән, тик ул купеларга дүрт кеше утырмый, уналты кеше утыра, дөресрәге — ятып тора иде. Анда купеның ике стенасына сигез нар куелган иде. Безне шул нарларда ай буе алып бардылар. Анда ятып торудан без бик нык ялыктык. Безне бер мәртәбә купебыз белән — уналты үсмерне карцерга яптылар, карцер дигәннәре үзебезнең үк купе булып чыкты, нарларның капкачларын төшерделәр дә аска, купе идәненә безне тыгызлап тутырдылар, анда хәтта борылу түгел, селкенергә дә мөмкин түгел иде. Шул рәвешчә ун сәгать басып торудан аяклар оеды, тәннәр тирләде. Бу — лаеклы, тиешле карцер иде, ник дисәң, безнең купе кырыендагы купега азык-төлек өйгәннәр, унбер яшьлек бер тоткын, моны сизеп алып, почмактагы тишекне пычак белән зурайткан, шуннан бөтен купега сохари, шакмаклы шикәр, консервы өләшеп чыкты. Без ул ризыкларны төне буе ашадык, ә көндезен, мичкәдәге селедка төсле, көне буе ач килеш тыгызланып басып тордык. Әмма бер генә үсмер дә шыңшымады, чыгарыгыз мине, дип гозерләнмәде.

Бер ай тулганда без Красноярскига килеп җиттек, анда бер тәүлек утыргач, Ачинск стансасына бардык, вагоннардан үсмерләрнең байтагын сакчылар кулларына күтәреп алып чыгарга мәҗбүр булдылар: тоташ ятудан да, ипи паекларын каракларга оттырып, баланда гына чүмерүдән дә хәлсезләнгәннәр иде.

Аннары безне колонналарга тезеп, бик озак җәяүләп алып бардылар, яннан конвоирлар һәм этләр барды, чыгып тезелгәч тә безне кисәттеләр: бер адым уңга, ике адым сулга — качарга җыену дип санала, конвойчылар кисәтмичә аталар!

Ялан кырда икеме-өчме метр биеклегендәге койма һәм чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган бер биләмәгә китереп керттеләр безне, бу инде — кырык өченче елның сентябрь башлары иде. Без анда ун көн чамасы яшәдек. Шушы койма биләмәсендә ике катлы итеп корган егерме-утыз метрлы нарлар иде, ул нарлар өй эчендә түгел, ачык яланда, койма белән әйләндереп алган яланда иде. Себер төне суык була, без, үсмерләр, бер-беребезгә сырышып йоклыйбыз, арка белән күкрәк туңмый, әмма астан да, өстән дә яннар, беләкләр шакыраеп ката иде.

Иртәгесен без койма буйларына тезелеп, кояшта җылынабыз, бу күчмә лагерьга атлы арба белән бик зур мичкә кергәнне көтәбез, мичкәдә безгә баланда һәм ипи алып киләләр, аларны күз ачып йомганчы чүмереп бетергәч, көндезге ашны көтә башлыйбыз.

Ун көннәр шулай интеккәч, бу күчмә лагерьда сүз таралды: имеш, безне Норильскига озатмакчылар, анда елга бер-ике мәртәбә генә пароход килә, срогыңны тутыргач та, кышын-язын-көзен өеңә кайта алмый интегәсең.

Этап белән җибәрер алдыннан үсмерләрнең сәламәтлеген тикшерәләр, олылар белән ничек кыланалардыр, аларын әйтә алмыйм, әмма бездән сәламәтлегебезне сорап чыктылар. Мин авырыйм, дидем, үскән чакта мин бәләкәй һәм чандыр идем, кабыргалар таякны шырылдатып йөртерлек дәрәҗәдә тырпаеп торалар иде, шунлыктан мине Норильск исемлегенә кертмәделәр, егермеләп үсмерне Березовка дигән, балигъ булмаганнарны хезмәт белән төзәтү колониясенә алып килделәр. Күпмесен җәяү атлаганбыздыр, күпмесен тимер юл вагонында килгәнбездер, инде оныттым, шулай да без иртән чыгып китеп, кичен генә Березовкага барып элгәштек. Тамакны туйдыргач, безне, егерме үсмерне, бер баракка кертеп бикләделәр — карантинга. Анысы 21 көнгә сузыла икән. Мин төнлә тагын бик каты акырышкан тавышка куркып уяндым. Тәрәзәдән законлы караклар кергән, алар карантиндагы үсмерләрнең яңа киемнәрен талыйлар иде. Яңарак костюм-чалбарны, күлмәкне салдырып алалар, авылдан килгән тоткыннар бу тәртипне белми икән, салырга теләмәгәннәргә караватка куелгән такталарны суырып алып, сыртына берне генә кундыралар, такталар сынып китә, авыл мокытын ул арада өч бандит чишендереп тә бетергән була, алар үзләре белән кырык ямаулы чалбарлар, тишек ботинкалар алып кергәннәр, шуларны киендергәч, карантиндагы үсмерләр танымаслык булып шыксызланып калды. Мин Казанның Тугызынчы колониясендә чакта ук матур киемнәремне ипигә алыштырган булганлыктан, минем кырык ямаулы чалбарыма да, иске күлмәгемә дә кызыгучы булмады, мин бу юлы тыныч калдым. Азактан белдек — бандитларның үсмерләр киемен талаулары колония түрәләре белән сүз куешып эшләнә икән, малайларның нинди акыруларына да карамастан, карантин бүлмәсенә бер сакчы да, надзиратель дә, бер тәрбияче дә кермәде.

Иртәгесен безне мунча кертеп чыгардылар.

Мунчага кергәндә, ишек төбенә куелган өстәл янында хәрби киемле бер кеше язып утыра иде. Ул исем-фамилияне, яшьне, нинди статья белән эләккәнне һәм һөнәрне сорый. Шул чактагы әрсезлегемә минем хәзер дә исем китә. «Маляр, художник» дип яздырдым бит, әй.

Тагын бер көннән карантин бүлмәсенә гражданский киемдәге бер урыс керде. Ул илле яшьләр тирәсендә иде. Өстендә соры костюм, ак күлмәк, кара галстук, аягында туфли, башы яланбаш, чәченә мул булып чал кунган иде.

— Ахунов кем була? — дип сорады ул.

Мин салам матрас өстендә сузылып яткан җиремнән, тимер караваттан торып, аның янына килдем.

— Киттек, улым, минем белән,— диде ул. Аның «улым» дип дәшкәненә, «гражданин Ахунов» дип дәшмәгәненә бик аптырадым. Сакчылар торган капкадан ул мине иреккә алып чыгып, бер конторга алып керде. Аның янтыгында наган кобуры да, үзе белән бергә мине алырга кергән сакчысы да юк иде.

Конторда чәчләрен кыска итеп кискән, кофта-юбка кигән ике яшь хатын утыра иде. Әлеге мине алып чыккан кешегә алар:

— Иван Михайлович, ничек тәвәккәлләп алып чыктыгыз сез бу зекны? Аның бит сакчысыз качып китүе ихтимал,— диделәр.

— Беркая да качмаячак ул. Аңа колхоздан бәрәнге урлаган өчен өч ел биргәннәр — бер пот бәрәңгегә. Тикшердем мин аның документларын. Качып китсә — ул бит ун ел ала. Авыл малае. Өстәвенә тугыз сыйныф белеме бар. Өстәвенә үзен маляр дип, художник дип таныта...

— О боже![1] — диделәр кыска чәчле ике маржа икесе берьюлы.

— Менә шулай, улым, мин Березовка колониясендә тәрбия эшләре буенча начальник. Иван Михайлович булам. Син үзеңнең һөнәрләреңне зур итеп яздыргансың. Буяучы, рәссам. Рәсем ясый белсәң, без сине клубка алырбыз, бездә ике ел утырган рәссамыбыз срогын тутырып, иреккә чыкты. Рәссамсыз калдык. Инде син рәсем ясый белмәсәң, буяучы булырсың, тоткын балалар яшәгән бүлмәләрне әледән-әле буяп торырга туры килә безгә. Колония зур — биш йөз үсмер. Тораклар да, бүлмәләр дә күп, өстәвенә шунда ук мәктәп тә бар. Аңладыңмы? Аңласаң, бик шәп. Буяу эшен белмәсәң, утын кисәрсең, утын кисәргә дә ярамасаң, фикал тазартучы, ягъни бәдрәфләрне җыештыручы булырсың. Менә сиңа бер табак ватман, менә сиңа пумалалар, менә сиңа «Япон яры» дигән открытка. Күчереп ясап кара шуны. Килештекме?

Мин, шатлыгымнан нишләргә дә белмичә, ватман кәгазе өстенә карандаш белән открыткадагы күренешнең контурын сыза башладым.

Тәрбия башлыгы мин карандаш белән сызып бетергәнче кулыма карап торды, сызып бетергәч, ватман кәгазен үзенә таба борды да күзен кысып карагач:

— Бара бу! Дәвам итегез,— диде.

«Япон яры» картинасын мин тоташтан ике көн буена ясадым. Тәрбия начальнигы минем янда утырмады, теге яшь хатыннар икесе дә урыннарында иде, алар алмаш-тилмәш мин ясаган картинаны карап киттеләр, үзара пыш-пыш сөйләштеләр, мин аларның «какой молодец»[2] дигән сүзләрен генә шәйләп калдым. Шуннан соң тагын да тырышыбрак ясарга тотындым картинаны, хәтта аңа челтәрле итеп рам да ясап куйдым.

Иван Михайлович кичке сәгать бишләрдә конторга кайтты, мин ясаган «Япон яры» (картинаның артына «Японский берег» дип язылган, анда субайларга утыртылган су эчендәге япон йорты, зәңгәр диңгез, ни өчендер сары төстәге күк йөзе, яшел агачлар бар иде) рәсемен ул озаклап, күзен кыса төшеп карады, ни әйтер икән, дип, мин ут йотып торган чакта:

— Булган бу! — дип кичәге сүзен әйтеп куйды.

Яшь хатыннар миңа карап елмайдылар, кул чәбәкләп куйдылар. Иван Михайлович мине үзе белән ияртеп алып китте.

Бараклар төсле үк, әмма алардан шактый биек һәм озын бер бинага алып керде. Анда безне симез гәүдәле, ике иякле бер маржа каршы алды. Исәнләштеләр.

---

[1] Ай алла!

[2] Нинди егет.

— Катерина, менә мин сиңа яшь рәссам алып килдем. Ул стеналарга сурәт төшерер, син аңа ярдәм итәргә тырышырсың,— диде.

Аннары без клубның залына кердек. Стеналар, түшәмнәр ап-ак итеп агартылган, аларга әле бернинди дә плакат эленмәгән, залның урындыклары бер почмакка өеп куелган иде.

— Улым, менә шушы стеналарга клейлы буяу белән рәсемнәр ясап чыгарга кирәк.— Ике тәрәзә арасына алып килде.— Әйтик, менә монда «Яшәсен совет гаскәре — җәяүлеләр!» Менә бу тәрәзә арасына «Яшәсен совет артиллеристлары!», калган ике тәрәзә арасына совет очучыларын һәм танкистларын ясарсыз. Буяуларны иртәгә кертерләр, төрле калибрдагы кистьләр дә булыр. Килештекме?

— Килештек,— дидем мин, боларның һәммәсе барып чыгарына ышанып җитмичә.

Үз гомеремдә, мәктәптә укыган елларымда, минем өчен буяулы булудан да зуррак бәхет юктыр кебек тоела иде. Арча кибетләреннән сатып алган майлы буяу «Яшәсен Май бәйрәме!» дигән плакат язарга гына җитте. Аннары миңа буяу алырлык акча тәтемәде. Хәтта педучилищеда да мин буяусызлыктан интегә идем. Майлы буяу белән минем табигать күренешләрен язып карыйсым килә иде. Шулай бервакыт Күпербаш авылы егете,— ул да безнең Казанбаш мәктәбендә укый иде,— майлы буяу белән урман картинасы ясап алып килде, без аның картинасына да таң калып карадык, азактан Арча конкурсында аның бүләк алуына да кызыктык. Һәрхәлдә, мин кызыктым. Мин дә, буяу булса, андый картинаны ясый алырмындыр кебек тоя идем үземне. Арчаның культмагында майлы буяу белән ясаган кояш баю, кояш чыгу картиналарына, алардагы офыкның алсулыгына, ул алсулыкның су өстендә шәүләләнүенә сокланып бик озак карап тора торган идем.

Менә хәзер миңа стена чаклы стенаны ышанып тапшыралар, иртәгә төрле төстәге буяулар, буяу пумалалары китерергә вәгъдә итәләр. Коры буяу нинди була икән соң ул? Аны җилемдә ясыйлар микәнни? Бәлки, ул мин Арчада чакта кызыл материягә клейлы акбур белән язган төсле буяудыр? Мин шуларны уйладым, тик боларның берсен дә тәрбия эшләре башлыгы Иван Михайловичка әйтмәдем. Әйтсәм, ул миннән баш тартыр дип курыктым. Әле шушы көнгә кадәр минем зур стеналарга коры буяу белән, юк, ялгыш әйтәм — клейлы буяу белән берәр метрлы плакат язу, берне генә түгел, өч-дүртне берьюлы ясау төшемә дә кергәне юк иде.

Иван Михайлович мине тагын үзе белән ияртеп алып китте. Ул мине ашханәгә, аш биреп тора торган тәрәзәгә китерде:

— Мин сездән үтенәм,— диде яулыгын өчпочмаклап бәйләгән, өстенә ак халат кигән аш бүлүче апага,— менә бу үсмер — безгә бик тә кирәкле кеше, аның тамагы туйганчы ашатсагыз иде. Килештекме?

Аш бүлүче апа миңа зур бер калай табак белән куе аш салып бирде. Мин тамагым туйганчы ашадым да кунарга клубка кайттым. Екатерина Семеновна (клуб мөдиренең исеме шулай иде) күршесендәге бәләкәй бүлмәгә урын җәеп бирде. Матрацына салам тутырган булса да, мин мамык түшәктәге төсле йокладым ул төнне. Төрмәледә Бикташев кебек явыз кеше, Красноярскига килгәндәге явыз сакчылардан соң, үсмер малайларны яңа киемен бирергә теләмәгән өчен генә такта сынганчы кыйнаган законлы караклардан соң, миңа беренче мәртәбә Иван Михайлович кеше итеп дәште, улым, диде, «гололобый»[1] дип мыскылламады, мин үземне иректә кебек хис иттем.

Иртәгесен ашханәгә барып тамак туйдырып кайтуга, тәрбия башлыгы әйткән буяу порошоклары һәм җилем килгән иде инде. Аны алып килгән кеше үзе дә буяучы булып чыкты. Саргылт мыеклы, күзлекле ул кеше алтмыш яшьләр тирәсендә булгандыр, аның күз тирәләрендә дә,

[1] Шәрә маңгайлы.

битендә дә җыерчыклар күбәйгән иде инде, әмма ул үзе әле эшкә бик җәптәш икән: су кайнатып, аңа җилем һәм буяу порошоклары кушып, ул миңа берничә чиләктә буяуны әзерләп тә өлгертте. Кичтән дөрес уйлаганмын, акбур белән җилемне кушып мин ясый торган буяулар икән алар.

Инде миңа стенага ясыйсы плакатларны табарга кирәк иде. Күршедәге китапханәгә кердем. Актарына торгач, сап-сары чәчле яшь кенә маржа кызы — китапханәче белән без танкистлар, җәяүле гаскәрләр, очучылар турындагы плакатларны гәзитләрдән табып алдык. Артиллеристлар турындагысы юк кына бит. Мин башта ни өчендер артиллеристлар, безнеңчә әйткәндә, тупчылар турындагысын стенага зур итеп төшерергә дәртсенә башладым. Эзли торгач, китапханәче кыз белән без икәү гражданнар сугышы чорындагы Чапаев, Петька, Аннушканың пулемет янындагы рәсеменә тукталдык. Бәләкәй рәсемне шакмакларга бүлеп (рәсем өстенә шакмаклар ясап, аннары шуны ничә мәртәбә зурайтканны исәпләп чыгарып, клуб стенасына шакмаклар ясап), мин эшкә тотындым. Клейлы буяу акшарлы стенага тигез ята иде, бәләкәй пумала белән, кара буяу белән мин булачак плакатның контурларын сызып чыктым, тоташ буяла торган урыннарын дядя Сашага тапшырдым, өч геройның да битләрен үзем ясадым.

Кичке сәгать бишләрдә плакат ясалып бетте. Дядя Саша артка чигенеп, якынрак килеп, плакатны карап торды да әйтте:

— Мин сине мактыйм, Ахунов,— диде.

Күңел үсеп китеп, икенчесенә дә тотынмакчы идем.

— Бүгенгә җитеп торыр, бозып куймагаек,— диде буяучы дядя Саша.

Ул арада тәрбия начальнигы Иван Михайлович та килеп керде.

Ул ашыгып Чапайлар янына килде, әле дә хәтеремдә, күзләре башта зур булып ачылды, аннары йөзенә елмаю чыкты, күзләре нурландылар, ул рәхәтләнеп көләргә тотынды.

Ә мин аңардан хөкем карары көттем. Хөкемне ул тиз генә чыгармады. Мин дә, буяучы абзый да дулкынлана башладык.

— Нигә Чапай? Нигә бүгенге сугыш геройлары түгел? — дип сорады ул бездән, ниһаять.

— Андый рәсемне таба алмадык. Плакат өстенә нинди сүзләр языйк, Иван Михайлович?

— Бернинди сүз дә язмагыз. Чапайларны белмәгән кеше юк. Моның Чапай булуы әйбәт тә әле. Романтика, егетләр, романтика! Яшьләр романтика ярата. Бу плакатыгыз сезнең — чын тәрбия чарасы. Башка рәсемнәрегез бармы?

Без аңа очучыларны, танкистларны, җәяүлеләрне күрсәттек.

Ул канәгать калды.

— Дәвам итегез,— дип, безнең белән саубуллашып, кайтып китте. Китәр алдыннан ул клуб мөдире бүлмәсенә кереп чыкты. Күрәсең, ул аңа безнең хакта җылы сүзләр әйткән, Екатерина Семеновна безнең плакатны бер мәртәбә карап киткән иде инде, ул чагында ләм-мим бер сүз дәшмәгән иде, бу юлы:

— Булдырган егетләр! — диде.

«Әһә! Начальник синең дә телеңне ачтырдымы?» — дип уйладым мин.

Без ашханәгә барып, тамак ялгап кайттык.

— Әйдәгез, безгә барып кына кунабыз,— дип тәкъдим ясады Саша абый, ашханәдән чыккач.

— Сезгә дигәне кайда соң ул?

— Буяу цехында.

— Анда кемнәр бар?

— Буяу мичкәләре дә мин.

— Ә ул цех кайда?

— Производство зонасында.

— Вахта аркылы чыгасызмы?

— Әлбәттә.
— Ә мине чыгарырлармы соң?
— Үзем сөйләшермен.

Мин капка янында торып калдым, Саша абый вахтер янына кереп китте. Ул анда озак торды, мин ник риза булганыма инде үкенә башлаган идем, ул арада Саша абый килеп чыкты да минем кулдан җитәкләп, вахта аша производство зонасына китереп кертте. Озын бер барак буендагы такта тротуардан бардык, Саша абый шул озын баракның ишеген ачкыч белән ачты, бик озын, аргы башы әллә кайларда ук булган бүлмәгә кердек. Мин анда унлап мичкә, аксыл-сары буяуга буяган, кайсыберләре шпаклевка белән сыланган унлап шкаф күрдем.

— Менә бу безнең буяу цехы була инде,— диде Саша абый.— Мин өч ел инде бу цехта мастер булып эшлим. Менә шундый шкафлар, өстәлләр буйыйбыз без, аларны йә нарат төсенә, йә имән төсенә кертеп буйыйбыз, менә бу мичкәләрдә буяу,— ул бер зур гына мичкәнең капкачын ачты, анда каймактай куе, җете ак буяу тулып тора иде. Башка мичкәләрне дә ачып күрсәтте. Аларында яшел, сары, зәңгәр, кызыл буяулар иде, стена буенда берничә бидон тора — аларында олиф икән, буяу сыекларга.

Минем өчен дөньяда берьюлы шул тамаша күп майлы буяу күрү гайре табигый нәрсә иде, башым әйләнеп китте, мин тәрәзә буенда үз уйларыма батып, озак басып тордым.

## Мастер булу өченниләр кирәк?

Александр Николаевич белән, ягъни Саша абый белән без Березовка колониясенең клубына атна-ун көн эчендә барлык плакатларны ясап чыктык. Шуннан соң клубта минем кирәгем калмады диярлек. Атна саен бер мәртәбә күрсәтелә торган кинофильмнарның белдерүен яза, клубның буялып бетмәгән урыннарын буйый идем, бер ай дигәндә ул эшләр дә бетте.

Клуб мөдире — юан марҗа Катерина янына озын буйлы, карчыга борынлы бер зекияләште. Алар бергәләп мөдир хатынның бүлмәсендә бикләнеп тә утыргалыйлар, очрашкан чакларында бер-берсенә яз кояшы кебек елмаялар, мондый елмаюлар астында нинди дер киная ята, шуңа күрә тоткыннар андый гамәлләрне шактый ук ямьсез итеп әйтәләр: «Лыбается как параша»[1], диләр. «Параша» дигәне — нәҗес мичкәсе, гадәттә, ул төрмә камераларында була, законлы караклар, берәр тоткынга җәза бирергә теләсәләр, аны параша янына яткыралар яки аны юарга мәҗбүр итәләр. Шөкер, миңа андый җәзаның эләккәне булмады, үсмерләр колониясендә тәртип нык, законлы каракларда н үсмерләрне мыскыл иттермиләр иде. Әмма минем «параша» турында сөйләвем юкка гына түгел. Катерина янынаияләнгән зек нәкъ менә законлы карак булып чыкты. Ул күптән инде балигъла р яшеннән чыккан, әмма үзен әле уналты яшендә дип кенә яздырган, врачлар гадәттәгечә тештән карап, аның яшен билгеләргә тырышсалар да, билгели алмаганнар, ул әйткәнгә риза булып, аңа уналты яшь куйганнар. Законлы ул карак табигать биргән сәләтләрдән мәхрүм түгел, клубта эшләүче берничә хатынны — зекларны һәм, әлбәттә инде,— Катеринаны үз янына чакырып, гитара уйный, үзе уйнаганга кушылып:

Я не пою про всю Одессу,
Вся Одесса очень велика,
Пропускаю всю капусту —
Восславляю Костю-моряка,—

[1] Нәҗес мичкәседәй елмая.

дип җыр башлый, тавышы таң калырдай матур, моңлы, ул кычкырмый, тавышы белән уйнамый, үз эченә китеп, барыбызны да онытып моңлана иде.

Шул хәтле матурлык, нәзакатьлек белән бергә, анарда тупаслык та, кансызлык та, үзен башкалардан өстен куярга тырышу да бар иде. Мин һәм Саша абый ясаган плакатларны күргәч, ул миннән:

— Өч баһадирны ясый аласыңмы? — дип сорады.

— Ясый алам,— дидем мин.

Ихтимал, миңа, ясый алмыйм, дип әйтергә кирәк булгандыр, минем беркатлылыгым бу очракта үземә зыянга булып чыкты. Әлеге озын буйлы зек миңа усал карап, үзем исәнләшмәсәм, исәнләшми йөри башлады.

Клубта идән юучы ике әсир хатын бар иде. Атнага бер мәртәбә үсмерләргә кино күрсәтәләр, клубка нибары 150 кеше сыя, биш йөз үсмерне өчкә бүлеп, өч мәртәбә күрсәтәләр киноны, алардан соң өч мәртәбә юарга кирәк идәнне, инде иң авыр эшләрдә эшләүче тагын 50 олыларны алсак, дүрт мәртәбә кино күрсәтәләр булып чыга. Шулай булгач, табигый, клубның бик дәү идәнен атнага өч-дүрт мәртәбә юарга кирәк булып чыга.

Баштарак юан марҗа Катерина миңа әйтте, идән юучы түтәйләргә кыен, алар икәү генә өлгерә дә алмыйлар, булышырга кирәк булыр, диде.

Мин булыша башладым — аларга су ташып тордым.

Бер атнадан идән юучыларның берсе котылып, иреккә чыкты. Идән юарга без икәү калдык. Тагын өч көннән идән юучыларның икенчесе авырый икән, клубның болын чаклы идәнен, әсирләр көзге балчыкны, агач табанлы башмакларына ияртеп кергән балчыкны юу минем өскә төште.

Баксаң-күрсәң, идән юучы әсир хатын һич тә авырмаган, мине түбәнсетү, кимсетү өчен марҗа Катерина белән законлы карак клуб идәнен юуны минем өскә юри аударып калдырганнар икән. Имеш, такыр башлы бер татар малае законлы карактан — кешеләрне таң калдырып җырлый белә торган адәмнән өстен булып чыксын! Моңа юл куярга ярамый. Я — ра — мый! Әнә идән юсын, әнә мескен булып яшәсен, рәссам мин дип, кукыраеп йөрмәсен.

Шушы аяусыз фәлсәфәгә төшенү белән мин моннан китү ягын карадым. Беркөнне, аш алырга чыккан җиремнән тәрбия начальнигы Иван Михайловичка әйттем:

— Гражданин начальник, клубта миңа эш бетте, әсир үсмерләр кино караганнан соң идән юу гына калды,— дидем.— Бәлки, мине буяучылар цехына күчерерсез, мин бит — квалификацияле кеше, мин анда күбрәк файда китерермен,— дидем.

— Ярый, улым, мин сине аңладым. Фикеремне иртәгә әйтермен,— диде.

Иртәгесен ул мине буяучылар цехына күчерү өчен колония башлыгы белән сөйләшкәнен, башлыкның моңа риза булганлыгын хәбәр итте.

Мин салам матрацымны күтәреп, китәргә җыенгач, клуб директоры Катерина янына килеп йөргән законлы карак минем юлыма аркылы төште.

— Такырбыш, син кая җыендың болай? — диде.

— Буяучылар цехына,— дидем мин.

— Кем рөхсәт итте?

— Иван Михайлович.

Законлы карак минем чыгу юлыннан читкәрәк китте, әмма миңа янап әйтте:

— Мин сине нишләтергә икәнен белермен!

Буяучылар цехына күчкәннән соң мин атна буе ул бандитның безнең янга килеп чыгуыннан, миңа кул күтәрүеннән куркып яшәдем. Әмма бер атнадан соң колония буйлап «Атаман» кушаматлы законлы каракны

унбер яшьлек малайның балта белән чабып үтергәнлеген хәбәр иттеләр. «Атаман» дигәннәре миңа янаган теге карак булып чыкты.

Моны мин хөрмәтле укучыларыбызга җентекләбрәк аңлатып бирергә тиешмен. Кеше хәтле кешене үтерү вакыйгасы хәтта колония шартларында да «ЧП» санала.

Бөек педагог Антон Макаренконың «Педагогик поэма» исемле китабын сез укыгансыздыр дип ышанам. Илнең иң авыр чакларында да ул сукбайлардан, кесә каракларыннан, хәтта бандитлардан кеше ясап чыгара. Ул аларга ышана, ул аларның намусларын уята. Отрядларның башлыкларын — талант ияләрен тәрбияли ул. Әнә шул активистлар башкаларга йогынты ясый.

Безнең Березовка колониясендә дә биш йөз үсмерне отрядларга бүлеп чыккан иделәр. Ул отрядларда егерме-утыз кеше санала, алар белән зур йогынтысы булган активистлар җитәкчелек итәләр, тәрбия начальнигы да, режим начальнигы да, колония начальнигы да активистларның биографиясен, тормыш юлын кыл иләктән үткәргәннәрдер инде. Халыкта: «Бер пычрак сыер бөтен абзарны буйый» — дигән мәкаль бар. «Атаман» кушаматлы законлы карак нәкъ менә шундый «пычрак сыер» булып чыга. Ул үзе балаларга йогынты ясарга, аларны уңай яктан тәрбияләргә алынса да, элекке шөгылен — караклар законы белән яшәвен ташламый. Үсмерләрне картада отып, аларның ипиләрен шестеркалардан җыйдыра, колониягә килгән яңа тоткыннарның затлы киемнәрен салдыра, үзенә буйсынмаган үсмерләрне кыйный. Ул боларның барысын колония башлыкларына, тәрбиячеләргә күрсәтми эшли, сакчылар белән сүз куешып, затлы киемнәрне аларга тондыра, тегеләре әлеге бандитка ни кирәк, ташып торалар. Ул хәтта ял зонасына, баракка кайткач, үсмерләр алдында аракы эчүдән дә тартынмый. Менә шушы адәм атлы «активист» үзе башлык булган отрядның тәмам канын эчкәч, аңар түзәр әмәл калмагач, ун елга утырган унбер яшьлек малай, әнисенә карата садистлык кылган әтисен балта белән чабып үтергән малай, кышын баракларга яккан чакта утын яра торган балтаны урлый һәм барлык отряд йоклап беткәч, «Атаманның» башына балта белән чаба.

Бездә гомер буе күп нәрсә формаль эшләнеп килде. Антон Семенович Макаренко бит активистларны башта үзе тәрбияләгән, аларның кристаллдай саф күңелле икәнлекләренә ышангач кына, отряд башлыклары итеп куйган. Ә монда гитара чиртеп, блатной җырлар җырлап йөргән бер бандитны отряд башлыгы итеп куялар.

Унбер яшьлек үтерүче судта ни өчен «Атаман»ны үтерүен сөйләп биргән, Березовка колониясе башлыкларының күзе маңгайга менә, алар ашыгыч рәвештә отряд башлыкларын этапка озаталар — берсен-бер калдырмыйча. Ә бит алар арасында намуслылары да булгандыр...

Хәлләр нинди генә борылыш алмасын, мин язмышым өчен кан калтырап торудан котылдым. Ә Саша абый мине бик тырышып малярлык эшенә өйрәтә башлады. Ул моны миңа карата изгелек эшләү өчен генә, үсмер егетне кызганудан гына эшләмәде бугай. Буяу цехында шкафтыр-өстәлләр ише йорт җиһазларын буяу белән бергә, балалар бакчалары, ясләләр өчен уенчыклар да ясыйлар иде. Мин буяу цехына күчкәнче, балалар яслесе өчен дип эшләнгән дүрт айлык продукция — курчаклар йоклату өчен кирәкле бәләкәй агач караватлар инде буялган килеш складта ята икән. Аларны меңләп кенә санныйлар иде. Менә шуларга ак ромашкалар, каз рәсемнәре, кечек сурәтләре төшерергә кирәк иде. Әгәр аларның һәркайсын кулга тотып, берәм-берәм сурәт төшерә башласаң, дүрт ай буена җыелган ул уенчыкларны ел буена да эшләп бетерерлек түгел иде. Уйлый торгач, мин уйлап таптым: безнең аргы башы чак күренеп торган озын цехка алтышар метр озынлыгында идән сайгаклары алып керттердем (күршедә генә агач эшкәртү цехы бар иде), аларны биек кузлаларга куйдырдым да уенчык караватларны шунда тезләреп чыктым. Малайлар бу эшне бик теләп башкардылар. Шуннан

соң мин уенчык караватларга сурәтне конвейр белән төшерә башладым. Ике малай минем янымда палитрага салынган буяуны тотып торалар, ә мин сул кулымның бармак араларына кыстырган дүрт кисть белән караватт башларына ромашка төшерәм, кыз баланың итәгеннән эләктереп алган ата казларны ясыйм — китте эшләр хутка. Саша абый минем уйлап табуымны бик хуплады.

Профессиональ рәссам колониядән котылып киткәннән соң дүрт ай эчендә җыелган уенчыкларны бер ай эчендә бизәдек тә бетердек.

План белән яши торган замана иде бит. Баксаң-күрсәң, үсмерләр колониясенең дә үз планнары бар икән. Мине колониянең производство бүлегенә чакырып, мактадылар, инженер-техник хезмәткәрләргә биргән төсле, аксыл костюм бирделәр. Янәсе, кешелеккә кияргә! Менә мин иректә чакта ала алмаган ак чалбарны кайчан кия алдым. Тик аның гомере озын булмады, буяучылар цехында ак чалбарны ак килеш асрап буламы соң?! Ни генә димә — бу барыбер минем хезмәтемне санга сугу иде.

Ярты ел дигәндә Саша абый миннән алтынчы разрядка торырлык маляр әзерләде. Мин шпаклевканың да, майлы буяуның да, әйберләрне төрле агач структуралары ясап буяуның да нәрсә икәнен белә идем инде. Шахмат тактасын, аның фигураларын лаклау мәктәбен дә уздым, буяуны иснәп карау белән нинди олифта ясалганын әйтеп бирер дәрәҗәгә җиттем.

Без Саша абый белән кичләрен мичкә ягып, шул ут яктысында сөйләшеп утырырга ярата идек. Эшебезне бик яхшы итеп алып баргангадыр, безгә көненә бер кило ипи бирәләр, ашны без котелок белән ашханәдән алып кайтабыз да суык килеш ашамыйбыз, мич плитәсендә җылытып алабыз. Иртән алган бер кило ипине өч кисәккә бүлеп куябыз — тәртипле яшибез. Колониядә бирелгән баланда белән, әлбәттә, ерак китеп булмый, ул шыр су дигәндәй, кашыкка эләгер нәрсә юк анда, әмма безгә бит әле өч бармак ясcылыгы балык кисәге бирәләр, ипи белән шуны да ашап куйгач, ярап тора, бөтенләй үк ач калган төсле түгел. Дядя Сашаның бик яхшы маляр икәнен белгәнгә күрә, иректәгеләр аңа кайчагында иске шкафларын, өстәлләрен буятырга китерәләр, колония җитәкчеләре аны бездән бушка буята, әмма иректәгеләрнең намуслары үлмәгән бит, алар куеннарына тыгып, ун бәрәңге яки ипи кыерчыгы, яки бер-ике стакан тәмәке алып киләләр, андый чаклар безнең өчен бәйрәм була торган иде.

Шулай бер кышкы кичтә, мич янында утырып, утын кисәкләренең чатырдый-чатырдый янганын күзәткән чакта, Саша абый әйтеп куйды:

— Карале, Гариф, син бит рәсем ясый беләсең. Ник әле без шул мөмкинлектән файдаланмыйбыз?

— Нишләп була соң, дядя Саша? — дидем мин.

— Хәзер бит сугыш вакыты, караватт янына куярга келәм юк, әгәр син шул келәмне алыштырырдай картина язсаң?

— Нинди картина?

— Иректәгеләр теләгән картина. Алар бит открытканы үзләре белән алып килә алалар.

— Ярар, без ул открыткадан картина язарбыз да бит, аны алучы булырмы соң?

— Анысы өчен син кайгырма, алучысын табу — минем өстә.

— Ярар, сынап карыйк, — дидем мин.

Саша абый агач эшкәртү цехыннан озынлыгы ике метрлы, биеклеге метр ярымлы рам ясап алып чыкты, аңа үзе йоклый торган җәймәне тарттырды, ак буяуга куе итеп буяп кызу мичкә сөяп куйды.

— Җәймәнне тикшерсәләр, нишләрсең, Саша абый? — дигән идем, — моны алучылар үз җәймәләрен китерерләр, — диде ул. — Гомер буе куркак булып яшәргә ярамый ич инде.

Кайнар мичкә сөяп куелган рам, андагы буяулы җәймә шакырдап кипкән иде. Мин бер атна, эштән соң, аңа «Украин төне» дигән картина ясадым. Саша абый мине гел мактап, үсендереп торды. Анда зур кара урман, сай гына су, шул урман буендагы судан үсмер малай эт белән чыгып бара, сеңлесен эт өстенә утырткан, сеңлесенең аркасыннан бер кулы белән кочаклаган. Айлы төн, эт белән балалар шәүләсе дә, урман да суда чагыла, ай исә су өстенә көмеш юл сузган.

Безгә, буяу теләнеп, чукрак рәссам килеп йөри иде. Саша абый картинаны аңа күрсәтте. Чукрак рәссам, кулын каш өстенә куеп, аннары бер кулын торбадай түгәрәкләп, картинаны озаклап карады да баш бармагын тырпайтып күрсәтте, аннары кисәк кенә кулын абзыем янына таба сузды: син ясадыңмы?

Саша абый аның белән телсезләрчә сөйләшә белә иде, кулларын бутап, нидер әйткәч һәм минем якка уң кулының бармагын сузып күрсәткәч, чукрак рәссам озак кына баш селкеп торды, аннары мине килеп кочаклады, бур-бур килеп, үз телендә нидер мыгырданды, кулы белән артын сөрткәндәй итте дә, ике кулын аркылы куйды.

— Күрән төсне артык кулланмасын, ул картинаның төсен ала,— ди, болай үзеңне бик мактады, ул теләсә кемне кочакламый.

Чукрак рәссам үзенә кирәкле буяуларны алып китеп баргач, буячылар цехы остасы Саша абый аның фаҗигале язмышын сөйләде миңа. Кузьма Ксенофонтович бик талантлы рәссам булган. 1936 елны, СССР Югары Советына сайлаулар үткәргән чакта аңа кызыл почмакны бизәргә кушканнар. Хәтеремдә, кызыл почмакны ул елларны «Сталин почмагы» дип йөртәләр иде. Моның талантлы булуыннан көнләшкән Пенза рәссамнары аның өстеннән шикаять язганнар.

— Нәрсә дип?

— Сталин почмагына печ итте, дип.

Кузьма Ксенофонтовичны кулга алганнар. Гаебен таныту өчен бик каты кыйнаганнар, колагын төйгәннәр, шуннан ул чукрак калган. Аның бездән китүенә әле бер ел гына. Туган-үскән якларына кайтмады инде, Березовкада төпләнеп калды. Оригиналь картиналар язмый инде хәзер, колония җитәкчеләре сораса, бәйрәм плакатлары яза, үсмерләр бүлмәләренә зур рәссамнардан күчереп, картиналар да язгалый.

— Нәрсә белән тамак туйдыра соң?

— Нәрсә белән тамак туйдырганын хода белсен, безнең токарный цехта агачтан кырып тәлинкәләр ясата, бездән буяу теләнеп ала, шул тәлинкәләргә табигать күренешләрен язып, Красноярскига илтеп сата. Сата да эчеп бетерә, аннары өстендәге костюмын — колония җитәкчеләре алып биргән костюмнарын сатып эчә, ахыр килеп, Березовкага тагын йолкыш хәлендә кайтып керә.

Мин аның ул гамәлләрен бик яхшы аңладым. Кузьма-рәссамның иң бирелеп эшли торган ун елы төрмәләрдә черегән, аннары аны мондагы колониягә җибәргәннәр, ул япа-ялгызы, табигать мул итеп биргән таланты белән, әйе, әйе, япа ялгызы утырып калган. Аның талантына сокланганнар әсирләр, колония җитәкчеләре аны кызганганнар, ач-ялангач итмәгәннәр, ләкин тоткын әсирнең дөньядан гайрәте чиккән — яшәвенең мәгънәсе калмаган. Дядя Саша аңа мин ясаган «Украин төне»н күрсәткәннән соң, Кузьма Ксенофонтовичның минем белән сөйләшәсе килгән. Моны миңа Саша абый аңлатып бирде. Аның минем белән сөйләшәсе килүен мин, әлбәттә, рәсем сәнгате турында сөйләшү дип аңладым, һәм ул нәкъ шулай булып чыкты да.

Мин, кайчан да булса колониядән котылып чыксам дип, истәлеккә Себер урманнарын ясый башлаган идем. Безне колониянең бәрәңге басуына конвой белән бәрәңге чүпләргә алып чыга торганнар иде. Себернең күкрәп торган тайгасын — күбесенчә ылыслы урманнарын мин шунда күреп кайткан идем.

Саша абый мине һәм чукрак рәссамны мин качып картина ясый торган бәләкәй бүлмәгә кертеп бикләде.

Кузьма Ксенофонтовичның күзе 40х40 сантиметр зурлыгындагы картинага төште:

— О-о-о! — диде ул, үз телендә ниләрдер сөйләнде. Өстенә кигән телогрейкасын салып ыргытты, җиңнәрен сызганды, мин палитра итеп тоткан фанер кисәгенә әллә ничә төрле буяуны салып, аларны болгатып, төрле-төрле кисть-пумалалар белән урманны ясарга кереште. Минем урман артык яшел икән, табигатьтә безнең күзгә шулай күренсә дә, сәнгатьтә ул алай була алмый икән, чукрак рәссамның яшел буяуга көрәнне, караны, кызылны, тагын яшелне, зәңгәрне кушуыннан ук мин буяуның чие була, бер-берсенә кушып, үзеңә кирәкле төсне ясаганы була икәнне аңладым. Аннары, бүлмә кечкенә булса да, ул артка чигенеп, якын ук килеп, үзе салган буяуны сынап-тикшереп карады. Минем кар ап-ак иде. Ул аңа зәңгәрсу йөгертте, кояш төшкән урыннарын гына җете ак итеп калдырды. Карның ак икәнен аңлау өчен шул җитә иде. Ул ярты сәгать пумалалар белән кул йөгерткәч, зур бүлмәгә, буяучылар цехына чыкты. Баксаң, ул язу яза белә икән, дядя Сашадан кәгазь-карандаш сорап алып, эре хәрефләр белән язды:

«Александр Николаевич, мин синең яшь художнигыңа килгән саен дәрес бирә алам, ул тиз төшенә үзенә кирәген, син миңа аның өчен буяу бирерсең».

Саша абый аның язуын укыгач, риза икәнне белдереп, баш какты һәм алар озаклап кул кысыштылар. Шул чагында чукрак рәссамның чаларган йон баскан таза, бик таза беләкләре минем хәтеремә мәңгегә сеңеп калды.

## Карцер

Саша абый минем шкафлар буявымнан да, шахмат фигураларын һәм шахмат тактасын шомартуымнан да канәгать иде.

«Мастер булу өчен, беренче нәүбәттә, үз эшеңә намус белән карарга кирәк. Килде-китте генә эш бирәүнең дә күңеленә ошамый.»

Мин кече яшьтән үк үзем өчен кагыйдә итеп алган — эшләгән эшемне җиренә җиткереп үтәү кагыйдәсен беркайчан да бозмадым. Ә бу Саша абыйның күңеленә хуш килә иде. Тиздән үзенең срогы тулачагын, үзе урынына мине мастер итеп калдырачагын ул миңа, кышкы озын кичләрдә, мичкә ягып, чатырдап янган пүләннәрне карап утырганда сөйли иде.

Мин ясый торган «Украина төне» бик тә кирәкле товар булып чыкты. Безнең производство зонасында пожарник булып эшләүче Ленинград хатыны күрү белән аңа кызыкты, вышка башында торган сакчылар (әсирләр телендә йөргәнчә әйтсәм — «попкалар») аркылы ireккә озатты һәм шул ук сакчылар аркылы безгә бер пот бәрәңге, ярты кило ак май китереп бирде. Менә кайчан буяучылар цехында бәйрәм булды!

Бәрәңгене пешерергә ашыкмадык.

Көн саен, гадәттәгечә, әсирләрне санап-барлап чыккач та әле бәрәңгене әрчи башларга тотынмадык, санау-барлау кабат булмасмы дип көттек. Андый хәл кабатланмады.

Кышкы кичтә сәгать сигезләрдән соң инде кап-караңгы була. Менә шунда гына без бәрәңгене әрчергә керештек. Андый-мондый берәрсе килеп керсә дип, үзебезнең янга буш мичкәне куйдык. Янәсе, тиз генә каплыйбыз да буяу мичкәләре янына илтеп куябыз. Бәхетебездер, янгынчылар да, төнге кизүләр дә күренмәде. Ут кебек кайнар плитәдә без кәстрүлдә бәрәңгене пешереп алдык, суын түгеп, агач кашык белән аны төйдек — боламык ясадык, аңа, ирекtә чактагыча, ак май салдык. Кичкә дип бүлеп калдырган ипиләребезне ашамаган идек, калай савытларга бәрәңге боламыгын тигез итеп бүлеп, ашарга утырдык. Бу инде сиңа колония баландасы түгел. Бәрәңге, майлы боламык — шул хәтле дә тәмле иде ки, андый да тәмле бәрәңгене минем беркайчан да ашаганым булмады.

Саша абый, соңгы кашык бәрәңгесен ашап бетереп, кашыгын ялап куйгач, әйтте:

— Рәхмәт сиңа, Гриша, мин, ниһаять, үземне иректә итеп сиздем,— диде.

Кыш чыкканчы без алтымы-җидеме «Украин төне»н ясадык бугай. Ленинград хатыны безнең арадашчыбыз булды, ул картина язар өчен җәймә алып килә, картинаны таякка төреп, вышка сакчысына илтеп бирә, иртәгесе төнне безгә йә бәрәңге, йә атланмай, йә тәмәке китерә. Бер картина ун стакан тәмәке тора иде. Ә тәмәке тартучылар аның бер шырпы тартмасын 400 грамм ипигә алмашып алалар иде. Без тәмәкене ипигә алмашу кебек нәрсәне белмәдек, чөнки Саша абый ел буе тәмәке өзеклегеннән тилмергән кеше, паровоз кебек пышкыта иде төтенне. Өчиледә бригадир чакта мин да тарткалый идем тәмәкене, мине тәмәке белән Салих абзый тәэмин итеп тора иде. Дядя Сашадан күрә колониядә инде мин тәмәкене ныгытып тарта башладым.

Ямьле май аенда, 1944 елның язында, Александр Николаевичны коткардылар. Ул мине кысып кочаклады, урысчалатып, өч мәртәбә үпте:

— Бирешмә, Гриша! Синең киләчәгең якты булачак,— диде.— Инде саубуллашыйк, менә сиңа минем адрес, хат язарсың, яме.

Тәки мин аңа хат язмадым, адресын каядыр, бер дә югалмый торган җиргә тыгып куйдым да югалттым. Эзләп-эзләп та таба алмадым. Әмма минем белән аның иң якты истәлеге торып калды, ул мине үзе урынына мастер итеп калдырды.

Ул киткәч тә мине конторга чакырып алдылар, хезмәт инженеры, хәрби дәрәҗәсе буенча капитан:

— Гражданин Ахунов, буяучылар цехында бүгеннән башлап сез мастер буласыз,— диде.

— Мин ул эшне булдыра алырмынмы соң?

— Булдырырсыз, сезне ул эшкә Александр Николаевич үзе тәкъдим итте, шуны ук тәрбия эшләре башлыгы Николаенко раслады.

Әйе, мин буяучылар цехында оста булып эшләдем. Зарланмыйм, минем кул астымда эшләгән егерме үсмер мине тыңлады, аяк чалып маташмады. Аларның үз бурычларын төгәл үтәүләрендә, ихтимал, минем дә катнашым булгандыр, ник дисәң, мин аларга ипине рекордлы паек итеп язып бардым, алар көнгә бер кило да ике йөз грамм алалар иде. Өстәвенә мин аларга «Украина төне» картинасын язган өчен алган тәмәкедән дә өлеш чыгара идем.

Шулай да әлеге тыныч-дәгъвасыз узган көннәр борчусыз булды дип әйтә алмыйм. Ни генә димә — Саша абый белән узган көннәр күңеллерәк тә, мәгънәлерәк тә иде. Дядя Сашадан соң да мин картиналар язып, ашарга таптым, тик, күрәсең, аңардагы гамь, аңардагы төгәллек миңа җитеп бетмәгән. Әгәр мин көндезләрен бәләкәй бүлмәгә качып, картина язарга керешсәм, Саша абый урамга берәр малайны каравылга куя, ул малай түрә-кара килгәнне күрсә, шундук: «Атанда!» яки «Полундра!» дип ишектән кычкыра, буяучылар цехы шундук «сугышчан әзерлеккә» килә иде: барлык малайлар буяу буярга тотыналар, ә мин, ешертен бүлмәдән чыгып, алар буяган шкафларны карап йөри башлый идем.

Үсмерләр колониясе тормышындагы бер кагыйдәне әйтергә онытып торам икән: мондагылар буяу цехында алты сәгать эшли, дүрт сәгать укыйлар иде. Уку җиденчене тәмамламаганнар өчен мәҗбүри иде. Мин, җиденчене генә түгел, тугызынчыны тәмамлый язган тоткын, укудан азат идем, аның каравы мине шул дүрт сәгатьтә агач эшкәртү цехына чакырып алалар, анда без, укудан азат ителгән берничә үсмер, снаряд ящиклары ясый идек. Хәзер дә уйлап куям, СССР дигән бөек державаның ерак бер Себер җирендә, үсмерләр колониясендә, тыныч көннәр белән сугыш вакыты бергә үрелгән булган икән. Бер яктан, балалар бакчалары өчен уенчык ясаталар, аны матур итеп рәсемнәр белән бизәтәләр, гаилә өчен кирәкле мебель әзерлиләр һәм бер үк вакытта снаряд ящиклары да

ясыйлар, колониядәге өлкәннәр нәкъ әнә шул эшкә җигеләләр. Монда снаряд ящигы гына ясап калмыйлар, фронт өчен кирәкле агач материалын да эшелон-эшелон итеп җибәрәләр иде.

Саша абый котылып китеп баргач, борчулар булуы турында яза башлаган идем. Шулай бер көнне мин, үсмерләр укырга китеп баргач, «Украина төне»н төшерергә утырдым. Гөнаһ шомлыгы, ишекне бикләргә онытканмын, өстәвенә бит әле иркенләп цех бүлмәсендә эшләп утырам.

Колония башлыгы килеп кермәсенме!

Бик усал кеше иде ул. Күзләре зур, тасраеп тора, кул астында булган үсмерләргә акырып кына сала иде. Бу минем картинаны бакты да, иренен бөрештереп, башын ия төшеп, чекрәеп карап тора.

— Кем ясады моны? — диде бу, тураеп басып.

Колония начальнигы янында үземнең төшеп калган түгел икәнемне күрсәтер өчен булса кирәк:

— Мин,— дидем кукыраеп.

Мактар инде бу, дип көттем. Кая ул мактау! Нәкъ миннән сорау алган Бикташев кебек, әтәчләнеп кунды бит миңа.

— Материал каян алдың? Молчать! Нинди өйдән алып килгән җәймә булсын ди ул! Колония мөлкәтен әрәм-шәрәм итеп ятасыңмы? Молчать! Нинди истәлек, ди ул? Тагын өстеңә яңа статья алырга телисеңме? Без анысын гына булдырырбыз! Фамилияң, әһә, Ахуновмы? Менә нәрсә, гражданин Ахунов, бу картинаңны хәзер үк клубка илтеп бир. Аңладыңмы? — Ул кырт борылып чыгып китте, чыккан чакта тәбәнәк ишеккә башын бәрде, ата-анасы белән җиде катлап сүгенде, мин аның безнең цех урнашкан барак буендагы агач тротуардан озын буе белән сузылып, тиз-тиз атлап киткәнен күреп калдым.

Озак та тормый клубтан тотлыгып сөйләшә торган бер тоткын килде. Әллә ничә ямаулы дәү кирза итеге белән ишектән килеп керүгә бусага янында туктап:

— С-с-сезме ул Ахунов? — диде.

— Сез кайдан? — дип сорадым.

— К-к-клубтан...

— Картина кирәкме? Картина юк. Мин аны утка яктым,— дидем.

Әлеге ертык киемле, тотлыгып сөйләшүче, ләм-мим бер сүз дәшмәстән, борылды да чыгып китте.

Озак та тормый, мин картинамны стена буенда тезелеп торган шкафлар артына яшерергә генә өлгердем, кораллы ике сакчы килеп, мине алып та киттеләр.

— Кая алып барасыз мине? — дип сорадым.

— Сөйләшмәскә! — диде конвойларның берсе, минем аркага мылтык түтәсе белән төртеп.— Баргач белерсең. Анда синең телеңне бик тиз кыскартырлар!

Мине вахта аркылы зонаның теге ягына алып чыгып, тәрбия начальнигы урнашкан бинага алып керделәр, мине үз иткән Иван Михайлович янына алып керәләр икән дип торсам, аның кабинеты яныннан уздырып, икенче катка алып менеп киттеләр, ишекне каерып ачып, конвоирлар мине тар гына бер бүлмәгә китереп керттеләр. Ишек төбендә үк әле мин акырып җибәргән тавыш ишеткән идем, кабинетка килеп кергәч, тавышның иясен дә күрдем.

Терсәк тиңентен кара резин перчатка кигән колония начальнигы һәм шундый ук перчатка киеп алган режим начальнигы чәчләре тузгыган, өстендәге киеме — ямаулы күлмәге ертылган бер тоткынны кыйныйлар иде. Мине бирегә алып килгән сакчылар, минем ике ягыма бастылар да ишек төбендә туктап калдылар. Резин перчаткалы ике башлык, колония түрәләре, безнең якка борылып та карамастан, тоткынны кыйнауларын дәвам иттерделәр. Мин шул чагында адәм балаларының ерткычлыгына таң калдым. Мәктәптә укыганда да, педучилищеда чакта да, безнең

ил — иң гуманлы ил, бездә төрмәдә кешегә тырнак белән дә чиертмиләр, дип тукып килгәннәр иде укытучыларыбыз, ә монда, төрмәдә түгел, үсмерләр колониясендә әнә нәрсәләр кыланалар: колония башлыгы битебашы кан булган тоткынга терсәккә тикле резин перчакта кигән кулы белән салып җибәрә, тегесе ишеккә бәреләм дигәндә, режим башлыгы шундый ук перчаткалы кулы белән китереп сылый.

Мине алып килгән сакчылар кыйналган, һуштан язган тоткынны сөйрәп алып чыгып киттеләр, мине шушы ике ерткыч кулында калдырдылар. Мин инде өметемне өзеп, ни булса ул булыр дип, күземне үк йомган идем, колония башлыгының кыска, усал боерыгы ишетелде:

— Гражданин Ахунов, килегез якынрак.

Килдем.

— Утырыгыз,— диде колония начальнигы.

Утырдым.

— Картина кайда?

— Мин аны утка яктым.

Режим начальнигы, мине кыйнарга әзер булып, аяк өсте баскан иде, колониягә килгәннән бирле мине үз канаты астына алган тәрбия начальнигы Иван Михайлович килеп керде.

Ике башлык белән дә исәнләште.

— Гафу итегез, иптәшләр, тоткынны минем карамакка тапшырсагыз иде. Үтенеп сорыйм.

— Алыгыз. Сөйләшегез. Минем боерыкны үтәмәгәне өчен мин аңа ун тәүлек карцер бирәм,— диде колония башлыгы һәм, сүзне беткәнгә санап, озын буе белән сөрәеп аяк өсте басты: — Иван Михайлович, сезнең карамакка тапшырам тәртипсез егетне. Сүзегез бетү белән аны карцерга илтеп тапшырыгыз. Туктагыз, ашыкмагыз, сакчылар килсен инде.

— Миңа сакчылар кирәкми,— диде Иван Михайлович.

Ул, колония начальнигы белән режим начальнигыннан аермалы буларак, бу юлы да гражданский киемнән һәм ул кием аның ягымлы мөгамәләсенә килешеп тора иде. Мине үз кабинетына алып керде. Анда инде теге ике яшь ханым юк иде. Без икәүдән-икәү генә сөйләштек.

— Син, улым, ике начальникның тоткынны ничек кыйнаганнарын күрдеңме?

— Күрдем, фашистлар да алай кыланмыйлардыр,— дидем.

Иван Михайлович, бармагын ирененә китереп, алай сөйләшмә, дип ымлады миңа, стеналарга күрсәтте: янәсе, бередә стеналар да язып бара.

— Әсирне нигә кыйнаганнарын беләсеңме соң?

— Белмим шул.

— Аны хатын-кызлар барагыннан тотканнар. Ә хатын-кыз тоткын йөкле булса, аны срогы тулмас борын азат итәргә кирәк. Моның өчен колония башлыгы белән режим башлыгының башыннан сыйпамыйлар. Югарырак начальстводан аларның үзләренә эләгә. Башкаларга сабак булсын өчен шулай кыланалар. Сине дә шул язмыш көтә иде. Картинаң кайда? Әйт. Барыбер әйттерәләр. Но аның каравы үпкә-бавырыңны изәләр. Беркемгә дә жалу белән бара алмыйсың. Картинаң кайда?

— Шкаф артына яшердем,— дидем, әмма, телем бик кычытып торса да, аны заказ белән эшләвемне, инде ул заказчыга ни дип җавап бирәсемне әйтмәдем.

Иван Михайлович мине бик җитди кыяфәт белән карцер сакчыларына илтеп тапшырды. Ул бәләкәй генә бер бүлмә, ул бүлмәдә биек сәке-нар, сәке өстендә берни дә, хәтта салам матрас та юк иде. Сакчылар мине шул бүлмәгә китереп керттеләр дә тыштан ишекне йозак белән бикләп алдылар.

Димәк, мин шушы тар бүлмәдә, как сәкедә ун көн аунарга тиешмен. Карцерда булып чыкканнардан ишеткәнем бар иде. Бередә тәүлегенә өч йөз грамм ипи һәм өч стакан кайнаган су бирәләр икән. Мин менә

каптым дисәң дә каптым. Ә нигә миңа ишекне бикләмәскә иде, яки эчкәреге кече бүлмәгә кереп ясамаска иде картинамны? И җүләр баш, исәр баш!

Шул борчулы уйларым белән как сәкедә борсаланып яткан чакта, карцер ишеге шалтырап ачылды да усал тавыш:

— Ахунов, на выход! — дип кычкырды.

Минем үзем белән берни дә юк иде, нардан сикереп төшеп, ишеккә юнәлдем. Эчкә курку төште, перчаткалы ике башлык мине кыйнарга чакыралар, дигән уй мине ярып узды. Сакчы солдат озаклап ишекне бикләде, мине үзләре ял итә торган бүлмәгә алып кереп, алдыма елмаюлы йөз белән бер тәлинкә итле аш китереп куйды.

Шаккаттым да калдым. Туктале, бу соң провокация түгелме?

— Моны миңа кем китерде? — дип сорадым.

— Син сорама, без әйтмибез. Ашавыңны бел. Каравыл башлыгы килеп керсә, ашамый да калырсың. Әйдә, алдыңа кара да умыруыңны бел, без ишек төбендә сакта торабыз.

Ачыккан идем, кичке ашны ашамас борын мине ике түрә янына китергәннәр иде, күңелемнән генә сакчыларга рәхмәт әйтеп, ашны әлләни арада ялтыратып куйдым.

Аннары сакчыларның берсе мине бик усал чырай белән карцерга китерде, ишекне бикләр алдыннан хәтта этеп җибәрде, шалтыратып ишекне йозак белән бикләгәне ишетелде.

Мин карцерда төн кундым.

Иртәсен иртүк, әле ашарга биргәнче үк, тагын ишек ачылып, минем фамилиямне кычкырдылар.

Чыктым.

Сакчы әйтте:

— Син азат, Ахунов, — диде.

— Ничек алай, миңа бит ун тәүлек биргәннәр иде?

— Башкаларга сөйләп йөрмә, үзең генә бел: буяу цехындагы үсмерләр бунт күтәрделәр, безнең мастерны кайтармасагыз, эшләмибез, — дип хезмәт инженерына әйткәннәр.

Шушы мәхшәр вакытында да мине яклаучылар табылуга бик сөендем, тоткын үсмерләргә күңелемнән рәхмәт укыдым. Алар мине «ура» кычкырып, кул чабып каршы алдылар. Колония башлыкларының аларның бунтын чынлап кабул итүләренә бик тә күңелләре булган, күрәсең. Бу очракта тагын мин бер нәрсәне аңладым — минем аларга карата ягымлы булуым, аларга норма бүлеп биреп, нормаларын үтәгәч, тик кенә утырырга яки китап укырга рөхсәт итүем аларның күңеленә хуш килгән булса кирәк. Юкса күршедәге столярлык цехында заманында Себер җибәрелгән бер кулак мастер булып эшли, сүз тыңламаган тоткын үсмерләргә кул ягудан да тартынып тормый иде.

## Ирекклә! Ирекклә!

Дядя Сашадан соң мин буяучылар цехында бер ел чамасы эшләдем. Минем мастерлыгымны конторда яраттылар. Мине теге чакта карцердан йолып алучылар да шул конторның җитәкчеләре булган икән. Алар колония һәм режим башлыкларына үсмерләрнең бунтын әйтеп тормаганнар, ул хәлне үзләре генә белгәннәр, башлыкларга хәлнең мөшкел икәнен, буяу цехының мастерын чыгармасагыз, анда тәртипсезлек башлана, аның бит инде картинасын талап алдыгыз, үзен чыгарыгыз, зинһар, дигәннәр. Болар миңа сәгате-минуты белән түгел, берничә ай соңрак калып ишетелде.

Яз якынлаша иде — кырык бишнең язы. Колония өстендә каргалар күптән оча башлады, аннары сыерчыклар күренде. Аяк астында кар

эреде, йөрү кыенлашты. Әмма колониядә ниндидер бер җанлану сизелә, мондагы тоткыннар Җиңү килүен, фашистларның дөмегүен көтеп яшиләр иде.

Мин дә шуны көтеп яшәдем. Халык теленә «Амнистия!» дигән татлы сүз кереп урнашты. Караңгы чырайлар яктырды, сөйләшүләр зарлану рәвешендә түгел, өмет тулы сүзләр белән алышынды. Март аенда колониядән качкан өч егетне бик кызгандылар, чөнки аларны этләр белән эзләп тотып алып кайттылар, сакчыларның тибә-тибә кыйнауларын, инде эшләре судта булуын икеме, өчме көн тоташтан сөйләделәр. Аларга бит, исәр башларга, качкан өчен, унар ел өстәячәкләр, ә монда эшләр җиңүгә таба, амнистиягә таба бара.

Минем өч еллык срогымның ике елы тулып килә иде инде. Шул ике ел эчендә мин әниләргә ничә хат язып салсам да җавап ала алмадым. Фронтка җибәрүләрен сорап та җавап булмады. Шуннан соң мин Саша абый белән (ул әле котылганчы!) бу хакта киңәшеп караган идем, ул гап-гади итеп аңлатты:

— Фронтка җибәрмәүләре табигый. Монда да эшче куллар кирәк. Синең хат-үтенечеңне колониядән бер җиргә дә җибәрмәгәннәр, үз кәнсәләрендә тотып калганнар. Өйдән хат алмавыңа да гаҗәпләнмә. Син үз телеңдә — татарча язгансыңдыр хатларыңны, моннан милли телдә язылган хатлар китми, ник дисәң, ул телләрне белүче цензура юк. Урысча язып җибәрик әйдә.

Мин әйтеп тордым, Саша абый минем хатны урысча язып бирде. Ул хаклы булып чыкты. Тагын бер айдан миңа Өчиледән хат салдылар, урысча язуларын сораган идем, урысча кемгәдер яздырганнар. Җылый-җылый, сөенә-сөенә язылган хат иде ул. Әни бәгырькәем, суд булып, мине Казан ягына алып киткәч, Өчилегә кайтасы урынга Масрага китеп барган, башлары миңгерәүләнгәндер инде бәгырьнең. Шул хатны укыган чакта йөрәгемнән кан тамды. «Гомерем булып, исән-сау бу зинданнан котылсам, әниемә бер генә дә авырлык китермәс идем», — дип күңелемнән ант иттем.

Авыл хәлләрен күп итеп язганнар. Уҗымга чыгып, өйгә кайтмый калган бозауларын төнлә бүре ашап киткән. Хәзергә Гайшә апа да, Сәҗидә дә, Рамазан белән Ризуан да исән, әни авыргалап торса да, үз аягында икән әле, тормыш авыр дип зарланмаганнар, минем болай да китек күңелемне тагын да ныграк китәргә теләмәгәннәрдер инде. Тик Нурулла абыйның — безнең үги әтиебезнең генә сугыш башланганнан бирле хәбәре юклыкны әйткәннәр — әллә үлгән, әллә әсир төшкән, билгесез, дигәннәр иде.

Шушы хат минем күңелемне тәмам алгысытты. Өчиленең чишмәләре, урманнары, зират яныннан ук башланып киткән басу-кырлары, үзәкләремне өзеп, искә төште. Сугыш чыкканның беренче елында җанда кабынган беренче тойгылар, тәүге мәртәбә төне буе Рәйсә исемле Казан кызы белән сөйләшеп ятулар — барысы, барысы җанны айкап алды. Әгәр мөмкин булса, бер генә минут та тормыйча, үзебезнең кечкенә Өчилебезгә кайтып китәр идем...

Юк иде шул әле кайтулар! Җиңү көнен көтәргә кирәк иде. Ниһаять, ул көн килде. Дөньяларны яңгыратып килде!

1945 елның 9 маенда безгә ашны майлы итеп пешерделәр, безгә сакчылар усал күз белән карамады, колония башлыгы белән режим начальнигы да юашланып калган, күрәсең, законлы каракларның тиздән иреккә чыгасын, аларны кыерсытсаң, үч алырга әзерләнә башлаячакларын сизәләр иде.

Аннары, кулны күкрәккә куеп әйткәндә, колония җитәкчеләре дә кеше бит, җинаятьчеләр арасында буталып, таштай катып беткән бәгырьләре шундый зур көнне, шундый бөек бәйрәм көнне йомшарып китүе дә мөмкин.

Җиңү бәйрәменең эчкә сыймас шатлыгын тойганнан соң без амнистия турында бөек Сталинның карар чыгарганын көтеп яши башладык. Кайсы көнне чыкканын төгәл генә әйтә алмамдыр хәзер, гәзитләр актарып, искене искә төшереп утырасы килми, әллә май азагында, әллә июньдә ул Указ чыкты һәм безнең Березовка үсмерләр колониясеннән кешеләр көтүе-көтүе белән китә башлады.

Тик мине генә коткарырга ашыкмадылар.

Бер көнне баш инженер мине үз янына чакырып алды. Кердем. Урын күрсәтте. Минем тиздән котылачагымны әйтте. Аннары чамадан тыш ягымлы тавыш белән сорады:

— Алга таба ничегрәк яшәргә исәп, Ахунов?

— Котылырга кирәк бит әле,— дидем мин.

— Анысы була да була инде аның. Котылгач нишләргә исәп дип соравым?

— Котылгач, исәп бер генә — туган якларга кайту.

Баш инженер дигәнем яһүд иде, мин буяучылар цехында чакта да без аның белән гел очрашып тора идек, тоткыннар белән мин аның беркайчан да үзен өстен куеп, тегене мыскыл итеп, кимсетеп сөйләшкәнен күрмәдем. Ул үзе дә ниндидер статья белән шушы колониядә утырган, дөресен әйткәндә, мин килгәндә дә утыра иде әле, әмма ул тоткынлыкта чакта да шушы колониядә хезмәтне оештыручы баш инженер иде. Мин килеп алты айлар узгач, ул котылды, әмма каядыр читкә китмәде, шушы урынында ук эшләп калды. Безгә кешелеккә кияргә аксыл костюм биргәннәрен әйткән идем, Вадим Кириллович теге чакта да шул аксыл костюмын кер кундырмыйча киде, менә хәзер мине чакырткан чакта да аның өстендә шул костюм иде әле. Ул инде иллеләргә якынлашып килгән, кап-кара күзле, калын кара кашлы, ялтырап торган пеләш башлы кеше иде. Аның пеләше үзенә килешеп тә тора иде бугай. Ягымлы итеп сөйләшүен дә, үзеннән түбәннәрне кимсетмәвен дә мин аның акыллылыгыннан һәм укымышлы булуыннан күрә идем. Мине колониядән китәр алдыннан үзенә чакырып алган икән, бу инде юкка түгел, моның ниндидер хәйләсе бар, дип уйладым.

Вадим Кириллович пеләшен кулы белән сыпыра-сыпыра:

— Беләсезме, Ахунов, сез туган якларыгызга — Татарстанга кайтырга бик ашкынып торасыз торуын, әмма анда сезне ашкынып көтәләрме икән соң? — диде. Беркавым сүзсез торгач, өстәде: — Кулда булган кешеләрне туган җире бигүк өнәп бетерми торган була...

Мин инде аның хәйләсен сизеп алган идем, шулай да чын дөресен үз авызыннан ишетәсем килде.

— Вадим Кириллович, сез моның белән нәрсә әйтергә телисез? — дидем.— Мине монда эшләргә кал дип әйтүегез түгелдер бит?

— Акыллы кеше сез, Ахунов. Белемле икәнегез әллә кайдан күренеп тора: ярты сүздән аңлап алдыгыз. Әйе, мин нәкъ шуның өчен чакырдым да сезне. Монда калырга ниятегез юкмы? Минем шуны беләсем килде.

Мин бу юлы турыдан ярып сөйләшүне кирәк тапмадым, баш инженерга үзем сорау бирдем — кылын тартып карыйсым килде. Менә шунда инде безнең ике арада көч сынашу китте.

— Монда калу нәрсә бирә соң миңа, Вадим Кириллович?

Ләкин яһүд абзыйны буш кул белән алырлык түгел, ул миннән хәйләкәррәк һәм тәҗрибәлерәк булып чыкты.

— Без болай сөйләшик...— дип ул тагын такыр баш түбәсен ышкып торды, күзлеген салып, аны озаклап сөртте: — Сезне, Ахунов, без хәзер иректәге кеше дип сөйләшик. Бер-беребездән бер нәрсәне дә яшермик. Әйтик, сезгә колония нәрсә бирде?

— Ике ел эчендә мин буяу эшендә мастер булып җитештем.

— Менә, менә, менә! Минем сездән шуны үз телегез белән әйттерәсем килгән иде дә! Димәк, Березовкадагы үсмерләр колониясе, яшермичә әйткәндә, сезгә хезмәт тәрбиясе бирде. Шулаймы?

Әлбәттә, шулай. Мин бит аны кире какмыйм.

— Бик яхшы. Инде болай дип сөйләшик: сездә, кадерлем, нииндидер оештыру сәләте бар. Башка цехларда тәртипсезлек тулып яткан чагында, сезнең кул астында эшләгән тоткын үсмерләр бер мәртәбә дә әшәкеләнмәделәр, бер мәртәбә дә законга сыймый торган эшләр эшләмәделәр, планны гел тутырып, продукцияне югары сыйфатлы итеп тапшырдылар. Буяу цехын без эштә гел алдынгылар рәтенә куеп килдек, тоткын үсмерләргә рекордлы паек бирдек. Ә бит башлыкларга мин шуны әйтә килдем. Сез картина язганда, саксызлык күрсәтеп, карцерга эләккәч, без сезне аннан йолып алдык. Сезнең кул астында эшләгән тоткын үсмерләр дә безгә теләктәшлек күрсәтте. Болар барысы безнең һәм сезнең файдага сөйли. Әгәр инде шулай икән, кайсыдыр ки матур итеп, сез дә безнең бер үтенечкә колак салмассыз микән?

— Нинди үтенечкә?

— Үз теләгегез белән, ирекле булып, буяу цехында калмассызмы?

— Вадим Кириллович, мин бит инде иреккә чыгар көннәремне дүрт күз белән көттем. Башкалар инде көтүләре белән иреккә чыгып киттеләр, ә сез мине инде, амнистия булганнан соң, бер айдан артык колониядә тотасыз...— дидем мин ялварулы тавыш белән.

Ул минем күзләремә төбәп карады, муенын кыскан галстугын бушатты, аннары тагын да йомшаграк, җайлырак тавыш белән сүз башлады:

— Аңлыйм мин: туган якларыгызны сагынгансыздыр, туганнарыгызны. Тик сез бер нәрсәне истән чыгармагыз — сугыш бит әле бетте генә. Җимерек калаларны төзәтәсе бар, тормыш әле сезнең Идел буйларында ун елсыз да җайга салынмаячак. Себер киңлекләрендә бит яшәү рәхәтрәк булачак. Әгәр сез буяу цехының мастеры булып, ирекле рәвештә каласыз икән, мин колония башлыгы белән сөйләштем, ант итеп әйтәм, ул сезгә бер гектар җир бүлеп бирәчәк, нарат бүрәнәдән йорт җиткезәчәк, иң чибәр марҗа кызына да өйләндереп куйсак?..

Ул өздереп миңа карады, мин аның зур кара күзләрендә үз дәлилләренең көчлелегенә, мине җиңә алачагына ышану күрдем. Ул өстәл яныннан торып басты:

— Йә, нишлибез, Ахунов? — диде.

— Мин Татарстанга кайтам, минем планнарым башка,— дидем.

Аның йөзе үзгәрде, кырысланмады, агарынып китте:

— Ярый, алай булгач, минем сүз бетте, сезгә кайтырга мөмкин,— диде. Кул биреп саубуллашмады, өстәл янына утырып, зур бер папка алды, мин чыгып китмәс борын ук шул кәгазьләренә күмелде. Аның бу гамәленнән аңладым: минем эшләр алга таба көйле булмаячак.

Баш инженер белән сөйләшү июль урталарында булган иде, июль дә узды, август та узып китте, колониядән инде амнистиягә эләккәннәр китеп беттеләр диярлек, миңа әле һаман хәбәр китермиләр. Ә бит билгесезлектән дә авыр нәрсә юк: ике ел буена зинданда утыру ул хәтле үк авыр булмаган иде, соңгы айлар җанны бик борчыды, күңелгә хәтта: әллә мин амнистиягә эләкмәдемме икән, дигән хәвефле уйлар да үрмәләп өлгерде.

Сентябрьгә кердек. Себер якларына чынлап торып көз килде: агачлар саргаеп, яфракларын койды, урманнар көннән-көн ялангачлана барды, мин аларны безне бәрәңге чүпләргә конвой белән алып чыккан чакта күреп кайттым. Биегәеп киткән Себер күгендә кошлар болыт-болыт булып, ярты күкне иңләп очалар иде.

17 сентябрь көнне мин төшемдә әнине күреп уяндым. Ул башын түбән иеп, беркемгә дә карамыйча һәм селкенмичә, җиргә төбәлеп утыра иде.

Шул көнне төштән соң мине хезмәт зонасындагы конторга чакырдылар. Баш инженер Вадим Кириллович минем белән коры гына исәнләште:

— Ахунов, сезнең фикерегез үзгәрмәдеме? — диде.

— Юк,— дидем. Кистереп әйттем.

— Иртәгә сезне ирекә чыгарырлар, кешелеккә кияргә дигән киемнәрегезне колония башлыгы бирмәскә кушты, димәк, шушы майлы киемнәрегез белән юлга чыгарга туры килә...

Мин аңа тик бер генә сүз әйтә алдым:

— Рәхмәт.

Безне якындагы стансага тикле озатып куйдылар. Әллә Ачинск, әллә Абакан — хәзер исемнән чыккан инде. Картадан карап торасым килми, йөрәгем бозылыр дип куркам.

Колония исталеге итеп столярлык цехында чемодан ясаткан идем, аны имән төсенә кертеп, үзем бик тырышып буяган идем. Шул чемоданыма юлга дип бирелгән өч кирпеч ипине, утын агачы чаклы бер колбасаны, икеме-өчме йөз грамм шикәрне салдым. Поездга дип акча бирделәр. Башта кепка, өстә майланып беткән чалбар, майланып беткән гимнастерка, төрмәчеләр кия торган бушлат...

Безне озата баручы стансага хәтле китерде дә кайтып китте. Билетмазар алучы булмады безгә. Үзем исталеккә дип хәстәрләгән чемоданны баш астына салып йокладым. Ә вокзал идәнендә ул төнне йоклаучылар күп иде. Йокладым дигәч тә әлләни йоклап булмады, йокыга куерып кына китәм дә сискәнеп уянам, инде йоклап киттем дигәндә тирә-юньдә купкан тавышлар уятты. Вокзалны актарып караклар йөри икән, шуңа тавыш куба икән.

Чират торып билет алырлык түгел, инде өч-дүрт көн билет ала алмыйча ятучылар бар икән.

Сары чәчле, сипкел битле яшь кенә бер егет сорады:

— Кая кайтасың, юлдаш?

— Казанга, — дидем.

Аның сипкелле бите елмаюдан җәелде:

— Ә мин Чистайга!

— Димәк, бер якка! Димәк, без якташлар — Татарстаннан. Тик ничек кайтырга? Монда бит билет ала алмыйча атна буе интегүчеләр бар икән. Ни дип әйтергә дә аптыраган.

— Аптырап торасы юк. Поезд баскычына утырасы да китәсе.

— Ә аннан йокыга китеп егылып төшсәң?

— Шуңа күрә бер баскычка икәү утырырга кирәк. Берең йоклаганда, берең уяу кала. Киттекме икәү?

— Китәрбез. Исемең кем синең?

— Коля. Ә синең?

— Минем Гриша.

Бәхетебез икән, Свердловскийга баручы поезд кузгалырга тора. Берберебезне ярты сүздән аңлап, Чистай малае Коля белән кузгалырга торган поездга йөгердек.

Икебез бер баскычка сикереп менеп утыруга, поезд кузгалып та китте. Кызулый башлауга салкын сентябрь җиле битләргә китереп бәрде. Төрмә бушлатының кул яссылыгы юка якасын күтәргән булдык. Кепкаларны басып кидек. Минем каешланып каткан гимнастерка арасыннан җил аркага үрмәли, суык тәннәрне кымырҗыта — түзсәң түз, түзмәсәң — поезд барган уңайга сикереп төшеп кал.

Көне буе поезд туктаган стансаларда җиргә төшеп, йөгерә-йөгерә, җылынып киләбез. Поезд озакка туктаса, башкасына сикереп утырабыз. Вагоннарны озата баручылар барында, поезд туктап торган чакларда утырмыйбыз, читтәрәк йөрергә тырышабыз: янәсе, маскировка! Болар барысы безнең уйдырмаларыбыз гына, безнең төрмә бушлатларын вагоннарны озата баручы хатын-кызлар, сугышлардан яраланып кайтып, тимер юлларга эшкә урнашкан ир-атлар әллә кайчан күреп өлгерде инде. Рәхмәт төшкерләре, алар безне күрмәмешкә салыналар, вагон баскычларыннан кумыйлар. Сугыштан соң адәм баласы әллә йомшаграк күңелле булып калган инде? Бик сирәкләре генә, тупаслыклары битләренә язылганнары гына куып җибәрә, йә баскычтан тартып төшерә. Көне буе

салкын җил сулап кайтып хәлдән тайган идек инде, баскычта килеш бер-ике мәртәбә йокыга куерган чаклар да булды, алай да үз вакытында уянып, баскыч тоткасына ныграк ябышып, мәтәлеп төшми калдык.

Алга таба да гомерне упкынга ташларга җөрьәт итмәдек, ике вагон арасындагы буферга кереп өлгердек, вагонны озата баручы күрми калды.

Күрми калды калуын, әмма буфер дигәннәре миңа бәхет китермәде, поезд туктаган чакта, вагоннар бер-берсенә бәрелгән чакта, минем колония истәлеге дип үзем ясап алып чыккан чемодан ике буфер арасына кысылып ватылды, капкачы каерылып чыкты, аны бәйләргә хәзер бау да юк, анда тутырган азык-төлек тә юлда коелып калачак иде. Ике кирпеч ипине мин кулыма алдым, колония бушлатының кесәсен тишеп, колбасаны шунда тутырдым, шикәрне Коляның капчыгына салдык, ә чемоданны юл уңаенда ташлап калдырдык.

Йөрәгемне умырып ташлагандай булды ул чемоданны ташлап калдыру! Ике ел буена зинданда утыруның истәлеге, шаһиты иде бит.

Кайсыдыр бер стансада җиргә төштек, теге ике кирпеч ипине сөйрәп йөреп булмый иде, аны саттык, ике йөз сум акча бирделәр — тагын берәр стансада шул акчага ипи сатып алырбыз дип уйладык.

Чемодан чаклы чемоданны чытырдатып ваткан буферга кабат керәсе килмәде, төнгелеккә вагон төбәсенә үрмәләдек. Без икәү идек, безнең белән тагын кемдер үрмәләде, без чалбар каешларыбызны чишеп алып, вагон түбәсендәге торбага үзебезне бәйләп яттык. Өченче юлдашыбыз, безнең белән танышырга да, хәвеф-хәтәрдән сакланырга да теләмәде. Ул вагон түбәсендә бер-ике сәгать аунап йоклагач, уянды. Башта торып утырды, аннары аягүрә басып бара башлады. Поезд барган уңайга төнге сентябрь җиле җилекләргә үтеп керә, аркаларны чымырдата иде. Мин, исән-сау өйгә кайтып җитә алсам, өч көн мич башыннан төшми йоклар идем, дигән фикергә килгән идем инде. Ә безнең өченче юлдашыбыз, төрмә бушлатын чишеп җибәреп, битен ачы җилгә каршы куеп кайта. Хәер, аңа алай озак кайтырга туры килмәде. Паровоз бик озын итеп кычкыртты, мөгаен, стансага җитә торгандыр. Юк икән, чуен юл күперен узасыбыз бар икән, паровоз кычкыртудан туктауга башыбызны күтәреп карасак, өченче юлдашыбыз юк, ул күпер араталарына бәрелеп түбәнгә очкан... И гомерләр, и сагышлар, и адәм баласының язмышлары. Аны өендә көтә торганнардыр, ул, бәлки, мине коткардылар, көтегез, дип телеграмм суккандыр. Инде менә ул юк, аны юллардан көтә-көтә әнисенең күзләре талыр инде...

Коля инде йоклап киткән иде, мин бүтән йоклый алмадым, поезд вагоны түбәсеннән җиргә очып һәлак булган өченче юлдашыбызны уйлап яттым. Ничәмә-ничә ел зиндан газапларына түзгәннән соң, туганнары белән күрешер көннәр җиткәндә генә шулай мәгънәсез үлемгә дучар бул инде, ә?..

Свердловскига без ике тәүлек дигәндә иртән кайтып җиттек. Чамадан тыш туңган идек, тәнне калтырау биләп алган иде, җылынырга исәпләп, вагон түбәсеннән җиргә төштек. Поезд хәзер үк кузгалырга итенсә дә, аңа утырырга ниятебез юк, базарга барып, җылы бәрәңге ашап, чәй эчеп аласыбыз килә иде.

Тик аларның берсе дә безгә насыйп булмады.

Иң әүвәл безгә ачкыч сатучы очрады. Бармак юанлыгы зур ачкычны кулга тотып карау белән, дулкынланып:

— Бу нәрсә ачкычы? — дип сорадым.

Күңелем көтелмәгән бер нәрсә буласын сизенә иде, шуңа сорадым.

— Вагон ачкычы, — диде сатучы.

Мин, бәхәсләшеп-нитеп тормастан, дөрес дулкынланган булуыма куанып, ачкычны бер йөз илле сумга сатып алдым.

Кайнар бәрәңге саткан җирне эзләп барышлый, отышлы уйнап ятучылар янына тукталдык. Каешны, бил каешын, чорнап куялар, әгәр син шуның уртасына эләксәң, берәр нәрсә отасың. Безнең күз алдында бер малай йөз сум акча отты, бер малай сәгать отып алды.

Күңелдә тагын дулкынлану уянды: мин бит Өчилегә акчалы да, сәгатьле дә булып кайта алам. Бил каешын ничек чорнап куйганнарын, аның уртасы кайда икәнлеген үз күзем белән күрдем, йөз сумга уйнарга килештек. Мин куйган карандаш каеш уртасында булып чыкмады, каештан читтә калды. Җан ачытты, икенче юлы отармын дип уйладым, анысы да каештан читтә икәне беленде. Мин инде ярсыган идем, күзгә ак-кара күренми иде, менә отам, менә отам ди-ди уйный торгач, минем акча бетте, өстәвенә — гөнаһ шомлыгы — Коляның да акчасын сорап алып оттырып бетердем.

Без, әле генә колониядән котылган ике егет, авыл гадәте гомерлеккә сеңеп калган ышану аркасында бер тиен акчасыз торып калдык.

Җанны үкенү биләп алды. Ике елдан артык колония тормышы да акыл кертмәгән икән мин исәргә!

Ач килеш, кайнар бәрәңге түгел, кайнар чәй дә эчмәгән килеш, тимер юл вокзалына әйләнеп кайттык.

Мәскәүгә таба баручы поезд тимер юлда тора, аның инде ишекләре бикләнгән иде. Без Коля белән, бер-беребезгә күтәрелеп тә карамыйча, вагон баскычына чүмәштек. Акча оттырып бетерү кайгысыннан икебез дә сүзсез идек. «Исәр баш, ахмак, акыл кермәсә дә кермәс икән...» — дигән үкенү җанны талый иде. Кинәт шунда искә төште: туктале, безнең кесәдә вагон ачкычы бар бит, бәлки, анысын алдап сатмаганнардыр...

Коляга аны-моны әйтмичә генә чалбар кесәсеннән ачкычны тартып чыгардым. Поезд инде ашкынып чаба, Коля күзләрен йомып йокымсырап утыра иде.

Култыксага тотынып, торып бастым, вагон ишегенең ачкыч тишеген эзләп таптым, ачкычны тыгып борсам, ишек ачылды да китте. Коляны якасыннан эләктереп торгыздым да вагон тамбурына сөйрәдем, аннары ишекне ачкыч белән бикләп куйдым. Менә инде без тамбурда, җилсез урында кайтабыз. Коля минем кулны эзләп табып, сүзсез генә кысты: «Егет икәнсең!» — дип әйтүедер инде.

Берәр сәгать без тамбурда сүзсез генә, стенага сөялгән килеш кайттык. Аннары ишек ачылды, ике солдат чыгып, тәмәке тарта башладылар. Шунда безгә күзләре төште:

— Сез каян? Ничек монда эләктегез?

Без, Коля белән мин, алмаш-тилмәш, үзебезнең кем икәнлегебезне, бирегә ничек эләгүебезне сөйләп бирдек.

Солдатларның яшьрәге, күзен кыса төшеп, безгә сынап карап торды, куе җирән сакал басканы безне үзе артыннан барырга чакырды. Аның артыннан без вагонның эченә кердек. Плацкарт вагон икән, нарларда солдатлар йоклап яталар икән.

Сакаллы солдат безгә югарыдагы шүрлекне күрсәтте, шунда менеп бөгәрләнегез, диде.

Без шунда менеп бөгәрләндек.

Инде йоклап китә язган идек, сакаллы солдат, минем ботинкалы аягымнан эләктереп:

— Сезнең ашыйсыгыз киләме? — дип сорады.

Мин аптырап калдым, ни дип әйтергә дә белмәдем. Ул арада минем арттан Коляның башы сузылды:

— Килә! Килә! — диде ул, бер үк сүзне кабатлап.

Сакаллы солдат безгә калын итеп кискән берәр сынык ипи, ярты банка тушенка ите бирде. Без шуны Коля белән икәү ялт итеп куйдык та, язмышыбыздан канәгать булып, йоклап киттек. Күрәсең, без күне буе йоклаганбыз, мин уянганда, безнең поезд Кукмара аша уза иде инде. Туган якның исемен ишетү җанга рәхәт сулыш өрде.

Арча стансасына җиткәнне мин сабырсызланып көтә башладым. Минем, колониядән котылып, иреккә чыккан чакта бер генә теләгем бар иде: Арчага төнлә кайтып төшсәк иде, минем майлы буяуга каткан киемнәремне туган ягым кешеләре күрмәсә иде.

Арча стансасына поезд төнге сәгать уникеләрдә килеп туктады. Дөньяны тулы ай яктырткан иде. Стансада көн кебек якты иде. Вокзал бинасын күрү җанны айкап алды. Мин киткәннән бирле монда бернәрсә дә үзгәрмәгән, су башнясы да, вокзал бинасы өстенә куелган «АРСК» дигән вывеска да, такталары акшарланган туалет-бәдрәф тә гел үз урынында иде.

Минем белән саубуллашырга дип тамбурга чыккан Коляга мин гади генә итеп:

— Без бүген минем авылга кайтыйк. Берәр көн ял итеп, мунчалар кереп китәрсең,— дидем.

Ул шундук риза булды.

Арча белән Өчиле арасы унике чакрым. Сугышка кадәр дә, сугыш вакытында да без ул араны җәяүләп өч сәгать уза торган идек. Бу юлы әллә нәрсә булды — Арчадан Өчилегә кайтып җиткәнебезне сизми дә калдым: аяк тигән җиргә тиде, тимәгән җиргә юк. Хикмәти хода, Арча стансасыннан чыккач, Күпербашка тикле сузылган Көтернәс болыннарын узып бетерә алмыйча җаннар чыга яза иде, аннары Казиле, аның бер чакрымга сузылган озын урамы, Казиленнән соң Казанбашка тикле җәелеп яткан болыннар, әтием күмелгән коммунистлар зираты, Казанбашның борма-борма урамнары, Казанбашны узып киткәч, хәлсезләнеп калулар, тегермән буасы, Казан суы, Көтек авылы, ул авылга кермичә, туры юлдан китсәң, Аракы елгасы, Көтек елгасы, Каенлык елгасы — зарыктыргыч дәрәҗәдәге шушы озын юлның бер генә бормасы да, бер генә авылы да, чокыр-чакырлары да күзгә ташланмады, туган йортыбызны, апа-сеңел-энекәшләрне күрү шатлыгы, бигрәк тә газиз әниемне өзелеп сагыну барысын оныттырды — Өчилегә өч сәгать урынына сәгать ярымда кайтып җиттек.

Өчиледә дә су кебек якты ай балкый иде.

Өчиле йортлары, тегермән, тау астындагы ат абзарлары бер генә мизгелгә, барысы бергә кушылып, тоташ бер манзара булып күз алдыннан уздылар шикелле — хәтергә сеңеп калмадылар. Хәтердә калганы шул — безнең урыс капка бикләнмәгән иде, бәләкәй йортның ике тәрәзәсендә ут бар иде, өйалды ишеге дә, өй ишеге дә бикләнмәгән булып чыкты.

«Төн урталары узды бит инде, ник бикләмәгәннәр?» — дигән уй күңелдән узып китте.

Караңгы өйалдыннан узгач, бәләкәй өебезнең ишеген тартып ачтым: кучкарда торган җиделе лампа һәм бәләкәй өйнең сәкесен тутырып йоклап яткан кешеләр күзгә ташланды. Хәер, әни йокламаган икән, ул өтәләнеп:

— Ястына төшә күрмәгез, ястына! — дип дәште.

Мин яртылаш бәрәңге белән тулган өй астына күз салдым, татарча белмәүче Чистай егете, дөбердәп, өй астына төшеп тә китте. Аннан аның:

— Гриша, дай руку! — дигән тавышы ишетелде.

Мин аны тартып чыгардым.

Никтер әниләрне сынап карыйсым килде:

— Можно у вас проночевать? — дидем, урысчалатып.

Әни хәвефләнеп Гайшә апаны уятты:

— Кызым, кызым, тор әле, нинди-дер урыслар керде.

Куркуга калган әнине алга таба да азаплыйсым килмәде:

— Әни, танымыйсыңмы әллә, мин бит Гарифҗан? — дидем.

Менә шунда инде өйдә мәхшәр купты. Кинәт барысы берьюлы уяндылар, буталдылар, бер-берсенә ниләрдер әйттеләр, әниебез Бибинур, юрганына буталып, аннан чыга алмый азапланды. Бу мәхшәргә шаккатып ишек төбендә өнсез басып торган Коляның ялгызын калдырып, мин әни янына атылдым, аны кочакладым, ул җылый, бите буйлап кайнар күз яшьләре ага иде...

Поездлан поездга сикереп, битләрне чеметтереп искән төнге Себер җилләренең җелекләргә үткән мәхшәрен тойган чагымда, өйгә кайтып житсәм, өч көн, өч төн баш күтәрми йоклар идем, дип күңелемә беркеткән булсам да, туган йортка кайтып керү белән йокы качты. Әни белән төне буе сөйләшеп чыктык.

Безнең йорттагы дулкынлануларны җаны белән сизгән Коля да иртән мин урамга чыккан чакта ук ишегалдына чыкты. Ул әле 18 яшен яңарак кына тутырган, иягенә бала йон гына чыккан япь-яшь егет булса да, ничектер бүген үз яшеннән олырак күренә, аның кыяфәте моңсу иде.

— Николай, ни булды сиңа? — дидем мин, аңа бу юлы никтер Коля дип дәшергә теләмичә.— Әллә син безнекеләр тиешенчә каршы алмадылар дип рәнҗисеңме? Торып тор, дәшмә, әллә мин синең акчаңны оттырып бетергәнгә хәтерең калдымы?

Коляның мин чиста күңелле икәнен поездларда кайтканда ук сизгән идем инде.

— Син Гриша, миңа үпкәләмә. Сезнекеләрне күргәч, күңел кузгалды. Мине дә әнием шулай зарыгып көтә торгандыр. Әти юк минем. Әти сугышта хәбәрсез югалды. Ә мине колхоз кырыннан ике кило бодай алып кайткан өчен утыртканнар иде. Ел ярымын утырдым менә, ярты елы прокурорга калды...

Мин авыр суладым. Аны җибәрәсем килми иде әле. Әмма күңеле кузгалган икән инде, интектереп үзебездә асрау да кыен... Мин аны Арча вокзалына тикле озатып куйдым. Әни аңа, юлына дип, ярты ипи, бер кадак май, бер кәстрүл бәрәңге пешереп бирде.

Без аның белән гел хат язышып торырга дип аерылсак та, аны алып киткән поездга мин озак кына карап, кул селкеп торсам да, бүтән күрешә алмадык. Дөнья мәшәкатьләре белән йөреп, мин аның адресын югалттым, аңа хат язарга да, бүтән күрешергә дә насыйп булмады.

Коляны озатып кайткач, әни мине бәрәңге күзикмәге белән сыйлады — ул минем мәктәптә укып йөргән чакларымда иң яраткан ризыгым иде. Әни аның камырын бик юка итеп җәя, бәрәңгесен сөткә изә, аннары барысы әзер булгач, сыер мае белән майлый иде. Күзикмәк яки башка урыннарда әйткәнчә, кыстыбый Өчиле кешеләренең бәйрәм сые санала иде. Әнинең бүген мине кыстыбый белән сыйлавы күңелемә бик хуш килде. Авызда гежгелдәп торган кыстыбыйны бер-бер артлы тәлинкәдән алып, әйтеп бетергесез бер рәхәтлек белән ашап утыруыма әнинең күңеле булды. Ул үзе ашамый, гел миңа гына карап утыра иде. Табын әйләнәсендә безнең гаилә генә — Гайшә апа, беркемгә дә игътибар итмәстән, майланган бармагын ялый-ялый, авызы резин туп кебек күпереп чыкканчы тутыра кыстыбыйны, тугыз яшьлек Рамазан, үги әтиебез Нурулла абый малае, теләр-теләмәсрәк ашый, ул авырып киткән, әле мин барында ук суык тидерүдән мантый алмаган, тик ул авыруын бирәүгә дә белдерергә теләми, үзе генә күңелсез йөри икән; алты яшьлек Ризуан, анысы да Нурулла абый малае, бик тере, әтисенә охшаган үтә чибәр, кара кашлы, кап-кара күзле, кылдай каты кара чәчле бөтерчек, бер тәлинкә кыстыбыйны сугып куйды да, әниебезгә кычкырып рәхмәт әйтеп, урын өстенә үрмәләде. Арада сеңлебез Сәҗидә генә юк, ул урта мәктәпне тәмамлагач, быел Саба якларына балалар укытырга китеп барган.

Без кич буе дөнья хәлләрен сөйләштек. Мин ике ел да өч ай эчендә Березовка колониясендә ничек яшәгәнемне, нилләр кичергәнемне, ни өчен минем хатларым Өчилегә килмәгәнне сөйләп бирдем. Гайшә апа мин югында Өчиледә, Көтектә нилләр булганны сөйләде. Әни сүзгә кушылмады, башын селкеп, Гайшә апа сөйләгәннәрне җөплəп кенә утырды.

Мин югында хәлләр шактый ук катлауланып киткән. Миңа иң әшәке характеристика язып, колхоз мөһерен сугып кул куйган Гомәр абыйның,

колхоз председателе Гомәр Ганиевне, нахак бәла ягып, төрмәгә утыртканнар һәм ул анда, бәрәңге кабыгы булса да җибәрегез, дип елап ялвара-ялвара, ачтан үлгән. Бу хәбәрне сөйләгәндә әни дә тыныч кына кала алмады.

— И улым Гарифҗан, син белмисең әле... Кыланып карадылар инде син югында. Әнә шул Гани Гомәре бер көнне, сине хөкем иткәч, атка атланып безгә менгән. Өчилегә, килеп керде бу атына атланган килеш капкадан, мине урман кисәргә җибәрмәкче була, синең белән табалый, аты белән өскә килә. Бөтен Өчилене бетереп кычкырдым да «Үтерәләр!» дип, сәнәк күтәреп кадарга киттем. Коты алынды, алайда! Аты белән артына чигенә-чигенә кече капкадан чыгып югалды. Бүтән чакта Өчилегә менеп тә карамады. Аннары утыртып куйдылар. Аннары шунда үлеп калды. Бәла ул агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. Ходай тәгалә бар ул, тигезли ул, бик сикеренә башласаң...

Гайшә апа сөйләвеннән мин Бикташевның җиде елга төрмәгә утыртылганын белдем. Кемнәрдәндер акча алып, тиешле-тиешсез кешеләрне төрмәгә яптырганы өчен утыртканнар. Ришвәтче, димәк.

— Бик шәп эшләгәннәр. Дөрес утыртканнар. Аннан да явыз кешене күргәнем булмады минем, нинди юк бәлаларне тагарга маташты бит ул безгә,— дидем. Әнинең чырае бозылганны күреп, соңгы сүземне йомшарта төштем: — Төрмә — җәннәт түгел, аны дошманыңа да теләргә ярамый.

Безне участковый Бикташевка язып бирүче, дөресрәге — әтинең дошманнары котырыгы буенча, алар язган язуны Төрнәлегә меңгереп бирүченең дә кем икәне беленде. Заманында, мин «Кызыл Көтек» колхозында бригадир булып эшләгәндә, мин иң нык кайгырткан, урман алып кайтырга атлар биргән күршебез, ирен сугыштан көтеп яшәүче хатын булып чыкты ул.

Менә шунда мин тагын бер тапкыр әни әйткән: «Бәла агач башыннан йөрми»,— дигән сүзне искә төшердем.

Мин зинданга эләккәч, нәкъ әнә шул мин өзлексез ярдәм иткән күрше апайның улы Сәҗидә сеңлемә шулай беркөнне: «Сарык башы елгада, сарык башы елгада!» — дип кычкыра икән. Сәҗидә — бик сизгер кыз, бу үртәшүнең мәгънәсен бик тиз аңлап алган: имеш, мин — үләксә, ә үләксәнең башы — елгада. «Елга» дигәне — үләксәләр күмә торган коры елга, сугыш елында без анда үлгән атларны күмгәнне, ул атларның үләксәләрен казып алып ашарга ач бүреләр җыелганны әйткән идем.

Сәҗидә — ир малайларның авыз-борынын җимерә ала торган батыр кызый, аны-моны уйлап тормый, әлеге үртәшкән малайны куып, өйләренә барып керә, теге малай куркудан мич башына кача, Сәҗидә аны мич башында тотып алып, башын стенага бәрә-бәрә кыйный. Шуннан соң безнең гаиләгә яман сүз әйтергә берәү дә җөрьәт итми башлый.

Гайшә апа авылның маҗараларын сөйли дә сөйли, әни аны җөпләп, баш кагып утыра. Мине чаккан күрше хатынның ире фронттан контузия алып, чукрак-телсез булып кайта. Авылда аны кызганалар, аның тизрәк терелүен телиләр. Бибинур әни беркөнне чишмәгә су алырга төшсә, әлеге чукрак-телсез ирнең хатыны белән ду китереп дәгъвалашканын ишетә. Бу юлы инде әни дә әдәп саклап тормый, Казанбашның Сукыр Аптулга — Габдулла абый Заһидуллинга житкерә моны. Иртәгесен чукрак-телсезне алып китеп ябалар һәм шуннан бирле аның хәбәре юк икән.

И дөньялар! Мин югында бәләкәй генә Өчиле авылында нинди мәхшәрләр булган. Дөньяның бер даһие әйткән: адәм баласында яхшылык белән явызлык бергә яши, дигән. Минем әни нинди изге күңелле кеше, тешен кысып, ятим балаларын багып үстергән кеше, үзенә дус итеп санаган күрше хатынының мине чагып, Төрнәлегә, милициягә минем өстемнән язу меңгергәнен белгәч, түзми шул инде, чукрак-телсез булып кайткан адәмнең ялганлап өйдә ятуын белә һәм аны тиешле урынына җиткерә...

Березовка колониясендә мастер итеп калдырырга теләгән чакта миңа Вадим Кириллович әйткән сүзләр искә төште. «Әллә анда сине туган җиреңдә бик өзелеп көтеп торалармы? Кулда булган кешене бик өнәп каршыламыйлар анда!» — дигән иде бит.

Моның шулай икәне беренче көннәрне үк мәгълүм булды. Әни белән Гайшә апа колхоз басуына бәрәңге алырга киттеләр. Өйдә мин, тугыз яшьлек боек бала Рамазан да ут борчасы алты яшьлек Ризуан торып калдык. Әниләрнең бакча бәрәңгесе алып бетермәгән иде әле, энекәшләр белән мин бакчага бәрәңге алырга чыктым. Көн кояшлы, әниләрне сөендерәсе килә, мин казыйм, энекәшләр чүпләп тора. Көтек мәктәбендә укытучы булып эшләүче Миңниса килде безгә. Ул үзе — Казанбаш кызы, минем заманда начар укучыларның берсе иде. Әнә шул кызыйны укытучы итеп Көтеккә куйганнар.

— Ни өчен син, Рамазан Хәйруллин, укырга төшмисең? — диде ул, беребез белән дә исәнләшмичә.

Рамазан кулына тоткан чиләген әйләндергәләп торгач:

— Ә мин укымаска булдым. Мин авырыйм,— диде.

Ник укымауның сәбәбе көн кебек ачык бит инде, авыру баланы кем көчләп укыта ала? Миңниса белешергә, баланың кай җире авырта, аңа ярдәм итеп булмыймы икәнен ачыкларга тиеш иде, югыйсә. Тик укытучы апасының моңа башы җитмәде.

— Укымый йөрсәң, әнә абыең хәленә калырсың,— диде ул авыру балага. Моның белән ул мине дә, минем энекәшне дә мыскыллады. Энекәш, минем өчен оялып:

— Мин терелəм әле, апа. Терелгәч укырмын...— дип аяк астында чәчелеп яткан бәрәңгеләрне җыярга тотынды.

Тугыз яшьлек авыру малай, минем яраткан энем, бәрәңге бакчасындагы ямьсез сөйләшүне, бәлки, озакламый оныткандыр да, әмма мин оныта алмадым. Сабагын да рәтле-башлы белмәгән, артта баручы булып сөйрәлгән Казанбаш сөрхәнтәе сине мыскыллап торсын, имеш! Укырга кирәк, педучилищены тәмамларга, укытучы булырга, Миңнисадай булдыксызларны утлы табага бастырып тирги алырдай укытучы булырга! Бәлки әле директор да булырга кирәктер?

Әмма мин инде быел укырга соңга калган идем. Мин селкенгәләгәнче, төпле бер фикергә килгәнче, сентябрь узды да китте. Минем кеше күзенә күренердәй өс-башым да юк, өстәвенә сугыш елларында безнең олы өебезнең тәрәзә пыялалары ватылып беткән, аларны да куйдырасы, коймаларны да төзәтәсе, әниләргә кыш чыгарлык утын, берәр центнер арыш белән бодай да әзерлисе бар иде.

Мин иң әүвәл кулымда булган һөнәремне — рәсем сәнгате белән буяу эшемне хутка җибәрергә булдым. Казанбашның Сукыр Аптул белән киңәшеп, авыл Советы кәнсәләренә юлбашчыларның портретларын ясадым. Рамнарын үзләре ясап бирделәр, алар тапкан ак бәсне рамнарга үзем тарттырдым да бер атна эчендә бишме-алтымы портретны коры буяу белән ясадым: Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, тагын кемдер — хәтердә калмаган. Һәрхәлдә Сталин түгел иде, мин аны ясарга курка идем.

Шушы портретлар өчен миңа Казанбаш авыл Советыннан бер мең тәңкә акча түләделәр. Шул акчага мин, аны-моны уйлап тормастан олы өебезнең тәрәзәләрен куйдырдым. Моңа әнием бик хәтәр сөенергә тиеш иде, минем уемча. Әмма ул тыныч кына:

— Ярар, үзегезгә каласы,— дип куйды. Авыр гына көрсенеп алгач, әйтте: — Укуыңа барасые бит, балам. Теге чакта да укымыйча бәлагә тарыдың. Җыландай телемне чыгарып әйттем бит, ташлама, балам, укуыңны, дидем.

Менә шундый инде ул безнең әни. «Укы!» — дип авыз сулары корый.

— Быел бит инде, әни, укырга соңга калдым,— дидем.

Аның чырае бозылды, тавышы ничектер кызганулы чыкты:

— Шулай да, улым, барып кара әле, белеш. Ятып калганчы — атып кал, дигәннәр бит борынгылар. Тыңла сүземне: үзең белмәсәң, өлкәннәр сүзен тыңлау да бер һөнәр.

Мин «Үрнәк» совхозына — педучилищеның сугыш вакытында урнашкан поселогына барып кайттым. Анда мин таныш ике генә кешене очраттым: берсе — татар теле һәм әдәбияты укытучы Рәмзия апа Вәлитова, икенчесе — безнең авылның Салих абый кызы Зәйнәп. Мин бригадир булып эшләгән чакта, сугыш чорында Зәйнәп «Кызыл Көтек» колхозының амбарчысы иде, хәзер әнә, сугыш беткәч, педучилищега амбарчы булып күчкән икән.

Аларның берсе дә миңа караңгы чырай күрсәтмәде.

Ләкин аларның икесенең мөнәсәбәте ике төрле иде. Рәмзия апа, мине күргәч, бите-башы яктырып, күзләрендә очкыннар уйнап, хәтта ки укытучы-педагог икәнен дә онытып, сөенеп-шатланып күреште:

— У-уу, Ахунов! Нинди үскән, нинди егет булган. Кайларда йөрдең әле син «хаҗда?» — Аның беренче соравы шул булды. Аннары ул мине өйләренә чакырды. Икәүләп, кара-каршы утырып чәй эчтек. Мин Рәмзия апаны бик ярата идем, ул усал чырайлы булса да, үзе укыткан фәнгә мөкиббән киткән кеше, студентларының тырышлыгын, татар теле һәм әдәбиятын биш бармак кебек белүләрен таләп итә иде. Мин аңа, безнең заманнан калган бердәнбер укытучыма, колониядә күргәннәремне, анда буяучы һәм рәссам булып эшләгәнемне сөйләп бирдем.

Рәмзия апа олы коштай зур гәүдәсе белән урыныннан торды, кухня якларыннан әйләнеп килде — дулкынланганы сизелеп тора иде.

— Ахунов, Ахунов, син миңа яңалык әйттең бит әле. Безнең училищеда рәсем ясый белүчеләр бер дә калмады бит. Миңа Тукай тормышыннан плакат кирәк. Син шуны булдыра аласыңмы?

— Булдырам, — дидем, ике дә уйламыйча. — Ни кушасыз, шуны булдырам.

— Бик яхшы. Син, алайса, миңа шул плакатны озакка сузмыйча гына ясап алып кил әле. Аннары... менә нәрсә? Безнең физкультура укытучыбыз урыс, ул хәрби занятиеләр дә үткәрә, үзе сугышта булган кеше, Суворов дип авыз суларын корыта. Син аңа Суворов портретын ясап алып килә алмассыңмы?

— Була ул, ни кушсагыз, шуны үтим. Тик минем дә... бер үтенечем бар бит әле, Рәмзия апа.

— Нинди үтенеч ул? Әйтеп күрсәтегез, Ахунов.

— Педучилищеда укуны дәвам иттерәсе иде бит. Әни бик тели шуны. Аның сүзен тыңламасаң да кыен, ул бит безне, ятим балаларны карап-багып үстерде...

— Кайгырма, Ахунов, мин сине яклармын. Синең бит мин акыллы студент чакларыңны, минем фәннән дә, башка фәннәрдән дә бик яхшы билгеләренә укыганыңны беләм. Урыс теле кыенрак иде бугай синең. Шәт инде ике елда урысча да өйрәнгәнсеңдер дип беләм. Красноярски якларында татарлар юктыр да анда.

— Красноярски краенда татар юктыр дип әйтә алмыйм. Мин ике ел да өч ай утырган Березовка колониясендә татар юк иде.

Без укытучым Рәмзия апа белән ике сәгатьләр чамасы сөйләшеп утырдык, ул миңа үзенең шактый авыр тормыш алып барганын яшермичә сөйләде. Аның ирен — әдәбият укытучысы Сөләйман ага Вагыйзовны, әсирлектә булганы өчен, ябып куйганнар икән. Рәмзия апага кызын һәм малаен үзенә карарга, авыр йөк булып җилкәсенә утырган педагоглык эшен дә сыкранмый-нитми алып барырга туры килә икән. Инде ул Арчага — элекке урыннарына кайтыр көннәрен түземсезлек белән көтә икән...

Рәмзия апа — сабыр табигатьле хатын, әмма боларны сөйләгән чакта мин аның тавышы өзелгәләп куюын сиздем, ул, миңа күрсәтмәскә тырышып, күз яшьләрен дә сөрткәләп алды.

## Һөнәрле үлмәс

Рәмзия апа заказларын тиз үтәдем. Укытучым миңа педучилищедан берничә табак ватман кәгазе, акварель буяулар биреп җибәргән иде. Авыл китапханәсеннән мин Тукай томнарын табып алып, андагы Тукай портретын зур итеп ватман кәгазенә ясадым, аннары Тукайның Уральск типографиясендә гәзит тотып төшкән фотосын кәгазьгә күчердем, бик тырышып Кырлай авылын ясап куйдым, китап тышлыкларын ясадым, плакатның читләренә чуар итеп, нәкышлы итеп бик матур рам сыздым.

Суворов портретын ясау плакат ясаудан ансатрак булып чыкты. Мин аны ак бәскә төсле коры буяу белән бөтен буена ясап куйдым. Ул хәтта минем үземә дә ошады.

Педучилищеда мин китергән рәсемнәрне кабинеттан кабинетка йөрттеләр, укытучылар бүлмәсендә барлык педагоглар җыелып карадылар.

Рәмзия апа минем ялгызымны гына бер почмакка алып килеп:

— Ахунов, синең язмышың хәл ителде, киләсе елны өченче курста укырга әзерлән,— диде.

Мин ясаган портрет белән плакат миңа тагын бер сөенеч китерде. Директор алар өчен миңа Салих абый кызы Зәйнәп мөдир булган складтан бер пар «американский» ботинка һәм бер пот өрдергән арпа оны бирдертте. Менә шуларны минем кулга тапшырган чакта күршебез Салих абзый кызы Зәйнәп миңа сөзеп-сөзеп карады. Бу әйберләрне аның миңа бирәсе килми, әмма кулына директор язуын тоттыргач, бирми дә булдыра алмый иде. Колониядән кайткан Ахун малаена шундый почет күрсәтү аның башына сыймый иде бугай. Хәер, мин моңа гаҗәпләнмәдем, кулдан кайткач, мине урамда очраткан Фатимәттәй күршеләренә әйткән:

— Анаңны чеметим, Ахун малае шешенеп кайткан өтерманнан! — дигән.

Тагын бер мәртәбә Вадим Кириллович сүзләре искә төшә: туган якларыңда сине ашкынып көтәләр дисеңме әллә?

Әни мин алып кайткан ботинкага әлләни исе китмәсә дә, өрдергән арпа онына сөенде: ул безнең гаиләгә умачлы аш пешерергә ике айга җитте.

Мин кайда да булса эшләргә, киләсе уку елын көткән арада тик ятмаска тиеш идем. Мине «Кызыл Көтек» колхозының клубына мөдир итеп алдылар. Мин анда концертлар оештырдым, спектакльләр куйдым, бизәп-бизәп стена гәзитләре чыгардым. Клубның эченә, матчаларга плакатлар язып элдем.

Бу вакытта инде мин үсмер малай гына түгел, егерме яшендәге җиткән егет идем. Мәктәптә укыган елларымда ук шигырь сөйләргә, суфлер булырга, тел бистәсе дигән исем алырга лаек булгангадыр, минем белән дуслашырга теләгән кызлар байтак иде. Арада шактый ук таза тормышлы кешеләрнең дә кызлары бар иде. Чибәрләрнең дә миңа күзе төшмәде түгел, тик мин үзем җирән чәчле, сипкелле, тәбәнәк кенә бер кызны — Рамазан абый Салаховның сеңлесен сайладым. Сугыш вакытында, мин «яланаяклы бригадир» чакта ук, күзем төшеп калган иде. Асия үзе дә моны сизгән икән — кулдан кайтып, беренче мәртәбә аулак өйдә утырган чакта, «өч кубометр утын кисәргә» дигән җәзаны үтәү өчен өй алдына чакыргач, ул минем куеныма сыенып, чиксез дулкынланган тавыш белән: «Гарифҗан, и дә теләдем соң синең мине чакыруыңны!» — диде.

Без караңгыда бер-беребезгә сыенып тордык.
Асиянең Миңлебикә һәм Фәтхия исемле ике сеңлесе бар. Миңлебикә, апасы Асия төсле җирән, юантык, Фәтхия исә тал чыбыгыдай нәфис һәм, апаларының капма-каршысы буларак, сызылып киткән кара кашлы, кара чәчле иде. Әнә шул ике кыз мине туган абыйлары кебек яраталар, клубта мин куйган концертларның җаны булалар иде. Алар матур итеп җырлый да, бии дә беләләр, концертка иптәш кызларын да тарталар иде.
Рамазан абый сугышта яраланган, үзе белән бергә фронтта катнашкан бер марҗа кызына өйләнгән, ул подполковник булган, әле өйләренә кайтканы юк иде. Әмма ул сеңелләренә аттестат җибәреп, аларны багып тора, ә сеңелләре өчәве бергә генә яши, әти-әниләре үлгән иде.
Асия белән безнең бер-беребезгә тартылуыбыз да, ихтимал, өзелеп яратышудан түгел, җаннарыбызның якынлыгыннан, икебезнең дә ятимлегебездән килгәндер әле.
Мин Асия Салахова белән дуслашуыма сөенеп йөрдем, чөнки мин Арча педучилищесына киткәнче боегып яшәмәдем. Көтек авылы безнең Кечкенә Өчиледән чакрым ярым ераклыкта, кайвакыт спектакльләр төнге уникедә генә бетә, япа-ялгызым Өчилегә кайту куркыныч, сугыш вакытында ишәеп калган бүреләр төннәрен елга буйларына чыгалар, ә миңа Өчилегә кайтып җиткәнче ике коры елга аркылы узарга кирәк иде.
Минем бәхеткәдер, мин «хаҗдан» кайтып, озак та узмады, СССР Югары Советына сайлаулар игълан иттеләр. Менә шунда мине Заһидуллин Габдулла абый («Сукыр Аптул») үзенә чакырып алды. Аны Казанбаш сайлау участогының мөдире итеп куйганнар иде.
— Гарифҗан,— диде ул миңа, кара чүпрәк бәйләгән күзен рәтлирәтли,— мин сине бик җитди эш белән чакырдым. Безгә сайлау участогын бизәргә кирәк. Ул синең кулыңнан килә. Авыл советы кәнсәләренә ясаган портретларың шуны раслый. Ләкин сайлау участогын бизәү — түләүле эш түгел. Мин сиңа колхоздан берәр пот бодай бирдертермен, артыгы булмас. Әтиең Ахунҗан белән бик дус идек. Әтиең хакына безнең участокны бизәп бир инде син, улым.
Мин риза булдым. «Әмма буяу табу, кызыл материя, фанер табу, рамнар ясау сезнең өстә»,— дидем.
Без Казанга барып, кызыл, ак, яшел, сары, зәңгәр буяулар алып кайттык. Буяу пумалалары сайладык. Мин атна буе Габдулла абый Заһидуллиннарда яшәп, плакатлар язу, сайлау көне календарен ясау, сайлау бүлмәләрен бизәү белән шөгыльләндем. Ул елларны кызыл материя табу ансат түгел иде. Габдулла абый Казанбашта такта ярдыртты, аларны струклатты, без әнә шул такталарны кызылга буяп, өстенә майлы ак буяу белән өндәмәләр яздык: Казанбаш сайлау участогына кергән сайлаучыларны — Көтек, Казанбаш, Өчиле, Каенлык авыллары кешеләрен коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына тавыш бирергә чакырдык. Урамнарның кара-каршы яктагы йортларын тоташтырган егермешәр метрлы такталарны аерым баганалар утыртып, кадаклап куйдылар. Шундый плакатлар Казанбашның урамнарына алты-җиде урынга куелды.
Ул да түгел, Арчаның район гәзитендә Казанбаш сайлау участогында эшләрнең үрнәк төстә куелуын мактап мәкалә басылды. Габдулла Заһидуллин исеменә анда ялкынлы сүзләр язылган иде. Габдулла абый миңа «Кызыл Көтек» колхозыннан бер пот бодай бирдертте. Тик ул бик тиз халык теленә керде.
Улы солдат хезмәтеннән авыру сәбәпле кайткан бер ана «Кызыл Көтек» колхозы председателе Зиннәт абый янына кергән. Дәгъва ясарга маһир ул хатын ишектән кереп җитмәс борын ук кычкыра башлаган:
— Өчиленең төрмәдән кайткан Ахун малаена бодай биргәнсез. Минем солдаттан кайткан улыма да бодай юк! — ди икән.
— Ахун малае бит сайлау участогын бизәде,— дигән колхоз җитәкчесе.

— Ул буяганны мин үзем дә буяп куям! — дигән җәнҗалчы апа.

— И нәгаләт! Бар әнә кайтып мичеңне агарт, урамда акырып-бакырып, кеше көлдереп йөрмә, — дигән Зиннәт абый.

Миңа боларны Габдулла агай Заһидуллин сөйләде. Район газитендә чыккан мәкаләне дә миңа ул укытты, күзенә япкан кара чүпрәкне рәтлирәтли әйтте:

— Энем, бик рәхмәт инде, сүземне тыңладың. Арча районында минем участокны беренче урынга чыгардың. Дөньяда төрле хәлләр була, авыр чагыңда мин дә сиңа булышырмын...

Габдулла абыйга булышу җае сәгате-минуты белән килеп чыкты. Без әлеге сүзләрне сөйләшеп бетерергә дә өлгермәдек, Казанбашның таш клубы янына ярсып торган кара айгыр килеп туктады, теракле матур чанадан (кошовкадан) өстенә толып кигән бер кеше төште.

Габдулла абый, ашыга-ашыга, аны каршы алырга урамга чыгып китте. Озакламый алар сайлау бүлмәләре ясалган кабинетка икәүләп килеп керделәр.

Габдулла абый кунагының толыбын салдырды, зур тире бияләйләрен морҗа буена илтеп куйды, алар шундук сөйләшеп киттеләр. Мин аларның сөйләшүләрен өстәл буенда тыңлап утыра идем, килүченең кем икәнен шундук аңладым. Ул Масра тегү әртиленең мөдире, Масра сайлау участогының да мөдире булып чыкты.

— Габдулла абый, сиңа килүемнең сәбәбен, шәт иншалла, аңлагансыңдыр инде. Бүген Арча районы газитен укыдым да күзем маңгаема менде. Заһидуллин Габдулла мөдир булган сайлау участогы беренче урынга чыккан лабаса! Туктале, мәйтәм, үз күзем белән күреп, үз колагым белән ишетеп, чынлап торып ышанып кайтыйм әле бу хәлләргә. Урамнарыңны әйләнеп чыктым: ул хәтле матур плакатларны кем язды сиңа? Сайлауга килергә чакырган календарьны кем ясады? Кайдан таптың син андый художникны?

Габдулла абый исән сыңар күзен миңа төбәде, кулын миңа таба сузды:

— Рәхим итеп, таныш булыгыз: менә минем уң кулым, барлык матур эшләремне башкаручым.

— Шушымы?! — диде кунак, гаҗәпкә калып. — Бик яшь түгелме соң бу? Син мине шаяртмыйсыңмы?

— Юк, туганкаем, шаяртмыйм. Әтисен утыз беренче елны кулаклар үтергән Гарифҗан бу. Кулыннан килмәгән бер эш тә юк. Плакат та яза, календарь да ясый, портрет сурәтләргә кирәк булса, коеп кына куя...

Ул мине үтереп мактый, мин комачтай кызарып утырам.

Кунак — таза нык борынлы, зур түгәрәк күзле, каты кара чәчле кеше — Габидулла абыйга гозерләнеп дәште:

— Слушай, Заһидуллин, шушы егетеңне миңа бер атнага биреп тора алмассыңмы?

— Мин аны бирмим дисәм, син — минем якын кешем, бирәм дисәм — аны бит бушка эшләтеп йөртергә ярамый. Әнисе авыру, өйдә, Гарифҗаннан башка, тагын өч балалары бар. Колхоз ипи бирми, ул әле өйләренә утын да, печән дә, икмәк тә әзерләргә тиеш булып чыга.

— Аңладым тел төбеңне, Заһидуллин: егеткә эшләгәне өчен түләрсеңме, димәкче буласың. Түлим — бүрек бирәм башына, өстенә сырган чалбар, телогрейка, аягына киез итек...

— Ә икмәк ягы? — диде Габдулла абый.

— Анысын да җайларбыз. Колхоз үзебезнеке. Бер-беребезгә ялынычыбыз төшми тормый бит.

— Алай булса, егет — синеке. Бүген үк алып китә аласың. — Габдулла абый миңа таба борылып, исән калган сыңар күзен кысты — борчак пешә, янәсе!

Берничә минуттан инде мин Масра тегү әртиленең мөдире белән янәшә утырып, кара айгырның бураннар уйнатып баруына соклана идем.

Казанбаштан Масрага без күп дигәндә унбиш минутта кайтып җиткәнбездер. Мин шул чагында бригадир булып эшләгән елымны сагынып искә алдым. Өч яшьлек кырыкмыш мине дә шулай җилләр уйнатып кына алып төшә торган иде Көтеккә...

Масрада мине әртил башлыгы бер әби белән бабайга урнаштырды. Миңа шундук бер кило бал, бер кило май китерделәр. Аш пешерергә ит тә китергәннәре мәгълүм булды.

Казанбашта ни эшләгән булсам, Масрада да шуны ук эшләдем: Казаннан буяулар алып кайттык, урамнарга такталар суздык, сайлау көненең календарен ясадык. Клубның эчен бик матур итеп бизәдек, тәрәзә араларына плакатлар язып элдек. Әртил мөдире Карл Марксны бик ярата икән, сәхнәнең бер кырыена коры буяу белән ак бәзгә мин Маркс портретын бөтен буена яздым.

Болар барысы бер атна эчендә эшләнде. Йокы миңа бик аз эләкте.

Бер атна эчендә мин боларның бер тамчы йокы йокламасам да эшләп бетерә алмый идем, урамнарга сузган такталарны тиз кибә торган кызыл буяу белән буяп торырга миңа колхоздан ике егет бирделәр. Бәхетемдер, алар эш рәтенә тиз төшенә торган булдыклы егетләр булып чыкты — тиз дә, сыйфатлы да итеп буядылар такталарны, мин ничек өйрәтсәм, шулай эшләделәр. Күрәсең, рәсем сәнгате белән заманында үзләре дә шөгыльләнгән егетләр булса кирәк.

Әртил башлыгы (исеме ничектер хәтердә калмаган) мине якын итеп аркамнан кагып торды, Казанбашта Габдулла абыйга вәгъдә иткәннәренең барысын да бирде.

Өстемә яңа телогрейка-сырма, сырган чалбар, аякка итек, башыма өр-яңа бүрек киеп, мин печән йөге өстенә менеп утырдым. Ә ул печән өстенә бер капчык бодай, бер центнер бәрәңге салынган иде.

Масра егете, минем такталарны буяп торган япь-яшь чибәр егет, мине ат белән Өчилегә кадәр китереп куйды.

Татар халык әкиятләрендә сәер бер такмак бар: ишегалдындагы эт чәңгелдәп такмаклый:

— Үләргә киткән абзый баеп кайта, ләң-ләң!..

Мин дә шул хәлдә идем. Әни моңа башта ышанмый торды. Безнең Кечкенә Өчиле ул чагында бик бәләкәй иде инде. Минем печән йөге өстенә утырып кайтканымны карарга авылның һәр өеннән кеше килде. Сөенечләрен дә, дәгъваларын да урам яңгыратып әйтергә күнеккән Шәйхинекеләр:

— Ахун малае мәкәрҗәдән кайткан! — дип авылга сөрән салдылар.

Бу хәбәр шул ук көнне Көтеккә дә ишетелгән. Мин кичен клубка төшкән идем, Көтекнең картлары миннән шуларны сорашып тордылар, үземне мактадылар, гомерең озын булсын, әниең сезне бик тилмереп үстерде, балаларының игелеген күрергә язсын! — диделәр.

Миңа, кием-салым алудан, печән һәм бодай алып кайтудан бигрәк, халыкның минем турыда яхшы уйлавы куанычлы иде.

Клубтагы яшьләр дә миңа якты күз белән карый торган булдылар. Минем Казанбаш мәктәбендәге даным янә үземә әйләнеп кайтты. Моны миңа бер кичне Асия да әйтеп торды. Ул миннән күзен алмый, мине сыйларга тырыша, ә сеңелләре Миңлебикә белән Фәтхия минем янга ук килеп, икесе ике ягымнан кочаклап алганнар иде.

Клубтагы эшләрем гел сөенечле булып бара, яшьләр көндезге эшләреннән кайткач, бар кадәре матур киемнәрен киенеп, клубка чыгалар, әйлән-бәйлән уйныйлар, җир җимертеп биилэр, мин югында үсеп җиткән яшьләр бер-берсен озатышып, авыл халкының гомерлек гадәтләрен, сөю-сөгадәтләрен дәвам иттерәләр иде.

Караңгы озын төннәре, бурап-бурап яуган карлары белән кыш узды. Сайрар кошлары белән яз килеп җитте. Сугыштан соңгы йолкыш атлары белән, барлы-юклы симәнәләре белән «Кызыл Көтек» колхозы кешеләре кырга чыкты.

Заманалар никадәр генә авыр булмасын, халык никадәр генә ачыкмасын — басуларны актарып җыйган өшегән бәрәңге бар иде, кыр-болыннардан җилен тутырып сөт алып кайткан сыерлар бар иде, барыннан да бигрәк җанга тынычлык иңдергәне — илдә сугыш юк, хәбәрсез югалган ирләрен көткән солдат хатыннары бар, юллардан күзләрен алмаган солдат аналары бар, учак көле астында сүнми яшәгән ут төсле, барлык күңелләрдә өмет чаткылана иде.

Язгы чәчү кампаниясендә клубта эш аеруча көчәйгән, өч бригаданың стена газитләрен чыгарту, аларны рәсемнәр белән бизәү, кырларга барып партия-хөкүмәт карарларын Казан газитләреннән уку — барысы минем өстә иде. Атлар кышны шактый ук өшәнеп чыкканга күрә, бакча җирләрен сукаларга ат бирмәделәр, иртә таңнан, яки кичләрен кояш баеганчы бакча җирен казып, бәрәңге утырту да минем өстә иде әле.

Ыңгырашмый-нитми, күңелләрне сүрелдермичә, барысын да ерып чыктык. Авылларда сугыштан соңгы беренче сабантуйлары үткәрелде. Халыкның күңелен алгысыткан, сугышка кадәрге бәйрәмнәрне искә төшергән ул ямьле көннәрдән соң, мин «Үрнәк» совхозына — Арча педагогия училищесына гариза илтеп бирдем.

Язмыш упкыннары белән өзелгән укуымны дәвам итәргә кирәк иде. Әниебез Бибинур моны берөзлексез, көн саен диярлек, минем исемә төшереп торды.

## Тагын — педучилище

**1946** елның сентябрендә мин тагын педучилищега барып кердем — өзелеп торган укуымны дәвам итәргә.

Биредә инде минем белән 1940 елны укый башлаганнардан берәү дә юк, алар училищены кырык өченче елны ук тәмамлап, кайсы кая китеп беткәннәр, элекке укытучыларымнан да, ихтимал, Рәмзия апа Вәлитова гына торып калгандыр.

Рәмзия апа мине, колониядән кайтканнан соң беренче мәртәбә күргәндәге шикелле, бу юлы да якты йөз белән каршы алды, үзе белән директор янына алып керде.

— Бу егет, фамилиясе Ахунов, исеме Гарифҗан, бездә ике ел укыган иде инде. Аның тормышында күңелсезлекләр килеп чыкты, шуңа күрә ул укуын өзеп торырга мәҗбүр булды. Безнең тырыш студентларыбыздан иде, алыйк без аны өченче курска, ул безнең йөзгә кызыллык китермәс.

Бу хәл мине сөендерде. Ире Сөләйман аганың әсирлектән соң төрмәгә ябылуы якынайттымы аны миңа, әллә татар теленә карата үтә игътибарлы булуым үз кеше иттеме, ничек булса да булды, Рәмзия Гыйләҗевна авыр чагымда мине яклады, миннән нидер чыгачагына өмет баглап тотынды һәм ана телебезнең байлыгын аңлатуга чамадан тыш күп көч куйды. Сугыштан соңгы елларның матди кысынкылыклары да, суык баракларда яшәп, туңу-күшегүләр дә, кыскасы, бернинди мәхрүмлекләр дә аны безгә таләп, хәтта мин әйтер идем, аяусыз зур таләпләр куюдан туктатып кала алмады.

Педучилище әле 1946 елны да «Үрнәк» совхозында иде, өч-дүрт айлар чамасы укыгач, кыш урталарында без үзебезнең төп йортыбызга Арчага күчендек. Бик суык кыш иде. Училищеның бер генә «полуторкасы» бар иде, ул әледән-әле ватыла торган иде, Арча юллары коточкыч бимазалы иде, «Үрнәк»тән бер мәртәбә Арчага 20 чакрымны узу белән, ул ремонтка туктый иде. Ник мин боларны озаклап сөйләп торам дип уйлыйсыз? Әнә шул ватык «полуторка» аркасында юлда безнең барлык бәрәңгебез өшеп бетте, педучилищеда студентларга дип пешергән кәбестә ашында шакырайган берничә бәрәңге йөзеп йөри торган иде. Бу юлы укуымда мин Арча районының Гөберчәк авылы малае Мөхәммәт Мәһдиев һәм

Гали Халитның энесе Яхъя Халитов белән туры килдем. Уку безгә авыр бирелми, ни дисәң дә, без зиһенле малайлар идек, әмма ачлык та, башка төрле бәлаләр дә үзәккә үтә иде соң! Мөхәммәт Мәһдиев, үзе язучы булгач, башта «Без — кырык беренче ел балалары» дигән талантлы, гаять үзенчәлекле повесть язды. Ә 1993 елны «Ачы тәҗрибә» исемле истәлекләр китабы бастырды. Бу әсәрләрнең икесендә дә тормышның ул замандагы фаҗигалары калку итеп күрсәтелгән. Ул әсәрләрнең икесендә дә минем дә исем бар. Повестьта мин Әлтафи исемле тотанаксызрак бер персонаж булып керсәм, «Ачы тәҗрибә»дә инде үз исемем белән үк алынган. Мәһдиев без кичергән фаҗиганы оста язган, өстәвенә мин эшләгән бер кыюлыкны да яшерми әйткән...

Каләмдәшем һәм якташым, Кечкенә Өчиледән биш-алты гына чакрым ераклыктагы Гөберчәк авылы егете Мөхәммәт Мәһдиевнең каләме үткен-усал икәнен беләм, уйлап чыгару һәм арттыру сәләте ифрат көчле икәнен дә тоеп торам, әмма бу очракта Мөхәммәт бер генә нәрсәне дә арттырмаган. Тормыштагыча бөтен зурлыгы, авырлыгы белән, төптөгәл детальләре белән сурәтләп биргән.

Хәлим ага Искәндәрев — педучилищеда урыс теле укытучысы иде. Үз фәненә фанатикларча мөкиббән киткән, шуны студентларга да сеңдерергә тырышкан икенче бер кеше булса, ул — Рәмзия апа Вәлитова гына булгандыр. Анысы да бит тел укытучысы, тик урыс телен түгел, туган телебезне, татар телен укыта иде. Ачлык-ялангачлыклар белән узган бер елда нинди генә авырга туры килмәсен, телгә карата, газиз ана телебезгә карата үзенең шәкертләрендә ярату уята алганы өчен без хәзер Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитовага кат-кат рәхмәт әйтәбез. Әдәби хезмәт өчен һава кебек кирәкле тел нечкәлекләренә беренче ныклы нигезне без — Яхъя Халитов, Мөхәммәт Мәһдиев һәм мин — аңардан алдык...

Мөхәммәт каләмдәшемнең Арча педучилищесындагы өченче курста күргән михнәт-газапларыбызны дөрес һәм тулы язган дип әйтсәм дә, шулай да бер вакыйганы әйтми калдыруын күрсәтеп узарга тиешмен.

Мөхәммәт училищедагы тәртипсезлекләрне, диплом бирмәсләр дип куркып, сөйләми кала. Мин, үземчә, утны-суны кичкән егет, андый чакта икеләнү-микеләнү дигәнне белми идем. Әйе, училищеда нинди тәртипсезлекләр бар, берсен дә калдырмый, ярдым да салдым. Әмма ул миңа кыйбатка төште. Мөхәммәт каләмдәш нәкъ менә шунысын әйтми калдырган. Моңарчы бик яхшы билгеләренә укып килсәм дә, дәрес вакытында җавап биргән чакларда миңа күпчелек укытучы «өчле» билгесе тамыза башлады, хәтта күрәләтә торып «икеле» куючылар да булды.


Әмма мин, «Үрнәк» совхозындагы кебек, стена газитендә директорны тәнкыйтьләгән өчен укытучылар каныкканга укуны ташлап кайтып китердәй унбиш яшьлек үсмер түгел идем инде. Тормышның ачы сабаклары мине ярсынмаска, тешне кысып түзәргә өйрәткән иде.

Мин сабагымны әзерләми килмәдем. Укытучылар биргән сорауларга чатнатып җавап бирә торган булдым. Шунлыктан студент иптәшләрем алдында укытучы-педагогларның миңа «өчле» билгесе куярга маташулары, шуны юрамалый студентлар алдында кычкырып әйтүләре класста ризасызлык тудыра, ә моны башында азмы-күпме акылы бар педагог сизми кала алмый иде.

Директор кушуы буенча «үч» алырга омтылган укытучылар түгел, үз юлымны туп-турыдан ярып барган, бернигә дә исем китмәгән мин җиңдем. Минем исем турысына тагын «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләре куна башлады.

— Укытучыларны кызык иттең бит син, кызык иттең, Гарифҗан, тәки төп башына утырттың бит, капитально утырттың, — ди иде Мөхәммәт сабакташым...

## ШИГЪРИЯТ



# Рашат Низамиев

### Татарстан турында моңсу җыр

Дәүләтенме югалтканга күрә,
Көче беткән нәсел-ыруның.
Чикләрең дә тормый инде хәзер
Урал-Алтайларга орынып.

Күпме генә сулар бөркесәк тә,
Безнең хыял — шиңгән чәчкәдер.
Басуларны тимер тутык баскан,
Нефть байлыгыннан ни кадер?

Коттеджлар гөмбә сыман үрчи —
Кемнәрнедер байлык сикертә.
Илгә төшкән бөтен авырлыкны
Авыл халкы тарта кич-иртә.

Су астына салым итеп салдык
Бабайлардан калган урманны.
Балтыйк буе илләреннән әнә
Ишетәбез бүтән җырларны.

Җилләр безне юатмакчы була:
Тәкъдиреңә, туган, түз, диптер.
Бу Рәсәйне бурлак сыман тартып,
Сөйрәп бару — бәхетсезлектер.

И котлыйсы һәм сөйлисе иде
Бәйсез Татарстан турында!
Танк тавышларын күмә-күмә,
Өмет кайный әле җырымда...

## Ике башлы!..

Байгуралар балда-майда йөзде,
Хәерчеләр үсте җил кыйнап.
Дөньяларны әйләндереп салды
Унҗиденче елгы инкыйлап!

Авып төште тарих чүплегенә
Ике башлы тугра-каракош.
Вәгъдә яуды: Рәсәй халыкларын
Без ирекккә алып барабыз.

Тел вә лөгать, икмәк уртаклашып
Яшәп алдык шулай җитмеш ел.
Чабатадан — космосларга кадәр:
Бер уйласаң, алга китмеш ел...

Империя! «Җенең» йокламаган,
Рәсәй тагын дулый, үртәлә —
Ике башлы тугра-каракошын
Дәһшәт белән өскә күтәрә.

«Демократик» кыланышларына
Карап тора дөнья шаккатып:
«Empire of evol»[1] яңабаштан
Гайрәт чәчә, туплар шартлатып!

Ике башлы «кош»ны терелттеләр,
Күз төбәгән болар кай якка?
Ике башлы усал каракош күк
Ике башлы була таяк та!

## Очыш

Кош каурые тамган зәңгәрлектән
Бер өн килә, килә чакыру!
Мин — очышта. Күңел канатымның
Болытларга ашкан чагы бу.

Аста — киңлек, сәер күренешләр:
Таулар чүгә, эри, югала.
Кан тамыры сыман кабарынып,
Тармакланып ята елгалар.

Һәр тарафтан хикмәт, мәгънә эзлим,
Авылларны күзлим биектән,
Туган йорты биргән иман белән
Кеше мәңге җиргә береккән.

Килеп чыгам шәһәр өсләренә,
Тып-тын йөзгән Икар шикелле.

[1] «Empire of evol» (*инглизчә*) — «явызлык империясе». АКШның элекке президенты Рональд Рейган Рәсәйне (советлар илен) шулай дип атаган иде.

Торбалардан чыккан кара төтен,
Суырып алып, йотар шикелле.

Офыкларда тарих төсмерләнә,
Һәм ачыла... еллар капусы!
Мәгарәдән күчә-күчә килгән
Кеше рухы, кеше яктысы.

Алтын айлы манаралар белән
Идел-йортның күге яңара...
Чиркәү чаңы кыйный офыкларны —
Кайсы чор бу, кайсы замана?

* * *

Ике күз биргән табигать —
Дөньяны күрер өчен.
Ике аяк биргән — җиргә
Нык басып йөрер өчен.

Ике кул — анысы инде
Кубрәкне күтәргә;
Тормыш йөген һаман саен
Алгарак этәргә!

Бер баш биргән — берәгәйле
Уйлана белсен, диеп,
Икейөзле булулардан
Саклана күрсен, диеп.

Табигать бик дөрес иткән —
Йөрәк тә бит бер әү җиткән:
Икеләтә сөяр өчен,
Гамь утында көяр өчен,
Иң хәсрәтле минутларда
«Уф, йөрәгем! — дияр өчен...

## Уен

Уйный идек җирдә, суда, күктә...
Күк дигәнем — агач башлары.
Ак парашют итеп күлмәкләрне,
Рәхәт иде аска ташлану!

«Чебиләгән» ялан тәпи белән
Буразнадан йолдыз эзләдек.
Җәен — яңгыр, кышын карлар булып
Сокландырды һәрбер үзгәлек.

«Ташкалага кем баш кала?» — диеп
Кайный идек, гүя кырмыска.

Уйный-уйный тап-тар тыкрыклардан
Чабып кердек олы тормышка!

Безнең җиңү, безнең алданулар
Чынлап уен булган лабаса...
Ә тормышта тәртип-кагыйдәләр
Карап торсаң — үзе тамаша!

Тормыш — уен, шундый җитди уен,
Яшеренеп битлек артында,
Күпләр әнә матур сүзләр сибә
Гаделлек һәм намус хакында.

Алтыннарын биреп сыный дөнья,
Йә күрсәтеп сыный сылуын.
...Бу тормышта, ниләр кылансаң да,
Иң кыены — Кеше булуың...

## Туган авылда очрашу

*Мин туганны белгәч, әткәй*
*Карурманга юл тоткан.*
*Нәни миләш алып кайтып*
*Янбакчага утырткан.*

Сал җилкәмә яшел кулларыңны,
Саумы, дустым — яшьтәш миләшем!
Дөнья күргән ир-егетләр сыман,
Бер утырыйк әле сөйләшеп.

Быел тагын җимеш өлгерткәнсең...
Безнең җимеш — эштә, шигырьдә.
Кылган эшең «сөт»кә китә барса,
Җанны борчу кыйнап тилмертә.

Кара күздә кырау алган саен
Тәлгәшләрең тула балланып.
«Кырау төшмәс безгә»,— диючеләр
Вакытлыча яши алданып.

Минем дә бит күңел бакчасындагы
Хыялларны, гамьне, гөлләрне
Көтмәгәндә тормыш кыраулары
Каплап киткән иде бер мәлне...

Чәчләремә «көмеш» өсти-өсти
Чыныктырды салкын кыраулар.
Ачы җилләр сине йолкыган күк,
Мине көн дә талкый сораулар.

Үз-үзеңне югалтмаска теләп
Мең терелеп, мең кат үләсең,—
Кеше булып яшәүләрнең хәлен
Тик бер тапкыр
Тойсаң иде икән, миләшем!

* * *

Була төрле: кәефле чак, кәефсез чак.
Бер үк җанга — йә татлы сүз, йә сүз-пычак.

Кайчакларда кыйналасың, үртәлә җан —
Яшәүләрдән ни мәгънә дә, безгә ни сан?

Бар өметем өзелдеме әллә дисәм,
Күңелдә нур — ышанычым-тәңрем исән!

Сатылма да, ватылма да, горур җаным,
Сынауларның иң зурысы — алда аның.

## Туган як кадере

Сагынулар чорнап алган чакта
Белмим, нинди дәва табасы?
Ярты җаным һаман синдә яши
Туган ягым, Байлар Сабасы!

Алмаларның исе нидән татлы,
Әрем исе була ник әче?
Шатлыгым да, сагышым да булып
Син яшисең җанда, Теләче!

Гомер диген —
Арта гына бара
Туган якларымның кадере.
Ике яктан кушуч туфрак белән
Ныгытылыр минем каберем...

## Язгы сурәт

*...гә*

Калкып чыктың кайсы елның языннан,
Ни язмыш ул — учларыңда язылган...
Күңелне уятыр, сызлатыр өчен
Килдеңме әллә йолдызлар багыннан?

Чәчкәйләрең агып төшкән — билеңнән,
Сүз әйтергә сусап торган иреннәр...
Синме бу ерып киләсең язларны —
Бер чәчәк — Яшел Үзәннәр иленнән.

Нурларың тылсым-кояшка тиң генә,
Язларны, ахры, китерден син генә.
Мин ышанмас та идем могҗизага —
Күр: чәчләреңнән йолдызлар сибелә.

Нинди гамьнәр кунды: дөнья үзгәрде,
Бар галәм тутырды минем күзләрне.

Аh, каләмем төште-китте кулымнан!
Җан белән уеп язамын сүзләрне.

Офыкларда өр-яңа көн кабынган,
Кул болгыйм сиңа мәхәббәт тавыннан.
Күңелне уятыр, егълатыр өчен
Төштеңме әллә йолдызлар багыннан?

## Әкият һәм чынлык

Әкиятләргә шундый ышандым мин —
Алиһәләр иде хыялым.
Ә соңыннан барыбер, җиргә төшеп,
Мин җир кызын сөйдем, оялып.

Син әкият булып килдең миңа,
Чынбарлыктан, алсу таңнардан.
Мәхәббәткә безме кичеккәнбез,
Әллә инде еллар соңарган?

Беләм, аңлыйм: яхшы булып бетә
Әкиятләрнең генә азагы.
Мин һаман да җавап таба алмыйм —
Ничек булып бетәр
Безнең сөюләрнең газабы...

## Елап торган кызны юату

Ник тетрәде әле керфекләрең,
Нинди җилләр узды кагылып?
Күк йөзедәй төпсез күзләреңдә
Яшең эзе тора чагылып.

Син елыйсың...
Күктә кояш көлә,
Бал кортлары кайта басудан.
Карурманның яшел капкалары
Мәңгелеккә табан ачылган.

Елмаясың...
Күлдә аккош елый,
Дөнья елый аңа кушылып.
Зонтикларга, агач башларына
Яңгыр булып ява шушы моң.

Белми калсын, күрми калсын сөю
Чәчәк сабын җилләр кискәнне...
Ник тетрәде әле керфекләрең —
Әйтерсең лә дөнья сискәнде!

## Төн

Башкаеңны иңнәремә салдың —
Җиңел, татлы иде бу мизгел.
Шушы кичтә кайнар иреннәрне
Сөю шәрабенә тигездем.

Чәчкәйләрең биткә сибелде дә
Урап алды мине «буран»га.
Өр-яңадан мин әйләнеп кайттым
Яшьлек дигән якты урамга.

Кулларыңны күкрәгемә куйдың
Сагышларны читкә таратып,—
Йөрәгемне гүя сыйпап узды
Карлыгачның нәфис канаты.

Башкаеңны күкрәгемә куйдың,
Бар дөньяма ялкын сикерде.
Җир шарына тәңгәл авырлыкны
Мин күтәреп тордым шикелле.

Назга юлыктымы, ирләр җаны
Яхшылыкка таба үзгәрә.
Хатын-кызның серен аңлар өчен
Серле булу кирәк безгә дә...

## Телсез

Яшисен яшәгән,
Ашыйсын ашаган...
Ә дөнья — тавышсыз аҗаган.

Күңел сак, күңел сак.
Күңелдә төрле чак...

Шатлыгың уралса җаныңа —
Эх бер сүз!
Хәсрәтең тоз салса каныңа —
Эх бер сүз!
Сүгенер чагыңда — бушанма,
Тешеңне кыс та түз,
Тавышың очмасын җиһанга...

Эх бер сүз!..

# Рифә Рахман



## КОЯШЛЫ ҖӘЙ

### Җиңелрәк булыр

Агач куышына
качкан кояшыгыз,
«Чәчләреннән» тартып,
чыгарыгыз аны.
Бетә булыр тыны.
Тыны кысылганнан
Авыр булыр хәле.
Авыр сулаулары.

Агач куышына
качкан кояшыгыз.
Әллә шуңа гына
сездә төн — чем кара.
Чыгарыгыз аны —
еламасын җаны,
Җиңелрәк булыр,—
чәче йолкынса да...

* * *

Утырасым килми
Ап-ак урындыкка,
Өстемдәге күлмәк
Кара төстә булгач.
Тегәрҗебен сүткәч,
Ишелмәсә өстән,
Тузмас кесәләрен
Йолкып ат син, кояш!

Утырасым килми
Ап-ак урындыкка,
Каршымдагы егет
Яшел күзле түгел!
Ала, куя кулын
Өстәл өсләренә.

Күңле тыныч түгел,
Күңле тыныч түгел!

Утырасым килми
Ап-ак урындыкка.
Язмыш миңа ялгыш
Куйгандыр ла аны.
Каршымдагы егет
Сары чәчле түгел,
Авыр булыр миңа
Монда калулары.

Утырасым килми
Ап-ак урындыкка,
Өстемдәге күлмәк
Кара төстә булгач.
Төшми кесәләре,
Төшми күңелләрем
Кара чәчле ярга:
Андый күңелләрне
Йолкып ат син, кояш,
Йолкып ат син, кояш!.

* * *

Исәр санап йөри танышларым,
Кунма минем күзем карасына.
Кунма минем ап-ак битләремә,
Кешеләрдән шундый кыенсынам.

Алсуланган бит очларың, диләр,
Кемнәр үпте сине, үсендереп?
Кунма инде иннек эзе булып,
Яшим әле мин дә, кеше кебек.

Кунма инде ачык изүләргә,
Башкаларның төшә карашлары.
Ирле санап йөрер танышларым,
Кем дә белмәс синең яратканны.

Кунма минем керфек очларына,
Сирәгәйтеп санын керфекләрнең.
Һич теләмим чит-ят кешеләргә
Мине сөюеңне белгерткәнне.

Кунма минем күзем карасына,
Кун син минем эчкән чәйләремә.
Кайтар мине — җәйнең эсселәре
Чәйнекеннән эссе җәйләремә.

Исәр санап йөри танышларым,
Кунма инде иннек эзе булып.

Кунма, Кояш, ап-ак тезләремә,
Озын итәк киям, кыенсынып.

## Кояшка үпкә

Җилләр җыеп киткән инде
Өстәлдәге җәймәләрне.
Синең белән бу таңымда
Болдырымда чәйләмәдем.

Ялгыз эчкән таты чыкты
Күзләремнең карасына.
Карап торам тәрәзәдән
Үпкәләгән бала сыман.

Карап торам болытларга,
Горур китеп барганына...
Күзгә дигән яшь буылды
Чәйләмәгән тамагыма.

Өстәлдәге җәймәләрне
Таңда җилләр җыеп киткән.
Ул җилләргә, чү (!) димәгәч,
Кояш, сине сөймим бүтән.

## Кояш — тауда

Кояш — тауда.
Билге салырмын да,
Ул кузгалыр күкнең түренә.
Очкыннары коелыр
Сөйгән кызлы,
Сүнгән мәхәббәтле
Күңлемә.

Кояш — тауда.
Билге салырмын да,
Ул кузгалыр безнең якларга.
Туган авыл,
Кызым көткән йортка,
Тамга куеп киттем
Капкага.

Кояш — тауда.
Билге салырмын да,
Каплап торыр аны болытлар.
Сөйгән ярлар
Онытылып торыр,
Ерагайган сыман
Офыклар.

Кояш — тауда.
Билге салырмын да,
Үзем кояш булып янармын...
Сөйгәнемә,
Авыл, кызга, сезгә...
Кызыл алма булып
Тамармын.

* * *

И якты көнем, мин синең белән
Кушылган идем, сөелеп-сөеп.
Йөгерә аяклар, йөгерә аяклар
Зәңгәр күктә дә туфрак бар кебек.

Таулар артында ни көтә мине?
Аер тәнеңнән, мин калдым куркып.
Көл итеп сипсен исеп тынар җил.
Ут булып яныйм — кызарсын офык.

Мин синең белән кушылган идем...
Мин синең белән яшәгән идем...
Йөгерә аяклар синең артыңнан.
Аер тәнеңнән, и якты көнем.

Таулар артында бар сыман упкын.
Синең шикелле, гел уттан гына...
Гел утта яну ялкытты мине,
Инде башка яр ал кочагыңа!

Мин синең белән кушылган идем...
Мин синең белән яшәгән идем...
Яшәгән идем, сөеп, алданып,
Таулар артында — тугайлар диеп...

* * *

Язмыйм шигырь — кояш баткан чакта.
Көрмәкләнә төсле телләрем.
Авырайган башны сала калсам,
Почмакларын тешлим мендәрнең.

Өстәлемә шәм яндырып куям,
Шәйләнсә дә әле әйберләр.
Гөл таҗына бөртек яшем булып
Өзелеп кенә төшә бәгырьләр...

Язмыйм шигырь, кояш баткан чакта
Кәгазьләрем бетә бозылып.
Гөл яфрагын кайнар сулу тарта,
Иренемә килә сузылып.

Ни дияргә белмим аңа да мин,
Көрмәкләнә төсле телләрем.

Тәҗларына бөртек яшем тама
Тәрәзәгә яткан гөлләрнең.

...Тәҗларына бөртек яшем тама
Гөлгә кунып калган көннәрнең.

## Югалыр көн

Яфраклар булып тапталыр бу көн.
Югалыр шулай аяк астында...
Түгә хәсрәтен боеккан шәүләм
Яңгыр суына кереп баскан да.

Син читләп узган бу күлдәвектә
Көзнең кайгылы сурәте тора.
Ап-ак болытлар каралып үтә,
Баткан кояшым нәкъ уртасына.

Яфраклар төшә, яфраклар төшә
Чит-читләренә тайпылып юлдан.
Яфраклар булып тапталмас өчен,
Кереп басар көн үзе дә суга.

Кире кайтмассың — киткән юлыңны
Себерде инде, себерде җилләр...
Син коеп үткән сары яфракны
Бөртекләп җыйды бөтен җиреннән.

Син керми узган бу күлдәвеккә
Илтеп ташлады барысын өеп.
Мин баскан суның нәкъ уртасыннан
Таралды яфрак нәкъ кояш булып.



# ШИГЪРИЯТ



Тәүфикъ
Әйди

# КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ

ЭСТОНИЯГӘ СӘЯХӘТ

**Кеше туа да әйләнә-тирәсе белән таныша башлый. Бусагадан ишегалдына, аннан урамга, аннан авылның яшел чирәменә яки шәһәренең соры асфальтына аяк баса. Ә дөнья киң һәм серле — киңлек арты яңа киңлекләр ачыла, шулар адәм баласының акылына һәм хисләренә бай азык биреп, аны тормыш гыйлеме һәм тәҗрибә белән сугара.**

**Эстония — шундый киңлекләрнең берсе. Мин анда төрле елларда дүрт мәртәбә бардым һәм шул сәяхәтләр вакытында күргән, ишеткән, белгәннәремне шулай ук төрле вакытта кәгазьгә төшердем. Соңгы дәвердә Эстония аеруча күп үзгәрешләр кичерде, заманында мин китергән мәгълүматлар инде өлешчә искерде, мин сурәтләгән кайбер вакыйгалар инде үткенлеген җуйды. Шулай да бу язмалар укучыларга эстон халкын күзалларга булышыр дип өметләнәм.**

**Эстония күпләрне кызыксындыра, әмма аның белән танышу татар баласына бигрәк тә файдалы. Ни өчен? Сәяхәтнамә шушы сорауга җавап бирү өчен язылды да инде. Әйдәгез сәфәргә, Балтыйк буе сезне көтә, хөрмәтле укучым!**

## Милләт бишеге

Бу сүзләрне язып куйгач, күз алдыма яшь бер чибәркәй килә. Җитен чәчле, зәңгәр күзле, алма битле. Аның сурәте эстон язучысы Лилли Прометның «Примавера» романы тышлыгын бизәп тора. Башында — чәчәк такыя, муенында — чәчәк муенса, кызыкайның нечкә кашлары, туры борыны, чия иреннәре шундый килешле — чәчәкләр матур, чәчәктән битәр туташкай матур. Чөнки ул — яз образы, «примавера» — яз бәйрәме дигән сүз. Бу китапны, Таллиннда өенә баргач, миңа автор үзе бүләк итте, романының исемен дә үзе аңлатып бирде.

Әмма җитен чәчле, зәңгәр-яшькелт күзле, алма битле чибәркәй сурәт кенә түгел. Ул — тигез асфальт юл буендагы яшел яулык бөркәнгән

---

[1] Әсәр кыскартып басыла.

каеннар, сагызлы коңгырт-сары кәүсәләре кояшта ялтырап торган нарат-лар, урман аланнарын хәтерләткән, кырыйларында зур-зур йомры таш өемнәре күзгә бәрелгән җыйнак иген кырларыдай үк чынбарлык, мине Сууре Яани авылына кунакка чакырган ягымлы бала. Юк, эчкерсезлеге, кызыксынучанлыгы, яхшы күңеллелеге белән шулай тоелса да, ул инде җиләктәй пешеп җиткән кыз. Кыюлыгы, тәвәккәллеге белән исә яшьтәш-ләренең күбесеннән өстенрәк тә. Уйлап карагыз, Эстониягә дүртенче тапкыр килүем, һәрьюлы монда танышкан язучыларыма, журналист-ларыма: «Авыл — милләтнең бишеге, гореф-гадәтләр, милли культура бозылмый саклана торган җир, милли рухи халәтне бары шунда танып белү ансатрак. Бер эстон авылын күрү шәп булыр иде!» — дип әллә ничә тапкыр әйтеп карадым, берсе дә алып барырга ашыкмады. Дөрес, Лилли Промет белән аның ире Ральф Парве үз машиналарында Таллиннга орынып торган миллионер балыкчылар колхозына — шәһәрчә поселокка алып бардылар, әмма без аның урамын тәрәзәдән генә тамаша кылып үттек тә — вәссәлам. Анда инде милли йөзен саклаган эстон тормышын, ни тырышсаң да, барыбер күреп булмас иде. Моның өчен, мөгаен, республиканың берәр эчкәрегә төбәгенә бару кирәктер. Һәрхәлдә, мин шулай уйлыйм. Шөкер, мине хәзер автобус нәкъ әнә шундый үзем күрергә хыялланган җиргә алып йөгерә — анда мине туган авылы белән таныштырырга вәгъдә биргән түгәрәк якты йөзле Һелен-Веста көтә.

Эстоннарның салкын мөгамәләле, аз сүзле булуы күпләргә мәгълүм. Молдаван язучысы Ион Друцэ: «Таллинн аэропортында мин бер эстон кызыннан автовокзалга алып бара торган юлны сорадым,— ди.— Ул бер җавап та бирмәде. Шунысы кызык, автовокзалда без аның белән кабат очраштык, аннары бер үк автобуста Пярнуга утырып киттек. Ул мине танып, күреп торса да, монда да ләм-мим эндәшмәде!»

Чегәнне хәтерләткән молдаван язучысы, бәлки, кызыкайны шикләндергәндер? Хәер, Друцэның шаярып кына язмаганлыгын мин инде үзем дә яхшы сынаган кеше. Шулай да... әгәр әүвәл татарча бытылдасаң, аннары урысчаны мөмкин кадәр ватып-җимеребрәк эндәшсәң... Тик молдаван язучысы татарчаны кайдан белсен?!

Һелен-Веста исә — бөтенләй башка. Аның күпләргә охшамавы исем-фамилиясеннән үк күренеп тора — һәммәсе парлы-парлы. Анасы берне, атасы икенчене кушкан. Әмма безнең танышып китүебез моннан да мәзәгрәк әле!

Мин бу юлы Таллиннга республикаларыбыз арасында әдәби атналык алмашуның төгәл вакытын һәм программасын, шуңа бәйле бүтән мәсьәләләрне ачыклау өчен килгән идем. Эстония язучылары берлеге шул көннәрдә совет авторлары әсәрләрен дә чыгаручы Көнбатыш Алмания нәшире Йылдырым Дажйәле әфәндене дә кабул итте. Эшлекле сөйләшүләрдән соң Язучылар берлеге җитәкчесе Арво Валтон безне якындагы кафега алып китте. Кунак табынына җиде-сигез кеше тупландык, сул ягыма Арво кабинетында үзен шактый иркен тоткан бер яшь ханым туры килде. Аның язучы түгеллеге, монда ниндидер гаилә йомышын йомышлап килүе аңлашылгач, бер эстон каләмдәшемнең Дубултыда очрашкан чакта шаяртып сөйләнүе исемә төште. «Валтонда татар каны бар, ахры,— дигән иде ул.— Әллә биш, әллә алты тапкыр өйләнде инде, һәммәсе белән берәр бала үстерә. Шунысы гаҗәп: барысы белән дә тату яши, гыйшык маҗаралары эшенә дә зыян китерми — күп яза, ничек өлгерәдер!»

Кафеда төрек Йылдырым әфәнде белән гәп кору кызыктырганлык-тан, мин сул күршемә әллә ни игътибар бирмәдем, шулай да бер мәл аңардан:

— Сез Валтонның яшь бичәсеме? — дип сорап куйдым.

— Нәрсә, нәрсә?

Тулы гәүдәле ханымга ирексездән дикъкать беләнрәк карарга мәҗбүр булдым. Йә хода, кафедагы тонык яктыда да аның чырае бик яшь

күренүен абайламый мөмкин түгел иде! Берьюлы әллә ничә кунак әңгәмә куерткanлыктан, Һелен-Веста соравымны ишетеп бетермәгән иде бугай, әмма гаҗәпләнгән тавышы мине сагайтты, башлаган сүземне ирексездән үзгәртеп:

— Сез Арвоның яшь хат... дустымы? — дип кабатладым.

— Юк, юк, сез башкача сорау биргән идегез шикелле...

— Кирәкле урыс сүзе искә төшмәгәндә әллә ниләр әйтелә инде,— дидем мин гаепле елмаеп.— Сез шундый яшь, чибәр!

Ишетеп, аңлап җиткермәгән төсле кайтарып сораса да, ул миңем башта ни дияемне чамалаган, моңа кәефе дә кырылган сыман иде. Үпкәсен белдергән кебек:

— Мин аның олы кызы! — дип әйтеп куймасынмы.

Мондый җавапны, билләһи, көтмәгән идем. Саташуымны яшерер өчен:

— Сездә Арво чалымнары бар шул,— дияргә ашыктым.

Кирәк ләбаса шулкадәр игътибарсыз булырга! Атаклы язучыга кем гыйшык тотмас, әмма илле дүртен тутырган, комы коела башлаган иргә бишенче яки алтынчы хатын булып барырга, чынлап та, мондый бала базмас шул.

Автобусыбыз диңгез буеннан материк эченә — көньякка таба туксанйөз чакрым тизлек белән элдерә. Салон тулы булса да, тавыш-тын ишетелми, юлаучылар нигездә эстоннар, аларда сабырлык, вәкарь буа буарлык. Урыслар монда үзләрен тыйнаграк тотарга мәҗбүр, берәмсәрәм миндәйләр тирә-якны тамаша кылудан бушамый. Хозурланырлык ят нәрсәләр исә монда шактый: юл буенда, тирән урлар, ерымнар казылган кыр чикләрендә, бетмәс-төкәнмәс өемнәр — бозлык дәвереннән калган, җил-яңгыр, кар-буран ашап, шомартып бетергән Алып чуерташлар. Эстон игенчесе гомере буе кырын шулардан арындырырга тырыша — юкка гына икмәк кибетләрен металлны чүкеп яки тактаны көйдереп ясалган, аркасына таш күтәргән ир-ат сурәте белән бизәмиләр шул. Әнә шул ташлы, уңдырышлы катламы юка көлсу туфракта тамак туйдырырлык иген үстерү өчен җиде кат тирне чыгару кирәк. Шук телле Юри Туулик беренче очрашканда ук: «Быел Псков өлкәсендә иген-таруны җыеп ала алмадылар — татар-монгол явы комачаулады!» — диде. Псков кырлары Эстониягә орынып тора. Шунлыктан мин: «Ә сезнең уңыш ничегрәк булды?» — дип сорадым. «Гадәттәгечә, егерме биш-утызар центнер. Сез бит безгә ярдәмгә чалмыйсыз, әдәбият атналыгы үткәрергә генә тәкъдим итәсез».

Тирә-як куе яшел, урманы да, үләне дә күкрәп үсә, чөнки монда яңгыр килә дә ява, килә дә ява. Диңгезнең дымлы һавасы бөтен Эстонияне сугарып тора, җир сазлыкка әверелмәсен өчен йөзләгән-меңләгән чакрым канау-ерымнар казырга туры килә. Алар һәрвакыт су белән яртылаш тулып тора. Татарстанда явымлы көз урып-җыюны өзә торган зур бәла санала, ә Эстониядә мондый һава гадәти.

Балтыйк яры буендагы поселокларда иллюминатор кебек түгәрәк тәрәзәле һәм кораб кебек җыйнак, матур итеп буялган чүлмәк түбәле өйләр тезелеп киткән. Материкка үтеп кергән саен әле тегеә, әле бу ялан уртасында ялгыз утырган хуторлар күренеп кала, алар инде каеннары һәм чыршылары, печән кибәннәре, каралты-курасы, коесы, дранча түбәле озын йорты белән караеп утыра. Бездәге такта капка-коймалар урынына — тере куаклар киртәсе. Асфальттан шул хуторларга таш түшәлгән тар юллар сузылган — шөкер, ташка кытлык юк монда!

Эстониягә ничә килеп, эстон авылын күрә алмавымнан зарлангач, Һелен-Веста, атасы белән киңәшеп тә тормастан, кафедан Язучылар берлегенә кайтканда, миңа үзләренә барырга тәкъдим итте. Сууре Яани Латвия чиге буендагы Вильянди районына керә, хәзер шәһәр саналса да, ул чын борынгы эстон авылы, XVI гасырда ук үз чиркәве булган. Татарча әйтсәк, Зур Иван исемле икән, хәзер анда ике меңләп

кеше яши. Өйләре иркен, кич кунарга да мөмкин. Әнисе шулай ук иҗат кешесе — кинорежиссер, кунакка татар язучысы килүгә кыенсынмас.

— Ә сез... әти кеше белән күптән аерым яшисезме?

— Әйе,— ди Һелен. Аннары минем икеләнеп торуымны үзенчә фараз итеп өсти.— Әти мавыгучан ич ул, аны авантюрист хатыннар гел алдап тора. Чын гаиләсе исә бары безнең белән генә булды. Әни белән беркайчан да кычкырышмадылар. Әле былтыр мине әтием Австралиягә дә алып барды. Мин анда бер кичне ялгыз йөрергә чыгып китеп, адашып та калдым. Бераз инглизчә аңлаша идем, ят кешеләрдән юл сораша-сораша, төн уртасында гына кайтып кердем. Әти шундый курыккан!

Валтон исә безнең ниятkә ни өченлер артык сөенмәде, хәтта кызын эстончалап бераз кыздырып та алды шикелле. Бәлки, беренче хатыны, ташлаган иренә үч итеп, ул җибәргән кешене тиешенчә каршы алмас, дип пошынгандыр? Һелен исә атасын, һәммәсе әйбәт булыр, дип тынычландырырга тырышты. Аңлашулары эстонча барса да, мин шулайрак чамаладым. Һелен хәзер үк кайтып китәчәк һәм, кунак юлга чыкканчы, өйләрен җыештыра торачак.

Арво, ниһаять, телефонга ябышты, Сууре Яанигә шалтыратып, беренче хатынының кәефен ачыкларга тырышты. Сүз уңаенда минем турыда:

— Кунак бик тәрбияле, итагатьле кеше, бер генә зур кимчелеге бар — эстон авылын күрергә ашкына. Тәмам чәер кебек ябышты инде, котылыр хәл юк...— дип шаяртырга маташты.— Ә безнең Һелен нәкъ синең шикелле: кешелекле, якты йөзле — аны инде кунакка чакырырга да өлгергән. Ике республика дуслыгын ныгытуга үз өлешен кертергә ниятләгән, ахры...

Экспресс-автобус оча гына. Мин инде үзем төшеп калырга тиешле Выхманы узып китмим тагын дип борчыла да башладым. Күршеләрдән сорар идем, барысы да шундый битараф кыяфәттә йокымсырап утыра, авыз ачарга да икеләнерсең. Чү! Автобусыбыз киң асфальттан тарына каерылды — димәк, Вильянди районы мосафирларын төшереп калдырыр өчен, әйләнеч булса да, Тарту юлыннан Выхмага таба борылды, күрәсең.

Выхмада унлап кеше кечерәк автобуска күчеп утырдык. Бер кызыгы — шофер сәер касса аппаратының «колагын» боргалап, юлаучыларына үзе билет сатты. Буржуаз Эстония дәвереннән калган аппарат иде бу. Бәйсезлек дәвереннән!..

Заманында Сууре Яанида Вестаның ата-бабалары алма бакчасы үстергән. Өлкән буын теге дөньяга китү белән бакча да сирәкләнгән, өй тирәсе — ямь-яшел чирәм. Урам ягында тере койма — сәрви куаклары кайда билдән тигезләп кыркылган, кайда бөтен буена дивар булып күтәрелгән. Биләмәнең бер ягында — кечерәк бәрәңге бакчасы, суган, помидор түтәлләре. Биләмәнең түрендә — кос, ерак түгел — мунча, йорт алды белән шуларга карап тора. Ә капка ягында аерым келәт салынган. Биләмәнең түрендә корылган бүрәнә йортка терлек абзарлары тоташкан. Мунчадан ары биек агачлык — кеше кулы тимәгән табигать башлана. Кура куаклары, кычыткан чытырманлыгы да шунда. Биләмәнең иркенлеге шундый ки, аннан җәенә икс-өч тапкыр чабып алынган үлән, печән белән хәтсез терлекне кышлатырга мөмкин. Агачлыктан утын әзерләп, байтак еллар берәүгә дә ялынмыйча гомер кичерергә була. Әмма Вестаның анасы Вирве ханым печәнне башка җирдән чабып алып кайта, утынны да читтән китертә — Эстониядә бездәге кытлык сизелми, колхоз кыры тәмам авыл кырыена килеп терәлмәгән. Кысанлыкта тарсынып яшәгән татар монда килеп эләксә, билләһи, сөенеченнән яшел чирәмгә атылып тәгәрәр иде!

Бу биләмә кияүдән — язучы Арво Валтоннан күп игелек күрмәгән сыман. Бервакыт ул Йошкар-Ола сәфәрендә чакта ике-өч сәгатькә генә Казанга килгән, мин өйгә кайтып җиткән арада өстәлемә кәгазьләрен җәеп салып, нидер сырлый да башлаган. Гаҗәпләнгән хатыныма.

— Хәзер безнең күп гомер юлда уза. Вакытны әрәм итәргә ярамый, теләсә кайда иҗат итәргә кирәк! — дип аңлаткан һәм яңа әсәрен язуын дәвам иткән.

Билгеле инде, Сууре Яанидә ул язучылыгына аеруча дәртләнеп бирелгәндер, чөнки мондагы хозур иркенлек, тынлык, котырынып үскән яшеллек кочагында, бик еш сибәләгән яңгырлар тышка чыгарга кызыктырмаганда, каләмен кулыннан төшермәгәндер. Шуңа күрә ул мунча мичеңең яргалануына, биләмәдәге печәннең чабылмавына илтифат итмәгәндер. Вирве ханым да төшерәчәк яңа фильмнарының сюжетын, каһарманнарын уйлап йөргәндер. Әйе, Рейманнарның өлкән буыны алма үстереп, умарта үрчетеп, нык, иркен йорт-җир корып гомер иткән. Яшьләр алар эшен мираска алмаган. Хәзер бу биләмәнең иң яшь хуҗасы Һелен Тарту университетында укырга әзерләнә. Тел-әдәбият белгече булырга. Әсәрләре утызлап телгә тәрҗемә ителгән талантлы язучының кызы сүз сәнгате белән мавыгу гаҗәпмени?!

Гасыр башындагы эстон авылы тормышын Рейманнар утарында бик ачык күрәсең. Абзар тулы терлек асраганнар — хәзер берничәшәр баш сарык белән тавык кына калган. Тышка аерым ишеге булган киң, тирән идән астының имән такталардан корылган шүрлекләрендә кайчандыр тонна-тонна алма сакланган — алар хәзер буш. Өйдә гомер буена чыдарлык итеп ясалган зур имән өстәл, караватлар — аларның кара буявы әле дә кырылып бетмәгән, лаклары гына тоныклана төшкән. Сары шкафларда нәселдән нәселгә туплана килгән савыт-саба. Бәллүре дә, фарфоры да җитәрлек. Беренче эстон энциклопедияләре, калын-калын сүзлекләр, кино сәнгатенә багышланган китаплар, матур әдәбият. Бормалы баскычтан чарлакка күтәрелсәң, җәйләрен рәхәтләнеп торырлык бүлмәгә килеп эләгәсең.

Терлек абзары өйгә тоташкан, явым-төшемле яки салкын көннәрдә эчке ишектән туры шунда узып, малларны карарга мөмкин. Әмма мондый уңайлыкның җайсыз ягы да юк түгел: абзарның «хуш» исләре өй эченә саркып керә, җәйләрен исә чебен-черки болыты ишек-тәрәзә ачылуын сагалап кына тора.

Сууре Яанидә гасыр башы белән гасыр ахыры бергә яши икән. Радио, телевизор, суыткыч янәшәсендә керосинка һәм каба. Дәү табакка су салып, шунда бит-кулыңны юасың. Мунчада исә су мичкә кертеп урнаштырылган зур түгәрәк казанда җылытыла. Егерменче йөз су краннары әле монда юк, әмма болдырында — тактаны көйдереп ясалган матур сурәтләр эленгән. Мунча иркен, сәке-урындыклары озын вә киң — утынга аптырамаган кеше салган аны.

Кунакчыллык тулы күләмдә күрсәтелсен, дипме, Һелен мунча ягарга тәкъдим итте. Кое — ун адымда, утын әрдәнәсе тагын да якынрак, мунчаны юып чыгарасы да ягып җибәрәсе генә бар. Әмма кояш кызарып баеп бара, ул мәшәкатькә керешсәң, Сууре Яани белән танышырга вакыт калмас та. Иртәгә инде кайту ягына чыгасы. Шуларны уйлап, рәхмәтемне әйтәм дә мунча йоласыннан баш тартам. Елдам гына чәй эчеп, үрдәге зиратка китәбез.

Зират — тарих. Бүген Сууре Яанидә ике меңләп кеше яшәсә, аларның элгәреләре, бәлки, инде ике йөз меңнән артык булгандыр. Бу дөньяга килгәннәр дә өмет, хыял белән яшәгәннәр, бер буын икенчесеннән әземкүпме белем, тәрбия һәм тәҗрибә алган, үз эзләнүләре, хезмәтләре белән шуларны тагын да бөтәйтергә, тормышын яхшыртырга тырышкан. Чатнама суыклар, чиләклəп койган яңгырлар, җил-давыллар, ваба кыргыны, Тевтон ордены, швед короле, урыс илбасарлары һөҗүмнәре — берсе дә Сууре Яанигә кагылмый узмаган. Шуларга бирешмәскә тырмашып, буын арты буын өзлексез көрәш алып барган, үзләреннән соңгыларга нидер мирас итеп калдырырга тырышкан. Яшел чирәм арасыннан сузылган тар асфальт тасма, шәһәрчекне ярып узган елгадагы тимер-бетон күпер, урамнардагы куе ябалдашлы агачлар, кара дранча һәм кызыл чүлмәк

түбәле өйләр, каралтылар — инде бу дөньядан китеп өлгергәннәрнең дә истәлеге. Зиратның ком сибелгән аллеяләреннән атлаганда, агач яки тимер рәшәткә белән киртәләнмәгән кабер өсләрендәге ташларны, җиргә кырын яткырылган мәрмәр такталарны карап, алардагы язуларны укып узабыз. Һелен үзе белгән әби-бабаларын, аларның мактауга лаек эшләрен телгә ала. Һәр кабер өстендә — тере чәчәкләр, шуның янында — дога кылып утырыр өчен таш яки агач урындыклар. Зират караучы алачыгыннан көрәк яки чиләк алып килеп, якыннарың каберен тагын да тәртипкә китерергә телисең икән, рәхим ит!

Зиратта йөрү мизгел һәм мәңгелек, көндәлек вак ыгы-зыгылар һәм гомерлек бөек эшләр, гөнаһлы һәм саваплы гамәлләр турында уйлата, үзеңнең бу дөньяда кунак кына булуыңны кабат-кабат исеңә төшерә.

Берәүләр бәхетле яшәсә, икенчеләр канәгатьлек тапмаган бу дөньяда. Әмма Сууре Яани халкы өметсезлеккә бирелмәгән, мәңгелек хакында уйлаган һәм гамәл кылган. Без монда эстон музыкасында якты эз калдырган композиторлар М. Саар, Й. Капп, В. Капп, дирижер В. Каап, нагышчы И. Келер хөрмәтенә баш идек. М. Саарның аерым башкаручылар һәм хор өчен язган җырларын, сюиталарын, В. Каппның киң билгеле романсларын, кантата, симфоник поэмаларын эстоннар әле дә яратып тыңлый...

Салкынча җил исә башлап, безне урыныбыздан кузгата. Караңгы зират аллеяларына кире ураласы килмәгәнлектән, кәҗә сукмаклары буйлап, шәһәр урамына төшәбез. Мәдәният йорты тирәсендә кинога килгән төркем-төркем тамашачылар күзгә чалына. Монда һәркем көяз, горур кыяфәтле, аз сүзле. Якындагы эчемлекләр кибете тирәсе купкә җанлырак — сыра дигәнең сүзгә саран ирләрнең телен чишкән кебек күренә.

Өйдә инде Вирве ханым кичке табын әзерләгән иде. Сүз җилеме өчен графин белән шәраб та килде. Йоланы үтәр өченме, беренче тост әйтүне миңа тапшырдылар. Әнкәле-кызлы синнән юньле теләк ишетергә җыенгач, сынатырга ярамый иде.

— Кадерле дуслар! — дидем мин. — Җыр бәйрәменең йомгаклау тантанасына эстон халкының биштән бер өлеше Таллиннга җыйнала һәм 200000 кеше беравыздан туган көйләрен яңгырата. Бер миллион эстон туган телендә ел саен уртача мең ярым исемдә китап һәм 104 исемдә журнал чыгара. Шушы хакта белгәч, аз санлы халыкның сокланырлык милли рухы, казанышлары белән танышасым килде. Бездә мең тапкыр ишетүгә караганда бер тапкыр күрү артык, дип юкка гына әйтмиләр. Килгән саен монда танышларым арта бара, халкыбызның гыйбрәтле тарихы һәм бүгенге матур эшләре миңа яшәү дәрте өсти — сезгә шуның өчен чын күңелдән рәхмәт...

Бәлки бу сүзләр кемгәдер купшы шикелле тоелыр, тик мин, чыннан да, ихлас уемны әйттем. Хуҗалар да моны нәкъ шулай тиеш сыман кабул итте. Кем кем, әмма алар үз бәясен белә иде!

Әллә, чыннан да, үзенә тугрылык сакламаган иренең дусты итеп кабуллады — Вирве ханым миңа артык ачылып китмәде. Сораулары да гади итагатьлелек үрнәге иде.

— Сууре Яани Татарстан шәһәрләреннән аерыламы?

— Сез Эстония турында язарга җыенасызмы?..

Билләһи дип әйтәм, ул бу сорауларга җавапны алдан ук белеп тора иде! Әмма йоланы үтәмичә булмый... Чөнки йола, гореф-гадәт кысасында яшәү канга сеңгән, табигый мәҗбүрияткә әйләнгән. Ата-баба рухына тугрылыкны изге санаган эстоннарда бигрәк тә.

Йола, гореф-гадәт законнан өстенрәк, чөнки алар элгәрерәк барлыкка килгән, гасырлар кичеп сыналган, дөрес һәм гадел, файдалы һәм кирәкле булуы шик уятмый торган тотрыклы кыйммәткә әверелгән. Милли йолаларын һәм гореф-гадәтләрен кадерләп саклаучы халыкның гына киләчәге бар.



*Ратуша мәйданы*

Эстония башкаласының тарихи үзәге — Ратуша мәйданы. Ратуша — урта гасырлардагы шәһәр идарәсе. Аның бинасы Таллиннда 1371—1401 елларда корылган һәм ул бүген бөтен Балтыйк буенда сакланып калган шундый бердәнбер архитектура һәйкәле. Әлбәттә, ул соңрак күпмедер яңартылган — 1436 елда түбәсе чүлмәк белән ябылган, 1530 елда аның чатыры башына сугышчы (карт Тоомас) кыяфәтендәге флюгер куелган, 1630 елларда чатыр өстеннән готик стильдә шактый биек манара калкытылган һәм флюгер да шуның башына күчерелгән.

Әмма аның борынгылыгы барыбер шик уятмый. Заманында аны корыр өчен кирпечләр берәм-берәм кәгазьгә төрелеп Алманиядән китерелгән, ныклык өчен измәне, камыр кебек, йомырка сытып ясаганнар.

Ратушаның беренче катында сәүдә иткәннәр, икенче катында шәһәр идарәсе утырышлары уздырылган. Шушында ук хөкем эшләре каралган. Чардакта һәм иң аскы катта сәүдәгәрләр малы сакланган.

Ратуша мәйданындагы тагын бер борынгы бина игътибарга лаек — анда Аурупадагы иң элгәреге даруханәләрнең берсе эшли башлаган. Язма чыганакларда 1422 елда искә алынган бу аптека әле дә туктаусыз хезмәт күрсәтә.

Ратуша мәйданы ерак гасырлардан бирле төрле тантаналар — яңа ел бәйрәме һәм карнаваллар, тамашалар һәм күңел ачулар уздыру урыны. Шундый бәйрәмнәрнең берсендә (1711) монда Рәсәй патшасы Беренче Петр да типтереп алган. Алман бароннары, швед һәм датчан аксөякләре дә монда хуҗаларча рәхәт чиккән. Һәр ташыннан тарих сулышы бөркелгән Ратуша мәйданында бер килүемдә мин дә фольклор бәйрәменә тап булдым — төрле шәһәрләрдән һәм авыллардан җыйналган эстоннарның җыр-биюләрен тамаша кылдым. Аннары шушы мәйданга орынып диярлек торган Язучылар берлегенең дүрт катлы яңа бинасына кереп, каләмдәшләрем белән таныштым. Эстон әдәбиятының тарихи дәвамчанлык рухын аеруча нык саклап үсүе миңа Язучылар берлегенең Ратуша мәйданына якынлыгына бәйләнгәндер сыман тоелды. Монда милләт тарихына әдәбият тамырлары килеп тоташкан, символик бердәмлек табигый муафыйклыгы белән кушылып, сәламәт әхлакка дәрман өстәп тора шикелле.

Теге яки бу ил белән танышу өчен анда бару һич тә мәҗбүри түгел, билгеле. Бер яхшы китап, бер әйбәт фильм да аны шактый тулы итеп күз алдына бастыра ала. Әмма сәяхәт итү мөмкинлеген, анда шул ил, халыкның белдекле, күренекле вәкилләре белән аралашу форсатың бар икән, нигә аны кулдан ычкындырырга?

Мин үзем Эстония хакында байтак белешмәлекләр актардым, эстон әдәбияты җәүһәрләрен байтак укыдым, хәтта тәрҗемә дә иттем — мәгълүматым, тәэсирләрем аз тупланмады. Әмма Лилли Промет, Айн Ка-

алеп, Арво Валтон һәм бүтән эстоннар белән утырдаш булу, дәвамлы аралашу Эстонияне генә түгел, гомумән дөньяны, тормышны кителмәгәнчә тирәнрәк танып белергә, һич тә өметләнмәгән гыйбрәтләр ...лырга сәбәп булды.

Вакыйгаларның эзлеклелеген сакларга тырышсак, Сууре Янигә киткәнче, кафедра сыйлану, аннан да элегрәк исә Язучылар берлегендә танышу әңгәмәсе булды. Берлекнең рәис урынбасары Арво Валтон, җаваплы секретаре Үло Туулик Алмания кунагына Эстония һәм аның әдәбияты турында сөйләделәр, нәшир Йылдырым әфәнде Дажйәле сәфәр чыгуының максатын аңлатты.

Таллиннга чит ил, бигрәк тә Көнбатыш Германия нәшире килүе аның эстон әдәбиятын тәрҗемә итеп чыгарырга җыенуы Язучылар берлеге җитәкчеләрен, әлбәттә, җанландырып җибәрде. Татарстан белән әдәби атналык уздыру зыян итмәс, әмма ул качмый, ГФРда әсәреңне чыгару ихтималы тагын да кызыктыргычрак лабаса!

Әдәби атналык уздыру мәсьәләсен Пауль-Ээрик Руммо, Үло Тууликлар эленке-салынкы гына хәл итеп маташканда, Алмания нәшире визиты Язучылар берлеге әһелләрен минут эчендә диярлек тәмам аякка бастырды — Валтон кабинетына бик тиз арада ЯБнең чит телләрдә иркен сөйләшә алырлык барлык хезмәткәрләре, «Лоомиң» әдәби журналының баш редакторы һ. б. җыелып өлгерде. Бу ыгы-зыгыны бераз күләмсерәп күзәтеп торгач, мин китәргә җыендым. Әмма үткен психолог А. Валтон, йөземә күз төшерү белән, ниләр уйлавымны чамалап алды һәм иң гөнаһсыз төстә:

— Тәүфикъ, төрек белән очрашу сиңа да кызык булыр, монда кал син! — дип тәкъдим итте.

Ярый әле тәкъдим итте! Чөнки мин бу мәҗлестә катнашмасам, Валтонның нинди тапкыр һәм шаян кеше икәнлеген белми калган булыр идем. Әсәрләрендә ул — усал сатирик, үтергеч көлү һәм мыскыл итү остасы.



*Арво Валтон*

Арво Валтон нәкъ менә мин килгән көннәрдә генә Язучылар берлеге рәисе урынбасары вазифасын өстенә алды. Урынбасар аталса да, чынлыкта ул рәисе иде. ЯБ идарәсе мактаулы рәис итеп күренекле язучы һәм сәяси эшлекле Владимир Бээкманны сайлаган. Әмма ул кыйммәтле вакытын Мәскәүдә һәм Таллиннда депутат, төрле дәрәҗәле урыннарда әгъза булып уздырганлыктан һәм киеренке иҗат эше белән дә шөгыльләнгәнлектән, ЯБ рәисе хезмәт хакыннан баш тарткан. Шуннан соң мәшһүр шагыйрь Пауль-Ээрик Руммо белән прозаик Арво Валтонны яртышар вазифага аның урынбасары булырга ризалатканнар. Минем күз алдымда П.-Э. Руммо эшләрен А. Валтонга тапшырды, чөнки ул елның яртысын армый-талмый язучыларны кайгыртып уздырган, хәзер инде аксый башлаган иҗатына бирелергә ашкына иде. Эстония ЯБ идарәсе Татарстан белән әдәби атналык алмашуны хупласа да, Руммо аны гамәлгә ашырырга һәвәслек күрсәтмәгән иде. Ихтимал, ул күп кенә эстон каләмдәшләре кебек, Көнбатыш белән бәйләнүне файдалырак санагандыр. Арво Валтон

исә рухы белән башкарак кеше иде. Үзлегеннән инглиз теле өйрәнсә дә, язмыш аны Шәрекъ белән дә бәйләгән — бала чагында Себер сөргенենә илтеп ташлаган, монда аңа төрле милләт вәкилләре белән аралашырга туры килгән. Чыңгызханга багышлап роман язуында да бәлки шул «хаҗ» сәфәре зур этәргеч биргәндер. Ул гына да түгел, тормышның гаделсезлеген үз язмышында тату, аз санлы халыкларның ачы михнәтләрен күрү Валтонны СССРның милли азчылыклары хокукын яклаучы чын көрәшчегә әйләндергән иде. Шунлыктан, ул ЯБ рәисе урынбасары вазифасын өстенә алган сәгатьтән Татарстан белән әдәби атналык уздыру мәсьәләләре дә бик тиз һәм иң әйбәт рухта хәл ителә башлады.

Ләкин бу турыда соңрак. Хәзер исә Валтон кабинетында нәшир Й. Дажйәлене һәм аны Мәскәүдән озата килгән кешеләрне кабул итү бара. Арво, мин дә аңласын өчен, урысча сөйли, аны хезмәткәрләренең берсе алманчага тәрҗемә итеп тора. Арво алманча да аңлый, әмма кайтарып сөйләргә кыенсына, ул инглиз телен өйрәнүгә күбрәк игътибар биргән. Йылдырым бәй ГФРда егерме биш ел яши икән, алманча бик шәп сиптерә. Аны берәү дә ни эстончага, ни урысчага тәрҗемә итеп мәшәкатьләнми, чөнки алманча төшенмәгән эстон язучысы, мөгаен, юктыр. Йылдырымны озата килгән әзәрбайҗан язучысы һәм Мәскәү марҗасы тәрҗемәгә мохтаҗдыр, әмма эстоннар моны юри аңламамышка салыша. Бәлки, алар да, Мәскәү марҗасын язучы буларак белмәгәнлектән, КГБ «күз-колагы» дип фараз иткәндер? Мондый очракта аңа инде тел белү фарыз, югыйсә ниндидер нәширне нигә әле икешәр кеше озата йөрергә тиеш?

— Без Аурупада аборигеннар,— дип башлый сүзен А. Валтон.— Балтыйк буенда инде биш мең еллап яшибез. Алманнар теориясе буенча, без Себердән килгән, имеш. Хата! Бозлык дәверендә үк эстоннар Карпат тавы буенда яшәгән, шунлыктан мин үзебезнең Аурупада иң борынгы халык булуыбызга ышанам. Һинд-европалылар исә Кафказ һәм фин-угыр кабиләләре катнашмасы дигән фараз да бар, алар бу кыйтгага соңгырак заманнарда күчеп килгән...

Шаккатып тыңлыйм, чөнки мин укыган китапларда эстоннарның бабалары фин-угырларның төркиләргә кардәшлеге, аларның бик үк ерак булмаган дәвердә Идел-Уралда күрше булып яшәүләре генә язылган иде. Әмма Валтонны сүзеннән бүлеп сорау бирмим, европалы буласы бик тә килә икән — булсын, һәр халык үз тарихын үзе тикшерсә, үзе язса хәерлерәк ич!

— Эстон теле төзелеше буенча төрки телләргә якын, яңа сүзләр тамырга өсте-өстенә кушымчалар ялгау юлы белән ясала, бездә дә җенес күрсәткече юк,— дип дәвам итә Арво. Бүлмәсендә утырган төрек белән татарга күңелле булсын дипме, шулчак безгә елмаеп төбәлә дә: — Күрәсез, Азия белән дә бәйләнешләребез бар,— ди.— Әмма грамматикабызда киләчәк заман юк. Шуңа күрә алманнар безнең хакта: «Димәк, тулаем эстон милләтенең дә киләчәге юк!» — дигәннәр. Алманнар Балтыйк буена килде дә китте, ә без һаман шушында яшәп маташабыз үзе... Телебез Азиягә якын булса, мәдәниятебез Балтыйк буеныкы.

— Эстония мәдәнияттә Скандинавиягә тартыла,— дип өсти Үло Туулик.

— Әдәбиятыбызда урыс йогынтысы сизелми,— дип дәвам итә Арво.— Аурупа тәэсирендә алга барганбыз. Күршеләребез латыш, литваннар да шулай. Без алар белән тату, дус яшибез, әдәбиятларыбызны үзара тәрҗемә итешәбез. Литваннар поляк белән, латышлар алман белән тыгызрак аралашкан, бу хәл аларның әдәбиятын үстерүгә дә шифалы тәэсир иткән. Әдәбиятта, бигрәк тә прозада, без латышлардан, аеруча литваннардан калышабыз шикелле. Әмма без күршеләрдән бер нәрсәбез белән алда: Балтыйк буеның иң биек тавы — Эстониядә! Сууре

Мунамягинең биеклеге 318 метр. Латвиядәге иң биек тау 315,5 метр гына. Безгә тигезләшер өчен күршеләребез аны балчык ташы биегәйтергә әзер, әмма балчык запасы Эстониядә дә бар...

Республикабызның мәйданы Татарстанныкының өчтән икесе кадәр, халкы Татарстанныкының кырык проценты чамасында,— ди Валтон җитди кыяфәттә.— Әмма без күлләр һәм бигрәк тә сазлыклар мәйданы буенча Татарстаннан да, Төркиядән дә шактый өстенрәк. Җиребезнең биштән бер өлеше сазлык булу безнең өчен аеруча зур горурлык!

Түгәрәк-тук йөзле Йылдырым бәй Валтонның юморына тиешле бәяне биреп, көлеп җибәрде.

— Халык тыгызлыгы Татарстанда бер квадрат чакрымга 54 кеше туры килсә, бездә — 35,— дип дәвам итә Валтон.— Әмма бу тармакта да шатланмый хәлебез юк: Гренландиядән мең ярым тапкыр өстенрәк ич без! Эстоннарның милли җене барлыгын да онытмыйк. Дөрес, ул бераз ахмаграк, әмма явыз түгел.

Йылдырым бәй шул арада Эстониядә халык санының табигый артуы белән кызыксына. Валтонның фабрикаларда һәм фермаларда, мәктәпләрдә һәм институтларда, шәһәр мәйданнарында һәм авыл клубларында көненә өчәр-дүртәр мәртәбә чыгыш ясавы тикмәгә түгел икән, сорауга яшен тизлегендә җавап бирә:

— Мең хатынга туры килгән балалар саны буенча Эстония Латвиядән генә калыша. Арттан караганда! Латвия исә бу җәһәттән СССР күләмендә арттан беренче. Ә без — икенче, шулай ук призлы урында. Эстониядә һәр гаиләдә уртача өч кешедән тора.

Үло Туулик дөньяны аркылыга-буйга гизгән җитди кеше, инглизчә, алманча, финчә иркен сөйләшә, французча укый. Валтонның шаярып гәп коруы кунакларда эстоннар турында әйбәт тәэсир калдыруына хәвефләнеп, сүзне күңеллерәк нәрсәләргә борырга тырыша.

— Эстония әдәбиятының халыкара элемтәләре бик киңәйде хәзер,— ди ул.— Финляндия, Швеция белән тыгыз хезмәттәшлеккә кердек, Скандинавия илләре җыеннарына еш чакыралар, Таллиннга бүтән илләрдән дә кунаклар һәм вәкилләр күп килә...

Валтон, күзләрен очкынландырып, реплика кыстыра:

— Бетә торган милләтне күреп калырга ашыгалар!

Үло Туулик бирешми, сөйләшүне моннан соң да җитди эзгә кертергә талпына.

— Без, хәтта, кайбер багланышларыбызны чикләргә дә мәҗбүр — җитмибез. Бөтенебез дипломатка әйләндек, әмма эстоннар җәмгысе дә бер генә миллион лабаса! — ди ул.

Үло Туулик белән беренче мәртәбә күрешкәндә үк мин аңардан эстон язучыларының чит илләргә барып йөрүе, анда әсәрләрен бастыруы хакында байтак мәгълүмат алган идем инде. Кызганыч ки, мин ул чакта әле аның чит илләргә багышланган сәяхәтнамәләрен укымаган идем. Соңрак мин аның Кампучия җәһәннәмен сурәтләгән «Биек күк» эссесе белән таныштым, авторның сүзгә бәрәкәтле, күзәтүчән һәм тирән белемле булуына сокландым. Хәер, «Артыш корылыкка бирешми» романын укыганда мин аның талантлы язучы булуын, кыска, әмма тыгыз язуын күреп ышанган идем инде. Мондый кешедән кайбер нәрсәләрне төпченеп утыруым аңлашыладыр: автономияле республика шартларында яшәгән татар язучыларына чит илләр белән бәйләнешкә керү үзе генә дә 1989 елда әле бик тансык, сирәк эшкә ашырыла торган бер гамәл иде. Эстоннар исә бу өлкәдә бездән күп алга киткән иде. Бердән, союздаш республика статусы аларга киңрәк мөмкинлекләр ачкан, икенчедән, аларга Финляндия нәтиҗәле булышып килә, дус ил саналганлыктан, Суоминың бу тырышлыгына Мәскәү каты бәрелми иде. Эстон әдәбиятының Көнбатыш зәвыгына һәм традицияләренә йөз тотып үсүе, күп кенә язучыларының берничә чит ил телен үзләштерүе дә соңгы рольне уйнамагандыр. Илләре бәйсез чакта Эстония язучылары оешмасы 1928 елда ук ПЭН-

клубка — Европа язучылары оешмасына әгъза булып керергә өлгергән. Көнбатыш әдәби процессына катнашырга тагын бер мөмкинлек алган иде. Сталин режимы Балтыйк буе җөмһүриятләрен көчләп СССРга «кушкач», чит илгә качып китәргә мәҗбүр булган эстон язучылары ватаннарында калган каләмдәшләренә булышуны һәрчак истә тотып яшәгән. Тоталитар коммунистик режимның хөр сулышны буып торган кысымы бераз йомшауга, әлеге факторлар һәммәсе бергә тоташып, эстон халкын тиз арада өметсезлектән уятуга, аның мәдәниятен җанландыруга кискен этәргеч биргән иде. 1989 елда Казанда хәбәрдарлык, хөррият, милли җанлану хәрәкәте кыюсыз һәм зәгыйфь кенә баш калкыта башлаганда, Эстония инде дөрли, аның авазы СССР күләмендә генә ишетелми, Көнбатыш җәмәгатьчелегенә дә иркен барып җитә һәм халыкара яклау казана, бу исә Мәскәү басымын тагын да сүлпәнәйтүгә китерә иде. Милли уянуны туендырып, көчәйтеп торучы бер көчнең нәкъ менә язучылар булуын мин Таллиннга һәр килүемдә һаман яхшырак төшенә бардым.

— Тышкы бәйләнешләребезне киңәйтү өчен без даими эзләнәбез,— диде миңа Ү. Туулик.— Мәскәү безне дә СССР вәкиле итеп чит илләргә чыгарырга бик ашкынып тормый. Ул анда ни чит илләр әдәбиятын, ни чит ил телен белмәгән Язучылар берлеге чиновникларын җибәрә, аларга инде берәр тәрҗемәче дә тагарга туры килә. Без исә чит илләр әдәбияты йөрәк тибешен яхшы тоеп яшибез, асыл нөсхәдән күп тәрҗемә итәбез, язучыларыбыз берничә чит телне су кебек эчә, кыскасы, эстонны чит мәмләкәткә алып бару күпкә файдалырак, тылмач йөртеп, валюта туздырасы юк! Без совет әдәбиятлары илчесе булырга күптән әзер, әмма Мәскәү өчен сөйкемле сөяк кенә була алмадык. В. Бээкман, А. Сийг көч хәл белән берәр мәртәбә совет вәкиллеге составына керә алды — шуның белән тәмам!.. Үз кабыгыңда йомылып яшәү ярамый — шул сәбәптән без хәзер Мәскәү катнашыннан тыш багланыш урнаштырырга кирәк. Чит ил нәшриятләре, университетлары, төрле вакыфлар белән багландык.

— Ә сез кем акчасына йөрисез соң? — дидем мин.— Валютаны кайдан табасыз?

— Министрлар кабинеты, мәдәният министрлыгы, чит илләр белән дуслык җәмгыяте булыша. Гадәттә, безне чит илдән үз хисапларына чакыралар. Көнбатыш мәмләкәтләрендә аз санлы халыклар үсешенә ярдәм итү вакыфлары бар, табарга гына кирәк. Алар безне хәзер хәтта бер айга иҗат йортларына да чакыра. Чит илләрдә лекцияләр сөйләп, анда басылган китаплары өчен каләм хакы алып, баеп кайтучы каләмдәшләребез дә бар. Тиздән мөмкинлекләребез тагын да киңәячәк. Һилсинкидә «Эстон телендә барлыкка китерелүче культурага ярдәм вакыфы» оештырыла. Финляндиядәге төрле ширкәтләр, байлар, хәлле мөһаҗирләребез аның карамагына бер ярым миллион фин маркасы күләмендә акча бирәчәк. Ул акча Һилсинкидә сакланачак. Әлеге вакыфны идарә итәр өчен алты кешелек бер комиссия кордык. Вакыф чит илләргә баручы мәдәният эшлеклеләребезне, читтә укучы иҗат яшьләребезне матди яктан тәэмин итеп торачак.

Рәсәй корсагына башы-аягы белән кереп бетеп, тышкы дөньядан тәмам аерылып, ихтыярсыздан үз эченә бикләнеп калганлыктан, без 1989 елда халыкара әдәби хәрәкәтнең баганалы төп юлыннан еракта шактый тоның, төссез тормыш белән яшәп ята идек. Үло Тууликның Һилсинки, Лондон, Стокһольм белән финчә, инглизчә, алманча телефоннан сөйләшүен күзәтеп утырганда мин моңа бигрәк тә ныграк ышандым. Ул күз алдымда Һилсинкидәге Ф. Туглас (эстон әдәбияты классигы) җәмгыяте утырышында Эстония вәкиле катнашуы, Стокһольмнан алты швед язучысының Таллиннга килүе, Лондонда бер каләмдәшенең әсәрен инглиз телендә бастыру хакында киңәште һәм мәсьәләне уңай хәл итәр өчен бер адым атлады. «Без кышкы буран каплаган Чирмешән яки Чүпрәле

районы хәлендә икән,— дип пошындым мин.— Алар мондый вакытта Казаннан тәмам аерылып кала — тимер яки су юлы булмаудан тыш, автомобиль һәм һава юлыннан да мәхрүм була, хәтта телефон элемтәсен дә югалта!»

Базар икътисадына күчү әдәбиятны авыр хәлгә куюын да Эстония бездән алдарак татыды. Җан исәбенә унбер китап чыгарып килгән республика (без — 0,7) яңа шартларда артка тәгәри башлады. Әсәрләре монарчы зур тиражда басылган эстон каләмдәшләребезнең өчтән бере каләм хакына шактый иркен яши ала иде — үзгәртеп кору моңа бик тиз чик куйды.

— Фәннәр юлыннан атларга туры килер,— диде миңа Үло Туулик.— Аларда сатылган һәр китаптан уналты процент керем авторга тия. Китапханәләр дә авторларга, әсәрләре укылу ешлыгына бәйле рәвештә, каләм хакы түли. Язучыларын бөлгенлектән коткару өчен дәүләт һәм төрле вакыфлар стипендияләр булдыра. Иҗатының уңышлы дәвам итүенә карап, каләмдәшләребез аны унбиш ел буена яки кимрәк вакыт алып торырга мөмкин. Инженерның уртача хезмәт хакы күләмендә...

Балтыйк буе халыклары белән безнең ата-бабаларыбыз да кызыксынган. «Шура» (1909, № 17) журналында Юлдаш углы бастырган «Латышлар, эстоннар вә без» мәкаләсендә эстоннарның саны 1897 елда бер миллион ике йөз меңгә җитүе һәм аларның безгә кан-кардәш булуы билгеләп үтелгән. «Җиде йөз ел элек алар алманга буйсындырылган, лютеран чиркәвендә чукындырылган, латин хәрефендә укый-язалар,— ди автор.— Алманнар аларны алманлаштырырга тырыша, ләкин эстоннар туган телләрен, гадәтләрен һәр нәрсәдән газиз тотып киләләр... Тырышлыкларын мактап бетерерлек түгел. Әле ун ел элек кенә алманнан һәрнәрсәдә түбән иде... Хәзер укый-яза белмәгән кеше табылмый. Укыган яшьләр милләтенә хезмәт итүне бурычы саный — мөгаллим, доктор була, җәмгыятьләр оештыра... Бары үзләренә генә таяналар, дөньяда эшләү мөмкин булмаган нәрсә юк дип ышаналар... Шул сәбәптән хәзер Русиянең иң алдынгы бер кыйсемен тәшкил итәләр».

Автор эстоннарның төрле һөнәрләр үзләштерүенә, игенчелектә дә зур уңышка ирешүләренә соклана һәм милләттәшләрен шулардан үрнәк алырга өнди.

Дөрестән дә, эстоннар нәкъ менә соңгы дәвердә күтәрелеп китә. Мәгариф һәм мәдәният учаклары анда күп гасырлар элек барлыкка килә, тик алар хаким милләтләр — датчан, швед, тевтоннар (алманнар) тарафыннан нигезләнә һәм шул телләрдә эшли. 1887 елда исә барлык уку йортлары урыс теленә күчерелә башлый. Шуңа да карамастан, 1915 елда инде 800 ләп эстон югары белем алуга ирешә, тагын бер меңләп егет һәм кыз югары уку йортларында укуын дәвам итә.

Эстон телендә белем алу өчен көрәш 1905 елдан соң көчәя, әмма бу эш тиз генә уңыш китерми. Иң элек башлангыч мәктәпләрнең беренче-икенче классларында гына эстонча укытырга рөхсәт ителә. Дөрес, бер үк вакытта хосусый мәктәпләрдә тулаем ана телендә белем бирү мөмкинлеге бирелә. Аннары инде чикләүләр тагын да киметелә, эстон урта уку йортлары дөньяга килә. Ләкин бик борынгы саналган Тарту университеты эстон телендә белем бирүне Эстония бәйсезлеккә ирешкән 1919 елда гына көйләп җибәрә ала. 1919—1939 елларда аны 5751 кеше тәмамлый, 1939/40 уку елында анда 2689 студент укый. Соңгылары, әлбәттә, тулаем дип әйтерлек эстоннар!

Таллинн һәм аның үзәге — Ратуша мәйданы борынгылыгы белән шөһрәтле, әмма эстон милли әдәбияты тарихы 150 елга сыеп бетә яза. Беренче күренекле язучысы Фридрих Крейцвальд (1803—1882) халык әкиятләрен җыеп эшкәртә, фольклор нигезендә «Калевипоэг» дастанын төзеп бастыра, сатирик-аллегорик повестьлар иҗат итә — киң кырлы эшчәнлек җәелдерә. Милли хисләрнең уянуына Лидия Койдула (1843—

1886) шигърияте (Габдулла Тукай иҗатын хәтерләтә) зур өлеш кертә, аның пьесалары милли драматургиягә нигез сала. Шигъриятне үстерүчеләр арасында моннан соң Юхан Лийв, Густав Суйтс, Марие Ундер исемнәре аеруча мәртәбәле урын ала. Прозаны үстерүдә Эдуард Вильде, Антон Тамсааре, Фридеберт Туглас һәм бүтән әдипләрнең әсәрләре аеруча әһәмиятле роль уйный. Соңгы дәвердә алар эшен Яан Кросс, Лилли Промет, Эмә Бээкман, Матс Траат, Энн Ветемаа, Пауль-Ээрик Руммо һәм башкалар дәвам итә. Халыкара танылган әдипләр һәм шагыйрьләр сафы, әлбәттә, югарыда саналганнар белән генә чикләнми. Эстон әдәбияты иллеләп телгә тәрҗемә ителгән, ике меңнән артык эстон китабы чит илләрдә дөнья күргән. Тәрҗемә итү буенча урыс, латыш, литван, мажар, фин, алман, украин, чех, поляк, румыйн телләре алдагы урында тора.

Эстон әдәбияты, чагыштырмача бик яшь булса да, сыйфат ягыннан бик тиз арада җитлегә һәм сәнгати камиллеккә ирешә, халыкара танылу ягыннан күп кенә борынгырак әдәбиятларны, шул исәптән, безнекен дә артта калдыра.

«Шура» журналы 1909 елда эстоннар санын 1,2 миллион чамасы дип фараз итә. Аларның табигый артуы аз булуын алдарак искәрттем, ләкин 1989 елда бөтен СССРда 1 миллион 27 мең генә эстон яшәвен ничек аңлатырга? Язучылар берлегендә мин бу хакта, әлбәттә, сорашмый кала алмадым.

Егерменче йөз давыллары Эстонияне дә читләтеп узмаган шул. Беренче һәм Икенче дөнья сугышлары, милли дәүләт төзү өчен көрәш, Сталин режимы тарафыннан аны ультиматумнар ярдәмендә тезләндерү һәм канга батыру, шушы афәтләр нәтиҗәсендә йөз меңнәрчә кешенең һәлакәткә таруы яки ватанын ташлап качуы эстоннар фаҗигасен ап-ачык күз алдына бастыра. СССРдан читтә яшәүче мөһаҗир эстоннар санын исә язучылар төрлечә — җитмеш яки өч йөз мең чамасы дип исәпли. Читтә икенче-өченче буында ук милли йотылу башланганлыктан, беренче сан, мөгаен, хакыйкатькә якынрактыр. Әйтүләренчә, эстоннар АКШта — утыз мең, Швециядә — егерме мең, Австралиядә — биш мең, Алманиядә һәм Англиядә өчәр мең яши, алар Дания, Норвегия, Суоми, Бельгия, Голландия, Франция, Канада, Аргентина, Бразилия, Яңа Зеландия һәм бүтән илләргә дә аз-азлап сибелгән икән.

Халыкның михнәт чигүләрен язучылары мисалында да күрергә мөмкин. 1940 еллар башында аларның өчтән бер өлеше Совет тылына күчерелә, янә өчтән бере чит илләргә качып китәргә мәҗбүр була. 1945—1950 елларда ватаныннан беркая китмәгән каләм ияләренең тагын бер өлеше сталинчылар тарафыннан төрмәләргә һәм сөргеннәргә илтеп олактырыла. Кыенлык белән үсеп җитешкән көчләр әнә шулай өч өлешкә бүленә — аларның берсе фашистлар һәм коммунистлар тарафыннан юк ителә, икенчесе эстон совет әдәбиятын барлыкка китерергә тотына, өченчесе мөһаҗирлектә-мохтаҗлыкта милли рухлы, иркле әдәбиятны үстерергә тырыша.

Коммунистлар һәм фашистлар һөҗүме аркасында милли рухлы укымышлыларның каймагы иленнән качып китәргә мәҗбүр булганлыктан, СССРга кушылган Эстониядә әдәбият-сәнгать көчләре бик нык хәлсезләнеп кала һәм бары 1960 елларда гына тулырак канлы тормыш белән яши башлый. Әүвәлге дәвердә, нигездә, Швециядә тупланган мөһаҗирләр исә бөтен көче белән үз йөзләрен саклар өчен кырыс көрәш алып бара — милли мәктәпләр, җәмгыятьләр, нәшрият ширкәтләре ача, ярым профессиональ театрлар, хорлар оештыра, спектакльләр һәм концертлар куя, китаплар һәм вакытлы матбугат чыгара.

Милләтне саклауның беренче шарты — милли әдәбият һәм сәнгатьне саклау, үстерү. Шуны бик яхшы төшенгән, сталинчылар тарафыннан Эстониядән эстоннарны кысырыклап чыгару, алар урынына Русиядән урысларны һәм бүтән милләт алаканатларын китереп тутыру, шуларны

механик аралаштырып, төп милләтне зәгыйфьләндерү сәясәте уздырылуын борчылып күзәткән мөһаҗирләр Швециядә эстон милли культурасын җанландыруга бөтен дәрт-дәрманнарын бирә. Шуның нәтиҗәсендә эстон әдәбияты 1986 елга кадәр ватанында түгел, мөһаҗирлектә (эмиграциядә) күбрәк чыгарыла. Кырык биш ел эчендә чит илләрдә эстон телендә 2600 исемдә китап дөнья күрә. Алар арасында эстон матур әдәбияты 750 исемдә, җөмләдән, 270 роман, 180 шигырь җыентыгы, 155 истәлек китабы, 70 хикәя җыентыгы, 50 балаларга һәм яшьләргә багышланган китап, 40 тәнкыйть һәм эссе җыентыклары, байтак санда классикларның әсәрләре һәм башкалар була. А. Сарестеның «Эстон теленең аңлатмалы сүзлеге», П. Саагпакның «Инглизчә-эстонча сүзлег»е, Б. Кангроның ике томлы «Швециядәге эстоннар» җыентыгы, дүрт томлы «Эстония турында истәлекләр», «Фин-угыр халыклары һәм телләре» дигән саллы очерклар китабы — мөһаҗирләр горбәттә әнә шундый кыйммәтле хәзинә барлыкка китерә. Иҗатта чын-чыннан искиткеч каһарманлык күрсәтү була бу.

— Бик зур әзерлекле, иң сәләтле язучыларыбыз, сәнгатькярләребез, галимнәребез китеп барган иде шул,— диде миңа Үло Туулик.— Бернрад Кангро (1910 елда туган), Калью Лепик (1920 е. т.), Аугуст Мяли (1900—1987), Ивар Иваек (1927 е. т.) — алар иҗат иткән әсәрләр һәммәсе хәзер ватанга кайтты, мирасыбыз бер урынга җыйналды. Бик әйбәт булды! Эстония язучылар берлегендә 1989 елда 193 әгъза исәпләнә. Чит илләрдә 41 эстон профессиональ каләм иясе яши. Аларның егерме өче Швециядә, җидесе АКШта, алтысы Канадада, икесе Суомида гомер кичерә, Австралия, Алмания, Англиядә — берәр язучы төпләнгән. Шуларның һәммәсе фидакарьләрчә иҗат итә — язган әсәрләрен каләм хакы алмыйча бастырып чыгаралар һәм укучыларга тараталар. Чит мөхиттә сибелеп яшәү җиңел түгел, яшь буын акрынлап гореф-гадәтләрен, телен, тарихи аңын югалта бара. Мөһаҗирләр эстон телендәге китапларны баштарак уртача 3000 данәдән бастырса, сиксәненче елларда бу сан 1200 гә төшә. Ватаннан күчеп китү — зур бәхетсезлек, әгәр аның белән бәйләнеш та өзелсә, фаҗиганең фаҗигасе. Шөкер, Эстония сиксәненче елларның ахырында капкаларын тышкы дөньяга да ачты. Ирексездән читкә китүчеләр ватаннарын күрергә кайта башладылар, эстон язучылары, композиторлары, артистлары мөһаҗирләр даирәсенә сукмак салды. Швеция, Суоми кебек мәмләкәтләрдә эстон язучыларның уртак корылтайларын уздыру, Австралиягә кадәр барып, эстон яшьләре фестивальләрен үткәрүләр гамәлгә ашты. Хәзер инде каләмдәшләрем: «Владивосток янында милләттәшләребезнең Эстляндия дигән авылы бар икән... Төркиядә ике эстон авылы нигезләнгән булган... Канаданың бер утравында ватанынннан инде күптән аерылган эстоннар яши, алар телебезнең архаик шәкелләрен — бик кызыклы үзенчәлекләрен саклый, имеш...» дип мәгълүмат алмаша, милләттәшләрен барлау һәм саклау планнарын кора. Чит илләрдә үскән эстон яшьләрен ватанга чакырып китереп ана телен өйрәтү, аларга милли тәрбия бирү өчен дәүләти нигездә чаралар күрергә тотына.

Язучылар берлегеннән урамга чыккач, мин тагын Ратуша мәйданын тамаша кылырга керештем. Таллиннлыларның моннан ничәмә гасырлар элек шундый матур борынгы биналар коруы, аптека ачуы, шуларны яшь буынга мирас итеп калдыруы бүген дә һәр эстонның күңелен нурландыра, рухландыра торган кодрәтле көч чыганагыдыр. Безнең мәһабәт тарихи корылмаларыбыз илбасарлар тарафыннан җимерелгән, яндырылган, әмма аларның бер өлеше шулай да сакланып калган — Казан кремле, Болгар хәрабәләре бүген дә татарның күңелен дулкынландыра. Язмышларда аерма да бар шул: Болгарны да, Казанны да үз атабабаларыбыз корган. Ә менә Таллиннның борынгы ныгытмаларын, чиркәүләрен, аптекасын һәм ратуша бинасын кем салган — датчаннар яки шведлармы, әллә тевтоннар-алманнармы — төгәл мәгълүм түгел. Бәлки, гади ташчылар арасында эстоннар да булгандыр?

Ә бүгенге горурланырлык казанышларда эстоннар өлешен ачыклау шактый ансат. Мисалга, 1986 елда алар телендә 1422 исемдә китап басыла, ягъни һәр эстонга уртача 12,2 данә. Татарда соңгы күрсәткеч 0,7 дән кимрәк. Эстоннарда һәр биш мең кешенең берсе — язучы, без илле мең кешегә генә бер каләм иясен үстерә алдык. Дөрес, хикмәт санда гына түгел. Сыйфат ягы тагын да әһәмиятлерәк. Эстоннарның шул яктан да сынатмавын алдарак җитәрлек сурәтләдем кебек. Ышандырыр өчен тагын бер гыйбрәтле мисал китерим. Эстония иҗат берлекләре идарәләренең берләштерелгән пленумында (2. IV. 1988) язучы Леннарт Мери республикадагы демографик хәлне, эстон милләтенең кризиска төшү сәбәпләрен анализлап чыгыш ясый һәм бөлгенлектән котылу юлларын тәкъдим итә. «Эстоннар хәзер Эстониядә үзләрен үз өендәге кебек хис итми. Милли өметсезлектән арынырга, милли аңны җәмгыятьне үзгәртеп коруга хезмәт иттерергә кирәк. Эстония Берләшкән милләтләр оешмасы һәм ЮНЕСКОга кабул ителергә тиеш. Эстонияне онытылган бер кечтеки ил итеп кенә телгә алмыйк. Аның мәйданы БМО әгъзалары булган 59 дәүләтнеке дәрәҗәсендә яки аларныкыннан зуррак, халкы буенча республикабыз БМО әгъзалары булган 53 дәүләткә тиң яки алардан өстенрәк. Эстония нәни дә, зур да түгел. Ул нәкъ менә үзенә лаек үлчәмдә»,— ди ул. Ә татар шагыйрьләре шушы дәвердә нишли? Нәби Дәүли: «Татарстан минем республикам, Россиянең матур җирендә»,— дип шигырь яза һәм аны меңнәргә җыр итеп җырлата. Илбасарларга колларча табыну рухында! Мәхмүт Хөсәен исә үзбәк, казакъ, грузин, украин халыкларына бала табып бирер өчен кызлар үстереп җибәрүе белән мактанган бер татарны бөтен милләткә үрнәк итеп куя («Яшәсен кияүләрем»), шуны бәхетнең төшкә дә кермәслек иң зурысы итеп таныта! Билгеле инде, бу шигырь дә бер заман сәхнәдән барлык бүтән җырларыбызны кысрыклап чыгарды һәм әрсез рәвештә тамашачыны эшкәртте...

Татарның, аның бабалары болгарның һәм башка төркиләрнең гомер буе үз җирләрендә яшәүләрен, урыслардан һәм тулаем славяннардан күп элегрәк бәйсез мәмләкәтләрен коруларын белмәгән кешеләрнең язучы булырга хакы бармы икән? Ратуша мәйданыннан узып баручы эстоннардан сорасак, алар мондый сорауның бирелүенә, билләһи, шаккатыр иде. Ничек инде үзеңне шулкадәр түбәнсетергә, башкаларга донор, ялчы вазифасында гына күрергә мөмкин?

Язучы милли аңлы, тирән белемле һәм горур булырга тиеш. Халык нәкъ менә укымышлыларына зур өмет белән карый һәм алардан милләтне баткаклыктан сөйрәп алып чыгуда башлап йөрүне көтә.

Эстон язучылары фикергә бай, сәнгатькә маһир булуларын күп телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләре белән исбатлады. Моннан тыш алар ата-бабалары үткәнен әйбәт белүләрен, аны образлы сурәтли алуларын, гореф-гадәтләрне яхшы үзләштерүләрен һәм аларга тугрылык саклауларын, тарихи тәҗрибәгә таянып, яңа шартларда газиз милләтләренә лаеклы яшәеш, киләчәк тәэмин итәр өчен көрәшә белүләрен дә таныттылар. Замандашлары рухи үсешенә көчле йогынты ясау белән бергә, гамәли оештыру сәләтләре барлыгын да күрсәттеләр. Шуннан соң Эстония җәмгыятьчелегенең язучы Леннарт Мерине Эстония җөмһүрияте президенты итеп сайлавы гаҗәпмени? Бу инде эстлар илендә әдәбиятның һәм язучыларның нindирәк урын тотуын искәрткән янә бер тәэсирле күрсәткеч булды дип шикләнми әйтә алабыз.

## Кемнәр күбрәк туа

Эстоннарның саны бик әкрен, бик әз артуын, хәтта егерменче йөз уртасында кимүгә йөз тотуын алдарак язып уздым. Шул ук вакытта язучылары өзлексез арта баруын да әйтмичә ярамый. Лилли Промет шаярып белдергәнчә, демографик шартлауны зарыгып көткән,

хыялланган Эстониядә язучылар балаларга караганда ешрак туа. Эстоннарның бу өлкәдәге үҗәтлеге әдәби гәзитләрендә басылган бер хатта да күренә:

«Кайчандыр халыкка Лидия Койдула иренең һәм балаларының шигърияттән ерак торуы ошамый иде,— дип яза сигез бала анасы Тимо Нутрия.— Хәзер язучыларның җәмгате һәм балалары чын-чыннан шигырь язарга кереште, әмма моңа да шатланмыйлар!»

Исландиядә халык ике тигез өлешкә бүленә диләр. Берсе — язучылар, икенчесе — укучылар. Эстония әлеге бу дәрәҗәдә үк түгел. Әмма сиксәненче еллар уртасында уздырылган романнар конкурсына 76 хезмәт тәкъдим ителә. Әйтергә кирәк, пьесалар ярышына да шул чама әсәр җибәрәләр. Билгеле инде, мондый конкурсларда танылган язучылар катнашмый.

Ә без шул вакытларда «Казан утлары» журналында хикәяләр ярышы уздырдык — тәкъдим ителгән язмалар саны өч дистәгә дә тулмады. Роман конкурсы уздырсак, бәхет сынаучылар, мөгаен, ун тапкыр кимрәк булган булыр иде. Мәгълүмат тулырак, фикер йөртүебез дәлиллерәк күренсен өчен, кабатлап белдерим: эстон язучылары мөһаҗирлектә, йортсыз-җирсез, мал-мөлкәтсез калып, чит илләрдә михнәт шулпасы эчеп йөргәндә кырык биш ел эчендә 260 роман язып бастыра, ә язма әдәбияты тарихы сигез гасыр белән үлчәнгән безнең хәзинәбездә татар романнары саны әле дә йөздән ашмаган. Дөрес, эстоннар роман дип тамгалаган әсәрләр исәбенә повестьлар да кертелә, әмма мондый искәртү белән генә без үз дәрәҗәбезне күтәрә, эстон дусларыбызның абруен төшерә алмабыз. Сан ягыннан бездән ун тапкыр диярлек әзрәк булган халыкның йөз ел эчендә прозада искиткеч уңышларга ирешүен һәм шулай татарга да үрнәк күрсәтүен тану, моның гыйбрәтле серләрен ачу бәлки күпкә файдалырак булыр? Шулай икән, без әдәбият турындагы сүзебезне Ратуша мәйданындагы очрашулар белән генә тәмамларга ашыкмыйк әле.

Әүвәл мәртәбә Таллиннга Ленинградтан поездда соң гына килеп төшкәнлектән, төнне вокзалда уздырырга туры килгән иде. Пыяла һәм тимер-бетоннан корылган бина иркен, уңайлы, якты. Әмма моңа артык гаҗәпләнмәдем, яңа вокзаллар кайда да салына, союздаш республика башкалаларына инде игътибар күбрәк тә бирелә. Ә менә гәзит-журнал киоскысы тирәсендәге җанлы күренеш мине чын-чынлап хәйран калдырды. Халык аның алдында иртәнге алтыда ук җыйналырга керешкән иде. Җиденче яртыда яңа гәзитләр килде, жидедә сату-алу башланды. Койрыгы боргалана-боргалана икенче залга сузылган чиратта йөзләгән кешене күргәч, мин кире үз урыныма килеп утырдым. Ачылган шәпкә генә шулайдыр, бераздан кеше сирәкләнер, аннары да алырмын, янәсе. Кәефне һич тә төшермичә, хәтта бераз сокланыбрак утыра бирдем. Чиратсыз акча сузып әрсезләнүченең заты юк. Ләкин чират сәгать сигездә дә, тугызынчы яртыда да кимемәде. Тиз елыша, әмма яңа кешеләр өстәлеп кенә тора иде. Вокзалда пассажирлар күплектәндер бу дип шәһәргә чыксам, иртәнге тугызда мондагы киосклар тирәсендә дә егермешәрутызар кешене күрергә туры килде. Эстон матбугатын укыйлар. Балалар, яшүсмерләр, олылар.

Туксанынчы еллар башында журналларыбызның тиражы кимүен бер язучыбыз татар телендә матбугатның күбрәк чыгарыла башлавы белән аңлатып, аларның санын чикләргә тәкъдим иткән иде. Янәсе, үзен-үзе акларлык тираж җыйналыр. Бу вакытта татарча журналларның саны уникегә җиткән иде. Ә саннары бездән күпкә ким эстоннар бу вакытта да йөздән артык журнал тибындагы басма чыгарды, гәзитләре дә бихисап иде. Таллинн чит илләрдәге эстоннарны да туган телдәге матбугат белән тәэмин итеп торды, алар өчен хәтта махсус «Кодумаа» («Ватан») гәзитен чыгаруны әле дә дәвам итә. Владимир Бээкман язуынча, Канадада Бөтен Дөнья күргәзмәсендә үткәреләчәк Эстония көне турында

чит ил эстоннары нәкъ менә «Кодумаа» аша белеп тора һәм күпләп Монреальгә киләләр.

Кыскасы, вакытлы матбугат, китап уку буенча эстоннарның дөньяда мактаулы урын тотуы күз алдында. Әйтик, алар саннары буенча элекке СССР халыклары арасында егерме икенче урынны гына биләсәләр дә, чыгарган китап исемнәре җәһәтеннән бишенче, аның тиражы ягыннан җиденче урында тордылар.

Эстон теленең иң борынгы язма истәлекләре XIII гасырга карый. 1535 елда туган телләрендә беренче китап — катехизис басыла. 1857 елда беренче эстон гәзите дөньяга килә. 1868 елда беренче тапкыр җыр бәйрәме уздырыла, 1870 елдә әүвәл мәртәбә ачык спектакль куела.

Халык тарихында якты эз калдырган мондый вакыйгалар эстон матур әдәбиятында лаеклы рәвештә чагылдырылган. Эстон милли аңын күтәрүгә хезмәт иткән тарихи-биографик романнарында Яан Кросс, мәсәлән, милли культураны тергезүгә күренекле өлеш кертүчеләргә генә түгел, хәтта Пугачев кузгалышын бастырган эстон генералы, без «патша ялчысы» дип кенә таныган Михельсонга да күләмле әсәр багышлаган. Сыйнфый көрәш принцибын кире каккан бүгенге көннәрдә түгел, марксизм ажгырып торган СССР шартларында! Бу уңайдан, татар язучыларының, генерал Тәфкилев бер якта торсын, халкыбызның даны һәм горурлыгы булган ул-кызларын да тиешенчә гәүдәләндерә алмауларына пошынасың. Яан Кросс исә 1988 елга кадәр дөнья күргән ундүрт романында бүтән милләт укучылары өчен дә кызыклы булган шәхес һәм хакимият, хакимнәргә сукырларча буйсынуга нигезләнгән җәмгыять күренешләрен сурәтли, иреккә, хөрриятъкә омтылучы каһарманнарга мәхәббәт тәрбияли.

Эстоннарның соңгы гасырларда чәчәк ату чорын кичергән Көнбатыш Европага бездән якынрак булулары һәм аның белән матди, мәдәни бәйләнешләргә иртәрәк һәм тыгызрак керүләре милли үсешкә дә уңай тәэсир ясаган. Патша Русиясенең халыклар төрмәсе булуын беләбез. Әмма аның золымы христиан халыкларга бер кадәр кимрәк тигән. Шуның аркасында эстоннар татарларга караганда милли театрны утыз алты ел әүвәл, милли гәзитне кырык сигез, туган телдәге беренче китапны җитмеш җиде ел элегрәк бастырып чыгаруга ирешкән.

Гасырыбызның җитмешенче-сиксәненче елларында СССР күләмендә Балтыйк буе халыклары әдәбияты үсеше игътибар үзәгендә торды һәм даими рәвештә югары бәяләнеп килде. Алар арасында литван әдәбияты укучыларга аеруча киң танылып өлгерде. Э. Межелайтис, Й. Авижюс, М. Слуцкис, А. Беляускас, Ю. Балтушис, И. Мерас әсәрләре бөтен Совет әдәбиятының казанышы исәпләнә башлады. Эстониягә килгәч, тагын бер яңалык ачтым: эстон әдәбияты да иң җитди игътибарыбызга лаек икән.

Соңгы вакытта иҗади күтәрелеш кичерүләре хакында күп укыганлыктан һәм күп ишеткәнлектән, кат-кат сәфәр чыктым мин бу якларга. Алтмышынчы елларда әрмән журналын алдырып, әрмән әдәбиятын укып, аларның укучыга милли тәрбия бирүләренә сокланган идем. Аннары игътибарымны Ә. Кикелбаев, С. Санбаев, С. Моратбәкев, У. Бүкиев шикелле яшь казакъ прозаиклары тартты. Аларның иҗади хасиятләре, чагылдырган тормыш даирәсенең киңлеге, әдәби осталыгы күңел дөньямны баетты. Тик бервакыт кулыма эләккән Эмә Бээкманның «Шыгырдавык» романы Балтыйк буе белән кызыксынуымны аеруча дөрләтеп җибәрде. Әсәрнең уйнак рухы, үткен гротеск, йөгерек фантазиясе, сюжет камиллеге һәм кызыклы образлары җанга ятышлы иде. Ленинградта аның «Саңгырау шөлдерләр» романы белән дә танышкач, автор хакында белешмә эзләргә тотындым. Илле яше дә тулмаган ханым кыска гына вакыт эчендә унбишләп роман бастырган икән!? Бездә хатын-кызлар

гына түгел, ир-егетләребез дә болай нәтиҗәле эшләп куандырганы юк. Бөтен совет әдәбияты күләмендә дә игътибарга лаек күренеш иде бу...



*Энн Ветемаа*

Эстон яшь прозаикларын бәяләү өчен Энн Ветемаа исеменә тукталу урынлы. Ул утыз биш яше тулганчы биш кыска роман яза һәм бу әсәрләр тиз арада урыс, француз, мажар, фин, грузин һәм латыш телләренә тәрҗемә ителә. Ә бит ул үзен шактый озак әдип исәпләмәгән, инженер-химик һөнәренә кызыккан һәм шул һөнәр буенча институт тәмамлагач, целлюлоза-кәгазь комбинатында эшләгән. Шул чакта шигырьләр язган һәм байтагын матбугатта бастырган. Һөнәр сайлауда ялгышуын аңлагач та сәләтен һаман әдәбиятта түгел, музыкада ачарга дәртләнгән. Яңадан югары уку йортына — бу юлы консерваториянең композиция классына кергән. Аның симфония, камера әсәрләрен, сүзен дә, көен дә үзе язган җырларын Эстониядә әле бүген дә яратып башкаралар. Пьесалар, нәфис фильм сценарийләре, шигырь җыентыгы, оратория өчен өч махсус шигъри әсәр яза — әмма Э. Ветемаа кечкенә романнар авторы сыйфатында киңрәк танылып китә.

Аның әсәрләрендә үз тормыш тәҗрибәсен файдалануын абайлау кыен түгел. Музыкант булуын «Авыз гармуны өчен мәрсия», химиклеген «Кытайча күкәй», архитектор улы икәнлеген «Монумент» романыннан чамаларга мөмкин.

Абрукас утравында туган, «дингез язучылары» дип даннары чыккан Юри белән Үло Тууликләр язмышы кызыклы. Алар — игезәкләр, бергә үскәннәр, бергә укыганнар, бик озак бер түбә астында яшиләр. Әмма иҗатта аларның һәркайсының үз йөзе бар. Үло кырыс, җитди яза, Юриның хикәяләре һәм повестьлары исә шактый ук тозлы-борычлы халыкчан юмор белән сугарылган — мин моны аларның хикәяләрен татарчага тәрҗемә иткәндә, редакциялагәндә бигрәк тә ачык тойдым. Алар икесе дә инде дистәләп телдә хуплап каршыланган әсәрләр бастырган. Игезәкләрнең икесе дә эстон милли холкын, туган як буяуларын әйбәт гәүдәләндерүләре белән сокландыралар. Әмма игезәк Тууликларны күп яза дип менә мактап булмый.

Без Юри белән ике мәртәбә язучыларның Рига тирәсендәге Дубулты иҗат йортында бергә туры килдек. Дулкыннар шавы астында арлыбирле дингез буен гиздек, гәрәбә яр буенда кызынучыларга күз салгалап, яр өстендәге сагызлы коңгырт кәүсәле наратларга, алар өстендә һәм ял итүчеләргә тәмам якынаеп кыйкылдашкан акчарлакларга карый-карый Балтыйк буе һәм Идел-Урал төбәге халыкларының уртак мәсьәләләрен телгә алдык, фикер алыштык, холлда яки бүлмәләребездә кайнар каһвә эчә-эчә соңгы әдәби яңалыкларны сораштык. Кул сузымы җирдәге Таллинннда гына яшәгәнлектән һәм профессиональ язучылык белән генә шөгыльләнгәнлектән, ул Дубултыга еш килә һәм монда ярты гомерен уздыра, латыш язучыларын гына түгел, шушында даими килә торган бик күп каләмдәшләрен дә яхшы таный иде. Дөресен әйткәндә, ул укымышлы яһүдләр белән генә аралаша, алар белән шахмат уйный, югары даирә әдәби «гайбәтләрен» тикшерә, әдәбиятта үзенең ныклы урыны барлыгына чын күңелдән ышанып, бераз кәпәренеп, кәязләнеп йөрергә ярата.



*Юри Туулик*

әсәрләре урысча басылмаган татар язучысына, Эстония белән бик каты кызыксынган өчен генә, илтифат бирергә мөмкин дип исәпли иде шикелле. Әмма тора-бара без аның белән шактый ук якынайдык.

— Юри,— дидем мин аңа бервакыт,— комачауларга өендә гаиләң юк, монда инде иҗат өчен шартлар бигрәк тә уңайлы, син бик күп язасыңдыр?

— Бездә гаиләләләр генә күп яза,— дип авызын ерды егетем.— Әнә ирлехатынлы Бээкманнар илле китап чыгардьi инде. Гаиләне асрарга күп кирәктер, ирексездән язалардыр!

— Сездә каләм хакына гына яшәргә мөмкинмени?!

— Раймонд Каугверыбыз — миллионер, романнары сиксәншәр мең тираж белән басыла. Поездда, трамвайда егылып укыйлар — ул мавыктыргыч сюжет, ул маҗаралар — кызык! Әмма... укыйсың да онытыла.

Тел төбеннән аңлашылганча, Юри көнкүреш колы булырга теләми, иҗатында югары сәнгатьлелеккә йөз тота иде. Күп язуны ул, әлбәттә, гаеп эш санамый, чөнки «иң әйбәт латыш әдипләре кемнәр?» — дип сорагач, Регина Эзера белән Альберт Бэлне — үрчемле иҗат итүче каләмдәшләрен атады.

— Эзера бик кызыклы новеллалар яза. Поляк каны бар аңарда, Көнбатыш культурасы сизелә, тыгыз, мускуллы проза иҗат итә. Бэлнең «Сылтау», «Көймәдәге кешеләр» романнарын укы, аз санлы халыклар язмышын символик рәвештә чагылдыра.

— Ә эстон каләмдәшләреңнән кемнәрне югары бәялисең?

— Даһиларны әйтәсеңме?— ди ул мутланып.— Мария Ундер белән Бетти Альверне яратам. Әйбәт шагыйрьләр.

— Ә Кросс, Траат, Валтон, Каллас, Үнт?

— У-у, карале күпме язучы бар эстоннарда,— дип көлә Юри.— Аз санлы халык өчен артык күп. Һәммәсе катастрофик рәвештә әйбәт яза тагын! Телевидениегә барып, сәгатьләр буе акыл да сата әле алар. Әмма соңгы вакытта Траат тарихка кереп батты, Үнт, ничек итеп укучыларымны биздерим икән, дип кеше аңламаслык рәвештә язарга тотынды.

— Сездә ярты сәгатьлек әдәби телесериал да бар икән ич. Язучы белән унбиш минутлык очрашулар да.

— Телефильм, радиопьеса, рекламафильмнар да эфирга чыга,— ди Юри җирән сакалын сыпырып.— Ансыз яшәү яшәүмени?

Чыннан да, соңгы дәвердә эстон прозасы зур үзгәреш кичерә: П. Куусберг, Э. Бээкман, Э. Ветемаа, М. Үнт романнарында композиция төзелешендә эчке күчешләр — хронологик эзлеклелек бозылу, төрле заман катламнары чиратлашу, эчке монологның төрле формалары өлеше арту; М. Үнт, Э. Ветемаа, Ү. Туулик кебек әдипләрнең чынбарлык «моделен» кыска роман рәвешендә корырга омтылуы; А. Валтон, В. Ваһиң әсәрләрендә реаль күренешнең шартлыга күчүе; күпләр тарафыннан сурәтләү тукымасына «аң агышы» кертелү — эзләнүләр төрле юнәлештә алып барыла. Нәкъ менә шушы тәҗрибәләр күп милләтле укучыларның игътибарын җәлеп итте һәм эстон прозасына мәхәббәтне арттыруга булышты.

Безнең проза нигездә бер урында таптанганда, эстон әдәбиятының зур күтәрелеш кичерүе нәрсәгә бәйләнгән иде соң? Реалистик проза һәр ике халыкта бер үк вакытта диярлек барлыкка килә — эстонның шул рухтагы беренче романы «Кырыс як» (Э. Вилде) 1896 елда языла. Муса Акъегетебез «Хисаметдин менла»сен 1886 елда иҗат итә. Сыйфат ягыннан карасак, егерменче йөз башында Гаяз Исхакый, Фатыйх Әмирхан, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимовлар прозасы шулай ук эстонныкына бирешерлек түгел. Культураның башка тармакларын алсак, безнең кайбер отышлы яклар да күренә: татар милли операсы эстонныкыннан өч ел әүвәл, балеты ике ел элгәрәк барлыкка килә һәм халыкара киңрәк таныла. Татар әдәбиятының борынгырак дәвер казанышлары исә чагыштыргысыз рәвештә баерак. Кол Галинең 1212 елда иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф»ын гына искә алыйк! Аның белән танышкач, Эстониянең атказанган язучысы, ЯБ идарәсе секретаре Арви Сийг бер хатында миңа: «Шулкадәр матур һәм эчтәлекле бүләк өчен рәхмәт сезгә. Аны укыган саен һәр милләтнең зирәк булуына ышана һәм соклана барам»,— дип язды. Шундый ук югары бәягә «Идегәй» дастаныбыз да лаек дип уйлыйм.

Эстон язма матур әдәбияты Ф. Крайцвальдның халык дастаны «Калевипоэг»ны җыеп, 1857—1861 елларда китап итеп чыгаруыннан соң башлана. Бу әсәр эстоннар өчен грекларның «Илиада»сы ролен уйный. Кабатланмас өчен, алдагы бүлектә телгә алган, эстон әдәбиятына житлегү алып килгән күренекле шәхесләрне санап тормыйм. Әмма Эгон Раннетның «Юлдан язган» пьесасы чит илләрдә ике йөздән артык театрда уйналуын искәртү артык булмас.

Яшь эстон прозасы менә шундый өлкәннәр казанышын үзләштереп мәйданга чыга. Бу — һәрбер җитлеккән әдәбият үз үсешендә атлап бара торган баганалы олы юл.

Эстония менә инде дүртенче гасыр кәгазь җитештерә. Монда борынгы һәм бүгенге дөнья культурасына искиткеч мәхәббәт белән карыйлар. Эстон телендә Һомер, Хәям, Нәваидан башлап Г. Лорка, У. Уитмен һәм бүгенге «модерн» язучыларга кадәр барысы да ана телендә басылган. Вольтер, Сервантес, Ремарк, Хемингуэй, Фолкнер, Белль — йөзләрчә башка милләт язучылары эстон укучысында югары һәм нечкә зәвекъ тәрбияләүдә катнаша. Шекспирның җиде, Чеховның сигез, Л. Толстойның унбиш, Бальзак, Горькийларның уналтышар, эстон әдәбияты классигы Э. Вилденең утыз өч томлыклары янә башкалар инде күптән республикада сәнгатьчә фикерләүне үстерүгә хезмәт итә. «Бөек сүз осталары», «Егерменче гасыр романы», «Егерменче йөз шигърияте», «Дөнья әдәбияты», «Нобель премиясе лауреатлары», «Төньяк илләре романы», «Тарихи роман» серияләре һәм аерым басмаларда классиклардан алып замандашларыбыз М. Фриш, А. Моравиа яки яшәештән мәгънә, матурлык асылын эзләүче В. Борхерт, Җ. Сэленжер, Җ. Апдайк, К. Абэ һәм хәтта экзистенциализм, абсурдизм, «яңа роман» тарафдарлары Ф. Кафка, Ж. П. Сартр, А. Камю, Җ. Ануй кебекләр дә урын алган. Шуларга элекке СССР халыклары әдәбияты килеп өстәлә. Эстоннар хәзер турыдан-туры кырык телдән тәрҗемә итә. Төрек, үзбәк, әзәрбайҗан, эсперанто, япон, монгол, кытай, һинд теле белгечләре дә бар монда. Эстон укучысы дөнья әдәбиятындагы яңалыкларны «Лоомиң» журналының атна саен чыгарыла торган кушымтасы буенча да күзәтеп бара ала. Менә бу әдәбият ташкыны укучыны һәм язучыны яшьтән үк сугара торган икенче куәтле һәм шифалы чишмә, эстон иҗатчыларына уңай йогынты ясый торган икенче шарт.

Дөнья әдәбияты җәүһәрләрен һәм күпсанлы фәнни-техник китапларны, вакытлы матбугатны кече яшьтән үк туган телдә укып үсү әдәбиятка әзерлеклерәк, белемлерәк яшьләр килүен, аларның беренче тәҗрибәне үк

югарырак баскычтан башлавын һәм житезрәк өлгерүен тәэмин итә. Шуның белән бергә, алда әйтелгәнчә, эстон зыялыларының әллә ничә чит тел белүен дә искә алыйк. Көнбатыштагы алдынгы карашлы, тирән белемле, талантлы язучылар казанышын аларның безгә караганда күп алданрак үзләштерүләре шуңа күрә һич тә гаҗәп түгел. Миңа эстон язучыларының чит илләр әдәбиятын асыл нөсхәдә укуларын гына түгел, Швеция һәм Суоми телевидение тапшыруларын да даими карап барула-рын күреп ышанырга туры килде. Радио исә аларга тагын да киңрәк офыклар ача икән.

Биолог Рейн Салури, тау инженеры Арво Валтон, икътисадчы Матс Траат, сурәтче Александр Сууман, врач Вайно Ваһиң... Эстон прозасы нинди бәхетле! Әдәбиятка бер-берсенә охшамаган тормыш юлы, эш тәҗрибәсе белән күпме кеше килә, чынбарлыкның яңадан-яңа тармак-ларын алып керүдә нинди бай мөмкинлекләр ачыла. Чыннан да, Энн Ветемаа, әгәр шагыйрь булмаса, композитор була алыр идемени һәм, әгәр әүвәл композитор, аңа кадәр инженер-химик булмаса, зур уңыш казанган кыска романнарын яза алыр идеме икән? Берничә каләмдәше-безне искә алмаганда, татар әдәбияты йөген исә туган телебезне һәм әдәбиятыбызны балаларга укытырга әзерләнгән педагоглар гына тарта. Бәлки шуңа күрә дә әсәрләребездә сәнгатьлелеккә зыян китерә торган дидактика, акыл өйрәтү көчледер?!

* * *

Урман купшы чыршылардан, нык кәүсәле, киң һәм куе ябалдашлы имәннәрдән генә тормый. Каен һәм юкә, miлэш һәм шомырт, гөлҗимеш һәм бөрлегән — төрле-төрле үсемлекләр аңа ямь һәм көч өсти. Әдәбият дөньясын да сәләте һәм дәрте, белеме һәм тәҗ-рибәсе, омтылышы һәм эшчәнлеге төрле-төрле шәхесләр тәшкил итүе кирәк.

Йөз еллык юбилейләре уңаеннан мин татар укучыларын күренекле эстон язучылары Ф. Туглас, О. Лутс иҗатлары белән таныштырдым һәм үз нәүбәтемдә Эстониядәге дусларыма Тукай белән Ибраһимовның шун-дый ук бәйрәмнәре якынлашуын хәбәр иттем. Хат язышулар бушка китмәде — А. Каалеп Тукай шигырьләрен тәрҗемә итте, О. Кунингас Г. Ибраһимов турында әдәби гәзитләрендә махсус мәкалә язып бастырды. Таллиннга чираттагы баруымда мин өлкән яшьтәге әдәбиятчы Оскар абый Кунингас белән дә очраша алдым.

Лилли Промет бер хатында аның турында: «Бик укымышлы, зыялы, яхшы күңелле, әдәби багланышларны үстерүгә ифрат игъ-тибарлы кеше»,— дип язган иде. Дөрес хәбәр иткән икән, Оскар абый Татарстан вәкилен шулкадәр ягымлы каршылады, әйтерсең, гомере буе мине генә көтеп яшәгән! Мәҗлесебез күңеллерәк узсын өчен ул әле үзе кебек тирән белемле һәм хуш күңелле Артур Лаастны — «Ээсти раамат» нәшриятенең өлкән редакторын да өенә чакырган иде.

Язучылар белешмәлеген укысаң, О. Кунингас тормышы һичбер болы-тсыз узган, иҗаты җиңү арты җиңүләрдән генә гыйбарәт булган дип уйларга мөмкин. Дөрес, белешмәлектә ул тәрҗемәче, әдәбият белгече һәм журналист дип кенә танытыла. Коммерция мәктәбен һәм колледж тәмамлаган. Ул, күрәсең, белемен үзлегеннән тагын да мулрак туплаган, Пярну театрында әдәби бүлек мөдире, Театр институтында әдәбият укытучысы, район мәгариф бүлегендә киңәшче вазифаларын аңа йөклә-үләре тикмәгә генә булмагандыр. О. Кунингас әдәбият, театр сәнгате тарихы һәм бүтән темаларга бик күп мәкаләләр язган, режиссер А. Сярев турында монография бастырган, аның латыш, алман, урыс, француз телләреннән әдәби тәрҗемәләрен санап чыгу гына да бик зур урынны алыр иде. Җиде тел белә Оскар абый, шуларның җиденчесен — француз-

чаны сөргендә үзләштергән ул. Менә шул сөрген хәлләре белешмәлектә шома гына урап узыла да инде.

Эстон укымышлыларына җәбер төрле тарафтан юмарт эләгә — «коммунистларга теләктәш» дип, әүвәл һитлерчылар эзәрлекләсә, аннары, «буржуйлар яклы, милләтче», дип сталинчылар төрмә-сөрген ачыларын татыта.

— Ниндидер партиядә, оешмада әгъза булу гына кешенең асылын ачып бетерми,— диде ул миңа.— Шәхеснең эчтән сәламәт, кешелекле булуы әһәмиятле. Ааду Хинт буржуаз республика дәверендә үк марксистик хәрәкәткә кушылып китте, совет дәверендә язмышын турыдантуры коммунистлар белән бәйләде, сыйнфый көрәш рухында бик күп әсәрләр язды, парламентыбызга депутат, СССР Язучылар берлеге идарәсенә әгъза булып сайланды. Әмма КПССның егерменче съездыннан соң Үзәк Комитетка кырым татарларын аклауны һәм ватаннарына кайтаруны үтенгән хатны нәкъ менә ул язды, хатын машинкада үзем басып бирдем. 1956 елда Мажарстанда тыныч халыкның үзенчә яшәр өчен баш күтәрүен совет танклары белән изеп ташлагач, нәфрәтен кеше алдында белдерергә курыкмаган җан да А. Хинт булды.

Оскар абый очрашуыбыз вакытында үзе хакында түгел, әнә шулай каләмдәшләре, Эстониянең әдәби хәрәкәте, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, мәдәни бәйләнешләр турында сөйләде, минем кызыксынуларымны канәгатьләндерергә тырышты. Үз хәзинәсендәге байлыкны минем белән уртаклашырга ул шулкадәр әзер иде ки, коляскада гына йөрергә мәҗбүр җитмеш сигез яшьлек карт башы белән китап киштәләрендә актарынырга керешүен мин исем китеп күзәтеп утырдым һәм, әлбәттә, аны бу мәшәкатьләрдән туктатырга тырыштым. Ә ул һаман, Татарстанда бәлки кирәге чыгар, дип әллә кайсы басмаларны табып бүләк итәргә талпынды. Ф. Туглас, О. Лутс, Г. Суйтс җыентыкларын, реклама буклетларын кулыма тоттырып:

— Әдәби бәйләнешләрне үстерү ике яктан да тырышлык сорый. Сез әле яшьләр, Артур белән киләчәктә эстонга да, татарга да файдалы күп эшләр эшли аласыз. Сезгә булышу — өлкәннәрнең мактаулы вазифасы,— диде.

...Тарту университетының урыс теле-әдәбияты бүлеген тәмамлаган Артур Лааст сүзчәнлеге белән мине аеруча сөендерде.

— Лилли Прометның миңа сезнең хакта сөйләгәне бар, ботак очы кардәшем ул минем,— диде Артур.— Лилли апам кебек, мин дә Шәрекъ белән кызыксынам.

Аның кызыксынуы буш сүз генә түгеллеген мин бик тиз аңлап алдым.

— Швед короле архивында «Татарико» бүлеге барлыгын беләсезме?— диде ул миңа.— «Скандинавия» (1985) җыентыгында бер мәкаләне укыганда, шул фондка юнәлтүне күреп алдым... Көнбатыш Эстониядә Казари елгасы бар, аның исеме ата-бабаларыгыз хәзәрләргә бәйләнгән. Бездә әле фон Арбузов, фон Баранов дигән алманнар да яшәгән, буыннарында татар каны агуын аларның исемнәре үк кычкырып тора. Бу нәселләрдән байтак хәрбиләр чыккан.

Мин әңгәмәбезне бүгенге тормышка якынайтырга тырышам. Катнаш гаиләләр, язучы Владимир Бэзкманның М. Горбачев җитәкләгән СССР вәкилләре составында Англиягә баруы, милли мәктәпләр язмышы һәм бүтән мәсьәләләр белән кызыксынам.

— Бэзкман Язучылар берлегебез идарәсе рәисе, күп яза, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша,— диде ул елмаеп.— Милли рухта яза, «Ишәк елы», «Коридор» романнарын укучыларыбыз җылы каршы алды. Инглизчә, шведча, урысча яхшы сөйләшә, сәяхәтнамәләре әллә никадәр!.. Катнаш гаиләләр безнең өчен бик куркыныч түгел, чөнки аларның балалары күпчелек очракта (җитмеш процент) эстон мәктәбендә укый, чөнки аларда белем, тәрбия бирү дәрәҗәсе югарырак. Чит телләр өйрәнүгә дә игътибар зуррак. Әмма катнаш гаиләләр артык күбәйсә,

файдасы да юк... Бездә татар телен өйрәнгән галим дә бар иде әле. Нурмекунд Пинт. Заманында Парижда белем алган, унлап тел үзләштергән, шул исәптән, Шәрекъ телләре белән дә кызыксынып яшәгән.

Теэт Каллас, Рейн Круус, Май Талвест...— мин эстон әдәбияты мәйданында җиң сызганып хезмәт иткән барлык танышларымны да бу язмаларда телгә алып бетерә алмам, ахры. Олпат гәүдәле, эстоннарга хас булмаган дәрәҗәдә дәртле Талвест ханым мине Язучылар берлегендә күргәч һәм кемлегемне аныклагач:

— Сугыш вакытында мин дә Татарстанда яшәдем ич,— дип кабынып китте.— Танышыйк, драматург Май апаң булам. Мин Чистай районының Каргалы МТСында бухгалтериядә эшләдем. Ике балам белән баш агроном өендә фатирда тордым. Мин дә, алар да урысча начар белә, аңлашырга сүз җитмәгәндә ым-ишарәләр дә ярады. Лилли Промет Татарстан хакында роман язды, мин дә уйлап йөрим әле. Тотынсам, аның шикелле язмас идем. Ул ерак култыктагы бер авылда яшәгән, шунлыктан күп нәрсәне күрә, төшенә алмаган. Хезмәтем һәм аралашкан кешеләрем киңрәк колачлы булганлыктан, мин татарлар турында да күбрәк белә алдым, гореф-гадәтләре белән дә яхшырак таныштым.

М. Талвест пьесалары чит илләрдә дә куела, аларның берсе японча да тәрҗемә ителгән икән. Талвест ханым безнең драматург Шәриф Хөсәеновне күреп белә, аның белән иҗади бәхәскә дә кергәне бар икән, шуңа күрә аңа күп итеп сәлам әйтүемне үтенде.

Арабыз ерак булса да, эстоннар белән дуслык мөнәсәбәтләребез күптәннән килә. Күренекле язучы һәм сәяхәтче Леннарт Мери, минем Казаннан килүемне белгәч:

— Таллинның үзәгендә «Татари» урамы бар, беләсезме?— диде.— Явыз Иван Казанны алганнан соң безгә һөҗүм иткән, әмма җиңелгән. Ул ияртеп килгән татарлар, яңа хуҗаның уңышка ирешә алмаячагын сизеп алу белән, безнең якка чыккан һәм, Таллиннда төпләнеп калып, татар бистәсенә нигез салганнар.

Леннарт Мери тагын да укымышлырак, күпне белә торганрак кеше. Татар әдәбиятчысына игътибар күрсәтеп, өенә чакырырга да, Хәсән Туфан хакында сорашырга, аның шигырьләрен тәрҗемә итеп карарга нияте барлыгын белдерергә дә онытмады ул. Аннары мине аптыраашта калдырып:

— Узган гасырда бер инглиз сәяхәтчесе Казан аркылы узганда ханлык архивларының Бохарага, аннан Себергә җибәрелүен ишеткән. Шул табылдымы әле?— диде.

Л. Мери Урта Азиягә, Якутстан һәм Камчаткага сәяхәтләр ясаган һәм бу хакта берничә китап язган. Себернең һәм Төркестанның үткәне, бүгенгесенә, шул якларда яшәүче халыкларга мәхәббәт белән иҗат ителгән ул китаплар Эстониянең әдәби премияләренә лаек булды, Мәскәү матбугатында һәм чит илләрдә дә югары бәяләнде. «Ак тынлыкка күпер» әсәрендә ул, мәсәлән, җиде йөз кешеле нанасан милләте һәм бүтән аз санлы халыклар, аларның мәдәниятен зур хөрмәт белән яктырта. Китапта татарлар да телгә алына, аның бер бүлеге кораб штурманы Фәриткә багышланган.

«Ак тынлыкка күпер»не укыганда барлыкка килгән тәэсирләремне уртаклашып хат язып салгач, Леннарт Мери миңа аны бүләк итеп тә җибәргән иде. Таллиннга юлым төшкәч, берничә тапкыр мин аның үзе белән дә күрештем. Урман арасындагы ике катлы йортка 1978 елның ноябрендә сәгать кичке тугызынчыда барып кердем. Өендәге гадәттән тыш пөхтәлек, чисталык игътибарымны җәлеп итте. Бөтен стеналарны биләгән киштәләр кадерле басмалар белән шыплап тутырылган иде. Фин, француз, урыс, инглиз, алман һәм башка телләрдә. Балачагы Берлиндә һәм Парижда узган хуҗа (дипломат улы!) аларны су кебек эчә икән. Идәнгә аю тиресе җәелгән — Леннарт абыйның төньякка сәяхәтләре хатирәсе.



*Леннарт Мери*

Л. Мери озын буйлы, ябык. Аны Төркестандагы милләттәшләребезгә җирле халыкларның мөнәсәбәте, Татарстандагы милли мәктәпләр хәле, республикабыз тормышы кызыксындыра. Сүзгә мавыгып, әле кульязмаларын, әле берәр китабын эзләп казына башлый. Кадерле вакытның шундый «техник» эшкә китүенә борчылып, мин аңардан кәгазь актаруларны кичектереп торуын үтенергә мәҗбүр булам. Леннарт абый елмаеп тагын каршыма килеп утыра. Миннән ишеткәннәрен кәгазьгә теркәп куя, аннары янә онытылып, папкаларын актара башлый. Казынуларының файдасы да тиде үзе — хуҗа Тарту шәһәренә шалтыратып, мине университет укытучысы Айн Каалеп белән таныштырды, Тарту университетының эстон теле бүлеген тәмамлаган милләттәшебез Рәмия Мифтахетдинова адресын да ачыклады.

Л. Мери Татарстанда берничә тапкыр булган, мари, мордва авылларына Казан аша барып, Идел буе фин-угыр халыклары тормышы, мәдәнияте белән танышып йөргән. Ул аларның әдәбияты, сәнгате үсүенә шатлана, мари театры белән алмаш гастрольләр ясый алуларына сөенә. Көнбатыш телләрен, мәдәниятләрен яхшы белүче галим, язучы һәм кинорежиссер, Суоминың Әдәбият, Фин-угыр җәмгыятьләре, Суоми язучылар берлегенең чит илдә яшәүче әгъзасы, Эстония ЯБ идарәсенең җаваплы секретаре Леннарт Мери соңгы очрашуыбыз (1985) вакытында:

— Йә, күңел үстерерлек нинди яңалык бар сездә? — дип сорады.

— Казанда Габдулла Тукай музее ачыла. Атаклы Шамилләр йортында урнашачак.

— Шамил белән Тукай рухы бергә кушылачак, димәк? — диде ул куанып. — Бик әйбәт, шул рухны саклагыз инде моннан соң!

Леннарт Мери кызыксынган мәсьәләләрнең берсе — татар гаиләләренең тотрыклылыгы иде. Бу тема аз санлы эстоннар өчен бигрәк тә актуаль, чөнки бу дәвердә аларда өйләнешүчеләрнең яртысы диярлек аерылыша бара иде. Нигә шулай? Яхшымы бу, яманмы? Эстон язучысы Эндель Теннов «Халык арту» романында менә шушы сорауларга җавап бирергә тырыша. Әлбәттә, сөт комбинатының утыз җиде яшьлек технологы Ээдүнең үзеннән бала тапкын Кәтрингә өйләнүе, бу гаиләнең тотрыксыз булуы, роман каһарманнары арасында булып узган бүтән вакыйгалар укучыларга нинди дер гыйбрәт бирми калмый.

Э. Теннов романы эстон халкының сан ягыннан артуына йогынты ясармы-юкмы, әйтүе кыен, әмма ул әсәрдә заманыбызның актуаль мәсьәләләре күтәрелүе күз алдында. Безгә инде андый әсәрләр белән таныштырга гына кала. Тик кайсылары белән?

Баштарак мин Эстониядә һәрнәрсәгә сокланып, куанып йөрдем. Республика төзек, халкы — культуралы, көнкүреше бай. Яңа фабрикалар, җылылык электр станцияләре, тагын әллә ниләр төзелеп кенә тора: Таллинида яңа йортлар гына түгел, тулы бер микрорайоннар барлыкка килә — туксан мең кеше яшәгән Мустамяэ, 120 мең кеше яшәгән Ласнамяэ һәм башкалар, яңгырдан соң шытып чыккан гөмбәләр төсле, ел үсәсен ай үсә! Юлларының төзеклеге, мең кешегә туры килгән телефоннар яки җиңел автомобильләр буенча элекке СССРда гел алда барды ул. Милли культура, милли рух торышы Эстониядә миңа инде идеальның идеалы булып күренде — мескен автономияле республиканың милли гайрәте сындырылган, изелгән һәм сытылган бер халкы вәкиле өчен бу

җөмһүрият, әлбәттә, башкача тәэсир калдыра да алмый иде. Әмма килгән саен танышлык тирәнәю, тыштан әйбәт күренгән чынбарлыкның аскы катламында инде дәһшәтле үзгәрешләр баруы һәм шуның ваемлы эстоннарны төн йокыларыннан мәхрүм итүен, аларның тормышын агулавын күрү мине дә айнытты. Тыштан чәчәк ату кебек күренгән кайбер күренешләр эстон милләтенең һәлакәтен генә якынайтуын монда күпләр, Леннарт Мери инде бигрәк тә яхшы аңлаган икән. Иҗат берлекләре идарәләренең берләштерелгән пленумында ул менә мондый саннар китереп сөйли:

— 1938 елда Эстониядә 1 миллион 131 мең кеше яши, хәзерге чикләребез эчендә эстоннар барлык халыкның 93,3 процентын тәшкил итә иде... Икенче Дөнья һәм Бөек Ватан сугышы нәтиҗәсендә Эстония 24 процент халкын югалтты... Республикабызда эстоннар өлеше 1945 елда 97,1 процент булса, 1986 елда ул 61,3 процентка төште... Сугыштан соңгы 43 ел эчендә Эстониягә ел саен 13000 кеше күчеп килде... 1984 елда исерткеч эчемлекләр эчү буенча (җан башына 11,3 литр!) без дөньяда беренче урынга чыктык...

Эш көче дә, чималы да булмаган Эстониядә яңа фабрикалар салу нигә кирәк булган соң? Мигрантлар (килмешәкләр) китереп тутыру өчен! Ә аларны китерү ни өчен һәм кемгә кирәк булган? Мәскәү хакимнәренә Эстонияне СССРның аерылгысыз өлеше итәр өчен. Мигрантларны күбрәк китереп, аларны төп халык белән механик рәвештә катнаштырып урнаштырган саен, эстоннар милли яктан зәгыйфьләнәчәк һәм тиз арада, күрше Псков өлкәсендәге кебек, нәсел-нәсәбен, үзенә хас үзенчәлекләрен исеннән чыгарган «совет халкы»на әвереләчәк! Димәк, мигрантлар ташкынын арттырырга кирәк!! План эзлекле үтәлә: яңа корылган, бөтен уңайлыклары булган йортларда һәр өч фатирның икесе аларга бирелә...

Эстоннарның Эстониядә азчылыкка калуы әнә шулай катастрофик рәвештә тиз бара, милләт буларак юкка чыгу хәвефе көчәя. Л. Мери шушы һәлакәтне булдырмас өчен хәленнән килгән барлык чаралар белән көрәшергә тотына, өметсезлеккә бирелгәннәрне уятырга, үзенә фикердәш итәргә талпына. Татарстан егете аның өчен ят дөньяга тәрәзә, Идел-Уралдагы хәлләрне сорашып калу өчен бик әйбәт форсат. Анда хәлләр тагын да авыррак икәнен белә, ирекле үсешне яклап бер җылы сүз әйтергә кирәклеген төшенә.

Аның кебек рухи терәк бирүчеләр, иманны ныгытучылар күбрәк очрасын иде ул дөньяда!

Бу очрашулардан соң инде байтак вакыт узды. Эстониянең бәйсезлеккә ирешү өчен алып барган көрәшендә Леннарт Мери һәрвакыт дәртләнеп катнашты. Аның иҗатында өзлексез рәвештә аз санлы кавемнәрне якларга тырышуы, бөтен эшчәнлеген үз халкының милли аңын уятуга багышлавы, Эстониянең халыкара бәйләнешләрен киңәйтүе, Көнбатыштагы җәмәгатьчелек фикерен Балтыйк буендагы хөррият, демократия көрәшен хуплауга юнәлтү хәрәкәте тора-бара тиешенчә танылды һәм бәяләнде — мөстәкыйльлеккә ирешкән Эстониянең яңа хөкүмәтендә аңа тышкы эшләр министры вазифасы йөкләнде. Хакимияткә менә шундый намуслы, бай мәгълүматлы, милли мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куя белүче кешеләр килсә генә, яшь дәүләтне халыкара мәйданда киң танытачак, республиканы алга таба ышанычлы алып барачак. Кечкенә дәүләт, аз санлы милләт өчен бу бигрәк тә әһәмиятле, чөнки аны адым саен төрле-төрле эчке һәм тышкы кыенлыклар сагалап тора. Шөкер, Эстония бу җәһәттән уңды шикелле!

Эстон әдәбияты, аны иҗат итүчеләр белән якыннан танышкач, без катлаулы чынбарлыкны, хакыйкатьне, шуны сәнгатьчә гәүдәләндерүне, матурлыкны тиешенчә аңлый, бәялибезме, алар хакында җитлеккән кешеләрчә фикер йөртәбезме икән, дип уйланырга һәм хафаланырга туры килә. Чөнки... мин күреп белгән соңгы егерме-утыз елда матбугатыбыз-

да, язучыларыбызның җыелышларында ике сүзнең берсе хезмәт темасы хакында булды. Язучылар берлеген озак вакыт җитәкләгән Гариф Ахунов бу җәһәттән аеруча гайрәт күрсәтте. Мондый шартларда әдәбиятыбызның чын мәгънәсендә беренче тарихи романын иҗат иткән Нурихан Фәттахны заманга йөз белән борылырга өндәү дә гаҗәп тоелмады. Ифрат катлаулы, матур әдәбиятта әле бер дә яктыртылмаган озын тарихы бар халыкның үткәнен гәүдәләндерергә алынган бердәнбер әдипне ниятеннән сүтелергә үгетләү шулкадәр кирәк идемени? Әдәбият вазифасын «Алга» яки «Коммунизмга» колхозында чөгендер уңышын күтәрүгә генә бәйләп кую акыллы буламы соң? Эстон язучылары әнә үз халкы тарихына гына түгел, ерак илләргә, ерак дәверләргә дә күз сала лабаса. Бер әдәби ел йомгагын ясаганда, Арво Валтонның Чыңгыз хан һәм аның мирасчылары эшчәнлегенә багышлап «Чиксезлеккә юл», Лео Метсарның борынгы Рим иле турында «Император Юлиан» романнарын язуын эстон җәмәгатьчелеге милли әдәбият тарихында куанычлы вакыйга итеп каршылады. Чөнки монда әдәбият алдына утилитар бурычлар кую гамәле юк. Чөнки монда әсәрнең кыйммәтен аның темасы да, тормыш материалы һәм вакыт чиге дә түгел, ә бәлки замандашларыбызны дулкынландырырлык, аларга гыйбрәт бирерлек мәсьәләләр куелу, шуның сәнгатьчә камил гәүдәләнделүе билгеләвен яхшы аңлыйлар. Нәтиҗәдә Арво Валтонның «Хәвефле ачыш» яки «Яшел биштәрле кеше» шикелле әсәрләре барлыкка килә.

## Барысы да истә


*Лилли Промет*

Лилли Промет 1975 елда телефоннан сөйләшкәндә мине өйләренә кичке алтыга чакырды. Вакыт иркенлегеннән файдаланып, бер китапханәгә керергә һәм аның иҗаты хакында мәгълүмат алырга карар иттем.

1922 елда туган икән. Таллинн гамәли сәнгать мәктәбендә керамика буенча рәссамлыкка укыган, аннары яшьләр газитендә эшли башлаган. 1954 елда беренче хикәяләрен бастырган.

Хәзер күпләгән новеллалар, повестьлар, романнар һәм пьесалар авторы. «Кара киемле кыз», «Караңгы тәрәзәләр заманы», «Бер җәй акварельләре» сценарийләре экранлаштырылган, әсәрләре төрле ил халыкларының дистәләгән теленә тәрҗемә ителгән Эстониянең атказанган язучысы икән ул.

«Ирләрсез авыл» романы да урыс, литван һәм румыйн телләрендә дөнья күргән, заманында Мәскәү матбугатында гына да аңа багышлап өч рецензия басылган. Әдәби мөнәсәбәтләр белән кызыксынып та, 1963 елда ук урыс телендә чыккан, Татарстан тормышын сурәтләгән бу әсәр хакында берәүдән дә берни ишетмәгән булуым шактый сәер тоелды.

Гыйнвар азагында иртән ява башлаган җепшек кар кичкә таба өзлексез сибәләп торган пыскак яңгырга әйләнде. Таллинн шәһәре читендәге Вабадусе бульварына килеп җиткәнче яхшы ук чыландым. Бусагада мине озын буйлы ябык бер ир белән мөлаем йөзле, йомшак тавышлы, ягымлы ханым каршылады.

Ральф Парве. Җәмәгатенә ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер торган, сүзгә ара-тирә генә катнашкан итәгатьле бер абзый хакында мин башта ук: «Берәр инженер-фәләндер инде бу, атаклы хатыны белән горурланып яшәүчегә охшаган»,— дип уйладым. Аңа юньләп күз салган да юк, йотылып Лилли Прометны тыңлыйм.

— Татарстанның Калинин районына ут эчендә калган Эстониядән килгәндә миңа нибары унтугыз яшь иде,— диде ул.— Бер төркем эстон Чишмәбаш авылында урнаштык. Тормыш бездә дә кысынкы иде, әмма монда шартлар тагын да кырысрак булып чыкты. Тик халык безне ягымлы каршылады, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты. Бәрәңгесен да уртаклашты, табак-савыт, бүтән нәрсәләрне дә табышты. Татарларның пакълыгы, чисталыгы безгә аеруча ошады. Күбебез телләрен өйрәнә башладык, мин дә остарып киттем. Чөнки Татарстанда яшәгәндә татар халкының гореф-гадәтләрен белеп, телен үзләштереп кенә чын интернационалист булырга мөмкин иде. Безне шуңа күрә халык та яратты шикелле. Мин Байсар мәктәбендә сызым, алман теле укыттым. Татарстанда ике ел яшәдек.

Лилли ханым эстон милли ашлары — балыктан әзерләнгән ризыклар белән сыйланырга кыстады, энҗе-мәрҗәннән муенса тезгән шикелле, сүзләрне сайлап-сайлап кына, уйчан гына сөйләде. Байсар мәктәбендә Әминә исемле шагыйрә хатын белән бергә эшләвен дә исенә төшерде. Бүләккә дип алып килгән «Татарстан совет язучылары» белешмәлеген ачып, Әминә Бикчәнтәева фотосын күрсәткәч, әңгәмәбез тагын да җанлана төште.

Казанга кайту белән мин Әминә ападан Байсар хәлләрен сораштым. Ул Мәскәү матбугатында Лилли исемле эстон язучысы исемен очраткач, «шул кыз түгелме икән бу, әдәбиятны бик ярата иде», дип юраса да, моны аныклый алмаган булган. Сәлам тапшыргач, хәзерге Актаныш районы Байсар авылындагы тормышны бик ачык сурәтләп бирде.

Качаклар арасында латыш, литваннар да була. Әмма эстоннар авыл халкы белән җиңелрәк якынаеп китә. Ирләрне фронтка озаткач, Байсарда укытучылар җитешми. Л. Промет Байсарга менә шул вакыт килә. Ата кулын тоймаган балалар бик шуклана, татарча аңламый торган нәзберек яшь кызны тыңламый аптыраталар. Ияләшү, әлбәттә, ансаттан булмый!

Эстоннар арасында укымышлы кешеләр ишле килгәнгә, алар Байсар, Чишмәбаш яшьләре арасында аң-белем таратуга һәвәсләнеп, клубта бергәләп кичәләр уздыралар, колхоз эшенә чыгып та ярдәм итәләр. Лилли дә, Әминә апа да авылга әниләре белән күчеп килгәнлектән, ике гаилә бик тиз дуслаша. Татарлар эстоннарны мунчага чакыра, көл белән кер юарга өйрәтә. Лилли Әминә апага җепне-җепкә эстонча ялгап, якорь сурәте төшерелгән кофта бәйләп бирә. Үзара ярдәмләшү, көнкүрешне бергәләп көйләү авыр заманда бигрәк тә кирәк булганлыктан, ул кофталарны башкаларга да бәйли, татар апайларына күлмәкләр дә тегә. Бәйләгәне өчен — бер дистә күкәй, теккәне өчен — әрекмән яфрагына төрелгән бер йомарлам май — хезмәттәшлек әнә шулай ике якка да файда китерә. Промет, әлеге эшләреннән тыш, буш вакыты табылды исә, китапка ябыша. Әминә ханым исә Байсарга килгәнче үк матбугатта инде байтак шигырьләр бастырган, республика балалар гәзитенең әдәби бүлеген җитәкләгән була. Шунлыктан аларның сөйләшер сүзләре, бүлешер серләре күп табыла.

Хәзер исә мин Татарстан хакында сораулар яудырган Лилли ханымда кунакта утырам. Ул бик кече күңелле. Урысча яхшы белүемә гаҗәпләнүен күрсәтә, ә үзе... миннән дә ятышлырак сөйләшә.

Сүз «Ирләрсез авыл» романына, әдәбиятларыбыз дуслыгына күчә. Татарстанга алар белән бергә Уно Лахт һәм тагын башка язучылар да күчеп килгән булган икән. Ральф Парве да фронтка Татарстаннан алынган һәм эстон укчы корпусы сафларында сугышкан. Ул татар хатын-кызларының хезмәттәге батырлыгы һәм, гомумән, хатын-кызның ирләргә караганда чыдамрак, рухи яктан көчлерәк, табигатьтән сәләтлерәк булулары турында сөйли. Үзебездәге горурланудан ерак мөнәсәбәтләрне күз алдына китерәм дә, ни әйтергә белми, мыштым гына колак салып утырам. Эстоннардан әсәрен беренче укыган язучым Эмэ Бээкман да, бүген якыннан танышкан икенче язучым да — хатын-кыз! Җитмәсә, нинди язучылар — роман, повесть, новеллаларны коеп кына торалар, исемнәре төрле милләтләрнең миллионнарча укучысына мәгълүм. Ральф абзыйга колак салганда, менә нинди рух икән монда, дип сокланмый булдыра алмадым.

Лилли ханым кулына урысча-татарча сүзлеген алып:

— Кызганыч ки, татарчаны онытып киләм инде,— диде.— Яшьлек юллары буйлап бер йөреп кайтырга бик кызыгам. Хәзер инде анда күп нәрсә үзгәргәндер, безне дә онытып бетергәннәрдер. «Ирләрсез авыл» дөнья күргәч тә татар укучылары һичбер хәбәр бирмәде...

Башка милләт язучыларының халкыбыз вәкилләрен гәүдәләндергән байтак әсәрләрен укыганым бар. Хуплау уятканнары да, нәфрәтләндергәннәре дә очрады. А. Крупняковның «Акпарс маршы» романында, мәсәлән, тарихи хакыйкатьне бозып, татар-мари халыклары дуслыгына кара күләгә төшерелә. Әдәп-әхлак ягыннан тискәре хисапланырга тиешле тарихи шәхесләр уңай каһарман итеп гәүдәләндерелә, уңай шәхесләр исә нигәдер тискәрегә әйләндерелә. Йошкар-Олада Мари язучылар берлеге рәисе Василий Юксерн белән очрашкач, шуларны искәртеп: «Нигә инде шундый әсәрләрне чыгарасыз?» — дидем. Ул минем белән килешеп: «Сүзегез дөрес, без гомер-гомергә тату яшәгәнбез, Крупняков арабызны бутый, хакыйкатьне ялганга алыштыра. Фаш итәбез, безне тыңламый. Ул мари түгел бит, әсәрләрен дә башта Мәскәүдә чыгара, аннары шундагыларга таянып, бездә»...— диде.

Крупняков һәм тагын кайберәүләр халыклар дуслыгын әнә шулай чалыш көзгедә гәүдәләндереп килде: урыс-мари, урыс-татар дуслыгын күккә чөйгән булып, татар-мари, мари-удмурт һәм башкалар татулыгын күздән төшерергә тырышты. Максаты һәм чарасы гап-гади: бүлгәлә һәм хакимлек ит! Мондый каләм ияләре әхлаксызлыгыннан гарык булганлыктан, «Ирләрсез авыл» романыннан бүтән рухны көтүем табигыйлеге шик уятмастыр.

Шөкер, бу әсәр төрле яктан бик әйбәт тәэсир калдырды. Беренчедән, ул татар әдәбиятында әле яңарак кына күренә башлаган импрессионистик алым белән язылганга тансык иде. Промет сәнгатьчә ачык детальләр, акварель, төсле йомшак карандашлар белән эш итүче оста. Иҗатта үзенә генә хас иманы бар. Мисалга, ул кеше язмышы һәм характерын аның дөньяга карашы нәтиҗәсе итеп сурәтли.

«Ирләрсез авыл» вакыйгалары татар авылы Такмакта ага. Үзәктә — күченеп килгән эстоннар. Роман әнә шуларның хосусый милекчелек мавыгуыннан, милли чикләнгәнлек карашларыннан арына башлавы, яңа тормышка ияләнүләрен гәүдәләндерүгә багышланган. Бу хәлләр совет тәртипләре инде күптән ныгыган татар авылында бара, димәк, эстоннар күңелендә борылыш хасил булуда Такмак халкының роле зур. Автор моны дәлилле итеп сурәтли, ихлас ихтирам белән тимерче Хәбибуллин, мәктәп директоры Искәндәр Сәлимев, көтүче малай Кәрим, фатир хуҗасы Фатыйма образларын иҗат итә! Хәбибуллин белән Ханнес һәм бүтән каһарманнарның җылы мөнәсәбәте аша татар һәм эстон халыклары арасындагы ягымлы бәйләнешне чагылдыра.

Лилли Промет «Ирләрсез авыл»ны Татарстаннан китүеннән соң егерме елга якын вакыт үткәч язган. Узганнар хәтерендә тоныклана

төшкәнгәме, әсәренә кайбер төгәлсезлекләр дә килеп кергән. Совет язучыларына «югарыдан» сеңдерелгән таләпләр әле беренче романын гына иҗат итүче яшь каләмне идеологик яктан йөгәнләп торуы да бик ачык ярылып ята. Татар тарихын, гореф-гадәтләрен, рухи халәтен, телен һәм мәдәниятен, үзенә генә хас тормыш-көнкүрешен Эстониядән гимназия бетереп килгән яшь кенә кыз бер-ике ел эчендә аны әдәби әсәрдә әтрафлы гәүдәләндерерлек дәрәҗәдә танып белә дә алмый, әлбәттә. «Намус», «Артта калган юллар»дагы кебек сугыш чоры татар авылын тулы канлы итеп сурәтләр өчен, шул җирлектә туып, Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттах сыман үсү кирәк иде. Промет моны яхшы аңлый һәм үз алдына, нигездә, милләттәшләрен сурәтләүне куя. Әмма әсәрдә сугыш заманы рухы, халыкның хезмәттәге каһарманлыгы, милләтләр дуслыгы да матур чагылдырыла.

Промет — психологик новеллалар остасы. Иҗади сулышы киң. Җылы, йомшак төсмерле буяулар белән эш итә, ачык сурәтләр бирергә ярата. Новеллаларына композицион төзеклек, тасвирлау нәфислеге хас.

Л. Промет кыска роман жанрында нәтиҗәле эзләнүләр алып бара. Аның «Мәзәкне кемнәр тарата?», «Примавера», «Каспар Юкси» һәм башка әсәрләре эстон прозасының җитди казанышлары исәбенә керә.

Таллиннда беренче мәртәбә гәп корып утырганда мин әле аның иҗатының барлык бу якларын белеп бетерми идем. Европаның танылган язучылары белән дусларча аралашып яшәүләрен дә гаилә альбомнарына адресымны теркәгәндә генә чамаладым. Аның битләренә, мин урнашкан креслога утырып, француз Жан Поль Сартр, фин Мартти Ларни, төрек Назыйм Хикмәт һәм бүтән каләм ияләре истәлек язуларын калдырганнар.

Вабадусе бульварының биек-биек наратлары ышыгында җыйнак ак коттеджлар тезелеп киткән. Тирә-якта дивар булып күтәрелгән урман. Хәер, мин төн караңгысында аның эченә кермәдем, кешедән сорашмадым, куелыгы, мәһабәтлеге белән ул үзе миндә әнә шундый тәэсир калдырды. Һәрхәлдә, шәһәрнең кырые иде инде бу. Мондый шартларда торучыларның байтагы бездә үз оясын имән ишекләр, башына карасаң, бүрегең төшеп китәрлек биек таза коймалар артына яшерә һәм еш кына капка баганасына: «Ишегалдында усал эт бар!» — дигән кисәтүле язу да кадаклап куя. Прометлар биләмәсенә исә тәбәнәк рәшәткәле киртәнең җил капкасын ачып керәсең. Өйләренең киң тәрәзәләре, нәфис җиңел ишегенең өске ягы пыяла гына. Ул ишекләр Промет әсәрләрендәге акварель буяулар белән гәүдәләндерелгән, ачык, җылы төсләр өстенлек иткән дөньяга алып чыга. Тормышы һәм рухи йөзе арасында гаҗәеп тәңгәллек. Бәлки менә шундый булганы өчен дә аңа укучылары еш киләдер.

Лилли ханым, саубуллашканда, Татарстан халкына кайнар сәлам һәм матур теләкләрен җиткерүне үтенде. Аннары:

— Кызганыч, Ральфның урысча җыентыгы кулыбызда юк, бүләк итә алмадык,— дип пошынды.

Казанга кайткач ачыкладым: аның ире Р. Парве дә китаплары дистәләгән телләргә тәрҗемә ителгән шагыйрь һәм драматург — республиканың әдәби премиясе лауреаты, СССРның биш ордены кавалеры, Эстониянең атказанган язучысы икән! Шигырьләренә нәфислек, фәлсәфилек, аерым бер моң хас.

Ике елдан соң кабат күрешкәндә мин инде эстон прозасы белән хәтсез танышып, бигрәк тә Лилли ханымның әсәрләрен укып, хәтта «Ирләрсез авыл» романыннан бер өзекне тәрҗемә итеп һәм аны «Азат хатын» журналында бастырып та килгәнлектән, әңгәмәбез тагын да ихласрак, җанлырак барды. Мин аңардан:

— «Ирләрсез авыл» романын сез нигә сюжетсез яздыгыз? — дип сорадым.— Безнең татар укучысы андый әсәрне авыррак кабул итә.

— Безнең әдәбиятыбыз көчле,— диде Лилли Промет.— Укучыларыбыз әзерлекле. Әдипләребез дә зәвекъле. Аларның күпчелеге мавыктыргыч сюжет кора ала. Чөнки аның калыплары күптән эшләнгән. Тик бит ул бик шартлы нәрсә булачак. Шуңа күрә без аңа алынмыйбыз. Әсәргә беренче нәүбәттә характерлар кирәк. Берәр проблема күтәрелү, фикер әйтелү мөһимрәк. Без яңалык ачарга, күңеленә фикер салып, укучыны үстерергә тырышабыз. Көнбатыш әдәбиятын күп тәрҗемә итәбез. Кайбер республикалар әйләнеп-тулганып, «чит илләрдәге казанышларны кабул итәргәме, юкмы?» дип баш ваткан арада, бездә инде каләм әһле генә түгел, гади укучылар да аның белән танышып өлгергән була. Шуңа күрә без яңа формаларга да һәвәсрәк. Әдәбиятыбыз эзләнүчән, яшьләребез көчле. Кайчак алар бәлки корырак, ялангачрак язадыр. Әмма яңалыгы була, кызык!

Мәскәүдә бер кыргыз язучысы белән сөйләшкәндә, аларның прозасына кагылган тәнкыйть фикере әйткәч, әңгәмәдәшем моны бик авыр кабул иткән иде. Гарьләнде, кимсенде дә, ахры. Бу яктан эстоннар бөтенләй башка. Лилли ханым, мәсәлән, Ленин премиясе лауреаты Ю. Смуул турында:

— Әдәбиятка сугыштан соң килде,— диде.— Белеме дә юк иде егетнең, нибары — сигез класс, әмма үзенчә яза. Без аның һәр әсәрен көтеп алып укый идек. Тик хәзер... искерде инде!

Прометларның шәхси китапханәсендә — алты мең том! Күпчелеге укылган. Уку аларга әллә ни комачауламый да, күрәсең. Лилли ханым инде алты томлыгын да чыгарырга өлгергән. Җитмәсә, дөнья әдәбияты тәҗрибәсен нык үзләштергәнлектән, Промет та, Парве дә велосипед уйлап табу белән мавыкмый. Язганнары — чын шигырь, чын проза, чын пьеса. Каһарманнары тән тормышы белән түгел, рухи тормыш белән яши. Гаҗәп түгел, сәнгать әсәре нәкъ менә шундый булырга тиеш тә. Әмма моңа ирешү өчен автордан да бик күп нәрсә таләп ителә шул!

Сәфәрләрнең берсендә без Таллиннга гаилә белән килдек. Бу юлы хуҗалар безгә аеруча кечелекле булды — Ральф абый үзе рульгә утырды. Лилли ханым шәһәр белән таныштырып барды. Безгә гүзәл сәнгать әсәрләре, фәнни казанышлар бүләк итеп калдырган үлемсез затларга баш ияр өчен зиратка баргач, мин ике нәрсәгә игътибар иттем. Беренчесе — бу зират барыннан бигрәк паркка охшаган иде. Сирәк наратлык арасында ямь-яшел чирәмлек, ком сибелгән юллар. Кабер өсләрендә купшы һәйкәлләрнең заты да юк. Барысында да бер төсле дип әйтерлек мәрмәр такта гына кырын яткырып куелган. Аларда гади генә итеп язылган исемнәр. Титулдәрәҗәләр дә саналмаган. Librariesталар алдында — тере чәчәкләр. Барысы да дип әйтерлек бер үк төрле гөлләр. Саный китсәң, монда нинди генә мәшһүр язучылар, галимнәр күмелмәгән. Язуларны укый-укый сукмактан атлаганда, рухыңны гранит сыннар авырлыгы изми, бөек шәхесләргә, аларны шушылай гади, әмма ихлас хөрмәтли белүче халыкка ихтирам хисе генә уяна.

— Гранит һәйкәлләр куя башласак, бик ихтимал, кибетчеләр язучыларны бик тиз узып китәр иде,— дип елмая Лилли ханым.— Чын ихтирам, мәхәббәтне күңелләрдә сакларга кирәк. Мәрхүмнәр хакына яхшылыкны, матурлыкны арттырып.

Икенче гаҗәпләндергәне — Лилли ханымның зиратка кергәндә дә, аннан чыкканда да Ральф абыйны җитәкләве булды.

— Ырымнарга бик ышанмыйм, әмма мин хәзер гел шулай итәм,— диде ул.— Ральф белән мин бик бәхетле яшәдем, киләчәктә дә аның белән янәшә атлыйсым килә. Гаиләнең кадерен яшь узган саен яхшырак белә барасың. Сезнең бу юлы сәяхәткә гаилә белән чыгуыгызны белгәч, без бик шатландык, балаларыгыз белән дә танышасыбыз килә иде...

Танылган бер эстон язучысы, совет җәберен шактый татыган һәм тоталитар системаны, Эстониянең бәйсезлеген юк иткән режимне җанытәне белән дошман күргән каләмдәшем, Л. Промет белән Р. Парве турында сүз чыккач:

— Алар беркайчан да әдәби хәрәкәтебезнең үзәгендә кайнамадылар, милли көрәштән һәрчак читтә калырга тырыштылар. Кызыллар!— дигән иде.

1989 елның азагында Лилли ханым миңа Мәскәүдә басылган яңа китабын — «Сез галиҗәнапкә алтын чәчәкләр»ен бүләк итеп җибәрде. Бу җыентыкка аның атасына, үз тәрҗемәи хәленә, әдәби иҗат мәсьәләләренә кагылган әсәрләре тупланган иде. Шушы китап белән танышкач, Л. Прометның Эстониянең советлашуына, аның СССР составына кертелүенә хезмәт итүе сәбәпләре аңлашыла. Ул — күренекле, әмма буржуаз Эстония һич тә кадерен белмәгән, ачлыкта-ялангачлыкта яшәткән художникның кызы. Советлар берлегендә мондый рәссамнарның тормышкөнкүреше бик һәйбәт булган дигән ышанычта тәрбияләнгән бала. Үзенчәлекле язмышы Л. Прометны эстон милләтпәрвәрләренең бәйсезлек өчен көрәшеннән чынлап та ерактарак тота. Әмма моңа карап кына аны тоталитар режим, шовинистик милли сәясәт тарафдары дип санап булмый — ул ялган интернационализмга, коммунизм тәгълиматының катып калган, гамәлдә акланмаган «теориясенә» һәм практикасына каршы үзенчә көрәште — моңа аның «Примавера» романы һәм бүтән күп кенә әсәрләре дәлил.

«Сез галиҗәнапкә алтын чәчәкләр» китабы минем алда Л. Промет абруен тагын да югарырак күтәрде. Нечкә ирониясе, йомшак сарказмы, каләмдәшләрен һәм үзен елмаеп тәнкыйтьләү һәм көлемсерәп мактау осталыгы, дөнья әдәбияты казанышларын яхшы белеп кыю һәм оригиналь фикер йөртүе белән ул мине тәмам әсир итте. Лилли ханым бу җыентыгында үзенә рухи азык биргән язучылар, рәссамнар, композиторлар, галимнәрне, гомер юлында очраган бүтән кызыклы шәхесләрне, аларның тормышларын һәм иҗатларын бер отышлы деталь яки вакыйга аша шундый ачык күз алдына бастыра ки, документаль бу язмалар — кыска эсселәр, интервьюләр, парчалар озын хикәя, романнарны алыштырырлык дәрәҗәгә җитә. Икеләнмичә әйтергә мөмкин — бу җыентык тәҗрибәле каләм иясенең иҗатын гына түгел, эстон әдәби һәм фәлсәфи фикерен тулаем да мактаулы югарылыкка күтәрүе белән игътибарга лаек. Димәк, Л. Промет эстоннарның милли горурлыгын, Эстониянең халыкара абруен күтәрүгә дә бик уңышлы хезмәт итә!

Гадәттәгечә, аның бу китабында да татар дөньясына кагылган сәхифәләр бар. Гаиләләре Таллиннга күчеп килгәч, алар монда мех белән сәүдә итүче татар сәүдәгәре Мәһдиев өендә фатирда торганнар икән. Татарстанның Чишмәбаш, Байсар, Пучы авыллары, Казанның Эстония вәкиллеге урнашкан Бауман урамы да язучы хәтерендә яши. Шушы хакта язылган сәхифәләрне укыгач, Лилли ханым күңелгә тагын да якыная, еллар томаны да тоныкландыра алмаган сурәте хәтердән китми. Аның сокландыра торган зыялылыгын, нәзберек-нәфис кыяфәтен, назлы-сөйкемле фигылен, ихтыяҗы чыкканда гаҗәеп итәгатьлелек, тыйнаклыкка төренгән әче теллелеген, кискенлеген Мәскәүдән килгән «өлкән туганнарны» кабул иткәндә күрсәгез икән сез! Каһвә эчеп утырганда шуларның берсе, үзен дөньяның кашка тәкәсе санаучысы, бик зур хөрмәт күрсәткәндәй:

— Лилли, сез урысча шундый матур сөйләшәсез, нигә урысча гына язмыйсыз?— дип «комплимент» әйтә.

— Мин алманча һәм инглизчә, финчә һәм французчаны да шул ук дәрәҗәдә беләм. Нигә соң әле мин шул телләрнең барысында да язарга тиеш?— ди хуҗа ханым.

«Өлкән туган», кайнар каһвәдән авызы пешкәндәй, берни әйтергә дә белми аптырап кала, аннары елмайгандай, сүзне уенга боргандай:

— Лилли, ә сез урысларны шулай да яратып бетермисез,— ди.

— Менә алманнар килде, 61000 бер гөнаһсыз кешене үтерде, менә сез килдегез, шулкадәр үк кешене Себергә сөрдегез,— ди Лилли ханым.— Нишләп әле без генә сезне яратырга тиеш, үзебез дә башкалар мәхәббәтенә лаек түгелмени?

Мәжлеснең ничегрәк тәмамлануын, Мәскәү әфәндесенең — бер тел белүне рекорд санаучы «галиҗәнапнең» шуннан соң «комплимент» әйтүдән дә, акыл сатудан да туктавын, үзе хакында начар тәэсир калдырмас өчен, сүзне башкага борып азаплануын күзаллау укучыларга, мөгаен, бик кыен булмас. Л. Промет һәр халыкның башкалар җиренә әйләнмәгән үз ватаны, ул ватанда иректә яшәүче үз халкы булырга тиеш дип аңлый, башкаларның да шушы хокукларны танып һәм хөрмәт итеп яшәүләре өчен сәләтен һәм көч-куәтен җәмгыятькә бирә. Онытып карагыз сез мондый кешене!

## Музейлар, театрлар иле

Юк, Эстония беренче нәүбәттә яшел яланнар, күгелҗем урманнар, зәңгәр күлләр иле, диярләр миңа. Эстония — диңгез буе дәүләте, янар сланецлар мәмләкәте, димәк, ул — балыкчылар, шахтерлар иле дияргә дә мөмкиннәр. Кемнәрдер аның матбугат, фән үзәге булуына басым ясар һәм аларның һәммәсе үзенчә хаклы булыр. Мәсәлән, элекке СССР халкының 0,6 процентын гына тәшкил иткән хәлдә, Советлар берлеге фән докторларының 0,7 проценты Эстониягә туры килде. Бу республикада галимнәрнең 85 проценты эстоннар иде. Фәннәр академиясе челтәрендә Татарстанда тел, әдәбият, сәнгать, тарих, иҗтимагый фикер, икътисадны өйрәнү буенча йөзләп кенә кеше шөгыльләнсә, Эстониядә бу эшне 560 лап кеше җигелеп тартты. Эстон теленә 94 халыкның әдәбияты, шул исәптән, илле дүртенеке турыдан-туры асыл нөсхәдән тәрҗемә ителде...



*Борынгы Таллинн һәм аның кунаклары*

Әмма театрлар һәм музейлар өлкәсендә, минемчә, эстоннар бездән тагын да өстенрәк иде. Җиде миллион татарга биш (айга бер-ике татарча спектакль куйган опера-балет труппасын болар исәбенә кертү кыен) профессиональ театр хезмәт күрсәткәндә, бер миллион эстонда алар

тугызау иде. Ягъни, җан башына исәпләгәндә, татарныкыннан унөч тапкыр артыграк. 3,7 миллион халкы булган Татарстанда 22 музей ачылса, Эстониянең бер миллион ярым кешесе 78 не булдырган иде. Димәк, җан башына тугыз тапкыр күбрәк!

Бу җәһәттән Эстония аерым музейлары белән генә түгел, аларның тоташ бер мәйданын тәшкил иткән борынгы Таллинн — Тоомпеа (югары шәһәр) белән дә мактана ала. Ул җиде гектар зурлыгындагы калкулыкка урнашкан. Ике кулны як-якка сузып иңләрлек тар урамнары, 1219 елда салынган ныгытма-замогы, бераз соңрак корылган калын диварлы нык манаралары, җанлы тарих сыман, үткәннәр турында сөйли. Кырык алты метр биеклектәге Озын Герман манарасы Таллинны менә инде биш гасыр буе афәттән саклап килә. Кырыс, ераклардан күренеп торган төз манарада бүген Эстониянең дәүләт әләме җилферди. Тоомпеа сараенда хәзер Республика министрлар кабинеты һәм Югары Мәҗлесе урнашкан. XIII гасырда салынган чиркәү исә Таллинның иң борынгы гыйбадәтханәсе санала.

Заманында Аурупада иң биек корылма исәпләнгән Олевисте чиркәве диңгез өсте тигезлегеннән йөз кырык метрга күтәрелеп тора һәм ул озак вакыт диңгезчеләргә маяк хезмәтен үти. Аркылысы егерме дүрт метрлы Юан Маргарита манарасы, очлы угын күккә терәгән Нигулисте чиркәве. Тоомпеадан шәһәргә, Балтыйк диңгезенә алып төшә торган Озын аяк һәм Кыска аяк урамнары! Монда һәр исем шагыйранә һәм ягымлы. Текә чирәп түбәле готик стильдәге йортлар арасында бормалы-сырмалы урам, тыкрыклардан узганда балачактан ук таныш туган авылыңа кайткандай буласың. Һәркайсы үзенә генә хас сыйфатлы биналарны, ят телдә сузык авазларга юмарт сүзләр язылган урам чатларын һәм игъланнарны карап йөргәндә, тарихын һәм үткән заман һәйкәлләрен олы ихтирам белән кайгыртучан саклый белгән халыкка ирексездән сокланасың. Җитен чәчле сылу кызлар, камыш буйлы егетләрнең җыр кебек агылган тавышлары озак-озак колагыңда чыңлап тора.

Тоомпеада йөргәндә әле тегендә, әле монда калкып торган замокларны гына күргәнгә, мин гид ханымнан:

— Сездә кремль юкмыни? — дип сорадым.

— Кремль урысларда гына була, — диде ул һич тә икеләнеп тормастан.

— Безнең Казанда да бар ич.

— Аны да урыслар корган.

Болгар ныгытмалары, Казан кремле, урысларга да ташпулатлар, шул исәптән, чиркәүләр дә корып биргән ата-бабаларыбыз хакында бераз аңлатма бирергә туры килде үзенә. Мисал итеп XII йөз ахыры — XIII йөз башында Владимир шәһәрендә болгар бабаларыбыз салган Үспен гыйбадәтханәсен дә телгә алдым.

— Сезгә каты бәрелдем, ахры, — диде гид гафу үтенеп. — Белешмәлектән укыганда ук шикләнгән идем аны, болай булгач, яңа чыганакларны караштырырга туры килер инде.

Таллинн буенча сәяхәтебез дәвам итә. Гид тарихи риваятьләрне шундый ягымлы, матур аһәңле тавыш белән шундый җиңелчә юмор да кушып сөйли ки, елмаймый, осталыгына сокланмый, сәләтенә көнләшми тыңлавы да читен!

Хәзер Тоомпеада кибетләр, кафе һәм ашханәләр, музейлар һәм административ идарәләр генә калган — һәммәсе илгизәрләргә хезмәт күрсәтә. Монда даими яшәгән халык соңгы дәвердә суы, газы һәм бүтән барлык уңайлыклары булдырылган яңа микрорайонга күчерелгән.

Тарихи һәйкәлләр Таллинның бүтән җирләрендә дә бар. Кадриорг паркы әнә шундый истәлекле урыннарның берсе. Рәсәй патшасы Беренче Петр аның агачларын хатыны Екатерина хөрмәтенә утырттырган. Парк эчендә патшаның үзе өчен салынган йорт тә исән. Мәгълүм ки, Беренче Петр бик озын — ике метр буйлы булган, әмма ул биек түшәмле

бүлмәләрдә яшәүне яратмаган. Шуңа күрә бу йортның ашханәсе ике метр бер сантиметр биеклегендә — патша башы тимәслек итеп кенә корылган.

Кадриорг паркыннан ерак түгел бер җирдә җыр бәйрәмнәре уздырыла торган корылма бар. Аның йөз меңнән артык кеше сыйдыра торган амфитеатры һәм утыз мең кешегә исәпләнгән сәхнәсе заманыбыз колачын күз алдыбызга әйбәт бастыра.

Таллиннда шагыйранә исемнәр кушарга яраталар. Мисалга, шәһәрнең йөз мең кеше яши торган бер микрорайонына Лиллекола (Чәчәк кала), энергетика товарлары фабрикасына Илмарине дигәннәр. Илмарине — тимерчелек алласы исеме.

Таллинн Алмания, Италия, Маҗарыстан, Суоми шәһәрләре белән туганлашкан — ул шул калалар белән ярышып үсә. Яңа сәүдә йорты, тимер юл вокзалы, аэропорт, «Эстония» театры, кинотеатрлар һәм нәшриятлар — башкаланың яңа архитектура бизәкләре. Дуслык һәм хезмәттәшлек һәйкәлләре дә күренә — финнәр салган егерме өч катлы «Виру» кунакханәсе, маҗарлар ярдәме белән барлыкка килгән «Маҗар ашлары йорты», кунаклар кабул итәр өчен Эстония үзе төзегән егерме сигез катлы «Олимпия» кунакханәсе әнә шундыйлардан.

Таллинн урамнарында йөргәндә җыйнак, чиста, безнекенә караганда шактый таррак трамвай вагоннарына күз төшми калмый. Башта алар сәер, кысан кебек тоела. Әмма таллиннлылар аңа шулкадәр ияләшкән, ыгы-зыгы, шау-шусыз барысы да сыя тагын.

Тулы бәйсезлеккә ирешкәнче үк, трамвай талоннарыннан алып игълан һәм эш кәгазьләренә кадәр монда барысы да эстон телендә иде инде. Латин хәрефендәге язуларга, тар урамнардагы озын буйлы, җитен чәчле кешеләр арасына килеп кергәч, монда үзеңне чын-чыннан чит илдә хис итә башлыйсың. Урысча эндәшүгә, монда һәр эстон ашыга-кабалана урысча җавап бирергә керешми, билгеле. Килмешәкләргә яраклашу, татар кебек, үз ватанында хуҗа булу тойгысын югалткан, коллык фигыленә бирелгән халыкта гына булырга мөмкин. Әмма урысча сөйләмендә акцентың ныграк яңгыраган саен, Таллиннда сиңа игътибар арта бара, тәрбияле эстоннар соравыңа алман, урыс, фин телләрендә иң кыска җөмләләрне сайлап җавап бирергә тырыша.

Эстониядә элек җил тегермәннәре, салам түбәле утарлар гадәти күренеш була. Хәзер инде салам түбә дә, җил тегермәннәре дә ачык күк астындагы музейларда гына саклана.

Эстон игенчеләре борын-борыннан бездәгечә авыл булып түгел, үз биләмәсендә утар корып яши. Алар гадәттә бер-берсеннән яртышар чакрымда урнаша, утарларны тоташтырган юл исә урам хезмәтен үти. Утарда йортлар, борынгы Төркестандагы кебек, ишегалдына карап тора. Караллы-кура йорттан аерым салына, мунча бер кырыйга читтәрәк урнаштырыла. Утарны җиләк-җимеш бакчасы уратып ала. Бездәгедән аермалы рәвештә, явым-төшем муллыгы аркасында, монда түбәләрне генә текәрәк коралар. Суур Яанидагы тормыш рәвеше, шулай итеп, музейларда күрсәтелгәнгә охшаган да, юк та!

Эстон милли киеменә буяулар чуарлыгы, кызыл төсне яратып куллану хас. Аны Кихну утравы кешеләре һәм көньяк-көнчыгыш Эстония халкы аеруча яратып кия. Милли киемнәр бәйрәм көннәрендә шәһәр халкы өстендә дә күренә.

Таллинн кешеләренең көязлеген бер карауда ук абайларга мөмкин. Монда арзанлы, әмма модалы кием кияргә яраталар. Күлмәккә һәм хәтта туннарга да эстон милли бизәкләрен чигәләр.

Эстон милли ашлары безнең өчен шактый ук сәер һәм ят: арыш, бодай, борчак, арпа оннарын сөткә, әйрәнгә изеп пешерелгән камыр азыгы; дуңгыз ите, ярма кушып әзерләнә торган кәбестә ашлары; кан колбасасы! Һәркем үзе әчетә торган сыра.

Эстоннар кичен утлар ягып, җыр-бию, уеннар белән егерме дүртенче июньдә урак бәйрәме уздырырга ярата. Бу көнне гөслә сыман милли уен коралы — каннель тавышы аеруча дәртле яңгырый.

Эстониядә алман һәм швед телләрендә укыта торган беренче гимназия 1631 елда ачыла. Бер елдан соң инде академия, ягъни Тарту университеты нигезләнә. Күрше илләрдәге шундый уку йортлары (Вильнюста — 1579) арасында ул икенче була һәм аның дүрт бүлегендә тиздән бер мең җиде йөз студент белем ала башлый. Әмма күрше дәүләтләрнең үзара сугышлары көчәю аркасында, бу югары уку йортының эшчәнлеге 1710 елда туктала һәм бу эш 1802 елда гына яңартыла. 1895 елда анда укыту алманчадан урысчага күчерелә.

Тарту университеты әле дә Эстониянең иң абруйлы фән һәм югары белемле белгечләр әзерли торган учагы. Анда йөздән артык фән докторы, биш йөзләп фән кандидатының лекцияләрен сигез мең ярым студент тыңлый. Астроном В. Струве, табигатьне тикшерүче К. Бэр, А. Миддендорф, хирург Н. Пирогов исемнәре Тарту университетыннан аерылгысыз. Беренче эстон галимнәре К. Петерсон, Ф. Фельман, Ф. Крейцвальд, М. Веске һәм башкалар нәкъ менә шушыннан үсеп чыга. Бүген дә гыйльми тикшеренү һәм укыту белән шөгыльләнүче П. Аристэ, Ю. Лотман, Х. Трасс, В. Мазин, Ю. Саарма, Л. Алликметс кебекләрнең исемнәре чит илләрдә дә билгеле.

Фин-угыр халыкларын өйрәнүгә, фәннең электрохимия, молекуляр биология, йөрәк хирургиясе һәм тагын бүтән тармакларын тикшерүгә Тарту университеты галимнәре аеруча җитди өлеш кертә. «Скандинавия җыентыгы», «Органик кушылмаларның реактив сәләте» шикелле халыкара басмаларны да нәкъ менә шушы университет чыгарып килә. Монда уникe гыйльми советта утыздан артык белгечлек буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклана. Тарту университеты еракгагы һәм якындагы күп кенә гыйлем учаклары, җөмләдән, Казан университеты белән дә тыгыз хезмәттәшлек урнаштырган. 4,2 миллион чамасы китап туплаган фәнни китапханәсе, астрономик обсерваториясе һәм ботаника бакчасы, ике дистәләп тикшеренү лабораториясе, нәшрияте һәм типографиясе гыйльми эзләнүләр алып баруга нәтиҗәле хезмәт итә.

Эстониядә 1990 елда җиде югары уку йорты һәм Фәннәр академиясе эшли, аларда җиде меңләп фәнни хезмәткәр, шул исәптән, 327 фән докторы һәм 2975 фән кандидаты (1987 ел) даими тикшеренү алып бара иде. Туган телдә фәнни-техник әдәбиятның күп басылуы, «Эстон совет энциклопедиясе»нең уникe томлы яңа басмасы 220 мең данәдән таралуы — чынлыкта һәр гаиләгә барып җитүе шулай ук бүгенге эстон халкының чын мәгънәсендә укымышлылыгы хакында сөйли.

«Тарих — тормыш остазы»,— ди борынгы фикер иясе Цицерон. «Тарихи үсешне күзалламыйча кешелекне дә, табигатьне дә аңлау мөмкин түгел»,— ди Герцен. Тарих белән күзгә-күз исә музейда гына очрашырга мөмкин. Чөнки монда үткәнне укып кына түгел, күреп, хәтта тотып карап та аңыңа сеңдерәсең. Музей үткән белән генә түгел, бүгенге тормыш, кеше эшчәнлегенең төрле тармаклары белән дә таныштырып, зиһенеңне баета. Монда акылыңа гына түгел, хисләреңә дә мул азык аласың. Эстония музейларында 1985 ел ахырында ук инде 4,6 миллион әйбер саклана иде. Музейларның да ниндие генә юк: Зоология музее, Диңгез музее, Сланец музее, Янгыннан саклану музее, Театр һәм музыка музее...

Таллинн шәһәр музеенда миңа бары тик Эстониядә генә күрергә мөмкин булган әйберләр аеруча ошады. Тукымадан эшләнгән чәчәкләр, төрле сыннар, табигать күренешен гәүдәләндергән чигешләр, нәни рәсемнәр, җон җебеннән бәйләнгән нәрсәләр эстон халкының үзенчәлекле фикерләү рәвеше, образлар, мифләр дөньясы белән таныштыра. Кеше һәм җәнлек сыннары, фантастик затлар шулкадәр кызык — хыялны уята, уйлата торган рәвештә шундый үреп ясалганнар ки, сокланмый хәлең юк.

Ул сыннарда уймак, көзге, каурый кебек нәрсәләр дә килешле һәм урынлы файдаланылган. «Йомгакның төш күрүе» экспонатын елмаймый тамаша кылу мөмкин түгел. Гомумән, бу бүлек яналыгы, үзенчәлеге белән мина аеруча хуш килде. Ваза, шкатулка, төрле-төрле бизәкле тәлинкәләр дә Эстониядә һөнәрчелек, сәүдә үсешен бик матур чагылдыра.

Университет галимнәре ярдәмендә Ф. Крейцвальд исемендәге Тарту әдәбият музеенда эстон телендә чыккан бөтен китаплар һәм газит-журналлар диярлек тупланган. Аның хәзинәләрендә тугыз йөз мең чамасы экспонат, шул исәптән, йөз мең кульязма һәм хат җыйналуы үзе генә дә аерым игътибарга лаек. Күренеп тора: Эстониядә бер генә күренекле язучының, бер генә күренекле галимнең дә кадерле мирасы әрәм-шәрәм ителми — дәүләт сагына алына һәм милли байлык сыйфатында яңа буыннарга мирас итеЛә. Аларны карап йөргәндә ирексездән татар әдәбияты өчен пошынасың: шушындый кайгыртучанлык күрсәтелгәндә, безгә ымы-шымы гына ишетелгән Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» трилогиясеннән икенче-өченче китаплар, Заһир Бигиев, Габделҗаббар Кандалый, Мөхәммәдъяр, ирексездән мөһаҗирлеккә киткән Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Зәки Вәлиди шикелле каләм ияләребезнең әсәрләре, күплләгән газит-журналларыбыз да безгә вакытында исән-сау килеп җиткән булыр иде.

Этнография музее, Классик борынгы әйберләр музее, Сәнгать музее, Парк-музей, атаклы язучыларның, сәнгать һәм фән эшлеклеләренең дистәләрчә махсус музейлары, республика һәм районнарның тарих музейлары — аларның һәммәсе үзенә бер мәктәп, үзенә бер гыйбрәт.

Эстон дәүләт парк-музеенда, мәсәлән, XVIII—XX йөз башы авыл корылмалары ачык күк астында җыйналган. Җитмеш бер гектар урманлы, таулы, болынлы мәйданда торак йортлар, каралты-кура, җил һәм су тегермәннәре, коелар, авыл кешесенең көнкүреш һәм хуҗалык әйберләре тупланган. Мунча, чиркәү, корчма, ындыр кебек корылмалар монда табигый хәлендә, бөтен җиһазы, бизәлеше белән саклана. Байлар йорты, фәкыйрьләр алачыгы, балыкчы утары һәм игенче биләмәсе — һәммәсе үз заманындагы хәлендә. Тамашачы ата-бабаларының йөз яки өч-дүрт йөз ел элек ничек яшәгәнен күрергә тели икән, рәхим итсен! Мичкә, гөбе, каба, агач җамаяк, сугу ыстаны, арба-чана, иләк-чиләк, кием-салым, эш кораллары — кырык алты мең экспонат арасында нәрсә генә юк! Аларны тамаша кылганда эстон халкының башыннан нинди дәверләр кичерүе, тормыш-көнкүреше заманнар агышында ничек үзгәрүе, үсүе аермачык күз алдына баса. Үзеңнең кайдан, нәрсәдән башлануыңны белү адәм баласы саналучы һәр җан иясенә фарыз. Белем һәм аң үзеннән-үзе генә һәр бәндәнең миенә кереп ояламый, һәр кемсә өчен уңайлы шартларда тәрбия алырга тиеш. Эстониядәге кебек, кешелекле һәм ватанчыл кешене бары шулай гына үстерергә мөмкиндер. Тоталитар режимнең Эстониядә аеруча тиз зәгыйфьләнүен, яңарыш хәрәкәтенең элекке СССР җөмһүриятләре арасында нәкъ менә Эстониядә дәрт-дәрманга ия булуын да мондагы шушы тәрбия челтәренә бәйләп карарга кирәк.

Эстоннар халык буларак уналтынчы йөздә үк формалашкан. Эстон теле фин-угыр телләре гаиләсенә керә. Алар финнәрнең һәм мажарларның, безнең күршеләребез мари, удмурт, мордваларның кан кардәшләре. Әмма күп гасыр элек Балтыйк буена килеп урнашу, бәйләнешләр зәгыйфьләнү аркасында, эстон теленә ят кавемнәр — алман, Скандинавия халыклары һәм славян телләре йогынтысы көчәя, кардәш телләр үзара ерагая бара. Шуның нәтиҗәсендә мажарлар белән уртак сүзләр өч йөз, мари белән уртагы алты меңгә генә кала.

Фин-угыр һәм төрки телләр Алтай телләре кардәшлеген тәэзи, шуңа күрә эстоннар белән татарларның да якынлык эзләрен табарга мөмкин. Урамда йөргәндә миңа «кола», «суур», «йок» сүзләрен дә ишетергә туры килде. Эстоннар авызыннан. Татарча «кала» (шәһәр), «зур», «юк»тан

аерма бик әз икән! «Суи», «пәә», «тәң» сүзләре исә безнең «җәй», «баш», «тәңкә»гә якын.

Эстон теле җәмгыяте, Таллинида чыгарыла торган «Кеэль я кирьяндус» («Тел һәм әдәбият») айлык журналы һәм мәкаләләре алман, инглиз, урыс, француз телләрендә басыла торган кварталлык «Совет фин-угырчылыгы» журналы эстон телен төрле яктан өйрәнүгә хезмәт итә.

Сурәтче И. Келер, уйма-сынчы (скульптор) А. Вейценберг унтугызынчы гасырның алтмышынчы елларында эстон сынлы сәнгатенә нигез сала. Беренче профессиональ композиторлар И. Каппель, М. Хярма милли музыканы үстерә башлый. Табигый ки, сәнгатьнең шушы тармаклары үсеше соңгырак дәвердә генә көчәеп китә. Моңа 1919 елда консерватория ачылу һәм Югары сәнгать мәктәбе нигезләнү аеруча нык этәргеч бирә. Бигрәк тә эстон гамәли сәнгате үрнәкләре Эстониядән читтә дә киң танылa. Керамика, металл, тире, тукыма белән эш итүче рәссамнар иҗаты эстон сәнгатен үстерүгә яңа сулыш өрә.

Соңгырак дәвердә Эстониянең графика сәнгате халыкара күргәзмәләрдә дә югары бәя ала. Аңа темалар төрлелеге, сурәтче уенның кырыс алымнар белән тормышка ашырылуы хас. Э. Окас иҗатында, мәсәлән, шахтерлар тормышы, андагы үзгәрешләр чагыла. Г. Рейндорф, П. Лухштейн һәм башкаларның исемнәре дә сәнгать сөюче күпләргә танылa.

Бүгенге эстон музыкасы профессиональ яктан югары дәрәҗәдә үскән сәнгать санала. СССР халык артисты Э. Каппның «Үч утлары» операсы эстоннарның илбасарларга каршы тарихи көрәшен чагылдыра. Аның «Калевипоэт», СССР халык артисты Г. Эрнесаксның «Давыллар яры» һәм бүтән опера, балетлары сәхнәдә бүген дә зур уңыш белән уйнала. Х. Эллер, Э. Тамберг симфонияләре республикадан читтәгеләргә дә ошый. СССР халык артистлары Г. Отс, Т. Куузик, А. Лаутер милли музыканы ерак-еракларга да яңгыратып, шөһрәт казануга ирешә.

Югары культуралы профессиональ башкаручылары булу, музыка, шул исәптән, күмәк җырлау традицияләре тирәнлеге эстоннарда нечкә зәвекъ тәрбияләнүенә, сәнгатьнең халык күңеленә тирән үтеп керүенә ярдәм итә. Бүген Эстониядә егерме дүрт халык хоры, унбер атказанган хор бар. Профессиональ коллективлардан Камера хоры, Ирләр академик хоры халыкара күләмдә мәгълүм. Соңгысы Татарстанда да берничә тапкыр гастрольдә булды һәм җылы кабул ителде. Музыкаль труппаларга ия «Ванемуйне» һәм «Эстония» театрлары ел саен дистәләгән спектакль куеп килә.

Музыкаль сәнгатьнең башы — махсус мәктәпләрдә. Бер миллионлы халыкның туган телдә укыта торган әнә шундый утыз алты мәгариф учагы бар. Милли сәнгатенең чәчәк атуы хакында лаф орган Татарстанда беренче милли музыка мәктәбе бары тик 1993 елда гына ачыла алды!

Кингисепп исемендәге академия драма театры бинасының соры известьташлары әле буе, әле киңлеге, әле кыры белән түшәлеп, үзенчәлекле мозаика барлыкка китерә. Бинаның кабарынкы почмаклары һәм ярым гөмбәз түбәле янкорма сыман бүселеп чыгып торган кабыргаларына, аерым өлешләре төрле биеклектә булган түбәсенә карагач, аның театр икәнлегенә дә шикләнә калдым. Тышкы формасы белән ул урта гасырлар гыйбадәтханәсен дә, феодаль замокны да хәтерләтә. Эстон архитекторлары әнә шулай милли традиция, стильне саклауга һәм дәвам итүгә ирешкәннәр. Театрның эче бик уңайлы, сәхнәсе тамаша залының теләсә кайсы почмагыннан яхшы күренә. Монда утырганда үзеңнең сәнгать сараенда икәнлегеңне бик яхшы тоясың.

Спектакль программасында цифрлар гына аңлаешлы булганга, күршемдә утырган кыздан андагы язуларны төшендереп бирүен үтендем. Ул тәрбияле, әмма шактый салкын төстә:

— Миин ниимесчә якии фиинчә генә сөйли аалам,— диде.

Казан татары икәнлегемне әйтеп, игътибар казанырга исәп иткән идем, файдасы булмады, колак радиоалгычын киеп, уңга-сулга борыл-

мыйча гына ике сәгать буе инсафлы гына спектакль карарга туры килде. Сәхнәдә Метерлинк әсәре уйнала иде. Психологик драма югары осталык белән куелган. Монда арзан алкышларга исәпләнгән тарту-сузу, шамакайлану юк.

Эстон театры турында сөйләгәндә яңадан «Ванемуйне»га һәм Тарту шәһәренә кагылмый узып булмый.

Тарту — зурлыгы ягыннан безнең Әлмәттән калыша торган шәһәр. Республикабызның нефть башкаласы ак ташпулатлары, төзек яшел урамнары, театры, Мәскәү нефть институтының филиалы белән күпләргә мәгълүм. Әмма Әлмәт нигездә эшче шәһәр, культура һәм фән үзәге сыйфатында Тартудан күпкә калыша әле. Тарту бакчалары буйлап узганда Барклай де Толльнең кырыс һәйкәлен тамаша кылырга мөмкин. Кызык бу тарих һәм язмыш дигәнең. Шотланд халкының улы Русиягә килеп фельдмаршал була, французларга каршы сугышларда урыс халкы өчен кан коя, ә һәйкәле эстон җирендә. Авыл хуҗалыгы академиясенең Лондон үзәгендәге йортларны хәтерләткән мәһабәт бинасына, эстон укымышлыларының мәккәсе булган Тарту университетына, киштәләрендә беренче эстон китаплары һәм Гете, Моцарт кульъязмалары, тагын бик күп гаҗәеп документлар сакланган гаять бай фәнни китапханәгә, дистәләгән музейларга һәм тау башында утырган «Ванемуйне»ның тантаналы сараена күз салганда ирексездән дулкынлану кичерәсең — монда тарих, мәңгелек символы сәнгать сулышы һәр тарафтан бәреләә кебек.

1870 елда барлыкка килгән «Ванемуйне». Аның яңа бинасында өч зал бар: төп залы — җиде йөз, кечесе өч йөз урынлы. Өченчесе — сигез йөз урынлы концерт залы. Бу залларда кайсы көннәрдә дүрт меңләп тамашачы сәнгать осталары белән очраша. Театр ел саен унбиш премьера әзерли — биш йөз илле спектакль куя. «Ванемуйне» һәр сезонда тугыз-ун драма, алты-җиде опера һәм балет сәхнәләштерә. Театр составындагы «Фике» җыр-инструменталь ансамбле концертлар бирә. Миллионнан артык кеше яшәгән Казанда опера спектакльләрен яртылаш буш залга уйнауны күргәләгәнгә, әле кайчан гына халкы илле-алтмыш меңнән артмаган Тартуның бу театрны стационарда эшләтә, яшәтә алуына чын-чыннан аптырыйсың. Аңа бит читтән бернинди акча ярдәме күрсәтелмәгән!

Музыкаль театр режиссерларының СССР күләмендәге семинарлары базасы итеп әледән-әле Тартуны сайлап алу, байтак чит ил сәнгать эшлеклеләренең шушы коллектив белән танышырга омтылуы да юкка гына булмаган, күрәсең.

Театр үсештә. Ул, үзенең киләчәген кайгыртып, иҗади студияләр ачкан. Аларга йөрүче укучылар, студентлар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр атнаның дүрт көнендә дүртәр сәгать сәнгать серләрен өйрәнә, остазларына алмашка килергә әзерләнә.

Иҗатына үткен форма, сәхнә шартлылыгы, ачык публицистика, замана рухы хас «Ванемуйне» театры белән безнең кайбер артист һәм режиссерларыбыз да таныш. Сәнгатьтәге хезмәттәшлегебез 1967 елда Казанга «Ванемуйне»ның сәнгатьчә җитәкчесе Каарел Ирд килгәч, тагын да ныгыды. Традицияләр һәм стиль, таләпләр һәм мөмкинлек — бу өлкәдә уртак фикергә дә киләсең, бәхәскә дә керәсең. «Зәңгәр шәл» спектакле хакында ул соңыннан болай дип язып чыкты:

«Былтыр Казанга баргач, татар театрында бер спектакль карадым. Бездә ул, мөгаен, уңыш казана алмас иде. Пьесаның һәм спектакльнең нигезенә милли дастан рухы салынган. Тамашачылар сәхнәдәге вакыйгаларны үтә якын кабул итте: гөрләтеп кул чаптылар, каһарманны алдап тозакка кертә башлагач, «Анда барма!» — дип ду килделәр. Зал тулы өлкәннәр үз хисен бик җанлы һәм эчкерсез белдерде. Мин моның белән һич тә уйлап эш итүче, салкын канлы эстон тамашачысы, театр сөюче буларак, татар тамашачысыннан әйбәтрәк, диярга җыенмыйм. Эш шунда ки, бу халыкларның рухи халәтләре төрле, тарихи тәҗрибәсе төрле»...

Әйе, тарихи шартлар халыкның рухи халәтен дә төрлечә формалаштыра. Шуңа күрә ике халыкта ике төрле зәвекъ булу да гаҗәп түгел. Әмма эстон һәм татар тамашачысын берләштерә торган яклар да бик күп икән. Мисалга, «Ванемуйне» йөз еллык юбилеен беренче эстон пьесаларыннан исәпләнгән Л. Койдуланың «Шундый Мүлек яисә йөз бизмән тоз»ын сәхнәләштереп бәйрәм итә. Тартуның интеллектуаль тамашачысы беркатлы каһарманнарның гади көнкүреш мажараларын Г. Камал театрындагы апайлар һәм агайлар төсле үк гөр килеп кабул итә, көлә һәм кул чаба. Сәнгатьнең тылсым көче кемнең генә йөрәген эретми!

Эстониядән кайткач, миңа К. Ирднең театр дөньясына багышланган китабы белән танышырга туры килде. Чит ил һәм совет сәхнә сәнгатенә, әдәбиятка һәм актерлык осталыгына, аерым әсәргә һәм теоретик мәсьәләләргә кагылган мәкалә һәм очерклар авторның гаҗәеп киң мәгълүматка, эзләнүчән характерга ия икәнлеген ачык күрсәтә иде. Актер, режиссер, театр тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе — мондый вазифаларны берьюлы башкарган кешеләрне үз сәнгатебез тарихы да белә. Милли театрыбызга нигез салучы Г. Камал яисә аның эшен дәвам иттерүче К. Тинчурин исемнәре нәкъ менә шул хакта сөйли. Ләкин, кызганыч ки, алар эшчәнлеге башлыча татар дөньясында гына танылды һәм бәяләнде. Каарел Ирд исә Эстония Югары Советы президиумы әгъзасы, СССР халык артисты, СССР дәүләт премиясе лауреаты дәрәҗәләрен казанып, күп кенә алдынгы чит ил театрлары спектакльләрен асыл сәхнәләрендә карап, алар тәҗрибәсе белән «Ванемуйне»ны сугарып, эстон сәхнә сәнгатен үстерүгә күренекле өлеш кертә, аның уңышларын киңрәк даирәгә таныту, шулай аның абруен күтәрүгә ирешә. Әлбәттә, бу хәл шулай ук ике халык сәнгатенең төрле тарихи үсеш шартларына бәйле.

Ванемуйне — җыр алласының исеме.


Кечкенә халыкның зур, илаһи сәнгате. Аның сәхнәсендә Эгон Раннет белән Бертольт Брехт, Максим Горький белән Һенрик Ибсен һәм дистәләрчә бүтән атаклы драматурглар, композиторлар очраша. Аның артистлары һәм режиссерлары, дирижерлары һәм балетмейстерлары дөнья театрлары буйлап сәяхәткә китәчәк эстон пьесаларына беренче сәхнә тормышы бүләк итә. Моны алкышламый мөмкин түгел.

Эстония дип авыз ачасың икән, аның үз традицияләре барлыкка килгән кино сәнгате хакында да сөйләргә кирәк. Дөнья чемпионы көрәшче И. Коткас, гроссмейстер П. Керес, олимпия чемпионы тимераякчы А. Антсон, теннисче Т. Лейус, җиңел атлет Р. Тэлп, баскетболчы В. Люютсепп исемнәрен дә телгә алмый ярамый. Әмма тырыш, сәләтле эстон халкы турында бу хәбәрләр барыбер диңгездән бер тамчы кебек кенә булачак.

## Татарга охшаган эстон

Телефоннан сөйләшкәндә татарча исәнләшкән Айн Каалепны күрер өчен мин Элва шәһәренә иртәнге унберләрдә килеп җиттем. Тартудан утыз чакрым чамасы көньяк-көнчыгышта урнашкан Элва шәһәрдән бигрәк авылны хәтерләтә иде. Нарат урманы эчендә утырганга, һавасы саф. Комлы үрләре арасында берничә күл ялтырап ята. Тарту халкы Элвага килеп, яшеллек кочагында ял итәргә, су буйларында кызынырга, кышын тау шуарга ярата икән.

Мин шәһәрчекнең көнчыгыш кырыендагы чыршы, наратлар арасында «яшеренгән» коттеджне эзләп тапканчы сәгать уникенче китте. Әмма Каалепларда әле иртә иде — мин аларга хуҗаны йокыдан уятып килеп кердем.



*Айн Каалеп*

Айн ага татарга охшаган кара чәчле, якты маңгайлы ябык бер ир-ат икән. Эш бүлмәсенә тәмәке исе сеңгән, кая карама — китап,кәгазь тузгып ята. Китаплары, нигездә, латин хәрефләрендә, кара-каршы ике стена буендагы киштәләргә шыплап тутырылган. Эстончадан тыш алман, инглиз, испан, фин, француз һәм бүтән телләрдә тупланган төрле-төрле зурлыктагы һәм калынлыктагы томнар. А. Каалеп теге яки бу дәрәҗәдә аңлап, кырыклап телдә укый икән. Латинча, грекчаны да өйрәнгән, төркиләр белән дә кызыксынып тора икән.

— Төнлә озык утырылды,— диде ул күз алдымда урын-җирен җыеп.— Рәхим итегез, утырыгыз, хәзер каһвә эчәрбез. Игътибар иттегезме кара кашлы, кара чәчле Айн абыегызга? Сары эстоннарга аз охшаганмын, әйеме? Безнең Вильянди ягында минем шикелләләр шактый. Уйлавымча, татар каны катнашкандыр безгә. Борын заманда ике арада элемтәләр ныграк булган, эстоннар культура ягыннан да Шәрекъ белән Гареп синтезы. Моны телебез дә куәтләп тора. Сез «мин, син» дисәгез, без «минә, синә» дибез. «Үлмәк» сүзебез төрки «улмак», ягъни булмактан киләдер әле. Тарту шәһәре исеме дә «тартар», ягъни «татар»дан алыну ихтимал!

Хуҗа тиз генә юына, табын әзерли: колбасалы бутерброд белән каһвә тәкъдим итә. Шул арада бик рәхәтләнеп минем барлык сорауларыма да иркенләп җавап бирә. Университет укытучысы булуы да сизелә, тиздән ул папиросын пыскыта-пыскыта ишекле-түрле йөреп, әңгәмәнең җебен әз генә дә югалтмастан, тарихи һәм бүгенге вакыйгаларга, эстон мәдәнияте үсешенең төрле мәсьәләләренә, әдәби тәрҗемәләргә, төрле әдәбиятларның даһи каһарманнарына кагылган мәгълүмат ташкынын ерып җибәрде. Аның белән әнә шулай әңгәмә корганда мин берничә сәгать эчендә Эстониягә ничә килеп тә белә алмаган ачышлар ясадым үзем өчен!

Эстоннар Балтыйк буенда яшәүче иң борынгы халыкларның берсе исәпләнә. Алар безнең эра башында ук иген игә, бишенче-алтынчы гасырларда монда һөнәрчелек үсә башлый. Балыкчылык, сәүдәгәрлек тә борынгыдан килә.

Эстон халкы гасырлар буе төрле илбасарлар белән көрәшергә, үзе теләгәнчә яшәр өчен, бик күп кыенлыклар күрергә мәҗбүр була. Датчаннар, шведлар, алманнар 1721 елга кадәр хакимлек итә, әле бүген дә сакланып килгән күпсанлы ныгытма-замоклар әнә шул тарихи бәрелешләр хакында сөйли.

Русия кулына эләгү, империянең яңа башкаласына якын булу Эстониядә XIX йөз ахырында ук төрле фабрикалар корылуга китерә. Кренгольм мануфактурасы заманында Аурупаның иң эре туку фабрикасы төсендә таныла. Тора-бара монда вагон төзү, кораб кору, фанера, целлюлоза, цемент һәм башка әйберләр җитештерү учаклары төзелә.

Гражданнар сугышы барышында, 1919 елда, Эстония, ниһаять, янә бәйсезлеген кайтарып ала — буржуаз республикасын нигезли. Бу сәяси үзгәреш аның икътисадына да тәэсир итми калмый. Совет чыганакларына күз салсаң, Эстониянең бәйсезлеге эстон халкына бәла генә

китерә, «сәнәгатендә кризис башлана, фабрика-верфьләре ябыла, эшсезлек, хәерчелек ябырылып килә». Әмма мин бүген үз республикасы тарихын, анда булып узган хәлләрне бик яхшы белгән галимнең өендә утырам, ул инде нәрсәнең ялган, нәрсәнең чын язылуын бик ансат төртеп күрсәтә һәм аңлатып бирә ала.

— Әйе, Беренче Дөнья сугышы алдыннан комсыз империянең илбасарлык омтылышларын көчәйтү өчен корылган куәтле линкорлар верфен, бәйсезлеккә ирешкәч, без сүтеп ташладык. Тыныч яшәргә теләгән кечкенә дәүләткә нәрсәгә кирәк ул? Рәсәй чимал чыганакларыннан мәхрүм калган тагын кайбер фабрикаларны эшеннән туктатырга туры килде, аларның иске җиһазлары белән Аурупада көндәшлек тотарлык товарлар җитештереп булмый иде, эчке базар исә тарайды. Петербург ихтыяҗларын канәгатьләндерүне күздә тотып үстерелгән авыл хуҗалыгы да куллану базарыннан аерылды. Чыннан да, шундый үзгәртеп кору барышында байтак кеше эшсез калды. Әмма хуҗалыкны яңа шартларга җайлаштырып кору, сәүдә бәйләнешләрен бүтән илләр белән бәйләү, илгә кирәкле яңа фабрикалар кору Эстония икътисадын бик тиз савыктырды, эшсезлек тә бик тиз юкка чыкты, без хәтта Польшадан эшчеләр китереп ялларга мәҗбүр булдык. Игенчелек, терлекчелек аякка басты — без инде утызынчы еллар азагында ук һәр савым сыерыннан өчәр мең литр сөт савып ала башладык. СССР мондый уңышка тагын илле ел узгач та ирешә алмады...

Бәйсез яшәү дәверендә барлык уку йортлары ана телендә белем бирә башлый, патша Русиясе вакытында даими эзәрлекләнгән эстон милли культурасы хөррият шартларында чын-чыннан яңарыш кичерә...

Эстон реалистик әдәбиятына нигез салучы Эдвард Вилде «Кырыс як», «Мяэкола сөтчесе» романнарында егерменче йөз башы эстон авылларындагы фәкыйрьлек, ачлыкны сурәтли. Ирексездән Мәҗит Гафури, Шәриф Камал әсәрләрендә гәүдәләндерелгән ярлылар тормышы искә төшә. Э. Вилденең «Мяэкола сөтчесе» баш каһарманы Тыну Прилуп, тормышын җиңеләйтү, берәр льгота алу хакына, хатынын карт морзаның сөяркәсе итүгә риза була. Ул чакта эстоннар нигездә авылда яши, күпләр гаиләсен туйдыра алмый интегә. Менә шуны истә тотканда, бәйсез Эстония, чыннан да, байтак алга китә — уңдырышлы катлавы бик юка, ташлы басулардан үз ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек уңыш алу дәрәҗәсенә җитә.

Әмма бу тыныч үсеш куәтле күршенең күзенә арпа булып утыра. Патша Русиясенең илбасарлык сәясәтен мираска алган СССР җитәкчеләре югалган биләмәләрне кире кайтару хыялы белән яна башлый — аларга да диңгезләргә ачылган «форточка» һаман кечкенә булып тоела.

Мин Айн Каалеп өенә 1978 елның ноябрендә килеп кердем. Бу вакытта әле, дөрес булса да, кайбер нәрсәләрне сөйләргә, бигрәк тә язарга ярамый иде. Каалеп — эчкерсез зат. Урта Азиягә барып, үзбәк каләмдәшләрендә кунак булган, үзбәк шагыйрьләрен эстончага тәрҗемә иткән. Әнә шулай дуслаштым дип уйлап, андагы бер танышына язган хатында ул Н. Хрущевны Һеббельс белән тиңләгән. Озакламый Эстония КГБсы «профилактика» эшен башлап җибәргән. Язучылар берлегенең ул чактагы идарәсе рәисе Юхан Смуулга бу эшне «йому», Каалепны бәладән коткарып калу өчен байтак көч куярга туры килгән. Теләсә кемгә ышанырга ярамаганын да белә А. Каалеп, әмма шундый нәрсәләрне сөйли миңа — исем китеп тыңлыйм. Бәлки ул мине тәкъдим итеп җибәргән кешеләргә ышанадыр? Әллә соң татарда илбасарларга каршы нәфрәтнең куәте булуына исәп итәме? Әллә үз йөрәгендәге нәфрәт шулай түгеләме? Сөйли...

Тышта ябалак-ябалак кар ява, нәни форточкадан бүлмәгә саф һава керә. Кулларын артка куйган Айн Каалеп, ишекле-түрле йөри-йөри туган халкы башыннан кичкән михнәтләрне, ул ирешкән казанышларны аңлата. Аннары ул кабаттан сүзне безгә якын булган тел-әдәбиятка күчерә.

— Эстониядә унтугызынчы гасырда алман, аннары урыс теле йогынтысы көчле иде,— ди.— Соңрак бер төркем укымышлылар француз культурасы казанышларын алга сөрә башлады. Бу әүвәлге ике агым тәэсиреннән арыну, мөстәкыйль нигезгә басуда әһәмиятле роль уйнады. Сүз байлыгыбыз милли җирлектә үсте, әмма кирәкне читтән дә алабыз. Мәсәлән, «үз-үзеңә хезмәт күрсәтү» дигән төшенчә эстонча берничә сүз белән аңлатыла иде. Озын, җайсыз. Берәү инглиз телендәге «селмо» сүзен тәкъдим итте. Үзе кыска, үзе телебезгә ятышлы. Шул кереп китте хәзер кулланышка!

Әдәби телне баету, атамалар сайлап алу буенча Эстониядә конкурслар игълан ителә икән. Эстон теле җәмгыяте дә милли мәдәниятне үстерүгә күркәм өлеш кертә. Күптән түгел бу җәмгыять Элва урта мәктәбендә тел традицияләрен ныгытуга багышлап махсус җыйналыш уздырган. Анда катнашучылар этимология, тарих, әдәбият, сәнгать үсеше мәсьәләләрен күтәргән, анда эстон телен өйрәнүче ике грузин кызы — Тарту университеты студентлары да катнашкан. Җәмгыятьнең Тарту бүлегендә галимнәр, журналистлар, укытучылар — барысы дүрт йөз кеше әгъза булып тора икән. Алар эстон халык авыз иҗатын җыюга саллы өлеш керткәннәр.

Каалеп күп телләрдән шигъри әсәрләр тәрҗемә итә. Барысын да асыл нөсхәдән. Софокл, Еврипид, Овидий, Шиллер, Һейне, Хикмәт, Лорка — дистәләгән шагыйрьләр, әдипләр нәкъ менә аның тырышлыгы белән эстонча сөйләшә башлый. Әйе, ул юкка гына Тарту университетының әдәби тәрҗемә кабинеты мөдире булып эшләми, юкка гына әдәби премияләр казанмый. А. Каалеп алман, инглиз, испан, француз телләрендәге әдәбиятны күзәтеп бара, төрки телләр белән дә иҗади кызыксына, танышыр өчен махсус Урта Азиягә дә сәяхәт иткән. Китапханәсендә казакъча, татарча китаплар да бар. Аурупа телләрендәге калын-калын томнар арасыннан килеп чыккан ул җыентыклар миңа Татарстанымны искә төшерде. Каалеп аларның берсен актаргалап:

— Миңа татарча иркен аңлар өчен басылып бер атна утыру да җитә,— диде.— Күп телләрне үзләштергәндә төрле системалар белән танышасың, яңаларын төшенү дә җиңеләя.

Айн Каалеп чын мәгънәсендә юмарт җанлы, гади һәм эчкерсез кеше. Эстоннарга шактый ук хас салкынлык, тәкәллефлелек, һавалылыктан азат булуы белән ул күпләрдән аерылып тора. Бу аның сөйләшүендә дә, башка мөгамәләсендә дә ачык сизелә. Ул, мәсәлән, миңа Тарту белән танышуны кайдан, ничек башларга кирәклеген дә аңлатты, берничә кешенең адресын да язып бирде. Язучылар берлегенең Тарту бүлегенә шалтыратып, кунакханәне дә кайгыртты һәм хәтта станциягә кадәр озатып та куйды. Игътибарның соңгы төренә мин Эстониядә бары Элвада гына тап булдым! Бу инде Айн Каалеп турында шулай ук нидер сөйлидер.

Казанга кайтып, «Социалистик Татарстан» газетенең 1957 елгы текмәсен актарганда, мин очраклы рәвештә яңа танышым исеменә юлыктым. Бер нәни мәкаләдә эстон матбугатының Һади Такташ, Мәҗит Гафури әсәрләренә урын бирүе хәбәр ителгән иде. «Эдази» газете укучыларын татар шагыйрьләре белән таныштыручы, әсәрләрен турыдан-туры татарчадан әйләндерүче хәерхаһ зат Айн Каалеп булган икән.

А. Каалеп белән хатлар алышу Эстониядә каләмдәшләребезнең тәрҗемәгә ни кадәр җаваплы карауларын ачык чагылдыра. Сүз аның бер шигырен Зәки Нури тәрҗемә итеп «Социалистик Татарстан»да бастырганнан соң башланып китте. «Мин верлибр алымы белән язган идем, тәрҗемәм рифмалы икән. Сез Назыйм Хикмәтне дә рифмалап татарчалаштырасызмы?» — дип сораган иде ул. Бездә рифмасызны рифмалыга әйләндерү яки киресенчә итү гадәти эш. Кызганыч ки, күпләрне бу бөтенләй борчымый, чөнки тәрҗемәче үзе дә күпчелек очракта сайлаган әсәренең асыл нөсхәсен тотып та карамаган була, куян шулпасының

шулпасы белән эш итә ул. А. Каалеп исә, мин атаклы Ф. Тугласны татар укучысына тәкъдим итәргә җыенгач, асыл нөсхәнең моңын тояр өчен, әсәрнең сүзгә-сүз урысчага «аудармасын» гына түгел, эстончасын да җибәрде! Проза өчен шулкадәр әһәмиятлемени инде ул?! Үзе Габдулла Тукайны эстон укучыларына танытырга алынгач, беренче нәүбәттә әсәрләрнең татарчасын юнәтте. Шунлыктан, Тукайның «Шагыйрь»е эстонча нәкъ асыл нөсхәдәгечә ритм, рифма, шундый ук музыкаль яңгырашта дөнья күрде.

Г. Тукай әсәрләрен эстончага күренекле шагыйрь, тәрҗемә эшенең танылган теоретигы һәм практигы Айн Каалеп әйләндерсә, сөекле шагыйребез турында эстонча беренче мәкаләне шундый ук абруйлы әдәбиятчы Оскар Кунингас бастырды.

Айн Каалеп сөйләгән тарихи серләрне, бик теләсәм дә, мин тиз генә кәгазьгә төшерә алмадым. Сәбәбе аңлашыладыр. Хәзер исә Молотов-Риббентроп килешүенең яшерен матдәләре тулысынча җәмәгатьчелеккә җиткерелде, Эстония үз бәйсезлеге белән янадан кавышты. Бу хакта минем язуымның үткенлеге дә югалды. Әмма язмыйча да ярамый: гаделсезлек белән көрәш дәртен иң авыр елларда нәкъ менә шушы Айн Каалеп кебек кешеләр саклап килде һәм яшьрәк буынга хакыйкатьне сеңдереп калдырырга тырышты.

## Балтыйк энҗесе

Латвияне Балтыйк диңгезенең гәрәбәле яры дип атыйлар. Гәрәбәсе булгач, аның энҗесе дә булырга тиештер инде? Халкының аз санлы, иленең кечкенәлегенә буенча Эстонияне һәм эстоннарны бәлки шулай атау урынлыдыр да? Шулар өчен генәме икән?

Мин бу хакта Таллинның Кадриорг паркында һәм Пирита пляжендә дә уйлап йөрдем. Моннан сиксән чакрымда, Фин култыгының аргы ягында, Суоми башлана иде. Балтыйк диңгезе Эстонияне тагын биш ил белән тоташтыра. Диңгез буенда урнашу аркасында республиканың климаты Татарстанныкыннан шактый җылырак — гыйнварның уртача температурасы бездәге ундүрт урынына биш градус кына салкын. Беренче мәртәбә монда килгәндә мин моны белми харап булдым: егермесе көнне яңгыр сибәли башлады, киез итегем чыпырдый башлагач, Таллиннда ботинкалар сатып алырга туры килде. Эстония башкаласының еллык уртача температурасы биш градус җылы икән. Явым-төшем Татарстандагыдан чагыштыргысыз дәрәҗәдә мулрак булганлыктан, эстон дуслар кышын да плащ киеп һәм зонтик тотып йөрергә мәҗбүр икән.

Бәйсезлек чорында Эстония табигый байлыкларын уйлап һәм сак үзләштерсә, икътисадын гармоник үстерүгә тырышса, совет дәверендә ул СССРның бер өлеше итеп карала һәм империя мәнфәгатьләреннән чыгып алга җибәрелә: цемент җитештерү һәм балык тоту бик тиз арада унбиш мәртәбә арттырыла, сланец казып чыгару елына утыз миллион тоннадан ашырыла, Эстонияне «интернациональләштерергә», халыклар дуслыгы республикасына әйләндерергә тиешле мигрантлар өчен зур-зур фабрикалар корыла һәм аларда эш кәгазьләрен йөртү урысчага — «милләтара аралашу теленә» күчерелә. Трансформатор, җылыту казаннары, бәрәңге алу комбайннары, сланец чыгару механизмнары, электр һәм радио аппаратлары гына түгел, хәтта нефть чыгару җиһазларын ясау да Эстониягә йөкләнә. Империя һәммәсен алдан чамалап планлаштыра: аерымланырга омтылсалар, нефть чыгару җиһазларына мохтаҗ Татарстан Эстониягә бәйле булсын, Эстония исә ул товарын сатар өчен Татарстанга, Әзербайҗанга яки Себергә ихтыяҗ күрсен. Эстониядә металл юк, нефть җиһазларын ясар өчен металл күп кирәк дисеңме? Бушка хафаланасыз, тегесен монда, монысын тегендә ташыганда, тимер юл транспортында эшсезлек булмаячак, шуның өстәвенә, ул Әзербайҗанны,

Татарстанны Эстония белән нык бәйләп торачак, моның файдасын инде империя юлбашчылары бик тә яхшы белә!

Бүре законнары гамәлдә чакта кечкенә ил дә, халык та тыныч һәм имин, үзе житештергән малга, табигый байлыкларына үзе хужа булып, бигрәк тә рухи хөрриятта, иректә яши алмый. Икенче Дөнья сугышы вакытында Эстонияне фашистлар басып ала, монда алар егерме концлагерь кора, гади халыктан алтмыш бер мең кешене, алтмыш дүрт мең хәрби әсирне юк итә. Лилли Промет әйтмешли, «Советлар килә...» Эстонияне фашистлардан азат итүдә милләттәшебез, Советлар Союзы Герое тупчы Габдулла Гарифуллин һәм башка татар сугышчылары да катнаша. Мин башта моңа хәйран горурланып йөргән идем, хәзер инде, күп кенә эстон укымышлыларының «азат итү» турысындагы фикерләре белән танышкач, бу хакта искә төшерергә икеләнәм!

Соңгы вакытта Татарстанның нефть хәзинәләре саекты, кайчандыр елына 104 миллион тонна жир мае биргән республикабыз хәзер 25 миллион дәрәжәсенә төште. «Илдәге өч моторның берсен татар нефте эшләтә!» дип горурланырга яраткан житәкчеләребез хәзер инде Татарстанның битум нефтен чыгару хакында проектлар төзеп мәйханә килә. Нишли болар, дип ачынам мин, киләсе буыннарга берни калдырмаска жыеналар лабаса. Нефть кыяр түгел, өч ай саен үсеп житешми, аны стратегик милли байлык санап, бәрәкәтле файдаланырга, халкыңның киләчәктә дә яшисе барын онытмаска кирәк. Бар чагында — бүре, юк чагында — шүре сәясәте ярамый, бер көнлек мәнфәгатьне куып яшәү — акылсызлык.

Эстониянең сланец байлыкларын елдан-ел арттырып казып чыгара барганда, андагы акыл ияләренең империя комсыз нәфесенә борчылуларын һәм нәфрәтләнүләрен мин хәзер тирәннән аңлап кабул итәм. Алар дөмбер якынлашканда ук хәвефне тоемлый, без давылдан соң гына уянабыз.

Эстониядә туып-үскән, гомер кичергән милләттәшебез Хәйдәр Мифтахетдинов:

— Без бик мәдәни халык арасында яшәвебез белән бәхетле,— дигән иде миңа.— Күршеләребез белән бер гаилә кебек торабыз, йортны да алар белән дүрт хужа баш кушып салдык.

Мифтахетдиновларны, төгәлрәге, Тарту университетының эстон телеәдәбияты бүлеген тәмамлаган Рәмияне татар-эстон мәдәни бәйләнешларын жанландыру эшенә тарту иде теләгем.

Рәмиянең бабалары Эстониягә Түбән Новгород өлкәсеннән 1850 елларда килеп урнашкан. Икенче буын инде эстон мәктәбендә белем алган — Хәйдәр абый механик, Рәбига ханым бухгалтер һөнәрен үзләштергәннәр.

— Без элек Нарва ягында яшәдек,— диде Хәйдәр абый.— Татарлар аерым мәхәлләгә тупланган, мәчетебез дә бар иде. Эстон мәктәбендә уку туктагач, жәен ана теле-әдәбиятын өйрәнә идек. Буржуаз Эстония заманында татар мөгаллимнәре Суомидан, Алмания белән Төркиядән киләләр иде.

Сугыштан соң Нарва, Раквере татарларының күбесе Таллинга күчеп килә. Әмма Хәйдәр абыйның ике сеңлесе кияүгә чыгып, Швециядә төпләнә. Абый кеше аларның хәлен белер өчен Стокһолымга да барып кайта.

Мифтахетдиновлар гаиләсе эстоннарга тәмам үзләшеп беткән. Жирле халыкның әдәбият-сәнгатен дә яхшы беләләр һәм яраталар. Әмма алар туган телне, туган жырны да онытмаганнар. Рәмия Казаннан сүзлекләр, бүтән китапларны да алдырган, татар әкиятләрен эстончага тәржемә итә башлаган.

— Кызымның Казанга барасы килә,— диде Хәйдәр абый.— Яхшы тәржемәче булыр өчен ана телен тагын да тирәнрәк белү кирәк. Татарстанда туган әдәбиятыбызны да кирәгенчә үзләштерер иде.

— Мине бу эшкә университетта Айн Каалеп этәрде,— диде Рәмия.— Искиткеч әйбәт кеше. Тартуга барсагыз, эзләп тапмый калмагыз. Ул мине Казанга Язучылар берлеге стипендиаты итеп бер-ике елга җибәрергә кызыга.

Мифтахетдиновлар гаиләсендә татар рухын саклауда Хәйдәр абый аеруча тырышлык күрсәтә, кебек тоелды миңа. Хәзерге гаиләләрдә ана кеше зуррак урын тота башлады. Чөнки бөтен өй эшләрен алар башкара, балалар тәрбияләү дә алар өстендә. Татар иренең патриархаль традициясен бу хәл бик нык какшата, аның психикасы моны авыр кичерә, типке (реакция) рәвешендә ул кәҗәләнә, урынсыз гаугалар чыгара яки күп нәрсәгә битарафлык күрсәтә, икенче роль уйнау белән килешә башлый. Бу инде милли гореф-гадәтләрнең дә йомшавына, ата-баба әхлагының зәгыйфьләнүенә һәм, хәтта, таркалуына да китергәли. Бу тискәре күренешләрдә марксизм идеологиясе һәм социализм системасы гаилә нигезенә салган «тигезлек» дигән бомба төп җимергеч көч булды, минемчә. Тигезлек дигән булып, без һәр җирдә, һәрвакыт хатын-кыз мәнфәгатьләрен генә яклый башладык. «Тигезлек» аның үзенә дә авыр йөк булып төште — аңа ике камыт кидерелде, өй эшеннән тыш ул иҗтимагый хезмәткә дә җәлеп ителде. Иренә матди бәйлелектән котылу, хәтта, тормыш алып баруда аңардан күбрәк көч түгә башлау хатын-кызга гаиләдә баш ролен дәгъваларга киң мөмкинлекләр ачты. Әмма ирләрнең зирәкләре һәм аңлылары бу иҗтимагый афәттән дә исән-имин котыла алды — алар гаиләнең матди ихтыяҗын тәэмин итүдә дә, балаларны тәрбияләүдә дә мичәүдәге ат дәрәҗәсенә төшмәде — авырлыкны төпкә җигелеп тартты.

Хәйдәр абый да әнә шундый нык буынлы, эшлекле кеше иде. Казаннан килүчеләр белән сирәк очрашканлыктан, ул сүзне әллә кайларга борып, вакытын җилгә очырырга теләмәде, үзе аеруча кирәкле санаган якны — милли татар гаиләләрен коруны кузгатты... Кайда яшәсәк тә, татарны сакларга кирәк, диаспорада бу эш аеруча кыен, алар Таллинннда Эстониягә гасыр башында яки аннан да элегрәк килгән иллелап гаиләне беләләр, ләкин совет дәверендә милли җәмгыять таркалган, үзара сирәк очрашалар. Ике кызың буйга җиткәндә, аларны парлы итү дә ата-ана өстендә булырга тиеш бурыч лабаса...

Рәмия финчә төшенә, инглизчә иркен укый, алманча да аралаша алырлык дәрәҗәдә иде. Тарту университеты һәм эстон мәктәбе әнә шундый әзерлек тә бирә икән. Аның да чит телләрдәге китаплары, төрле альбомнары һәм энциклопедияләре бар. Мондый милләттәшләребезне татар мәдәниятенә хезмәт иттерү уе мине, әлбәттә, күптән кызыктыра иде. Бергәләп планнар кордык һәм Рәмия бераздан Татарстан язучыларының нәүбәттәге съездына кунак булып килде, милли башкаласы, андагы күренекле шагыйрьләр, әдипләр, галимнәр белән танышты, туган телен, әдәбиятын махсус өйрәнер өчен бераздан Казан университетына Эстония Язучылар берлеге стипендиаты буларак килергә җыенды. Әмма... адәм баласы ниятли, ниндидер башка көчләр язмышны хәл итә! Казанга дип юлга чыккан Рәмияне Мәскәүдә талыйлар — бөтен багажын, андагы кием-салымнарын һәм хәтта акчасын да вокзалның саклау камерасыннан «шуыталар». Кызыкай кире өенә борылып кайтырга мәҗбүр була. Ул арада Хәйдәр абый вакытсыз дөнья куя. Планнары бер-бер артлы җимерелүен күргән Рәмия шуннан соң эстон егетенә кияүгә чыга...

Сиксәненче елларда Эстония татарлары таркау хәлдә тормыш итеп ята иде. Аларның милли рухын алтмыш дүрт гаиләнең «Сөембикә» журналына язылуыннан гына бераз чамалап була иде.

1989 елгы җан исәбе алу мәгълүматларына караганда, монда дүрт меңләп милләттәшебез яши, аларның яртысы Таллинн шәһәренә тупланган иде. Азчылык милләтләрне йоту сәясәтен тоткан тоталитар режим какшагач кына, алар үзара якыная, милли җәмгыятьләрен барлыкка

китерә башлады. Соңгы килүемдә (1989) мин шул җәмгыятьнең актив эшлеклеләре — рәссам Тимер Сәйфуллин, укытучы Фәүзия Һадиуллина, артистлыкка укыган һәм рекламфильмдә эшләгән Гаярь Зарифлар белән таныша алдым. Алар соңрак Казанга, Татар милли корылтайларына килеп, башкалабыз белән элемтәләрен ныгытып, шактый эш башкардылар. Җөмләдән, татар балалары өчен якшәмбе мәктәбе, өлкәннәр өчен әдәбият-сәнгать кичәләре оештырып, беренче мәртәбә сабантуй да уздырдылар, Татарстаннан артистлар чакырып китереп, профессиональ сәнгать көчләребезнең концертын, спектаклен тамашага кылуга да ирештеләр. Институтның татар теле-әдәбияты бүлеген тәмамлаган Сарман кызы Фәүзия милли җирлегеннән күптән аерылган Эстония татарларына туган телне һәм җырны кайтару буенча нәтиҗәле эшләп килә. Әмма Эстониянең тулы бәйсезлеккә ирешүе Татарстан белән бәйләнешләрне шактый какшатты. Милли матбугатыбызга язылу халыкара почта хезмәте баскычына куелганлыктан, аларны алдыруга күпләрнең буе җитми башлады. Чөнки Эстония икътисадын базар тәртибенә көйләү күп катлаулылыклар китереп чыгарды, халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсе күчешнең беренче дәверендә шактый түбәнәйде. Барып-килеп йөрүләр сирәгәйде, чөнки юл бәяләре бик нык артты.

Гаярь белән Тимернең ата-бабалары инде күптән Түбән Новгород якларыннан күчеп килгән, егетләрнең икесе дә шушында туып-үсеп, эстон телендә белем-тәрбия алган, икесе дә эстон кызларына өйләнгәннәр. Сүз байлыклары зурдан түгел, әмма икесе дә татарча сөйләшергә тырышалар. Алар Таллинида татар җәмгыятенең ныклы бер оясын, базасын корыр өчен шактый эзләнделәр, ләкин икътисадый бөлгенлек канат җәйгән дәвердә моңа ирешү бик кыен иде.

— Безнең татар төшеп калмый, тырыша-тырмаша, барыбер күтәрелү юлын таба,— диде миңа Гаярь.— Менә мин дә сәнгатькә хезмәт итәргә теләгән идем, әмма хәзергә бер кооперативка эшкә керергә мәҗбүр булдым. Совет чорында татарларның бергә оешуы шикле нәрсә исәпләнә бит. Шунлыктан әле дә кайберәүләр милли җәмгыятебез барлыкка килүен белми. Сибелеп яшәгәч, бергә җыйналу да ансат түгел. Ләкин безнең тырышлыкларга эстоннар теләктәш карый. Алар безгә милли аңны, гореф-гадәт, культураны саклауда да үрнәк.

Аның сүзләрен Фәүзия Һадиуллина да куәтләде:

— Җыйналышыр өчен бер мәктәптә, бер балалар бакчасында урын бирделәр. Әлегә дәреслекләребез, сүзлекләребез җитми. Югыйсә үз җырына, теленә тартылган милләттәшләребез байтак. Эстон дусларыбыз безгә радио-телевидение тапшыруларында катнашуга да юлны ачырга әзерләр — көчебез генә җитсен...

Балачактан ук зурлап кабул итеп, инде риваять, легенда дәрәҗәсенә җиткереп, Тукай тормышын һәм иҗатын өйрәнгәнгәме, миңа ул бик еракта калган шәхес, ул яшәгән еллар да инде чал тарих булып тоела иде. Ә монда, Таллинида, 1989 елда мин Тукай яшьтәше Нурҗиһан әби Мәһдиеваны күреп гаҗәпләндем. Ул Актаныш районының Уразай авылында дөньяга килгән, 1945 елдан Эстониядә яши. Аның кызы Гатия апа:

— Хәтере әйбәт әле,— ди.— Ирем дә, улым да дөнья куйдылар. Әҗәкүлдән күчеп килгән идек, шушында төпләнеп калдык. Әни, картаеп китсә дә, миңа иптәш әле. Туган якларга сирәк кайтабыз, тамырларны әнкәй генә гел искә төшереп тора. Таллин урамында балалары белән татарча сөйләшеп йөргән Фәүзияне очраткач, бик сөендем. Хәзер инде таныш татарлар тагын да артты, шалтыратып, хәл белешәләр, күңелле булып китә. Бер Иләшкәч, монда җайга салынган тормышны ташлап кайтып китеп тә булмый шул.

Эстония башкаласындагы Татари урамы шәһәрнең нәкъ үзәгендә, бер башы белән Таллинның иң матур җире — Җиңү мәйданына килеп терәлә. Таллин кунакларының байтагы бу урам белән танышмый калмый, чөнки анда кунакханәләр идарәсе урнашкан. Бүтән урамнардан ул бер

ягы белән дә аерылмый: шундый ук текә чирәп түбәле йортлар, шундый ук тар тротуарлар. Әмма Җиңү мәйданындагы «Палас» кунакханәсендә яшәгәндә, янәшәдә генә эстонча беренче иҗеккә басым ясап әйтелә торган «Татари» урамы сузылу күңелгә гел рәхәтлек биреп торды. Эстониядә тагын бер җирдә — Нарва шәһәрендәге Иске Паймыр урамында да татарлар тупланып яшәвен хәбәр иттеләр миңа.

Эстон дөньяга йә кармак, йә ишкәк тотып килә, дигән әйтем бар икән. Ихтимал, элеккерәк заманнарда диңгез бу халыкның тормышында хәзергедән дә әһәмиятлерәк урын тоткандыр. Кешенең табигатьне үзләштерү мөмкинлекләре кайчандыр бик чикле булган — ул җирне ашлау, аны яхшырак эшкәртү, яхшырак чәчүлек куллану, эшне тиз һәм вакытында үтәү кодрәтенә тора-бара гына ия булган. Шуңа күрә дә эстон ипи телемен зур кисмәгән, ашаганда сынык калдырмаган.

Хәйдәр абый раслаганча, эстоннар — һөнәрле халык. Уйлап табуга, кул эшләрен оста башкаруга зур әһәмият бирәләр монда. Һөнәрчелек әйберләрен сатып алуга да игътибар җитәрлек. Икътисадый яктан бигрәк, әхлак ягы әһәмиятле санала.

Әдәбият — милләтнең бәгъре, шуна күрә теге яки бу халыкны яхшырак танып-белер өчен, әдәбиятларын күбрәк уку файдалы. Шул ук вакытта язучылары белән аралашу да гыйбрәтле — милләтнең холыкфигылен, җитлегү дәрәҗәсен чамалыйсың.

Вакыт кысанлыгы аркасында, мин кайбер каләмдәшләремә үз милли әдәбиятларыннан биш кенә том проза исемлеген төзеп бирүне үтенгән идем. Әмма үзбәк дускай да, әзәрбәйҗан кардәш тә исемлекне озынрак төзеделәр — аларда иң яхшы дигән әсәрләрне һич тә биш томга гына сыйдырып бетереп булмый иде! Эстон әдәбияты үрнәкләре исемлеген исә мин үзем яздым һәм аны берничә таллиннлы каләмдәшемә күрсәтеп киңәштем. Һәркайсы берничә исемне кирәкмәскә чыгарды. Шагыйрә Лий Сеппель исә, аңа күз йөгертү белән, кайбер әсәрләрне сызып атудан аеруча тәм табып:

— Сез нәрсә, боларны инде без үзебез дә укымыйбыз, әйе, әйе! — дип кычкырып җибәрде.— Эстоннар инде аларны мәктәптә өйрәнмичә кала алмый. Тик сез баш ватып интекмәгез. Менә боларын да уйларга кирәк!..

Аның тырышлыгы белән сайланма эстон прозасы исемлеге икеләтә кыскарды. Әле яхшы дип калдырганнарының да җитешсез якларын Лий әйтми түзә алмады. Казанга кайткач, мин гыйбрәт өчен исемлектән сызылган кайбер эстон повестьлары белән дә таныштым. Бездә алар да, һичшиксез, макталып телгә алыныр иде!

Муса Җәлил шигырьләрен турыдан-туры татарчадан тәрҗемә иткән Лий Сеппель белән дә мине Леннарт Мери таныштырды. Шагыйрә, Тарту университетының эстон теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, Бакыда әзәрбәйҗан телен өйрәнгән. Ул төрек, әзәрбәйҗан шигъриятен эстон укучысына җиткерү белән шөгыльләнә, оригиналь әсәрләр дә иҗат итә. Татарчадан тәрҗемәләрнең Эстониядә әллә ни артмавын Лий ханым Татарстанның үз тырышлыгы чамалы булуына бәйли.

— Әдәбиятыбыз башка телләрдә дә дөнья күрә алсын өчен, без иң яхшы әсәрләребезне аерым-аерым хикәя, шигырь җыентыклары итеп туплап, инглиз, алман, француз телләрендә сүзгә-сүз тәрҗемәләрен әзерлибез һәм аны башка халыкларның тәрҗемәчеләренә бүләк итәбез. Әдәбиятыбыз, язучыларыбыз турында язылган белешмәлекләрне, махсус монографияләрне дә әлеге телләрдә бастырып чыгарабыз. Болар барысы да ят милләт фикер ияләренә безнең белән танышу, ошаган әсәрләрне сайлап алу, аннары инде кирәкле әсәрләрнең асыл нөсхәләрен табу мөмкинлеген җиңеләйтә. Мәскәүдә күп телләрдә чыгарыла торган «Совет әдәбияты» журналының Эстониягә багышланган махсус саны дөнья күрүдә дә безнең активлык соңгы рольне уйнамагандыр. Әмма... иң мөһиме, әлбәттә, әдәбиятның сыйфат ягы инде!

Таллинида һәр килүемдә мин бер кафеда тукланырга иялэштем — монда беркайчан да диярлек чират торасы, кышын чишенәсе юк, бик тиз хезмәт күрсәтелә. Иртә ачыла, соң ябыла, ризыкның исә томалап пешерелгән әчкелтем кәбестә белән сосискасы, каһвәсе һәрвакыт булып тора. Кая барсаң да, каһвә генә, Таллинида чәй табармын димә! Бу хакта әллә инде Лилли ханыма да зарланган булганмын, бер килүемдә ул мине телефоннан өйләренә чакырып:

— Менә дигән һинд чәе белән сыйлаячакмын. Англия фирмасыныкы. Бу фирма чәй житештерү белән 250 ел шөгыльләнә инде. Менә күрерсез, ул совет фабрикалары чыгарган, чүп үләннәре кушылган «һинд» чәенә бөтенләй охшамаган, миңа аны Суомидан китереп бүләк иттеләр,— диде.

Лилли ханым татарларның чәй яратканын яхшы белә. Дөнья күргән кеше буларак, үзе дә каһвә, какаолар белән генә чикләнми, төрле үләннәр кушып пешерелгән чәйне сәламәтлеккә аеруча файдалы саный.

— Чәй сары мәтрүшкә, шалфей, акчәчәк, эт шомырты чәчәге кушып пешерелсә, тонусны, кәефне күтәрә,— ди ул.— Бу үләннәрне сөт белән кайнатып эчсәң, мигә, бөерләргә шифалы. Сез яшь шул әле, дәваланырга ихтыяжыгыз юктыр.

Инглиз чәеннән әллә нинди тәмле хуш исләр килә. Чәй эчкәндә сүз «Примавера» романы тирәсендә куерды. Бу романны Мәскәүнең рәсми даирәләре ошатмаган, аңарда «бөек өлкән кардәшкә» ихтирамсызлык, хәтта аны мыскыл итү рецидивларын тапканнар, инде типографиядә басылып беткән хәлдә, аны сатуга чыгарырга теләмәгәннәр, хәзер инде аны чит илләрдә тәржемә итеп бастыруга таяк тыгалар икән. Романны чит илләрдә исә бик яратканнар, Мәскәүнең каш җыеруыннан өркемәгән дәүләтләр инде бастырып та чыгарганнар. Әйтик, Суоми, Румыйния, Словакия. Румыйннар мажар телендә дә баскан, шул тиражның бер өлешен, алдан ук килешеп куеп, Мажарстан да сатып алган. Ә менә болгар, поляк, чехлар әле һаман нәшер итәргә рөхсәт ала алмыйлар, имеш.

— Сез анда шовинистларны тешләгән шул,— дидем мин.— Алар моңа күнекмәгән, җеннәре чыгуы аңлашыла.

— Каһарманнарымның исемнәрен алмаштыру тәкъдимнәрен дә ишеттем инде,— диде Лилли ханым әче елмаеп.— Христиан исемнәрен кайберәүләр нигә урысныкы гына итеп санайдыр. Сез романымны тулысынча аңладыгызмы икән? Анда мин дини мифләрне, аларның каһарманнарын да символик рәвештә файдаландым. Күп белемлегемне күрсәтер өчен түгел, кинаялэп фикер әйтер өчен.

— Сезнең кыенлыкларны ходай безгә бирсен иде,— дидем мин көрсенеп.— Без хәзер бөтенләй фажигале шартларда яшибез. Сиксәненче еллар Казанында соңгы татар мәктәбе жан биреп ята. Житмешенче елларда безнең бер укымышлыбыз Свердловск өлкәсенең Себер чигендәге бер татар авылына барып лекция сөйләгән. Тын да алмыйча тыңлаганнар моны. Сүзен тәмамлагач: «Сораулар бармы?» — дигән бу. Залның өне дә ишетелми икән. Соравын кабатлагач, залдан берәү кыюсыз гына: «Лекциягезне тагын бер кабатлагыз әле»,— дип үтенгән. «Сез мине аңламадыгызмыни?» — дип аптыраган лектор. «Аңладык, әмма үз колагыбызга үзебез ышанмыйбыз — татарча да лекция сөйләп була икән ләбаса. Инде егерме ел туган телебездә доклад-лекция сөйләгәнне ишеткәнебез юк иде, бик тансыкладык!» — дигән әлеге абзый.

— Хәзер шушы хәл Татарстанга да якынайды, күренекле өлкән язучыларыбыз да: «Без инде соңгы көзге яфраклар хәленә калганбыз икән, язганнарыбызны укырга укучы да бетеп килә»,— дип сукрана. Яшьләребез хәзер иҗат итәр өчен башка тел өйрәнергә мәҗбүр,— дидем мин хуҗаларга.

Лилли ханым безнең милли яшәешебез шулкадәр мөшкел хәлгә төшүен күз алдына да китермәгән икән. Минем һич тә шаярып сөйләшмәвемне төшенгәч, ул:

— Тәүфикъ, сез татарча укучы бер кеше калганчы туган телегездә язарга тиеш,— диде.— Язучы яза икән, димәк, әдәбиятыгыз яшәячәк. Әдәбият үсү милли телнең яшәвен аңлата. Теле дә, әдәбияты да яши икән, милләт тә юкка чыкмаган дигән сүз. Бәлки әле хәлләр сез аңлатканча ук өметсез дә түгелдер, бәлки тиздән уңай үзгәрешләр башланыр. Халыкара багланышларыбыз зәгыйфьләнсен, без тышкы дөньядан ераклашсын, аерылсын өчен, берничә ел элек югарыдан килгән әмер белән Тарту университетының француз теле бүлеге ябылган иде. Без шуны кире ачтырыр өчен даими чыгышлар ясап тордык, өзлексез «югарыга» мөрәҗәгатьләр яздык һәм менә максатыбызга ирештек...

Соңгы укучы юкка чыкканчы!.. Берәр юату сүзе ишетергә теләсәм дә, мин мондый ук киңәшне көтмәгән идем.

— Сездә хәлләр әйбәт әле,— дидем мин. — Урамда урысча эндәшүчегә җавап бирмичә узучылар да әз түгел. Казанда мондый мөгамаләне милләтчелеккә санныйлар, билгеле.

— Безне дә аңларга кирәк,— диде моңа каршы Лилли ханым.— Күп киләләр Эстониягә, һәммәсе урысча сорау бирә. Аларның барысына да урысча гына җавап биреп торсак, тиздән Таллиннда туган телебез яңгыравы ишетелми дә башлар. Болай да инде без хәзер башкалабызда азчылыкка калдык.

Саубуллашкан чакта Лилли ханым:

— Таллиннга яңадан юлыгыз төшкәндә берәр чит ил телен дә өйрәнеп килсәгез, әңгәмәләребез тагын да җанлырак булачак,— диде.— Без инде сезгә «эстон телен үзләштерегез» дип әйтмибез. Тик безне һаман бер телдә сөйләшү йончыта. Абайлагансыздыр, кирәкле урыс сүзләрен исемә төшергәнче миңа хәйран төртелеп торырга туры килә. Зыялыларыбызның рухи халәте исә аралашу коралын да төрлеләндерүне хуп күрә.

Укымышлылар, әлбәттә, кайда да аңлырак инде. Чын укымышлылар! Ә менә гади халык милләтара багланышларны ничек кора? Аларның фикер йөртүе ничегрәк?

Кунакханәгә кайткач, мин монда кизү торучы хезмәткәр белән сөйләшеп утырырга тырыштым. Әңгәмәбез тиз генә ялганып китмәде. Беренчедән, аңа яңадан-яңа кунакларны урнаштырып мәшәкатьләнергә туры килде. Аннары... аның монда килүчеләр белән серләшеп утырырга һич тә теләге юк иде. Татарстаннан юлга чыгуымны, эстон әдәбиятын яратып укуымны аңлатып, кызыксынуымның ихласлыгына ышандырыр өчен, яңа сатып алган «Эстонча-урысча сүзлег»емне дә алып килеп күрсәттем, нинди татар икәнлегемне әнә шулай шактый озак танытып торгач кына, ул бераз ачылып китте. Унынчы классны яңарак тәмамлаган кыз икән. Күптән түгел генә шушы эшкә урнашкан.

— Килүче кунакларның күпчелеге эстоннармы?—дидем мин.

— Кая ул! Безнекеләр, кайчан карама, эштә. Русиядән урыслар агыла. Киләләр, киләләр, үзләренең шәһәрләре юкмы икән әллә аларның?

— Ошамыйлармы әллә алар?

— Ничек ошасын инде? Теләсә кайда төкерәләр-какыралар, чүп ыргыталар, сүгенәләр—фуу! Чәчәкләребезне таптыйлар, каршыларында кызыл ут янып торуга карамастан, урам аша чыгып китәләр.

— Барысы да андый түгелдер инде?

— Эстон теле, культурасы белән берсе дә кызыксынмый. Ә малыбызны кирәксенәләр. Алар безне бөлдерер, Эстониягә зыян итәр өчен генә киләләр. Безне хөрмәт итә белми дә, белергә теләми дә алар...

Эстониягә латышлар, литваннар, финнәр һәм бүтән ил ватандашлары да килә, әмма аларны бер дә хурлап телгә алмады бу туташ. Урыс агай да: «Ят монастырьга үз уставың белән килеп кермиләр»,— ди үзе. Әмма гамәлдә еш кына моны онытып җибәрә. Шуңа күрә «Палас» кунакханәсе хезмәткәренә ул дәгъва белдерергә дә, үпкәләргә дә тиеш түгелдер. Монда кемнең кемлеген тиз чамалыйлар, үзләренә таләпчән булган шикелле, башкалардан да кешелекле, әхлаклы булуны көтәләр. Аз санлы

халык ул эстоннар, кечкенә ил ул Эстония. Әмма, ата-бабаларыбыз әйткәнчә, кечкенә, кечкенәдән йөзек кашы ясыйлар, зур белән ләгән төбен ямыйлар...

## Күңел якынлыгы

Халыклар дуслыгын үстерүдә әдәби тәрҗемәләрнең мактаулы урын тотуын беләбез. Ләкин бу өлкәдә татар-эстон хезмәттәшлеге башлангыч хәлендә генә әле. Л. Койдула, Э. Вилде, Ф. Туглас, А. Тамсааре кебек халыкара танылган күренекле язучылары булуга карамастан, бездә илленче елларга кадәр эстон матур әдәбиты гомумән тәрҗемә ителмәгән.

Татар-эстон мәдәни бәйләнышлары Эстония СССР составына кергәнче кенә юлга салына башлаган. Атаклы галимебез Мөхәммәт Идриси, мәсәлән, эстон телендә эшли торган линотип һәм язу машинкаларының клавиатурасын ясап биргән. Г. Камал исемендәге татар академия театрында Эйно Альтның «Сукыр», Әлмәт театрында Эгон Раннетның «Юлдан язган» пьесалары куелган. «Балтыйк буе хикәяләре» җыентыгында, ике басмасы чыккан «Балтыйк буе шагыйрьләре» китабында һәм вакытлы матбугатта эстон әдәбияты үрнәкләре урнаштырылган.

Эстониядә безнең сәнгатебез әүвәле Фәрит Яруллинның «Ванемуйне» театрында куелган «Шүрәле» балеты белән танытыла. Аннары бу әсәр Таллинн сәхнәсенә дә күтәрелә.

Эстон телендә безнең әдәбият Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» (1953 ел. 10000 данә), Гомәр Бәшировнең «Намус» (1953 ел. 8000 данә) романнары һәм Муса Җәлил шигъри җыентыгы «Батырлык юлы» (1969 ел. 5000 данә), Ләбибә Ихсанованың «Саралан малайлары» (1973 ел. 15000 данә) повесте төсендә укучылар кулына килеп керә. Алдарак язылганча, вакытлы матбугатта Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Һади Такташ әсәрләре дә дөнья күрә.

Татарстан Бөек Ватан сугышы вакытында эстон сәнгать эшлеклеләрен дә үзенә сыендырган. Татар дәүләт филармониясендә Прийт Пыйлдроос җитәкчелегендә хәтта махсус эстон ансамбле дә оештырылган.

Сәнгать байлыкларыбызны алмашуга да мисаллар китерергә мөмкин. Татар җыры «Сандугач»ны эстон кызлары да яратып башкара. СССР халык артисты Георг Отс исә Салих Сәйдәшевнең «Әдрән диңгез»ен яңа буяулар белән баетып яңгырата. Минемчә, ул бу җырны мелодраматик рухта сузучы кайбер татар артистларыннан аермалы рәвештә, киңрәк колачлы, баерак төсмерле, кырысрак һәм дәһшәтлерәк итеп башкара, табигать стихиясен тулырак күз алдына бастыра. Хәер, диңгез буенда үскән җырчының көйне йөрәгенә тирән сеңдерүе һәм аны үзенчәлекле бәян итүе гаҗәп тә түгелдер. Шунлыктан Отсның җырга яңа төсмерләр кушуы сәнгатебез өчен бик тансык хәл. Мин алдарак телгә алган Арви Сийг сүзләренә иҗат ителгән җырны Ринат Ибраһимов башкаруында тыңлау исә эстон дусларыбызга күңелледер.

Таллиннан китәр алдыннан мин тагын бер мәртәбә киштәләрендә меңнәрчә эстон китабы тезелеп торган кибеткә сугылдым. Көтмәгәндә күзем латин хәрефләре белән басылган татар исеменә төште. Рафаил Такташның сәнгатькә багышланган монографиясе — эстон телендә. Шагыйребез Һади Такташның улы эстон укучысына юл тота! Бу уңайдан, бәлки, Рафаилның анасы Гөлчәһрә Хәмзина-Такташеваның сугыштан соңгы елларда Эстониянең гаделия министры булып эшләвен дә телгә алырга кирәктер? Аңа тукталабыз икән, нигә соң әле Эстония сәхнәсендә Республиканың халык артисты А. Бәдретдинованың уңышлы чыгыш ясавын, Әхмәт Даутовның В. Кингисепп исемендәге Эстон академия драма театрында уйнавын, шагыйрә Л. Хөсәенованың эстон шигъриятен

урысчага тәрҗемә итүен, сурәтче Нәкый Бикташовның Эстония сәнгать институтында белем алуын да әйтеп китмәскә? Алар барысы да ике халыкның хезмәттәшлегенә мисал лабаса!

Хезмәттәшлегебезне раслаган икътисадый алыш-бирешләрне дә онытырга ярамас. Татарстан Балтыйк буена компрессорлар һәм самолетлар, мех һәм полиэтилен, автомобильләр һәм медицина кораллары, кетгут һәм фото-кинотасма, тагын башка әйберләр җибәреп тора. Эстония үзе балык консервлары һәм радиолгычлар, экскаваторлар һәм электр двигательләре, тукыма һәм кием-салым, янә бүтән нәрсәләр бирә. Мондый хезмәттәшлек Эстония тулы бәйсезлеккә ирешкәч тә тукталып калмады, аның хөкүмәт вәкиллеге махсус Казанга килеп, ике якка да файдалы килешүләр төзеп китте.

Милли тигезлек, гаделлек турында лаф орырга яраткан тоталитар коммунистик режим СССР халыкларын төрле сортларга бүлеп идарә итте, автономияле республика статусына гына ия татар халкына Русия алашасы вазифасы гына йөкләнде, империя өчен кара эшләрне башкару тапшырылды, рухи эшчәнлеген нормаль җәелдерү төрлечә чикләнде һәм тоткарланды. Хәтта әдәбият-сәнгать атналыклары уздырганда да Татарстан автономияле республикалар даирәсендә генә калдырылды. Үзбәгестан белән атналык алмашырга теләгәч, безгә аның Каракалпак АССРын, Украинага барырга омтылгач, бер өлкәсен генә атап күрсәттеләр. Халкыбызның горурлыгын кимсеткән, аның хәтта кардәш халыклар белән табигый бәйләнешләрен сакларга комачаулаган мондый әхлаксыз тыюлар мине дә күптәннән борчып килә иде. Шуңа күрә икенче тапкыр килүемдә бу хәлләрне Лилли Прометка сөйләп бирдем.

— Эстоннарда гаделлек хисе көчле. Бәлки сез әнә шул ямьсез милли сәясәтне кире кагып, безнең белән тиң баскычта әдәбият атналыгы алмаша алырсыз? Бу адым сезне автономияле республика дәрәҗәсенә төшермәс, әмма безгә әнә шул автономия кысаларыннан чыгарга омтылышыбызда күңелле, дәрт өсти торган бер вакыйга булыр иде. Сезнең казанышлар белән танышу, бәлки, безнең аңгырайтылган башыбызга гыйбрәт очкыннары төшерер, уятыр һәм уйлатыр иде...

Аз санлы халыкларның СССРда уртак кайгылары, уртак борчулары бик күп, аларны аерым-аерым гына уңай хәл итү мөмкин түгеллеген Л. Промет та, аның ире Р. Парве да бик яхшы аңлыйлар иде. Шуңа күрә алар тәкъдимемне хакимияттә утырган җитәкчеләргә төшендереп карарга булдылар. Мәсьәлә тиз генә хәл ителмәде, әмма РСФСР карынында газапланган Татарстанга дусларча илтифат күрсәтү уе әкренләп ныгый барды һәм 1989 елда Эстония Язучылар берлеге идарәсендә рәсми рәвештә хупланды. Эстон дусларыбыз бу бәйрәмне уздыруда аннары шундый зур егетлек күрсәттеләр — безне башта үзләре кабул иттеләр. 1989 елның декабрендә Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәлгать Галиуллин, Равил Фәйзуллин, Ринат Мөхәммәдиев һәм башкаларны эченә алган сигез кешеле вәкиллек Таллиннга килеп төште.

Әдәби атналык уздыруның төп максаты Эстониянең төрле тармаклардагы казанышлары, бигрәк тә әдәбият-сәнгатьтәге уңышлары белән танышу, Эстония укучыларын, җәмәгатьчелеген Татарстан һәм аның культурасы белән таныштыру, дуслык, хезмәттәшлегебезне яңа югарылыкка күтәрү иде.

Атналык файдалы узды. Эстония матбугаты, радио-телевидениесе кунакларга зур игътибар күрсәтте, татар әдәбияты үрнәкләре эстон һәм рус телләрендә җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителде. Язучыларыбыз эстон каләмдәшләре белән очрашты, Таллинн һәм Тарту шәһәрләре, авыл районы, университет, китапханәләр һәм музейлар, мәдәният йортлары һәм фабрикалар, Балтыйк буеның үзенчәлекле табигате һәм тарихи-архитектура һәйкәлләре, Таллинның татар диаспорасы вәкилләре белән танышты. Татар язучылары Эстония тормышын, эстон халкының милли рухын, ирек өчен алып барган көрәшен күреп, тоеп, каләмдәшләре белән эчкерсез шәхси дуслык урнаштырып кайттылар.

1990 елның июнендә Татарстан Эстония кунакларын кабул итте. Чынлыкта исә республикабызга эстон һәм фин язучылары бергәләп килде. Берләшкән вәкиллекнең җитәкчесе, Эстония Язучылар берлеге рәисе урынбасары Арво Валтон Татарстан Язучылар берлегендә узган очрашуда:

— Татарлар җиде миллионлы халык, эстоннар — бер генә миллион. Сезнең белән тигезләшер өчен, без якын туганнарыбызны — биш миллионлы Финляндия вәкилләрен дә алып килергә булдык,— диде.

Уен-көлкенең мәҗлесне җанландырып җибәрүе хак. Әмма безнең өчен тагын да куанычлысы — күрше автономия республикалар белән генә әдәби атналыклар алмашырга мәҗбүр булган Татарстанның бу юлы союздаш республика һәм бәйсез дәүләт вәкилләрен рәсми рәвештә кабул итүе иде.



*Татарстанда эстон әдәбияты атналыгы (сулдан уңга): Үло Тонтс, Ерма Каннила, Харри Йыгисалу, Анита Конкка, Арво Валтон, Ринат Мөхәммәдиев, Тәүфикъ Әйди.*

Татарстанда узган эстон-фин әдәбияты атналыгында эстон язучылары Валерия Вилланди, Харри Йыгисалу, Үло Тонтс, Олев Ремсу, нәшрият хезмәткәре Мария Оямаа, фин язучылары Ерма Каннила, Анита Конкка һәм СССР-Суоми дуслык җәмгыяте хезмәткәре Пулму Маннине катнашты. Кунаклар башкалабызда һәм Болгарда тарихи һәйкәлләребез, музейларыбыз белән танышты, Тукай-Кырлайны тамаша кылды, сабантуйда катнашты, каләмдәшләре һәм укучылар белән очрашты, аерым язучыларның өйләрендә булып, татар тормышын якыннан күрә алды. Бу көннәрдә Татарстан матбугаты Эстониягә багышланган, эстон әдәбияты, сәнгате казанышларын сурәтләгән байтак язмалар нәшер итте. Радио-телевидение аша кунакларыбыз эстон культурасы үсеше хакында сөйләде. Атналык көннәрендә күренекле эстон әдипләренең новеллаларын туплаган «Бәхетлеме икән ул» җыентыгы, гәзит-журналларыбызда эстон каләмдәшләребезнең шигырьләре һәм хикәяләре басылып чыкты.

Беренче мәртәбә Татарстанга килгән эстон һәм фин язучылары әдәби атналык алмашуның ике якка да файдалы икәнлеген үз күзләре белән күрде, үз акыллары һәм хисләре белән моңа тирәнтен ышанды. Катлаулы һәм озын тарихлы татар халкының, Балтыйк буендагы өч республиканың — Латвия, Литва, Эстониянең тулаем икътисады суммасыннан өстенрәк куәткә ия Татарстанның бүгенге тормышы белән танышу, аның юмарт кунакчыллыгын тату аларны сокландырды һәм гаҗәпкә калдырды. Алар монда үзләрен якын күргән, хөрмәт иткән халык яшәвен, бу халыкның Балтыйк буе белән дуслыкка һәм хезмәттәшлеккә омтылуын бөтен күңелләре белән тоеп дулкынландылар. Шушы тәэсирләрен Арво Валтон «Сезнең халыкка сокланам» («Социалистик Татарстан», 29.VI.1990) дигән интервьюсендә, Олев Ремсу «Оккупациягә 450 ел» («Ээсти экспресс» г., 17.VIII.1990. Таллинн) мәкаләсендә уртаклашты, безгә мәхәббәт тулы язмалар бүтән басмаларда да нәшер ителде. Хәбәр итүләренчә, бездә булган язучылар атналык тәэсирләрен кайтып сөйләгәч, Шәрекъкә таба борылуны дәрәҗәле эш санамаган, Казанга килергә вакытын «әрәм» итәргә теләмәгән кайбер эстон «бөекләре» форсатны кулдан ычкындырулары өчен бик үкенгән икән. Атналыкта катнашкан күренекле әдәбият галиме Үло Тонтсның соңрак миңа язган хатында (29.VI.1990) исә менә мондый юллар да бар иде:

*«Кадерле Тәуфикъ! Хәзер инде мин Казанга яңадан бару турында хыялланам. Мин сезнең бирәр уку йортыгызда эстон әдәбияты турында унбиш-егерме сәгатьлек лекцияләр сөйли алыр идем. Милли культура үсешенең әһәмиятен күрсәтеп, аз санлы халыкның мәдәни тәҗрибәсен сурәтләп. Шәхсән ышануымча, без бары көчле милли культура барлыкка китереп кенә, үз йөзебезне саклап кала алдык».*

Күренекле эстон шагыйре һәм галиме Миһкел Веске (1843—1890) үзенең соңгы гомерен Казанда уздыра — университетыбызда фин-угыр телләрен укыта, әдәби иҗатын дәвам итә. Ул дөнья куйганнан соң, университетта фин-угыр телләреннән икенче эстон профессоры Николай Андерсон сабак бирә.

Миһкел Веске үлеменә йөз ел тулганда без аның шигырьләрен татарчага тәрҗемә итеп чыгардык, Республикабызда эстон әдәбияты атналыгын уздырдык. Эстония картасына күз салгач, мин тагын бер кызык хәлгә гаҗәпсендем: кунакларыбыздан Харри Йыгисалу һәм Арво Валтон Казари елгасы төбәгендә туган иде! Бәлки бу очраклы туры килүләрдер, әмма миңа монда табигатьнең ниндидер бер эчке бәйләнеше, бөек эчке сере дә бар кебек тоелды!

Валерия Вилландинең Мәдинә Маликова; Харри Йыгисалу, Анита Конкка, Үло Тонтсларның Аяз Гыйләҗев; Ерма Каннила, Пулму Маннине әфәнделәрнең безнең өйләрдә булулары, Арво Валтон, Олев Ремсу, Мария Оямааларның күренекле татар язучылары белән дустанә шартларда аулакта очрашулары, эчкерсез әңгәмәләре, үзләрен кызыксындырган мәсьәләләрне иркенләп ачыклаулары арабызда күңел якынлыгы, теләктәшлек барлыгын бик ачык күрсәтте. Бу аралашу өч республика җирлегенә татулык, үзара ярдәм орлыкларын чәчү булды. Ул орлыкларның көне-елы белән уңыш бирүен көтәргә ярамый, әмма без игелек чәчүебезне һәм аның кайчан да булса һәркайсыбызга яхшылык булып кайтасына ихлас ышанабыз.

Без Татарстанда уздырылган эстон әдәбияты атналыгында катнашкан Суоми (Финляндия) язучылары хакында электән берни белми идек. Әсәрләрен тәрҗемә итүне дә оештыра алмадык. Әмма алар — күп кенә кызыклы романнар авторы Анита Конкка ханым һәм күренекле әдип, Суоми Язучылар берлегенең элекке рәисе Ерма Каннила әфәнде Татарстанга килә алуларыннан бик шат калдылар.

— Мин татарларның безгә ерак кардәш булуын белә идем, әмма аларның шундый эчкерсез, ягымлы, туганнарча җылы мөнәсәбәт күр-

сәтүләрен һич тә көтмәгән идем,— диде Ерма әфәнде.— Болгарда һәм Казанда тарихи һәйкәлләрегезне күрә, үткән тормышыгыз белән якыннан танышу, шундый матур, күп бизәкле сабантуй бәйрәмегездә катнашу, җыр-биюләрегезне тамаша кылу, тәмле-татлы ризыклар белән сыйлану — барысы-барысы мине чын-чыннан әсир итте. Мин монда үзем өчен яңа дөнья ачтым. Сезнең белән элемтәләребез элегрәк башланмавын кызганам!

— Без гел Парижга, Римгә, җылы диңгез буйларына тартылабыз,— диде Анита ханым.— Анда бару җиңел, сервис ансат тәэмин ителә, туристлык фирмалары бөтен мәшәкатьне үз өстенә алып, сәяхәтләрне даими оештырып тора. Көнбатыш телләрен иркен белү психологик киртәләрне дә киметә. Әмма мин дә Көнбатыш белән генә мавыгу файдалы түгеллеген Татарстанга килгәч бик әйбәт аңладым. Ел саен Суоминың һәр унынчы кешесе чит илләргә бара. Көнбатышка! Ни өчен? Әйтерсең, башка якларда мәдәният, матур табигать, безне санга санаган халыклар юк!

— Мин Суомида да татарлар яшәвен белә идем, әмма аларның фән һәм мәдәнияттәге тырышлыкларын, милли гореф-гадәтләрен, туган телләрен саклау буенча зур эш эшләүләрен Казанга килгәч, «Татарико» җыентыгын укыгач кына ачыкладым. «Татарико» җыентыгы исә 1987 елда Һилсинкидә басылган икән! Кызык та, уңайсыз да булды моны ачыклау. Алданрак кызыксынырга кирәк иде ләбаса! — дип өстәде Ерма әфәнде.

Мин бу урында Арво Валтон сүзләрен китерү дә урынлы булыр дип уйлыйм.

«Казан татарлары кая гына барып чыкмаган,— ди ул алдарак телгә алынган интервьюсендә.— Евразиядә аның йогынтысы бик зур булган. Бу аның көчле, зыялы булуына бәйләнгән. Шунысы кызганыч, урыс халкы әле һаман чын тарихтан җитәрлек дәрәҗәдә хәбәрдар түгел. Шуңа күрә хәзерге урыс әдәбиятында да «татар» сүзен бик начар мәгънәдә телгә алалар. Бу, билгеле, безнең дә эчне пошыра, гаҗәпләндерә. Әмма эстоннар арасында сезгә хөрмәт зур».

Димәк, без бер-беребезне аңларга омтылабыз, тарихыбыздан дошманлык эзләп казынмыйбыз. Мин дә Эстониягә начарлык, тискәрелек эзләргә барып йөрмим — яманлыкны үз илеңдә, үз халкыңда да җитәрлек табарга мөмкин. Мин бу сәяхәтнамәмдә эстоннарның бик күп яхшы сыйфатларын, матур казанышларын сурәтләдем һәм, еш кына үзебезне алар белән чагыштырып, игътибарны татарның, Татарстанның кимчелекләренә юнәлттем. Яхшы якларыбызны күрмәгәнлектән һәм белмәгәнлектән, аларны тиешенчә бәяләргә теләмәгәнлектән түгел. Горурланырлык сыйфатларыбыз да, казанышларыбыз да бар. Ләкин безгә шулар белән масаеп, шуларга канәгатьләнеп яшәмәскә иде. Дөньяда кечкенә дә төш кенә илләр бар, нигә әле безгә шулар белән ярышып гомер итмәскә?

Эстониядән кайтып китәр алдыннан, мин Таллинда «Эстонча-урысча сүзлек» сатып алдым һәм монда еш ишеткән «тере» сүзенең мәгънәсен ачыкладым. Аннары инде үзем дә Эстониядәге танышларыма шул сүзне әйтеп эндәшергә өйрәнештем:

— Тере!

Ягъни «сәлам», «исәнмесез»!

Әмма «сау булыгыз!»ны сүзлектән таба алмадым. Китап калын, аны укып чыгарга күп вакыт кирәк иде. Аннары, бер телне тулаем үзләштерүне теләп торганда, икс сүз белән генә барыбер котылып булмаячак, дип тә уйлап куйдым. Дөресен әйткәндә, Эстония, аның күркәм кешеләре, сокландыргыч бай мәдәнияте белән һич тә саубуллашасым килми иде. «Тере»не кат-кат кабатлау исә рәхәт тә, күңелле дә. Мәңге тере бул, гореф-гадәтләреңне, үз йөзеңне саклап чәчәк ат син, горур эстлар иле!

*Таллин-Казан 1976—1994.*

## ШИГЪРИЯТ



# ФИРАЯ ЗЫЯТДИНОВАГА 50 ЯШЬ

**Фирая Зыятдинова (Шиһапова) 1945 елның 5 сентябрендә Әтнә районының Мамыш авылында туган. 1963 елда Казан дәүләт университетының татар әдәбияты һәм тел бүлегенә укырга керә, аны тәмамлагач, мәктәптә укытучы булып эшли. 1969 елдан — Татарстан китап нәшриятында. Бүгенге көндә ул — яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир.**

**Шигырьләре башта республикабыз газета-журналларында, гомуми җыентыкларда басылып чыга. Аннары бер-бер артлы «Матур буласым килә», «Язгы ярсу», «Ташкын» исемле шигырь җыентыклары дөнья күрде. Фирая — күп кенә популяр җырлар авторы да: аның шигырьләренә Л. Батыр-Болгари, М. Шәмсетдинова, Р. Әхиярова, Р. Кәлимуллин кебек композиторларыбыз көйләр («Мин сине шундый сагындым», «Китмим әле яшьлегемнән», «Кышларның бураннары» һ. б.) яздылар. Фирая балалар өчен дә иҗат итә — быел аның «Айнур» исемле китабы басылачак. Юбилее белән котлап, бу санда укучыларыбызга шагыйрәнең яңа шигырьләреннән бер бәйләм тәкъдим итәбез.**

## Дулкыннар

Йөгерә торгач ярларына
Барып җиткән дулкыннар.
Юлда күпме күргәннәрдер —
Арып киткән дулкыннар.

Чал башларын ярга салып
Бушаналар дулкыннар.
Бу давыллар бер тынар дип
Ышаналар дулкыннар.

Тик озакка түзалмаслар —
Уянырлар дулкыннар.

Тагын давыл эчләренә
Юл алырлар дулкыннар.

## Уйлама, дисең...

*Уйлый күңелем, уйлый күңелем,*
*Уйлый күңелем төрлесен...*
Халык җырыннан

Уйлама, дисең, уйлама,
Гөлләр үсә тирәңдә...
Гөлләр дә күзгә күренми —
Кердем, ай-һай, тирәнгә!

Уйлама, дисең, уйлама,
Уйлама бик тирәннән...
Нишлим — йөрәк дулкыннарым
Бик тирәнгә көйләнгән.

## Күбәләк

Язгы иртә. Кояш балкый.
Нурлар таган атына.
Тәрәзәбез каршысында
Бер күбәләк талпына.

Оча, китә, тагын килә,
Күбәләк соң ни аңлый?!
Пыяла да вата алмый,
Бүлмәгә дә кералмый.

Ә аннары... Нишләсен ул
Сырхаулар арасында?
Сизмичә дә кулым сузам
Сап-сары канатына.

Мин дә тәрәз вата алмыйм,
Шул күбәләк хәлендә.
Ә шулай да мин бәхетле
Гомернең бу мәлендә.

Яз килә, дөнья уяна.
Ак өмет — җаным тулы.
Яз килә Кояш төсендә —
Сары күбәләк булып.

## Кая барам?

Бу юлларның чиге юктыр —
Инде күпме гомер барам.

Нәрсә эзлим, нәрсә кирәк,
Нәрсә көтә алга табан?

Үргә менәм, үрдән төшәм,
Барына да мин җитешәм.
Югалтамын да табамын,
Кая таба мин барамын?

Егылам да тагын торам,
Абынам да тагын егылам.
Нәрсә эзлим, кая барам,
Кайсы якта минем кыйблам?

Кем соң мин бу дөньяларда:
Армас-талмас бер юлчымы?
Җирдә иң-иң моңлы җырын
Эзләп йөргән бер җырчымы?

Нәрсә эзлим, кая барам?
Бу баруның мәгънәсе ни?
Җавап көтеп мең-мең сораль
Бертуктаусыз җанны кыйный...

* * *

Теләсә ни уйласыннар минем хакта,—
Үзем беләм «кара йөрәк» түгелемне.
Намусым да, вөҗданым да, шөкер, исән,
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

Теләсә ни уйласыннар минем хакта,—
Үзем беләм түбән җанлы түгелемне.
Алтыннарга сатылмастай җаным исән —
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

Сөйләсеннәр, дуласыннар туйганчы бер,—
Ә мин беләм көлеп кенә йөреремне.
Диңгездәге таш кыядай нык торамын —
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

Җырлап яшим, көлеп яшим, бәхет санап
Бар нәрсәне якты итеп күрүемне.
Төн артыннан көн туасын беләм ич мин —
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

* * *

Бар иде курку да күңелдә:
Нигәдер ышанып бетмәдем...
Сөенеп беталмыйм: мең шөкер —
Үземә хыянәт итмәдем.

Үттеләр көн арты көннәр дә,
Шикләнү һаман да китмәде...

Хәзер мин бәхетле: мең шөкер! —
Үземә хыянәт итмәдем!

* * *

Матурлык коткарыр дөньяны, Матурлык! —
Дип әйткән бер акыл иясе.
Бик килә күзенә туп-туры карыйсы,
«Кая соң Матурлык?» — диясе.

Бар кеше — эшмәкәр, сәүдәгәр, үзе — кол,
Азгынлык чорнады дөньяны.
Күгебез пычранды, әллә соң шундый дип
Күрергә теләдек без аны?!

Батырып җир өстен чүп-чарга, сөремгә,
Без кая барабыз ашкынып?
Нинди көч туктатыр бу комсыз һәм әрсез,
Чарасыз хәрәкәт ташкынын?

Дөньяны афәттән, үлемнән коткарыр
Кая соң Матурлык, кая соң?
Юк, туктый алмабыз, ахры, без,— һәлакәт
Каршында һәммәбез чарасыз...

* * *

Кеше башы саен хәсрәт,
Адым саен кайгы.
Күрмәс хәлгә килә кеше
Кояш белән Айны.

«Нишләп болай?» — дигән сорау
Тынгы бирми миңа.
Нигә Кеше күмелгән соң
Сагыш белән моңга?

Тынгы бирмәс бу сорауны
Кемгә биреп багыйм?
Әллә нинди өмет белән
Йолдызларга карыйм...

* * *

Бер кителсә, дөнья гел кителә,
Бер сүтелсә, йомгак сүтелә.
Кире ураулары, ай-һай, кыен,
Сүтелмә син, йомгак, сүтелмә!

Бер кителсә, дөнья гел кителә,
Гел кирегә китә эшләрең.

Мондый сүлпән түгел идең бит син,—
Әйтче, Йөрәк, әйтче, нишләдең?

Бер сүтелсә, йомгак гел сүтелә,
Гел сүтелеп бетсә, нишләрмен?
Кире урау өчен вакыт җитмәс,
Сүтелмәскә көч бир, и Тәңрем!..

* * *

Тагын инде рәнҗеттеләр —
Рәнҗетергә маташтылар.
Әрнүләрдән тынмас җанга
Тагын инде таш аттылар.

Тагын инде маташтылар
Нәфрәт ташын кузгатырга.
Ак түбәле чатырымны
Давыл кебек тузгытырга.


Ничә еллар әрни Йөрәк,
Һаман дәшми, һаман түзә.
Кимсетелеп яшәсә дә,
Пәйгамбәрләр дә бит түзгән.

Мин Пәйгамбәр түгел анысы,
Җирнең гап-гади бер кызы.
Тешне кысып түзәм, үзем
Утлы күмер кебек кызу.

Нәфрәт учагыннан алып,
Утлы күмерне күтәрмәм.
Минем нәфрәт утларыннан
Пешмәсеннәр, дим, бүтәннәр.

Тырышмасын кара көчләр:
Йөрәгемдә тик Ярату.
Саклый нәфрәт-рәнҗүләрдән
Фәрештәнең ак канаты.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Кави Латыйп

# ҖИДЕНЧЕ СӨЯРКӘ

НОВЕЛЛА

Тимер юл тирәсендәге төнге һөҗүмнән соң һәлак булган командирны алмаштырган кече лейтенант җиде кешедән торган отрядны бер утарга алып килде.

— Отбой! Таң атканчы ял итеп алыйк, аннары күз күрер,— диде кече лейтенант.— Утар хуҗасы белән сөйләштем, безне өенә кертергә ризалык бирде. Сигезегезгә дә урын табылыр, диде.

— Сигезенчесе кем?— диде рядовой Зәйдуллин.

— Кем булсын, синең әсирең,— диде командир.— Утар хуҗасы һәммәбезгә дә йокларга урын табар, дип уйлыйм.

— Йокы ястык сорамый,— диде Зәйдуллин.

— Что по-русски означает?— дип сорады кече лейтенант.

— Это значит, что сон подушки не просит. Әле аның бездә монысы да бар: «Бер кичкә — кер мичкә», урысчасы болай: «Одну ночь можно провести и в печи».

— Шәп әйтелгән.

— Татар әйтсә, шәп тә әйтә, рас та әйтә инде ул!

— Шулай да, рядовой Зәйдуллин, синең урының сарайда. Әсир хатынны саклау сиңа боерыла. Сакта каласың. Матри, качмасын. Качырсаң, башың белән җавап бирәсең!

— Есть, баш белән җавап бирергә!

— Вот так, шутки в сторону.

— Есть, в сторону!

Командир кул сәгатенә карап алды.

— Хәзер төн уртасы, сәгать унике. Итак, рядовой Зәйдуллин, таңга кадәр, алмашчы көтмә. Ни пуха, ни пера... Скажи, к черту.

— Тел күтәрелми,— диде Зәйдуллин.

Юлдашларының алтысы да өйгә кереп китте, ә рядовой Зәйдуллин сак астына алынган әсир хатын белән икәүдән-икәү калды.

---

[1] Кави ЛАТЫЙП (1927) — *фронтовик әдип. «Солдат эзләре», «Хәтер йомгагы», «Йолдыз тапкан егет» һ. б. шигырь һәм проза китаплары авторы. Казанда яши.*

— Киттек,— диде сакчы, әсиргә боерып.
— Кая?
— Әнә теге салам түбәле сарайга. Туп-туры, яме, уңга-сулга борылмаска!
— Борылсам, нишләрсең?.. Дәшмисең, нигә атам дип янамыйсың?
— Бәлки атармын да.
— Телеңә тилчә чыккыры, каһәрле бәндә икәнсең.
— Атлавыңны бел. Качалмассың, әнә күктә тулган ай балкый.
— Әйе, бу җиһан дигәннәре кемгә — тулган ай, кемгә — кара урман. Өзеп әйткәндә, сиңа — тулган ай, ә миңа — кара урман.
— Шуңа кулыңа корал тоттыңмы?
— Әле дә ул минем кулда.
— Бир мылтыгыңны. Ышан сиңа. Йә атарсың.
— Патронсыз мин ничекләр итеп атыйм?
— Син, бәлки, берне булса да итәк астында яшереп калдыргансың?
— Итәк астында патрон түгел, ә бөтенләй икенче әйбер. Сез ир-егетләрне тарта торган тере нәрсәкәй...
— Телеңә салынма, атлавыңны бел. Винтовка штыклы.
— Аллага шөкер, сукыр түгел, күрәм.
— Ай яктысында штык ялт-йолт итә, шулаймы?
— Винтовкадагы ялт-йолт итә дә бит, ә менә тегесе, шинель астындагысы ничектер? Сынап караганың булмадымы?
— Прекратит посторонние разговоры!
— Күрәм, син бабник түгел икәнсең.
— Ә кем бабник? Атаман Тарас Дорошенко ничегрәк?
— Зарланмас идем, бер кочса, җир тишегенә керердәй буласың. Оныта алмамдыр мин аны.
— Онытырлык булсаң, кулыңа мылтык алмас идең?
— Ул үзе миңа гашыйк булды...
— Гашыйк булган, ә үзе гыйшкын ташлап сугыш кырыннан качкан. Инде син — әсир, үзеңне сак астында тотарга мәҗбүрмен. Яудашларым җылы өйдә ял иткәндә, мин синдәй тоткын белән мәшгуль.
— Ә син саклама.
— Бик сакламас идем дә, кече лейтенант кушты.
— Ул минем качудан шүрли.
— Юк, шүрләми, әсир сак астында булырга тиеш. Тәртип шулай куша.
— Сиңа, солдат, ничә яшь?
— Унсигез.
— Бик тә борынгы кеше икәнсең шул. Хи-хи.
Тоткын хатын сарай эченә кереп китте, рядовой Зәйдуллин, штыклы винтовкасын тоткан килеш, ишек төбендә басып калды.
Ай да болытлар арасына кереп качты. Дөм караңгы төн, күзгә төртсәң күренмәс. Янәшәдә генә поездларның пуфылдап узганы ишетелә. Аларның йөрешен рядовой Зәйдуллин хезмәт иткән уналтынчы укчы бригада карамагындагы «Бронепоезд — 39» тәэмин итә. Ул бронепоезд икегә: «Литер — А» белән «Литер — Б»га бүленеп, Олевск — Сарны — Ровно һәм Сарны — Костополь — Ровно участокларында курьерлыкны башкара. Шулай да тимер юлда һәлакәтләр булгалап тора.
...Ниһаять, җәйге таң атты. Колак төбендә генә: «Та-та-тук-тук!» — такылдатканы-тукылдатканы ишетелде. Әллә автоматтан аттылар, әллә тукран тукылдатты — аңламассың.
Рядовой Зәйдуллин сарай ишеген ачты.
— Аталармы әллә? — диде әсир хатын.
— Юк, тукран тукылдата,— диде сакчы.

— Туеп беттем инде шул тукран дигәннәреннән. Өченче ел урманда яшим. Яшим түгел, юк, иза чигәм. Атаман Дорошенконың сөйрәлчегенә әвереллем. Гел йә схрон[1], йә шалаш...
— Сөйгән ярың янында икән, шалашта да оҗмах. Үзеңне атаман Дорошенконың мәгъшукасы диден түгелме?
— Әйе, җиденче сөяркәсе.
— Калган алтысы кайда?
— Икесе һәлак булды, дүртесе сөргенгә сөрелде. Инде менә чират миңа җитте. Мине нишләтерләр икән?
— «СМЕРШ» әйтер.
— «СМЕРШ» нинди мәгънәне аңлата?
— Смерть шпионам, дигәнне.
— Ә мин, синеңчә, шпионмыни?
— Кем белгән сине. Бәлки, шпион ук түгелсеңдер.
— Алайса, синеңчә, кем соң мин?
— Атаманның сөйгәне.
— Юк, сөйгән яр бер генә була. Ә мин — сөяркә.
— Әйе, җиденче сөяркәсе, диден бит әле.
— Аңар мин, чыннан да, җиденчеседер, ә миңа килгәндә, ул — минем беренче мәхәббәтем. Бер үк вакытта — соңгысы да.
— Ни өчен соңгысы?
— Күңелем сизә, һәлак булачак ул — Тарас Дорошенко. Шәхсән, мин үзем аның башына җитмәгәем. Тәгаен үч алачакмын мин аңардан. Хикмәт шунда, алдады ул мине мыеклы Тарас, алтын сарайлар вәгъдә итте. Хәер, мин хәзер дә сарайда. Ләкин исеме җисеменә туры килмәгәнендә... Һава суларга чыксам, каршы килмәссеңме?
— Ярамас, кече лейтенантның сине күрүе ихтимал.
— Таз баш, һава сулыйм дигәннең икенче мәгънәсе бар аның. Монда утырмам бит инде.
— Шунда гына башкар, карап тормам.
— Йа рабби, нинди хәлгә калдың син, Наталка?!
— Ярый, Наталка, миннән яхшылык күр, һавага чыгарга рөхсәт итәм үзеңә.
— Сак астындамы?
— Әлбәттә, шулай.
— Синең урыныңда булсам, мин сине азат итәр идем.
— Итәр идең?
— Билгеле.
— Ә мин сине азат итмәячәкмен, ә һава суларга рөхсәт.
Берникадәр вакыт булганнан соң, атаманның җиденче сөяркәсе — Наталканы рядовой Зәйдуллин яңадан сарайга әйдәп, ишеген япты да сакта торуын дәвам иттерде. Поездлар йөри, кошлар сайрый. Кояш үзенең югары ноктасына күтәрелде. Ләкин «СМЕРШ» та, кече лейтенант та никтер күренмәде. Карыны ачты егетнең, җәйге челләгә күрәме, җаны көйде, үлеп су эчәсе килде. «Өйгә кереп, су сораргамы әллә? Юк, кирәкмәс, атаман сөяркәсеннән җилләр исүе ихтимал. Түзәргә кирәк, түзәргә. Юлдашлар мине тәмам онытмаслар. Үзләре белән берәр хәл булмагае?!
Бераздан түземе төкәнде. Йөгереп килеп, өй тәрәзәсен шакыды. Бер сакалбай чыкты. «Утар хуҗасы булса кирәк?» — дип уйлады сакчы.
— Ни йомыш? — диде карт.
— Коралдашлар синдәме?
— Нинди коралдашлар? Кызыл погонлылармы?
— Әйе, шулар.
— Киттеләр алар.
— Кайчан?
— Таң сызылыр-сызылмас. Ә син кем?

[1] Схрон — нәүрәп.

— Сакчы.
— Кемне саклыйсың?
— Бер хатынны.
— Кем ул?
— Атаманның сөяркәсе.
— Наталка, димәк. Кайда ул үзе?
— Сарайда.
— Нишли ул анда?
— Сөеклесен көтә,— диде солдат, шаяртып.
— К...тек сарайга.
— Ярамый, рөхсәт кирәк.
— Кемнән?
— Кече лейтенанттан.
— Утар хуҗасы ул түгел, мин. Сарай да минеке.
— А...ысы шулайдыр, ләкин, батька, рөхсәтсез яра...ый. Менә кече лейтенант килер, рөхсәт бирер.
— Килмәсә?
— Килергә тиеш, әбәзен...

Сакчы кире әйләнеп килгәндә, сарайның ишеге шар ачык булып, әсир хатыннан җилләр искән иде инде. «Шаяртма, Наталка! Ничекләр итеп минем рөхсәттән башка, үз белдегең белән китәргә булдың? Җитмәсә, чибәркәй, мине син шинельсез калдыргансың. Төн суык дигәч, үз өстемнән салып бирдем бит, җүләр. Ит яхшылык, көт яманлык — нәкъ безнең татар халкы әйткәнчә. «Поездлар йөри тора, тәгаен тимер юл буйлап станциягә тәпиләгәндер».

* * *

Рельс буйлап ике кеше атлый: берсе — сакчы Зәйдуллин, икенчесе — әсир Наталка.

— Каһәр, шинелең аркасында тагын мин синең капкынга эләктем. Чабуы җирдән сөйрәлә, ташлап калдырырга булган икән. Җүләрмен!

Аннары әсир дәшми, сүзсез генә атлавын дәвам иттерә. Ә шинельгә килгәндә, ул рядовой Зәйдуллинга да ике үлчәмгә зуррак иде, рота старшин...сы аны егет өстенә көчләп кигезгән иде. «Ир-егетләр егерме биш яшькә кадәр буйга үсәләр, ә син унсигездә генә»,— диде ул. Зәйдуллин нишләсен — риза булды, эт каешыдай шомарып беткән, үзсүзле старшинаны тыңламый булдыра алмады.

Кинәттән паровоз кычкыртканы ишетелде. Зәйдуллин артына борылып карады: хәрби эшелон иде. Күп тә үтмәде, ул килеп тә җитте: әсир хатын эшелонның сул ягында, ә сакчы — уң ягында калды. Әсир Наталка, шинель чабуын күтәрә төшеп, урманга таба йөгерде. Нишләргә дә белмәгән сакчы, кисәтү ниятеннән, гөрселдәтеп һавага атты. Әсир хатын җан-фәрманга чаба бирде, артына борылып та карамады. Урманга кергәч, ниһаять, ул, өстеннән солдат шинелен салып җиргә ташлады да, йөгерүен тагын да көчәйтә төште. Әмма кая таба чапканын әсир үзе дә белмәде, тәвәккәлләп, йөгерде дә йөгерде. Коры җирне узгач, мүкле сазлык башланды, ә ул кесәл сымак дерелдәп тора иде. Наталканың, баскан саен, әле бер аягы, әле икенче аягы батты. Шуңар аңар челән коштай сыңар аяк белән генә дә басып торырга туры килде. Мүкле сазлык аны йотып алыйм дигәндә генә, Наталка икенче урынга сикерде. Ә инде аланга чыккач ул, аудан ычкынган җәнлектәй, элдертте генә. Аланны узгач, әсир ешлыкка кереп китте. Битен ылыс тырнады, аның коры инәләре чәч араларына тулды, хәтта төймәләре ычкынган күлмәк изүеннән кереп, күкрәкләрен чәнечте. Дөрес, ешлыкта ул, теләсә дә, йөгерә алмады, ирексездән тукталып калды. Әмма, шәрә куллары белән

чәнечкеле ботакларны чигендерә-чигендерә, алга юл ярды. Еракта тагын мылтык аткан тавыш ишетелде. Наталка сискәнеп, яшел ылыс агачы астына яшеренде. Ул тирә-якка колак салып, күзәтергә керешге... Урманны яңгыратып тукран тукылдата. Шулчак урман күгәрчене кычкырып җибәрде. Әлеге тавыштан, җир тишегенә керердәй булдып, бер куян йөгереп узды. Һавадагы карчыганың ниндидер бер нәни кошка ташланганлыгы күренде. Наталка яшеренгән урынны фаш итәргә теләгәндәй, җәнҗалчы саескан очып йөрде. Хатын сагаеп кына урыныннан кузгалды, ләкин аны аяклары тыңламады. Әйтерсең лә алар үзенеке түгелләр иде. Озак атлады ул ешлык эченнән. Ниһаять, тау итәгенә чыкты. «Тауга менәргәме-менмәскәме? — дип уйлады әсир хатын. — Менәргә! Ләкин ничек? Болай да аяклар тыңларга теләми». Атлап түгел, юк, дүрт аяклап, үрмәләп менде Наталка тауга. Күтәрелгән саен тау биегрәк тоелды, күз алдында үсә торды. Ниһаять, ул тырмаша- тырмаша тауга менеп җитте.

Җәйге эңгер-меңгер иде. Наталка, кая барырга, кайда керергә урын таба алмыйча, тау сыртында арлы-бирле йөренде, күңеле белән ул үзен әле һаман да әсир дип хис итә иде. Наталка үзенең җанын да, тәнен дә аңлап бетерми иде. Аны йокы басты, ирексездән күз керфекләре йомылды. Гүя алар ташка әверелде. Чалкан ятты да Наталка, йокыга китте. Күпме йоклагандыр, ул уянганда кояш шактый югары күтәрелгән иде инде. Эссе иде, битен пешереп сул яктан кайнар җилләр исте, күзенә тузан тулды. Наталка кояшка озак карап ятты. Кинәт аның борып-борып эче авырта башлады. Яткан урыныннан торып, икенче җиргә барып утырды, юк, авыртуы туктамады, көчәя генә барды. Карынын тотып, аягүрә басып торды, сызлану-әрнүе туктамады. Арлы-бирле йөри башлады, әле монда, әле тегендә бәрелде-сугылды. Юк, эч авыртуы бетмәде. Яңадан җиргә чалкан сузылып ятты вә бар тавышка: «Человеки, ратуйте! Ратуйте! Умираю![1], — дип, сөрән салды...

* * *

Наталка уянганда аның янында рядовой Зәйдуллин утырып тора иде.

— Монда кайдан килеп чыктың? — диде Наталка, гаҗәпләнүдән күзләре зур булып ачылды.

— Җир тишегеннән.

— Әйе, ишектән йөрисе урында тишектән йөрибез. Син дә, мин дә...

— Бу синең үзеңнән килә, ә мин — солдат, кая боерылар шунда барам.

— Ә мин — сөяркә, атаман сөяркәсе. Сез — солдатлар telendә, ППЖ диләрме әле?

— Әйе, полевая почтовая жена, диләр. Теләсәң, полевая походная жена, дип әйтеп була. Сиңа кайсы ошый?

— Берсе дә ошамый, алай дип офицерлар, генералларның сөяркәләренә әйтелә бугай. Ә минем сөяркәм офицер да, генерал да түгел, бер самостийный атаман.

— Самостийный булгач, ул инде үзе патша, үзе Алла. Минемчә, шуңар аның җиде сөяркәсе дә инде.

— Әйткәнемчә, чекистлар алтысының башына җиттеләр, хәзерге вакытта атаманның бердәнбер сөяркәсе — ул мин, Наталка!

— Менә шуңа күрә син минем әсир дә инде. Киттек, әйдә!

— Кая?

— Сарны комендатурасына.

— Юк, мин Сарныга кайта алмыйм, авырыйм.

— Ни булды? Нинди авыру?

— Хатын-кызлар авыруы, бала төшердем.

---

[1] «Кешеләр, коткарыгыз! Коткарыгыз! Үләм! *(Украинча)*.»

— Ничә айлык иде?
— Өч айлык.
— Кемнән иде?
— Синнән түгел, әлбәттә. Ә менә син аның башына җиттең. Синнән кача-кача бәлагә тап булдым. Йөгерүләр, тауга менүләр ярамады. Аһ, качмаска булган икән!
— Хатын-кыз акылы гел төштән соң.
— Инде ничекләр итеп кеше күзенә күренергә, хәтта эчке күлмәгем дә канлы.
— Чишен! — диде солдат, кинәттән генә.
— Син нәрсә, шаштыңмы әллә?
— Юк, шашмадым. Сиңа үз күлмәк-ыштанымны салып бирәм.
— Үзең нәрсә белән каласың?
— Гимнастерка, галифе белән. Эчке күлмәк белән кольсонны солдатка алынгач кына кия башладым мин, хәтта простыня дигәнен дә белми идем.
— Мендәр тышлыгын беләидеңме?
— Анысын белә идем.
— Димәк, син авылдан.
— Шуннан.
— Мин дә авыл кызы. Әтием белән әниемне кулаклар дип Себергә сөрделәр. Ә мин — аларның бердәнбер кызлары, качып котылдым. Башта урманда бер урманчыда яшәдем, аннары Тарас бандасына килеп каптым, соңыннан сөяркәсенә әверелдем... Ә синең яраткан кызың бармы?
— Анысын эчке күлмәк-ыштанны салгач әйтермен.
— Алайса мин дә чишенәм, әнә таудан күренгән урман күленә карап тор.
— Чишен дидем бит инде, бу килеш сине мин ничек комендатурага алып кайтыйм?
— Юлда качсам, нишләрсең?
— Тырышып карадың ич инде... Качарга ниятләнүең туачак балаң башына гына булган ул. Җир-Ана куенына тапшырырга кирәк аны.
— Кемне?
— Баланы, әлбәттә. Кайда ул?
— Менә, — диде Наталка, эчке күлмәгенә уралган төенчекне солдат кулына тоттырып.
— Нинди исем кушабыз?
— Анысы нигә тагын?
— Үле туса да бала җир-Ана куенына исем белән китәргә тиеш, мөселманнарда шулай.
— Ә мин католичка.
— Без аны барыбер мөселманнарча җирлибез. Син үзең моңа каршы түгелме?
— Юк.
— Алайса, аның исеме Таһир булсын.
— Без — украиннарда ничегрәк була соң ул исем?
— Тарас дип әйтимме...
— Юк, үз исемеңне куш.
— Рәис була инде алайса.
— Раис дисеңме?
— Әйе.
— Матур исем. Куш шул исемне.
— Димәк, миңа мулла вазифасын да башкарырга туры киләчәк.
— Анысы кем тагын?
— Дин әһеле, сезнеңчә — изге ата, безнеңчә — мулла.
— Бул, әйдә, мин каршы түгел. Тик җәһәтрәк, тау белән тау очрашмаса да, кеше белән кеше очраша: кемнеңдер тауда булуы, безне күреп калуы ихтимал.

Белгән догаларын укыганнан соң, солдат көрәге белән бер аршын чамасы кабер казып, баланы Җир-Ана куенына тапшырды: «Бәхил бул, Рәис-адаш, авыр туфрагың җиңел булсын!» — диде.

* * *

Озак еллар югалып торганнан соң, Наталка туган җиренә кайтты: паспорт алып, пропискага кергәч, эшкә дә урнашты. Үзе урнашты, ә менә күңеле һич кенә дә үз урынында түгел иде. Чит-ят кеше бит ул биредә. Ашаган икмәгеннән дә, эчкән суыннан да тәм тапмады, хәтта сулаган һавасы да килешеп үк бетми иде. Кан басымы күтәрелде. Ә бит ул көн-төн табигать кочагында иде, урманда яшәде, эшләде. Кече урманчы-техник Наталка, урманны урап кайтканнан соң, һаман саен үзенә таныш бер тирән күл янына килеп утыра иде. Җәйге күлдә гел бер күренеш: камышлар арасында шөлди дигән сөйкемсез кошчык йөзсә, су өстендә буш көймә чайкала. Шөлди булып шөлди үз күлен, үз оясын тапкан. Ә Наталканың бүгенге хәл-әхвәле суда чайкалган буш көймәнеке сымак. Дөрес, көймә чылбырлы, дулкын аны күл уртасына, тирән урынга алып китә алмый. Мөмкин булса, Наталка кулаякларын гына түгел, ә җанын да чылбырлар иде. Тик шулай гына ул биредә тәмам төпләнер иде. Ә бәлки аңар элеккеге эш урынына кире кайтмаска, урманчы булып урнашмаска булгандыр? Кара урман шавы күңеленә гел шом сала, үткәннәрне исенә төшерә, ерак истәлекләрне яңарта, тар сукмак буйлап аның хәтер йомгагы тәгәри-сүтелә. Ул тар сукмак Наталкага күптәннән таныш, аннан ул күзләре бәйләнгән килеш тә адашмый уза алыр төсле. Сукмактан гынамы, бар урманны гизә алыр шикелле. Урман аның стихиясе, алай гына да түгел, гыйшкы да. Беренче мәхәббәте Тарас белән ул шунда кавышты... Ерак Себердә хөкем срогын уздырганда да, тайгада яшәгән вә эшләгәндә дә ул туган җирендәге Сарны урманы белән саташты, урман шаулый-шаулый аның төшләренә керде, меңнәрчә чакрымнан мәхәббәт урманы үз авазын-аһәңен ишеттерде. Шушы ылыслы урман хатынга Себердә яшәргә, эшләргә дәрт-дәрман өстәп, көч-рух биреп торды. Ә хәзер туган як урманы аңар икенчерәк күз белән карый сымак, хәтта мәһабәт Демон шикелле артыннан күзәтеп йөридер кебек. Урманның колагы, күзе бар сымак Наталкага, гүя урман ишетә, күрә. Хәтта аңар бармак төртеп күрсәтә: «Винтовка түтәсе белән башын ярып, мөселман гаскәри мәетен, муенына таш бәйләп, суга салучы ул — син! Ә бит солдат ихласлыгы, беркатлылыгы аркасында фаҗигагә дучар булды. Урман күле аша ишкәкле көймә белән чыкканда винтовкасын, ышанып, синең кулыңа тоттырды. Ихласлык, беркатлылык — җан иясе өчен һәлакәт ул. Гаскәринең сөякләре күл төбендә, ә мин — Демон сине коткардым: хөкем карары белән атылырга тиеш булсаң да, минем үтенечем буенча, сәргаскәр[1] Сталин үлем җәзасын ун ел төрмә белән алмаштырды».

Сугыштан соң берничә ел узгач, милләтчедән коммунистка әверелеп өлгергән элеккеге атаман Тарас Дорошенко, тоткынның үзенә дә белгертмичә, төбәктәге житәкче әшнәләре аша җиденче сөяркәсе Наталканы үлем тырнагыннан тартып алды. Ә солдатның мәете бик тә тирәндә, күл төбендә. Водолазлар аны тапсалар да, өскә чыгара алмады. Ниндидер бер яшерен көч бирәсе килми, имеш. Урман күленең үз иясе — Су кызы бар, дип телдән-телгә, тикмәгә генә, риваять күчмидер. Үз җинаятен тануына Наталка үкенми. Солдатның гомере бер мизгелдә өзелде. Ни кылганын Наталка үзе дә аңышмый калды. Көймәдә чакта: «Үтер!» — дип, аның колагына атаман Тарас Дорошенко әйткәндәй булды... Ә менә

[1] Сәргаскәр — башкомандующий.

Наталка үзенең исән калуына, хөкем карары белән атылмавына шатлана алмый. Кем аркасында үлем җәзасы ун ел төрмә белән алмаштырылганын да белми, бәлки, белмәстер дә. Вөҗдан газабы үлем җәзасыннан да әрнүлерәкме әллә? Атылган булса, болай гомер буе газапланмас, җәзаланмас иде. Наталка суга ташланса, тирән күл төбенә барып җитәрме? Урман күле иясе — Су кызы аның җәсәден кабул итәрме? Ә яшь солдат? Ул винтовкадагы штыгы белән янамасмы? Су кызы да, солдат та — икесе дә бер сүзледер әле?! Тауда чакта солдат яраткан кызының булуы-булмавын әйтмәде, тәгаен ул Су кызы кочагындадыр. Икесен дә, кайчан булса да, бер күрер әле. Урман күленә Наталканы җаны юкка гына тартмыйдыр. Урманны урап кайтты исә, түгәрәк күл янына килә вә күңеленә кереп-сеңеп калган хатирәләрне, канлы көрәш елларын һәм юлларын уйлап утыра... Су төбендә изге күңелле солдат егет, ә күңелендә — тәүге мәхәббәте Тарас. Соңгысыннан Наталканың бик тә үч аласы килә. Элеккеге атаман исән булса, ул аны үз куллары белән әнә шулай таза наратның бер ботагына асып куяр. Мәетен урман күленә ташламас иде — Су кызы хыянәтчене кабул итмәячәк. Мәхәббәт бер генә була, бер генә! Күңелендә ярала башлаган мәхәббәтне Наталка үзе юк итте. Көймә күл уртасына җиткәч кенә, Наталканың колагына Тарасның: «Үтер!» дигән тавышы ишетелде. Ә бит Наталка атаман мәхәббәтеннән тәмам арынып, бушанып калган иде. Карынындагы өч айлык баланың төшүе язмыш кушуы булып, Наталканың Тарастан инде азат булуын сөйли иде. Сөйли иде, ләкин ул чакта яшьлеге белән Наталка хыянәтче хакына җинаять эшләп ташлады. Ә бит өч айлык көмәнле Наталканы чекистлар кулына калдырып, Тарас сугыш кырыннан качты. Гафу итү мөмкин түгел иде. Килер бер көн, Наталка аның башына җитәр, хәтта милләтче битлеге дә аны Наталка хөкеменнән коткарып кала алмас, юк, кала алмас. Хәер, Тарас Дорошенко инде милләтче түгел, ә коммунист иде. Наталка ул хакта әлегә белми иде вә белергә дә теләмәде. Төрле көрәшчеләр: милләтчеләр, коммунистлар... килә дә китә, ә мәхәббәт — мәңгелек, гашыйклар үлми, дип уйлады ул. Наталка үзен Тарасның чын гыйшкы, сөйгән яры дип йөргән иде, юк, элеккеге мыеклы атаманның ул, чыннан да, корбаны гына булган икән. Нинди аяныч, мәхәббәт корбаны Наталка власть колы булган солдатны корбан итте. Уйнашчы Тарас исән калды. Чыннан да, Наталка да, солдат та, телиләрме, теләмиләрме, икесе дә бер язмыш кешеләре — коллар вә корбаннар иде. Шулай булгач, Наталка уйлавынча, солдат үләргә тиеш түгел иде. Наталка бу юлы да ялгышты. Гомере булып яшәсә, ул тагын нинди ялгышлыклар эшләр иде икән? Бәлки, урман күле әйтер: су да телгә килә, диләр түгелме? Бик мөмкин...

# ПУБЛИЦИСТИКА

# «КОЛХОЗ ТАРАЛА МИКӘН?..»

(КҮМӘК ХУҖАЛЫК РӘИСЕ ЗАМАН, ЯШӘҮ ҺӘМ ҮЗЕ ТУРЫНДА)



Бу язманың герое — Зеленодол районының «Комсомолец» күмәк хуҗалыгы рәисе Хәлил улы Хәмит Хәйруллин. Ул — 25 елга якын хуҗалык җитәкчесе, шуның 17 елы — «Комсомолец»та. 1944 елда Норлат авылында туган. Хәлил абый белән Бибисара апаның ун баласыннан алтынчысы Хәмит була. Норлат урта мәктәбен тәмамлагач та армия сафларына китә. Солдат хезмәтеннән кайткач, Күгеш авылында укытучы, «Ключи» совхозында комсомол оешмасы секретаре, Ленин исемендәге, Киров исемендәге колхозларда партком секретаре вазифаларын башкара. Аннары Вахитов исемендәге колхозда рәислек итә. Ә инде 1978 елны «Комсомолец» колхозы членнары аны үзләренең башлыклары итеп сайлап куялар.

Хатыны — Клара, Норлат урта мәктәбендә укытучы, Россия федерациясенең халык мәгарифе отличнигы. 1994 елда бу гаиләнең көмеш туе булды. Өч бала үстерәләр. Олысы Марат «Комсомолец» колхозында агроном булып эшли. Уртанчысы Илшат — Казандагы төзүче инженерлар институты студенты. Кызлары Ләйсән 1995 елда урта мәктәпне тәмамлады.

Хәмит Хәйруллин җитәкчелек иткән колхоз (аны хәзер күмәк предприятие дип атап йөртәләр) районда алдынгылардан санала. Ул үзе дә тирән фикер йөртүче, киләчәкне күреп, кешеләр белән эшләү осталыгына ия җитәкчеләрнең берсе. Аның әйтер фикерләре дә, сөйләр сүзләре дә күп.

Хәмит Хәйруллинга «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә. Ә 1995 елда ул «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән исемгә лаек була.

1994 елда Хәмит Хәйруллинга «бодай короле» дигән кушамат тагалар. Күмәк хуҗалык бу елны дәүләткә 715 тонна югары сыйфатлы (клейковиналы) бодай тапшырып, дан казана. Аңа район хакимияте затлы тун бүләк итә. Уңыш бәйрәмендә исемен мактап телгә алалар.

Менә шушындый шәхес белән әңгәмәм үткәннәрне искә төшерүдән башланды...

— «Комсомолец» колхозын кабул итеп алгач, эшне фермалардан башладым. Карап, танышып йөрим. Абзарлар җимерек. Наратлы фермасында сыерлар атналар буе савылмаган. Чәчү борын төбендә, ә орлык юк. Техника паркы ташландык хәлдә. Татар Әҗәле фермасына барып керсәм, чәчләрем үрә торды. Шунда берәү сыер савып утыра. Сораша торгач, кибетче икәнлеген белдем. «Балаларыма сөт кирәк», — ди бу. Нишләргә? Киттем йорт саен йөреп сыер савучы эзләргә. Берсенә әйтәм, икенчесенә, өченчесенә... Юк фермага килүче. Шуннан соң клубта җыелыш җыярга булдык. Халык җыелмады түгел, җыелды. Бәлки, яңа персидәтел ни әйтер икән, дип тә килгәннәрдер. Бик каты сөйләштек, аңлаштык; үгетләдем дә. Бәлки кызып та киткәнмендер,ләкин әйтәсе сүземне әйттем. Аңладылар. Күпләр фермага килергә риза булдылар. Эшләр җайлана башлагач, үзләре дә нишләргә белмәделәр. «Ирләребез сүзен тынлап йөргәнбез

икән»,— ди берсә. Түләү тәртибен дә җайга салдык. Уңай шартлар тудырырга тырыштык. Эшләр шулай әкренләп китте бит хутка.

— Таркау хуҗалыкны аякка бастыру, тәртип урнаштыру җинел булмагандыр,— дип сорыйм аның сүзен бүлдереп.

— Мин үземнең хезмәтемдә һәрвакыт белгечләргә таянырга тырыштым. Алар белән аңлашып, киңәшеп, сүзләренә колак салып, аларның да фикере белән исәпләшеп эшләгәч, үзеңә дә җиңел, эш тә җайлы бара.

Зоотехник Әгъзам Гобәйдуллин, ветврач Петр Кочугин, агроном Мәдинә Зарипова кебек үз эшләренә чын күңелдән бирелгән белгечләр рәиснең таянычы була. Алар Хәмит Хәлил улының уң кулы булмасалар, хуҗалыкның 1978 елга кадәр җыелып килгән 11 миллион сум әҗәтен ничекләр түләп бетерер идең? Шуңа күрә ул белгечләрнең берсен дә кешеләр алдында ким-хур итмәде, киресенчә, бәлагә тарыганда, урынсызга гаеп ташлаганда йолып кала белде.

— Сез бүгенге көндә хуҗалык җитәкчесенә иң элек нинди сыйфатлар кирәк дип саныйсыз? Элек планнарны арттырып үтәсәң — шул яраган. Ә үти алмасаң...

— Хәзер дә план, дәүләт заказы дигән нәрсәләрдән котылып булмый. Әмма иң әүвәл кешеләр күңелен күрә белергә кирәк. Алар белән яхшы мөгамәләдә булырга, аларның кайгы-борчуларын, шатлык-куанычларын уртаклашып яши белергә тиешсең. Әлбәттә, үҗәтлек тә кирәк. Хәзер бигрәк тә. Эш — соранып йөрүгә калды. Ишектән кусалар — тәрәзәдән керә бел!

Хәтерлим әле: терлекләргә ашатырга салам да юк вакыт. Киттем Казагыстанга, Кустанай өлкәсенә. 40 градус салкын чор. Йөри торгач, саламы булды, ә вагон бирмиләр. Шуннан соң тугыз адреска тугыз телеграмма җибәрдем. Берсе Мәскәүгә — тимер юл җитәкчелегенә, икенчесе — обкомга, өченчесе — Зеленодолга, горкомга... Озак та үтмәде, 500 вагон бирделәр. Төяделәр. Тагын шулай Краснодар краена баргач та салам бирми озак азапладылар. Барыбер, каерып алып кайттым. Безнең эштә борыныңны күтәреп йөрүдән файда юк. Мин әтинең сүзләрен еш искә төшерәм. «Улым,— диде ул миңа бервакыт,— түрә булдым, дип чабатаңны түргә элмә». Аннары колхоз персидәтеле булып алгач, «Авыр йөк алгансың өстеңә, йөзеңә кызыллык китермә»,— диде.

— Югарырак урынга эшкә китәргә дә җай чыккан чаклар булгандыр?

— Булды. Без башта ук хатыным Клара белән сөйләшеп куйдык: авылдан китмибез. Ун бала арасыннан кем дә булса әти-әнине карарга, аларны киләчәктә шунда җирләргә тиештер бит. Әти белән әни безнең белән яшәделәр. Аларны шушы нигездән соңгы юлга озаттык.

— Тормышта төрлесе була бит. Мондый четерекле эштә гел ярап кына да бетеп булмый. Җитәкчеләрнең кәефенә карап эшләү дә холкыгызга ят шикелле...

— Сиксәненче еллар башында эштән алырга йөрделәр. Ләкин план үтәмәгәнгә яки эш бармаганга түгел — тел тик тормаганга. Шулай да минем гомер юлында гел яхшы кешеләр генә очрап торды. Бу яктан мин үземне бәхетле дип әйтә алам.

* * *

Хәмит Хәлил улы авыл хуҗалыгының бүгенге хәлен, аның эчке мөмкинлекләрен яхшы белә.

— Бүгенгечә караш белән яшәгәндә авылны кризис хәленнән чыгаруга ышану кыен. Крестьянны беркем якламый да, санга да сукмый. Карарлар, законнар күп, әмма берсе-бер үтәлми. Авыл хуҗалыгы,— дип дәвам итә Х. Хәйруллин,— промышленность белән чагыштырганда шундый мескен хәлгә куелган ки, күпме ашлык, ит, сөт сатып, шул акчага бер комбайн да юнәтә алмыйсың. Менә хәзер техника паркын яңартасы бар. Безгә бүгеннән 7 «Дон» комбайны кирәк. Ничек сатып алырга? Литрын 1500 сумга сөт сатыпмы? Хәзер теш пастасы белән сигарет та ул бәя тормый. Техника гына түгел, ашламасы да, төзелеш материалы да кирәк. Гомумән, ашламасыз авыл хуҗалыгын үстерүгә исәп тоту — перспективасыз эш.

Авыл хуҗалыгы промышленность белән бер төрле шартларга куелмый торып, без беркайчан да кризис баткаклыгыннан чыга алмаячакбыз. Колхозыбыз тапшырган сөтенә айлар буена акча ала алмый. Сөтне базарга чыгарып сатаргамы? Ләкин һәркем аны эшли алмый. Тагын бер генә мисал: ит комбинатларына тере мал илтеп тапшырабыз, үз транспортыбыз белән. Суйганнан соң үлчәнгән иткә генә акча түләнә, ә бавыры, аяклары, тиресе, эчәгесе, мае өчен сукыр бер тиен дә эләкми безгә. Менә син ел буена ни газаплар чигеп терлек үстер!

— Ә нигә соң күмәк хуҗалыклар үз продукцияләрен үзләре сата алмый. Мәсәлән, нигә кибет ачып җибәрмәскә? Әйтик, Казанда яки Зеленодолда. Колхоз һәм совхозлар үзләренең сәүдә челтәрен булдырсалар, үз продукцияләрен базарларда, ярминкәләрдә сата алмаслар идемени?

— Әгәр күмәк хуҗалыклар үзләре житештергән әйбернең 50—60 процентын гына да үзләре сата алса, без болай акчага тилмереп яшәмәс тә идек.

Хәзер халык мал-туарны күп асрый. Колхоз капка төбенә кадәр салампечәнен, ашлыгын китереп торгач, ник асрамаска! Тик менә соңгы вакытта халык үз хуҗалыгында житештергән итен-сөтен сата алмый җәфа чигә. Йонны җыймыйлар, тире хәзер беркемгә дә кирәкми. Чит илдән алган белән озак яшәп булмаячак. Дәүләт халыкның үзеннән арткан продукциясен алмагач, авыл кешеләре терлекләрнең баш санын киметергә мәжбүр булачак. Без инде терлекләрнең баш санын саклап калу өчен тырышабыз. Шуннан башка авыл хуҗалыгының киләчәге юк. Булган запас озакка бармас...

Кайбер демократлар авыл хуҗалыгына акча бирүне күпсенәләр. Бер генә илдә дә ул дотациясез яшәми. Хәтта авыл хуҗалыгы алга киткән Америка Кушма Штатларында да, Голландия һәм Канадада да фермерларга дәүләт булыша, дәүләт һәрьяклы ярдәм күрсәтә. Ә без продукция саткан акчабызны да вакытында ала алмыйча интегәбез. Гомер буена чит илдән ашлык алып яшәп булмый.

— Үзебезнеке генә житми бит.

— Алтмышынчы елларга кадәр Советлар Союзы чит илдән ашлык сатып алмаган. Ә без бүгенге көндә бөтен җир шары буйлап теләнеп йөрибез. Авыл хуҗалыгында эш сезонлы. Шуны искә алып, күмәк хуҗалыкларга процентсыз кредитлар бирергә кирәк. Инде процент белән бирелгән очракта да процент суммасын түләүне кичектереп торырга-да була бит лабаса. Мәсәлән, биш-ун елга.

— Әлбәттә, авыл хуҗалыгында эшләрнең барышы барыбызның да тормышкөнкүреше дәрәҗәсенә кагыла. Башка тармакларның үсүе дә шуңа бәйле. Шулай булгач, Рәсәй хөкүмәте моны белә торып, авыл хуҗалыгын таркатуга алып бара. Колхоз һәм совхозларны бетерәләр, чәчү мәйданнары кими, терлекләр саны азая. Шөкер, бездә бу яктан хәлләр күпкә яхшы. Әмма Рәсәй сәясәтенең мондый кыланышы безгә — татарстанлыларга да начар йогынты ясамый калмас.

— Америка Кушма Штатларында крестьянга, фермерларга аеруча зур мәхәббәт белән карыйлар. Алар, халыкның 2-3 процентын гына тәшкил итсәләр дә, илне туйдырып торалар бит. Бездә крестьянга ничектер тәккәберләнеп карау гадәте бар. Америка Президенты Рузвельт авыл хуҗалыгын күтәрүне фермерларга льготалар бирүдән башлаган. Ә фермерлар бөтен илне туйдыра башлагач, илнең бөтен экономикасы үзеннән-үзе алга киткән.

Рәсәй үсеп килүче илләр рәтенә кертелгән. Ә мондый илләргә көнбатыш өченче категориягә кергән әйберләр җибәрә. Гомумән, Рәсәйгә чит илдән кергән ашамлык, эчемлек һәм сигаретларның 80 проценты, сыйфаты буенча, өченче категориягә керә икән. Билгеле, алар Татарстан кибетләрен дә читләтеп үтми.

Юк шул, без үз кадеребезне үзебез белмибез.

* * *

Демократлар югары мөнбәрләр артына басып, кулларын болгый-болгый сөйләп, җирне бик тиз сатып җибәреп, колхоз һәм совхозларны бетереп, балда-майда йөзәрбез, дип никадәр генә шапырынмасыннар, халыкны алай гына алдап булмый. Рәсәйдә беркайчан да җиргә хосусый милек булмаган. Еш кына Столыпин реформасына таянырга, шуны мисал итеп китереп, авыл кешеләрен ышандырырга телиләр демократлар. Янәсе, җиргә хосусый милек кенә безне кризистан чыгара, фермер хуҗалыклары гына Рәсәйне, шул исәптән Татарстанны да менә дигән итеп туйдырып торачак. Әгәр Столыпин реформасының чын асылына төшенсәң, демократлар уйлаганча, җир белән теләсә ничек эш итәргә ярамаганлыгын бик тиз шәйлисең.

Күпне күргән, гомере буена җир белән эш иткән Хәмит Хәйруллин үзенчә фикер йөртә:

— Бездә, чит илләрдән күреп, хосусый милеккә күчү бара. Колхоз һәм совхозларны көчле-көчле берләшмәләргә, коллектив предприятиеләргә, кооперативларга, ширкәтләргә әйләндерәләр. Безнең «Комсомолец» колхозы да хәзер күмәк предприятие дип йөртелә. Җир шул ук, халык шул ук, элеккечә продукция сатабыз. Барыбер акчасын вакытында бирмиләр. Хикмәт исем үзгәртүдәмени?!

Хәзер пай бүлешү китте. Ярый, мин биш гектар җир алдым, ди. Нишлим аның белән? Нәрсә белән эшкәртәм. Техника алырга минем миллионнарча сум акчам бармы? Ярый, техника алуга ирештем ди, минем ике улым бар, без ничек тә җир эшкәртеп, иген үстереп мәш килеп ятарбыз. Ә башкалар? Безнең халык күмәкләшеп эшләргә өйрәнгән инде ул.

— Җиргә хосусый милек кертү безнең законнар белән рәсмиләштерелгән. Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Өстән кушалар икән, борыла да алмыйсың. Авыл хуҗалыгында экспериментлар күп булды...

— Законнарны кешеләр чыгара. Шунсын беләм: чит илләрдә, күбесендә, җир, нигездә, дәүләт кулында. Мәсәлән, Голландиядә, гомумән, җиргә хосусый милек юк. Авыл хуҗалыгы иң алга киткән Израилдә дә җирне дәүләт арендага биреп тора. Кешене милеккә якынайтабыз, дип җирне хосусыйлаштыру нәрсәгә китерер, әйтүе кыен, әмма чит илләрдә авыл хуҗалыгын алып бару тәҗрибәсен үзебезнең шартларны, халыкның гореф-гадәтен санга сукмыйча механик төстә күчереп куярга тырышу яхшыга китермәячәк.

— Ул чакта колхоз һәм совхозлар да, берләшмәләр, күмәк хуҗалыклар, коллектив предприятиеләр дә бетәчәк ич.

— Хәзер колхозларны бетерү өчен бөтенесе эшләнә. Башта техниканы, ашламаларны кыйммәтләндерделәр, аннары, тапшырылган продукциягә акча бирми башладылар. Бик тиз генә фермер хуҗалыклары да төзеп куймакчы идек. Фермер безнең шартларда үзен дә туйдыра алмый. Әгәр колхозчы колхоздан чыгарга теләми икән, нигә аның теләгенә каршы барырга? «Бөек «реформатор» Юрий Черниченко, колхозчының колхоздан чыгып, фермер булып яшәргә теләмәве авыл халкының наданлыгы белән аңлатыла, ди. Менә сиңа кирәк булса! Шуның кебек демократлар колхоз һәм совхозларның моңа кадәр продукция житештерүне арттыра барганлыкларын, шул күмәк хуҗалыклар ашатып-эчертеп торганлыгын таныйрга теләмиләр.

— Чит илләрдә дә хәзер фермер хуҗалыклары берләшәләр.

— Шулай. Хәзер ялгыз гына яшәп булмый. Крестьян эшенә тупас тыкшынырга ярамый. Аны ничек эшләргә, ни чәчәргә, күпме чәчәргә өйрәтәсе юк. Мин үз тәҗрибәмнән беләм. Без 1994 елда барлык төр терлекчелек продуктлары, ашлык сату буенча дәүләт заказларын үтәдек. Мал-туарның баш санын киметмәдек. Халыкка теләгән кадәр салам, печән, ашлык бирдек. Йортлар салуда булышабыз. Күпләр транспорттан бушлай файдаланалар. Авыл йортларына газ керттек. Колхоз исәбенә. Бу эш һаман дәвам итә. Юллар салдык. Тормыш, заман авыр булса да халык зарланмый. Акчасын вакытында, айныкын айга биреп барырга тырышабыз. Шулай булгач, күмәк хуҗалыклар кемгә тия, кемгә комачаулый? Минемчә, югары табышлы колхоз һәм совхозларны сакларга кирәк. Крестьянның ризалыгыннан башка хуҗалыкны үзгәртеп корырга маташу закон белән тыелырга тиеш.

Колхозчылар, күмәк хуҗалыкларны бетерик тә фермер хуҗалыклары төзик, дип алдын-артын уйламыйча кампания җәелеп киткән бер заманда җыелышка җыелалар. Колхоз рәисе Хәмит Хәйруллин барысын да аңлатып бирә. Ник бер генә колхозчы колхоздан аерылып чыгып, үзе җир алып, фермер хуҗалыгы төзергә риза булсын. «Гомер буена бергә эшләдек, шулай эшлик, колхоз яшәсә, без дә яшәрбез»,— диләр алар җыелышта.

Яшиләр. Авылда тормыш сикәлтәле юллардан барса да, хезмәт кешесенең башы нужадан чыкмаса да, ул өметен өзми, күнел төшенкелегенә бирелми. Чөнки аның авыр чакларда да хәленә керә белә торган, һәрчак ярдәм кулы сузарга әзер торган Хәмит Хәйруллин кебек җитәкчеләре бар.

* * *

— Мин күп нәрсәгә әтидән өйрәндем. Әле дә хәтердә. Яшьрәк вакыт. Йоклап киткәнмендер инде. Әти уята: «Тор, улым, безнең заманда калхуз персидәтелләре болай озак йоклап ятмыйларые, тор!» — ди. Әтинең сүзе закон. Вахитов исемендәге колхозда эшләгән чаклар да искә төшептөшеп куя. Анда бик иртә тора халык. Иң элек хуҗалык җитәкчесен күрергә тиеш колхозчы. Шулай булмаганда сиңа ышаныч та шуның кадәр генә була. Эшең барса, тыныч кайтып йоклыйсың. Шулай итеп, әти мине тәртипкә, төгәллеккә өйрәтте.

Еллар уза, гомер уза. Инде, ходай исәнлек биреп, тагын да матуррак яшәргә, илгә, җиргә бәла-каза килмичә, тыныч кына хезмәт итәргә язсын. Бу җир йөзендә

хужалык җитәкчесе булып эшләүдән дә авыр вазифа бар микән. Ал юк, ял юк, көнне төнгә ялгап, һаман эштә алар.

— Иң ачуны китергәне шул: күмәк хуҗалыкларны сүз белән, аннары техникага, ашламаларга, төзү материалларына бәяләрне кыйммәтләндереп тарата алмагач,— ди Х. Хәйруллин — налог салып таларга керештеләр. Белмим, мондый хәл кая алып барыр. Ләкин әлегә күмәк хуҗалыкларның экономикасы ныгуга бернинди өмет юк. Хуҗалык никадәр күбрәк продукция сатса, шулкадәр күбрәк налог түли. Үз колхозчыларына никадәр күп хезмәт хакы бирсә, аңа шулкадәр күп салым салалар. Без 1994 елның 1 нче яртысында гына да 38 миллион сумнан артык налог түләдек. Ә моңа әле керем налогы керми. Без налог түләргә һич тә каршы түгел. Әмма һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш. Ни өчен әле колхоз ай саен эш белән тәэмин итү фондына акча түләп барырга тиеш! Авылда эшсезлек көтеләмени? Мин алай булыр дип уйламыйм. Яки менә янгын фондына түлә. Анысы елга бер тапкыр булса да берәгәйле. 6 миллионнан артык! Нинди дер фәнни-тикшеренү эшләре өчен дә налог түләп барабыз. Вакытында түләмәсәң, штраф салу белән яныйлар. Моннан тыш башка чыгымнар да муеннан. Миллионнар ага гына. Ел саен саткан сөт акчасының кимендә 10 проценты электр энергиясенә түләргә китә. Кредит, ссудалар зур процентлар белән бирелә. Ә кредитсыз яшәп булмый. Эш шуңа барып җитте, кадрлар әзерләү өчен дә колхоз янчыгыннан акча каералар.

Менә шулай яши, эшли бүген авыл. Кайберәүләр авылда тормыш җиңел, халык яхшы яши, барысы да үзенеке, диләр. Анысы шулай. Ә моның өчен күпме хезмәт куелганын авыл кешесе үзе генә белә.

— Авыл ничек тә түзәр дә, яшәр дә. Крестьянның бәрәңге бакчасы, малтуары бар. Ә менә шәһәр халкы авылдан башка ничек яшәр икән? Нигә без шуны онытабыз? Без — игенчеләр. Шулай икән, без иген үстерергә, терлек үрчетергә тиеш. Чит илләрдә булып кайтучылар фермер хуҗалыкларын бик тә мактыйлар мактавын. Ләкин алар безнең кебек газ кертеп тә, юл салып та, клуб төзеп тә йөрми. Йә иген үстерә, йә терлек асрый. Юк, авыл кешесенең хәленә керә белү җитми бездә.

Мин үзем фермер хуҗалыгы булдыруга каршы түгел. Тик кайберәүләр, фермер буласы кешегә җир бирдең дә шул җиткән, дип бик җиңел уйлый. Билгеле, элегрәк техника алып калганы эшләп китәр. Продукциясен дә күп бирер. Бүгенге фермер хәзерге бәяләр белән техника сатып ала алыр микән? Ярар, колхозларны тараттык, ди. Хезмәт ветераннарына, пенсионерларга кем ярдәм кулын суза? Колхоз булышмаса, кайсы крестьян бу кыйммәтчелек заманында үзенә йорт салып чыга ала? Бәлки кайбер партияләр авыл кешесенең мәнфәгатен кайгыртыр? Белмим, әле берсенең дә авыл хуҗалыгына таба йөз белән борылганы юк.

— Базар мөнәсәбәтләре ныгыгач, үз продукциягезгә үзегез хуҗа булырсыз, дип беләм.

— Әйткәнемчә, иң элек товар җитештерүчеләр белән аны эшкәртүчеләр арасындагы гаделсезлекне бетерергә кирәк. Авылны бик нык кимсетәләр. Шәһәрдә әнә бездән сорап тормыйлар, арзанга алалар да күпме кирәк бәяне күтәрәләр. Ленинград блокадасы вакытында да ипигә бәяне арттырмаганнар. Сөтне карагыз. Без бер бәягә сатабыз, кибеткә килеп җиткәнче ике тапкыр чамасы арткан була. Эш шунда: реформа акрын бара. Патша министры Столыпин дәүләтнең арыклана барган, сула барган иң йомшак агы — крестьян, аңа ярдәм кирәк, дигән.

— Җиргә дәүләт биргән ашламаны кертәсез бит, ягулыкны да бирер торалар, юк дисәң дә, азмы-күпме техникасы кайта.

— Дөрес, Татарстан хөкүмәте ашламаның бер өлешен үз исәбеннән каплый. Анысы әйбәт. Әле ягулыкка да түзәрлек. Ә менә техника белән эшләр чыннан да хөрти. Быел чәчтек, урып та җыйдык. Киләсе елда да техниканың булган кадәресен ямап, төзәтеп эшләрсең. Аннан соң? Хуҗалыкларның техника паркы бик искергән.

* * *

Теләсә кайсы башлыкның кәефе, күңел көрлеге, эшкә мөнәсәбәте күп яктан аның шоферына бәйле. Шофер халкы җитәкченең кая һәм ничек басканына, ничек сулаганына кадәр белеп тора. Юкка гына мыни, юлга чыксаң, юлдашың үзеңнән яхшы булсын, диләр. Хәмит шоферыннан бик уңды. Икесе дә фамилиядәшләр. Равил 25 ел буена гел аның белән янәшә. Ике Хәйрул-

лин чирек гасыр эчендә бергә-бергә никадәр юл кичкәннәрдер, күпме төннәрне кырда бергә үткәргәннәрдер.

— Шоферлар барысы да бер калыптандыр инде,— дип сорыйм Хәмит Хәлил улыннан.

— Алай түгел. Равил тәртипле, карусыз. Безнең эштә вакыт белән исәпләшү юк. Хуҗалык җитәкчесен йөрткән шоферга ял бик эләкми. Һәркемнен гаиләсе, тормышы бар. Бу яктан да килешеп, аңлашып эшлибез. Кирәк чакта аңа ял биреп, мин үзем дә машинаны йөртәм.

— Шоферлар күп белүчән була, ә башлыклар киләләр дә китәләр.

— Минем Равилдән яшерен эшем юк. Иң мөһиме — намусың саф булсын. Без аның белән бер гаилә кебек яшибез. Татулык, бер-береңә ихтирам, ярдәмләшү, бер-береңнең хәленә керә белү — шуңа ни җитә?!

Шулай сөйләшеп утырганда сүз иярә сүз чыгып, Хәмит элек бергә эшләгән кешеләрне искә төшереп узды. Гадәттә, җитәкчеләр бергә яшәп, бергә эшләп ялга киткән ветераннарны онытып җибәрүчән. Гомумән, бу — безнең җәмгыятебезнең бер чире. Әмма Хәмит Хәйруллин элекке дусларын, хезмәттәшләрен онытмый. Яхшылык җирдә ятмаска тиеш.

Җитмештән узган хезмәт ветераны Рәшит Хәсәнов сөйли:

— Без Хәмит Хәлилович белән гомер буе бергә эшләдек. Пенсиягә чыккач, монда авыл җирендә яшәү кыен булыр, Зеленодолга күчик мәллә, дип уйлашкан идек хатын белән. Шуны Хәмит белән киңәшкән идем. «Китмә, Рәшит абый, бергә-бергә яшәрбез»,— дигәч, күңел нечкәреп китте дә калдык шушында. Хәйран гына яшәп ятабыз. Рәхмәт аңа, гел ярдәм итеп, булышып тора. Нинди генә йомыш белән барма, бервакытта да «булмый, юк» дигән сүзен ишетмәссең. Аннары, Хәмит кешенең яхшылыгын онытмый. Үч саклый белми.

Күмәк хуҗалык рәисенең эш вакыты күпмегә сузыладыр, әлегә моны төгәл генә исәпләгән кеше юк. Шулай да якынча ул тәүлеккә 15 сәгатьтән дә ким эшләми. Бер дә хәрбиләрдән ким түгел. Аерма шунда: хәрбиләр 25 елдан пенсиягә чыга. Хуҗалык җитәкчесе ел тәүлегенә, айлык отпускасыннан башка, ялсыз эшли. Ә ир-атка алтмышын тутырмый пенсия бирмиләр. Менә нинди гаделсезлек!

* * *

Хәмит Хәйруллин узган ел 50 яшен тутырды. Шушы гомеренең яртысына якыны күмәк хуҗалык белән җитәкчелек итүгә бирелгән. Ләкин рәис замана авырлыкларына карап күңелен төшерми. Колхозчылар да үз итәләр, якын күрәләр, хөрмәт итәләр. Хәмит Хәйруллин кебек асыл ирләр булган җирдә эш тә гөрләп бара. Аның колхозына сукмак өзелеп тормый. Монда өйрәнергә, киңәш сорарга, тәҗрибә алырга киләләр. Яшьрәк җитәкчеләр аннан ярдәм сорар, өлкәнрәкләре аның белән киңәш-табыш итәр. Хәлил улы Хәмитнең һәркайсы белән уртаклашыр эше бар. Хәзинәдә бары. Үзе зур планнар, якты хыяллар белән яши. Күңеле — гаделлектә, яхшылыкта. Бирсен ходай!

**Мөнир АБДУЛЛИН.**

# ҖӘЛИЛЧЕ АБЫЕМ ТУРЫНДА

Рушад абыем Хисаметдиновка Ходай Тәгалә юкка гына озын гомер юлламагандыр. Фашист коллыгыннан котылып, Ватанга исән-имин әйләнеп кайту, җәлилчеләр хакында үз халкыбызга житкерү нәкъ мәнә аңа язган икән.

Муса Җәлил үзенең «Моабит дәфтәре»ндә Рушад абыйны иң якын иптәшләреннән берсе — көрәштәше дип атый. Татар зыялыларыннан торган бу яшерен оешма, уникe мең әсирнең рухын күтәреп, коралны дошманга каршы бору юлларын күрсәтә. Бу — искиткеч җиңү, сугыш тарихында кабатланмас мисалдыр.

Кылган эшләренең бәясен җәлилчеләр яхшы беләләр, илгә йөз аклыгы белән кайту турында хыялланалар. Рушад абый еш кына яратып көйли торган җырда мондый юллар бар:

> Оркестрлар уйнар җиңү маршын,
> Йөрәкләрдә шатлык дулкыны.
> Безгә карап дуслар сокланырлар,
> Безне мактап, балкыр таң нуры!

Әмма илдә аларны бәхет көтеп тормый шул. Рушад абый өчен дә моңа кадәр күрелмәгән газаплар башлана. Совет суды аны атарга хөкем итә, аннан бу рәхимсез карар 25 еллык каторгага белән алмаштырыла. Күпмедер еллардан соң Гази Кашшафка КГБ генералы болай ди: «Легионның яшерен эше хакында сөйләүче бердәнбер Хисаметдинов булды. Шуңа күрә җәзасын да алды...»

Совет концлагерьларыннан котылып чыккач, Рушад абый җәлилчеләрнең көрәше турында төрле аудиторияләрдә чыгышлар ясады. Аның хәтере бик шәп, мавыктыргыч итеп сөйли белә иде. Тормышта шактый гаделсезлекләр күргән кеше буларак, ул инде күп нәрсәдән өметен өзгән иде, хәтта реабилитация артыннан да йөрмәде. Хәтерлим әле: миңа, Татарстан китап нәшриятының редакторы буларак, И. Зәбировның «Җәлил һәм җәлилчеләр» исемле китабын редакцияләргә туры килде. Кульязмада Рушад Хисаметдинов шәхесенә карата да хәтсез урын бирелгән иде. Бервакыт мине директор кабинетына чакырталар. Анда «Черек күл» кешесе утыра. «Без Хисаметдиновны җәлилче дип санамыйбыз!» — ди бу. «Ничек алай?!» — Ачудан минем тыным кысылды. «Хисаметдиновның туганы була ул,— ди нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдинов.— Кирәк тапсагыз, икенче редакторга алыштырабыз». КГБ кешесе ашыгып: «Юк, юк, кирәкми. Хисаметдинов турында язылганнарны гына кыскартсын»,— диде. Бәхеткә, минем эшемне кем дә күзәтеп тормады, кульязмада абыем хакындагы бер генә сүзгә дә тимәдем.

Нинди генә авырлыкларга тарымасын, Рушад Хисаметдинов көчле шәхес булып калды. Күтәренке рухлы, тормышның тәмен белеп, кызык таба белүчән, бәлагә юлыкканнарга һәрчак ярдәмчел иде ул. Рушад абыем 1992 елның 27 августында дөнья куйды. Ул үзенең күргән-белгәннәрен кәгазьгә төшереп калдырмаган. Бәхеткә, халкыбызның атаклы рәссамы, скульпторы Бакый ага Урманче белән әңгәмәләре магнитофон тасмасында сакланып калган. Бу ике шәхес — күптәнге дуслар иде. Икесе дә язмышның ачысын-төчесен нык татыганнар, тоткынлыкның тән һәм җан җәрәхәтен кичергәннәр, шуңа күрә ярты сүздән аңлашып, бер-берсенә тартылалар иде.

Бу язманы Бакый ага Урманченең хатыны, аркадашы Флора ханым Әхмәтова кадерләп саклаган. Моның өчен аңа без мең-мең рәхмәтлебез. Тасмадагы язмаларны, табигый сөйләшү рәвешендә сакларга тырышып, укучыларга тәкъдим итәбез.

Азалия БАДЮГИНА.
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



## Рушад Хисаметдинов

# ДУСЛАРЫМНЫҢ ВАСЫЯТЕН ҮТӘДЕМ

**1976 ЕЛ, 28 ФЕВРАЛЬ.** Казанга килеп, Муса Җәлилнең 70 еллык юбилеенда булу — минем өчен зур шатлык. Тагы бер шатлыгым — Бакый ага Урманче белән танышуым. Ишетеп кенә белә идем Мусаның бюстларын ясавын һәм безнең татар халкының күренекле таланты икәнен. Менә хәзер аларның өйләрендә бер өстәл янында утырабыз. Якын күргән дустым Мостафа Ногман да биредә. Ул да күренекле шагыйрьләрдән, аның шигырьләренә язылган җырларны сокланып җырлыйбыз.

Мин бик күп дусларымны югалттым — Муса Җәлил белән бергә көрәшеп йөргән егетләрне әйтәм. Хәзер инде, илемә кайтып, Мусаны белгән, аны яраткан дусларын таптым. Һәм алар минем дусларым булдылар — Муса белән кайчандыр таныш булган Бакый абыйны, Алма-Атадагы профессор Латыйф ага Хәмидине күздә тотам. Мостафа, Муса белән якынлыгы булмаса да, матур итеп язган шигырьләре белән аны күз алдыма китерә.

...Төрмәдә утырган чакта Муса бигрәк тә күчле шигырьләр, җырлар язды. Аның кайбер шигырьләрен Гайнан Кормашевныкы дип әйтүчеләр бар. Ярый әле соңыннан Казандагы белгечләр таныдылар. Шул ук «Вислага» дигән шигырен Мусаныкы дисәм, Солтанбәков: «Юк, ул Гайнанныкы», — ди. Мусаның тагы «Төрмәдә» дигән шигыре бар. Миңа бик ошый ул. Аны да Солтанбәков, Гайнан Кормашевныкы, дигән иде. Юк! Ул шигырьне Муса сеңелләренә багышлап язган. Мин аны Тегель төрмәсендә утырганда алдым. Мусаның үз кулы белән язылган иде. Менә ул шигырь:

Төн. Төрмә. Тирән тынлык.
Бер тавыш юк төрмә эчендә.
Тик тыштагы төнге часовойның
Аяк тавышы гына ишетелә.
    Йокы килми, төрле уйлар килә,
    Әнә анам, бала, сеңелләр.
    Ә иркәмнең соңгы язган хатын
    Тагы бер кат укыйм күңелдән.
Хатларыңны алдым, җаным, рәхмәт сиңа —
Онытмыйсың әле иркәңне.
Өзлеп сагынам сине, өзлеп-өзлеп,
Кавышыр көннәр тагы җитәрме?
    Мин шатланып сиңа кайтыр идем,
    Иркем булса иде кулымда.
    Булса иде билдә үткен кылыч
    Һәм алсу таң барыр юлымда.
Ачы тормыш җиле кире исте,
Кылыч та юк миндә, мылтык та.
Ә йөрәгем әле һаман тибә —
Ишет аны төнге тынлыкта.
    Төн. Төрмә. Тирән тынлык.
    Бер тавыш юк бүлмә эчендә.
    Тик тыштагы төнге часовойның
    Аяк тавышы гына ишетелә...

Мусаның бу шигырен мин шушы көнгә хәтле дулкынланып укыйм. Миңа аны реабилитировать итәргә туры килде бит! Солтанбәков, Гайнан Кормашевныкы дип, Шәйхи Маннурга һәм башкаларга сөйләгән. Шуннан соң бу шигырьне, Җәлилнеке түгел, дип әйтә башладылар. Ләкин Гази Кашшаф белән Әминә ханым башка фикердә булдылар. Германиядән кайткач та, мин Әминә ханымны Мәскәүдә табып, аңа укыган идем. «Бу — Мусаныкы, аның язу стиле»,— дип җылап җибәрде Әминә ханым. Гази Кашшафка да язып салдым: «Гайнан Кормашев, мин әйтәм, якын дустым иде, минем исән калуыма сәбәпче — ул. Аның да матур шигырьләре бар («Данияма» дигәне, мәсәлән). Төрмә шигырендә бит: «Әнә анам, бала...» — дигән сүзләр бар, ә Гайнан — өйләнмәгән яшь егет. Шулай булгач, болай язуы мөмкин түгел. Гайнан Кормашевның стиле дә башкачарак бит. Ахыр чиктә, бу шигырь икенче басмага кергән, дип әйтәләр. Тәрҗемәсе дә бар икән инде. «Стихотворение «Ночь. Тюрьма» принадлежит перу Мусы Джалиля»,— дип язып та чыкканнар.

Арабызда күбесе шагыйрьләр иде. Муса Җәлил белән Абдулла Алишны әйтәсе дә юк инде. Кормашның матур гына шигырьләре бар, ләкин ул Мусаның шәкерте шикеллерәк иде. Башкалары да язып маташтылар. Мин үзем гомеремдә бер шигырь дә язмадым.

Бер көнне Муса белән сөйләшеп тора идек (Гайнан да шунда). Мин әйтәм: «Бөтен дусларым — шагыйрьләр. Алма-Атада улым калды бит. Шуңа багышлап бер шигырь дә язып бирә алмыйсыз»,— дим. «Тукта әле, тукта,— ди Муса,— сөйлә әле, сугышка кайсы җирдән киттен син?» Мин әйтәм: «Алма-Атадан киттем». «Нинди җирләрдә тордың?» Ә үзе каләм, кәгазен алды, нәрсәдер яза да башлады. Мин аңа Казагыстанның матур табигатен, киң җәйләүләрен, алма бакчаларын мактыйм. «Кичләрен, мин әйтәм, Таифә белән, улыбызны алып, өчәү шул бакчаларда рәхәт чигеп йөргән матур көннәребез бар иде. Менә хәзер инде шул чаклар төшләремә керсә икән, дип йөрим». Мин сөйләп тә өлгермәдем, Муса миңа шигырь суза: «Урман кызы» көенә җырларсың, ди. Шул арада язып та өлгергән!

Җыерчыклар кереп, чал керсә дә,
Мактанырлык минем юлым бар —
Биек күксел тауның итәгендә
Арысландай минем улым бар!
　　Бөтен дөньяларны шаулатырлык
　　Галим булыр, бәлки, ул бала.
　　Гасырларның исен китәрерлек
　　Шагыйрь булыр, бәлки, ул бала.
Бик күп еллар узды мин киткәнгә,
Бик күп сулар акты тугайда.
Улым, Равил, сагынамын сине
Их, күрәсе килә шулай да!
　　Алсу таңда, биек күксел тауда,
　　Гөл бакчаның җәйге кичендә,
　　Өчәүләшеп йөргән чакларыбыз
　　Кайчак керә ярсып төшемә.

* * *

Шагыйрь булуыннан файдаланып, фашистлар Муса Җәлилдән коммунистларга каршы берәр әсәр яздырмакчылар иде. Язам, дип йөрде дә, «Шүрәле» либреттосын иҗат итте. Ләкин ул коммунистларга каршы түгел, киресенчә, фашистларның безнең илгә һөҗүм итүләрен чагылдыра иде.

Әсәр баштагы күренешләре белән матур тәэсир уята. Авыл халкы, яшьләр печән чабалар, хозурлык, шаян җырлар, такмаклар, уен-көлке, биюләр кыза бара — әнә шулай шау-гөр килеп йөргән вакытта кинәт кара болытлар куера, күк күкри, яшен яшьни — яр астыннан бер җанвар килеп чыга. Аны күрүгә, халык, егетләр-кызлар артка чигенә башлый. Әлеге җанвар, сикерә-сикерә (аны Гәрәф Фәхретдинов уйнады), койрыгын болгый-болгый, кешеләргә таба бара. Үзара такмаклар әйтелә. Шуннан соң, егетләр, кызлар, картлар, яшьләр бергә кушылып, сәнәге-ураклар, балта-көрәкләрен күтәреп, шүрәле-җанвар өстенә киләләр. Төрле җырлар бер туктамый яңгырап тора — опереттадагы шикелле. Шүрәле артка чигенеп, ярдан төшеп китә. Шуннан болытлар тарала, кояш чыга, янадан матур күренешләр ачыла...

* * *

Безнең арада рәссамнар да бар иде. Сезнең белән танышканда, Бакый ага, күз алдыма шул яшерен оешмадагы егетләр килде. Берсе — Хәмиев дигән Башкортстан татары, капеллада ике рәтле гармунда уйный, үзе бик талантлы художник та иде.

Бер көнне Муса капеллага килде (ул еш кына шулай килеп йөри иде). Шәфи Алмаз аның үзен генә калдырмый, күләгә кебек ияреп йөри. Кайчакта аларга Гариф Солтанов тагылган була. Шәфи Алмазны (ул эчәргә ярата иде) эчереп, йоклатырга тырышабыз. Шул арада үзебезгә кирәкне сөйләшеп ала идек.

Китәр алдыннан, ашыгып кына, Муса миннән: «Рушад, сезнең арада рәссам юкмы?» — дип сорады. Мин әйтәм: «Бар». «Әйт әле, матур итеп татар кызын, авыл кызын ясасын». Андый рәсемнең нәрсәгә кирәген дә әйтмәде. Мин дә әллә ни әһәмият бирмәдем моңа. «Тизләтсен, тизләтсен аны»,— диде дә китте. Шуннан Хәмиевне чакырып алдым да: «Слушай, Хәмиев, син художник бит, бирәр татар кызы сурәтен зу-ур итеп яса әле. Авыл күренеше дә булсын. Буяу, башка кирәк-яраклары бар»,— дим. «Рушад абый, мулланың ярдәмчесе Шамбазов та художник бит,— ди бу. (Бар иде мулланың шундый мәәзин шикеллерәк кешесе. Тагы Сабирҗан дигәне бар иде — фамилиясен хәтерләмим инде.) Шунын белән бергәләп эшләсәк, тизрәк булыр иде. Ул да бик матур ясый»,— ди.

Ун көн дә узмады, сурәт әзер булды, диярлек. Шуннан сорыйлар болар миннән, кызның аягына чабатамы, әллә туфли киертергәме.

Аптырап калдым. «Ярый,— мин әйтәм,— аягын ясамый торыгыз, аягына нәрсә кидерергә икәнен, мин сезгә соңрак әйтермен». Муса килгәч: «Беттеме, беттеме?» — ди. Мин әйтәм: «Аягына нәрсә киертәбез, дип сорыйлар». «Аягына бик матур итеп... (хәзер нәрсә кияләр соң?) туфли булсын. Чабата кирәк түгел»,— диде Муса.

Эшләнеп бетте рәсем. Муса аны легионерлар киләп-сарып йөри торган җиргә, иң күренекле урынга куярга кушты. Куйдык. 10—15 адым ераклыктан караганда, шундый гүзәл татар кызы балкып тора! Күзләре, керфекләре, кашлары дисеңме, башындагы яулыгы, күлмәге дисеңме! Карап торам мин монарга, күңелдә әллә нинди хисләр туа — Алма-Ата исемә төште, сеңелләрем. ...Шулчак искәрәм: янәшәмдә берничә легионер — кульяулык йомарлап, елап торалар. Яшереп кенә күзләрен сөртәләр. Шул көннән бирле сурәт алдыннан кеше өзелмәде. Һәркем үзенә нинди дер бер юаныч таба, күрәсең. Авылларын, сөйгән кызларын, аналарын күз алдына китерәләрдер. Бу — үзе бер психологик тәэсир иде. Менә нәрсәдә икән хикмәт! Аңладым мин Мусаның хәйләсен — сәнгать аша кешегә йогынты ясарга тырышуын. Илгә кайту теләген көчәйтергә теләгәнен...

* * *

Француз партизаннары арасында йөргәндә, француз җырларын өйрәндек. Мин татар җырларын өйрәтә идем аларга. Рота командиры мсье Жорж Мусаның «Сагыну»ын шундый яратып җырлый иде! (Ул безне рус дип белә иде. Татарны анда «тартар» диләр.) Сезнең көйләр нинди, дигәч, мин аңа «Сагыну»ны җырлап бирдем:

> Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
> Юлларыңа тезәм мин...

Француз белән җырлап йөрдек бергәләп.

Бер французда «Монлюк төрмәсе» дигән значок күрәм. «Кес кесе сө?» «Бу — нәрсә?» — дип сорыйм тегеннән. «О,— ди бу,— Леон төрмәсе «Монлюк»та утырган сәяси тоткыннарга, Макизарларга бирелә торган хөрмәт билгесе ул». (Партизаннар — бик хөрмәтле кешеләр анда). «О, мин дә утырдым бит анда!» — дим. «Алайса, архивына барып, сезнең делоны эзләтергә ки-



**Рәсемдә:** Р. Хисаметдинов (1941 ел, август)

рәк,— ди.— Чит ил кешесе буларак, Сезгә бигрәк тә зур ихтирам булачак»,— ди. Бардым Леонга. Кай вакытта утырганымны әйттем. Архивны немецлар алып китәргә өлгермәгәннәр икән, кәгазьләрне тиз таптылар. Мине «Ассоциация узников»ка хөрмәтле әгъза итеп алдылар. Значогын да, документын да бирделәр, бик матур гына итеп. Президентлары кул куйган анда. Шул значоктан файдаланып, мин бөтен Францияне йөреп чыктым! Парижга да, Марсельга да бардым, Леон белән Ле-Пюи да калмады...

* * *

Татарларның дүртенче актык батальоны шул Ле-Пюида иде. Легионерлары француз партизаннарына төркем-төркем качып беткәннәр. Анда немецлардан берничә кеше генә калган. Шунда Гарәф Фәхретдинов татар егетләре — партизаннар белән килеп, шул немецларны, легион командирлары белән следовательләрен тотып, судка бирәләр.

Сугыш беткәч, Садыйков белән (өлкән лейтенант, яшерен оешмага катнашкан башкорт егете иде ул), без Ле-Пюига бардык. Анда Муса Җәлилне искә алу, банкет шикелле бер нәрсә булды. Татар, башкорт егетләре — бик күпләрендә французларның I, II дәрәҗә «Мария-мадонна» орденнары, зур бүләк алганнары да бар иде арада...

**1988 ел, 4 март.**

**Р. Хисаметдинов.** Кәрим Ходжаев дигән дустымның язмышы бик кызганыч. Хрущев заманында, 1962 елда, гомуми амнистия булды бит әле. Со снятием судимости. Ни дигән сүз инде бу? Димәк, Конституция буенча, ул совет гражданына бирелгән бөтен хокуклардан файдалана ала. Ә Кәрим файдалана алмый. Бу кеше мораль яктан бетерелгән була бит инде? Моны һаман саен «пленный» да «пленный» дип рәнҗеткәннәр. Балаларына да көн күрсәтмәгәннәр. Оныкларына хәтле — 10 нчы класста укып йөриләр икән — кыерсытканнар.

Кердем сельсоветына, бөтенесен сөйләп бирдем. Анда бер татар хатыны утыра иде. «Белмәдек бит, абый,— ди.— Үзе бигрәкләр дә юаш инде, бер нәрсә әйткәне юк үзе турында»,— ди. Мин әйтәм: «Ходжаев — Муса Җәлилнең яраткан бер иптәше иде. Капеллада скрипкада уйный иде ул. Иң ышанычлы егетләрнең берсе иде. Легионга ант биреп кермәде, хозротада иде. Франциягә баргач, француз партизаннары ягына качты. Францияне немецлардан азат итүдә күп хезмәт күрсәтте». Мин үзем белән шактый күп фотоматериаллар алып кайткан идем. Берсендә без парад вакытында сафта китеп барабыз. Америка, инглиз полковниклары карап торалар, француз оркестры уйный. Шул рәсемнәрне күрсәтеп: «Әнә, мин әйтәм, Ходжаев алда бара». Бер Абдулла дигән егетебез немецлар чигенгән вакытта һәлак булды. Шуны әтәчләр куелган француз катафалкына салып, күмәргә алып барган рәсемебез бар. Монда да Ходжаев басып тора, мин дә кырыйда! Шуларны күреп, сельсовет апасы: «Белмәдек бит, белмәдек! Ун ел буена бер нәрсә сөйләгәне булмады»,— дип өзгәләнде.

Мәктәбенә бардым, директорына. Балаларны җыеп зур очрашу уздырдык. Кәрим исемле малаен гел үземнән калдырмадым.

Кәрим Ходжаев үзе авырып, больницага кергән иде.

КГБга барып чыктым. Аны бит нәрсәдәдер гаепләгәннәр, шаһит буларак, нәрсәләрдер сораганнар. Мин әйтәм: «Не беспокойте его пока, он болен. Лучше помогите, чтобы, как участнику войны, в отдельную палату поместили. А я, пожалуйста, отвечу на все ваши вопросы. Багаутдинов кызыксындырамы?». Бар иде андый кеше. Булмаганны булды, дип әйтә алмыйсың бит? Мондый сорау алуларны күп кичердем. Мин бөтен кешене дә белә алмыйм, әлбәттә. Бәлки башка группаларда булгандыр — Гайнан төркемендә, йә Әмировта. Сәйфелмөлековның үз төркеме бар иде. Оешма зур иде, күп тармаклы. Барысын Муса да белмәгәндер — җитәкчеләрен генә. Менә шундый конспиратив булганга күрә оешманың эше дә нәтиҗәле булды. 4-нче батальон тулысы белән французлар ягына чыга. Кәрим дә шулар арасында...

Әстерхан ягындагы татарлар үзләрен «нугай» дип йөртәләр икән һәм шуның белән бик горурланалар. «Алайса, мин — Себер нугае»,— дим тегеләргә.

**Б. Урманче.** «Нугай» — ул «татар» дигән сүзнең синонимы.

**Р. Хисаметдинов.** Шулайдыр, ләкин телләрдә бераз аермалык бар...

* * *

**1988 ел, 24 март.**

**Р. Хисаметдинов.** Казан тарихының сигез вариантын язып чыкканнар. Берсе әйтә: Хәсән исемле кеше килгән дә шуның исеме калган, имеш...

**Б. Урманче.** Юк, бу бик гади мәсьәлә. Халык белми, аңлатырга кирәк аны. «Ан» — елга дигән сүз. Мәсәлән, Чирмешән — чирмеш елгасы, Чулман — Чулым елгасы. Себердә дә күп елга атамалары «ан»га бетә. Казан — каз елгасы дигән сүз. Монда казлар күп булган, күрәсең, татар казны ярата бит...

**Р. Хисаметдинов.** Безнең бабаларыбыз болгар булгандыр инде, ә рус тарихчылары безне һаман монголлаштырырга тырышалар. Максатлары — болгарлардан ераклаштыру, күрәсең.

**Б. Урманче.** Анда да ялгышлар бик күп. Без болгар түгел, Болгар илендә яшәүчеләр генә. Болгар — ул шәһәр исеме, өлкә исеме, ләкин халык исеме түгел. Гарәпләрдә шулай язылган. Алар бик яхшы тарихчы бит. Моны бик ачык язып калдырганнар. Болгар — ил исеме, ә халкы — төрекләр, татарлар инде. Аның белән безнең башны әйләндерәләр — берәр төрле файда чыкмасмы, дип. Мин таптым моның хикмәтен. Русның башында да, йөрәгендә дә, җанында да «татар» дигән исем. «Татар» дигән исем зыя. Себер татарларында да, Кырым татарларында да, Кавказ татарларында да зыя. Зур милләт. Бетми, һаман яши. Аны ничек тә ваклап бетерергә кирәк. Себер татарлары — сезнең татар түгел ул, алар фәлән дә төгән, дип. Безнең халыкны да кайбер галимнәр котырталар: «Сез — татар түгел, сез — болгарлар! «Татар» — яман исем ул!— дип. Ә безнең халык бер дә яман түгел. Руслар тырышалар ничек тә татар исемен кимсетергә, төшерергә. «Кем соң сез?— диләр.— Менә бит, болгарлар сез». Ә болгар икән, ул кечкенә генә булып кала. Менә Идел янында Болгар дигән шәһәр булган, шунда болгар дигән халык торган. Кечкенә генә халык. Аңардан куркырга да кирәкми, тарих өчен дә әһәмияте юк. Ә «татар» дигән сүзне бөтен дөнья белә бит аны! Яхшы, болгар булып киттек, ди инде без. Хәзер әйтә башлыйлар: «Болгар соң ул төрек булганмы, әллә славянмы? Болгарлар культуралы булганнар, төрек түгелдер алар, славяннардыр». Ә тарихта андый фикерләр бар. Шуннан, бара торгач, безгә әйтәләр инде: «Сез бит татар түгел икән, сез — славяннар!» Бераздан әйтәчәкләр: «Сез бит славян булгач, сез — руслар! Сезгә русча сөйләшергә кирәк». Менә шулай итеп, безне рус итәр өчен баскычлар ясыйлар. Без, татарлар, шундый инде — мода ярата торган халык. Бик тиз үзгәреп, җилякланып китә кай вакыт. Шуңа күрә, әйдә, болгар булыйк әле, дип куәтләп алалар. Безне бит алфавит ягыннан да шулай иттерделәр. Һич модельләштерер өчен түгел — руслаштырыр өчен эшләнде. Чөнки татар халкы турыдан-туры рус хәрефенә күчми иде ул вакытта. Бик каты тора иде татарлар. Латиннан русчага күчү җиңелрәк.

**Р. Хисаметдинов.** Куликово сугышы турында язганда «татаро-монголы» диләр. Ухов дигән язучы: «Казанские татары — прямые наследники Великих Булгар»,— ди.

**Б. Урманче.** Анысы шулай ул. Болгарның асылы бит — татар.

**Р. Хисаметдинов.** Әбрар Кәримуллин, алайса, болай яза: «татар» исеме «тат» дигән милләттән чыккан. Көнбатышта исә «татар» дигән сүз теге дөньядан чыккан куркыныч явыз рух мәгънәсендә йөри, ди. Алма-Атада минем бик сөйкемле дустым бар иде — Латыйф Хәмиди. Сез белә торгансыздыр?

**Б. Урманче.** Инде!...

**Р. Хисаметдинов.** Ачык күңелле кеше иде, мәрхүм. Аның белән без төннәр буе сөйләшеп утыра идек. Шул Кәримуллинның диссертациясен фоторәсемгә төшереп, миңа җибәргән иде. Анда болай дигән: кая барса да, «мин — татар» дигән сүзенә Европа кешеләре аптырап, мөгезе кая икән моның, дип, карыйлар икән. Мин дә аның шул хезмәтен машинисткаларга биреп, күбәйттем. Татар интеллигенциясе белергә тиеш мондый язмаларны. Әбрар Кәримуллин анда бик ышандырып яза.

**Б. Урманче.** Ул бик галим кеше. Ләкин аның үз эше бар. Ул китапчы бит, татар матбугатын тикшергән. Бу өлкәне аннан яхшы белгән кеше юк бездә. Башка өлкәгә катнашып, боза ул эшне. Бу бит тарихчылар күтәрәсе мәсьәлә.

**Р. Хисаметдинов.** Алай да... анда бик кыю язган ул. Укыгач, уйлап куйган идем: интектергәннәрдер инде моны, дип. Әйтергә ярамаганнарны әйткән бит. Теге «өч хәреф» бер дә тик тормый бит. Мине дә чакырып алдылар бер көнне. Сүз җәлилчеләр турында барды. Унбер кешенең башы киселде бит. Бер Мусаны гына исҗә алдылар. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты — болар,

әлбәттә, барысы да хаклы, ләкин аның белән бергә тагы ун кеше һәлак булды.

**Б. Урманче.** Мин әйтәм, бер генә кешене күрсәтү дөрес түгел. Алар унбере дә геройлар бит!

**Р. Хисаметдинов.** Һичшиксез!

**Б. Урманче.** Монда безнең бик зур район бар — Ленин районы дип йөртәбез инде. Шунда бик зур һәйкәл ясарга кирәк, дөньяга күренә торган итеп. Мин әйтәм, һәркайсының рәсеме бар — бюстларын куярга кирәк.

**Р. Хисаметдинов.** Әйе шул, бу — изге бер эш булыр иде! Менә бит, исән кайтучылардан без биш-алты кеше калдык. Мусаның якын күрәштәшләреннән, дим. Теге «Моабит дәфтәре»ндә гарәпчә язып калдырган бит ул якын дусларының исемнәрен. Тугызынчы булып минем фамилиям тора анда. Без Мусаның 60 еллыгында да, 70 еллыгында да Оренбурга барганда сөйләштек. Хакыйкать юк, дибез. Мин бит бу турыда Брежневка да язган идем.

**Б. Урманче.** Сау вакытта һәркайсыгызның бюстларын ясап калырга кирәк. Син бар, кем тагы сау?

**Р. Хисаметдинов.** Шәрипов бар, Дим Алиш — без шулай Гарәф Фәхретдиновны атый идек. Ул бичараны да интектерәләр Ташкентта. Аның өстеннән тагын язып биргәннәр. Монда КГБда Галиев бар вакытта, мин шуның янына кереп сөйләшкән идем. Немец офицерының ординарецы булган, дип язганнар. Бөтен булган медальләрен тартып алганнар: «Син — «участник войны» түгел»,— дип. Менә тугыз ел инде ул үпкәләп, газапланып яши. Яклаучы да юк үзен. Гази Кашшаф исән булса, яклап бирәр сүз әйтер иде, чөнки ул — Муса Җәлилнең тоткынлыкта язган кырык шигырен алып чыккан кеше, шунда язган «Шүрәле» либреттосын алып кайтты. Эчтәлеген тулысынча белә, нинди җырлар файдаланылган, нинди сүзләр сөйләнелгән — барысын яттан белә.

**Б. Урманче.** Ординарец булса, ни булган?

**Р. Хисаметдинов.** Юк, булмады һәм була да алмый! Немецларның үз законнары бар бит. Арийский офицер икән, аның ординарецы да бары тик немец кына була ала, чөнки офицерның сер итеп саклаган корреспонденциясе дә шуның кулы аша үтә. Анда русны якын да китермиләр, татарны инде бигрәк тә. Ул ординарец түгел, уборщик булырга мөмкин — ишек төбендә утырып, итекләрен тазартучы. Мин Галиевкә: «Сез, КГБ кешеләре, ничек ышанасыз пычрак бер доносчик язып биргән мондый ялаларга, бу бит күренеп торган ялган!» — дип әйттем. «Шулаймыни? Белмәдек бит без»,— ди Галиев. (Яшь кенә кеше иде, киткән икән КГБдан.) Икенче яла: Фәхретдинов, имеш, үзе теләп барган легионга. Юк, алай түгел, Муса Җәлил заданиесе белән! Муса бит капелла төзеде. Дүрт



**Рәсемдә:** җан дуслар Бакый Урманче һәм Рушад Хисаметдинов (1976 ел, 14 июнь)

батальонны дезорганизовать итәр өчен бик көчле яшерен оешма кирәк иде. Анда эшләр өчен андый-мондый гына, шалдыр-гөлдер йөри торган башларыннан бер грамм сәяси уй төшмәс егетләр ярамый иде. Монда грамоталы, йогынты ясардай, әсирләрнең психологиясенә, аңына тәэсир итә алырлык, меңләгән татарлар арасында эшләрлек кешеләр кирәк иде. Мин шул вакытта качмакчы булып йөри идем. Ниятемне Гайнанга ачтым. Моны ишеткәч, Муса: «Юк, дигән, аны капеллага житәкче итеп куябыз!»— дигән. Үзе белән сөйләшкәндә, мин әйтәм: «Муса, мин бит ноталарны белмим»,— дим. «Нәрсәгә кирәк аның нотасы?!— ди бу миңа.— Егетләр сине хөрмәт итәләр — шунысы кадерле аның». «Ярый, алайса»,— дим. Чыннан да, берничә ай эчендә бу яшерен оешма шундый зур, күп тармаклы булып өлгерде. Барысы дүртлек-бишлектән, дүртлек-бишлектән тора, боларның житәкчеләре Муса берүзе генә белә. Рядовойлар берсен-берсе белмәскә тиеш. Конспирация әйбәт куелган иде. Шуңа күрә оешманың эше дә нәтижәле булды. Дүрт батальонның берсе дә илгә каршы мылтык күтәрмәде, кайбер сатлык жаннардан кала. Андыйлар, саный китсәң, башка халыкларда күбрәк тә булды...

**Б. Урманче.** Капеллада кемнәр бар иде соң? Нindирәк кешеләр?

**Р. Хисаметдинов.** Едлинога килгәч мине, ветврач буларак, атлар янына куйдылар. Немец ветврачы бар иде инде, шуның тирәсендә мин дә йөри башладым. Немец киемнәрен бирделәр безгә — иске кайзер униформалары.

Беркөн шулай музыка тавышын ишеттем. Берәү бик матур итеп гармунда татар көен уйнапмы уйный, аңа скрипка авазлары да кушыла. Чамалап шул яктагы баракка таба киттем мин. Барак ишеген ачып кердем, исәнләштем. Беренче танышкан кешем Кәрим Ходжаев булып чыкты, бик әйбәт Әстерхан егете. Хәзер дә күз алдымда: скрипкада уйнап тора. Тагын Сабитов дигән кечерәк буйлы Әстерхан егете дә бар иде анда. Суликов, Самирханов һәм Хәмиев дигән Башкортстан егете белән таныштык. Соңрак яшерен оешмада минем группада булды ул. Ике рәтле гармунда өздереп татар көен уйнаган егет шул үзе булып чыкты. Үземнең дә мандолинада уйнавымны әйткәч, алар тиз генә уен коралы табып китерделәр. Шунда бергәләп, борынгы татар көйләрен сыздырып уйнап та жибәрдек. Шулай итеп, мин алар янына көн аралаш килә торган булдым.

Берзаман Берлиннан озын гына буйлы, кылыч борынлы Солтанов дигән кеше килде. Шәфи Алмаз белән икесен бергә еш кына күрә идем мин аны. Ул вакытта инде безнең Муса да Берлинда яши дип белә идек. Әйтергә кирәк — элекке максат — япа-ялгыз гына качу оештырудан Муса һәм аның якын көрәштәшләре әһәмият тапмыйлар — ничек тә булса көрәшне эчтән алып барырга, фашистларның пропагандасын эчтән жимерергә кирәклекне алга куялар иде. Аның өчен дошманның ышанычын яуларга, аннан, яшерен оешма төзеп, әсирләр арасында пропаганда алып барырга уйлыйлар. Шуңа күрә Муса капелланы булдырырга тырыша. Концертлар куеп, башка лагерьларда да сәяси эшне алып барырга мөмкинлек туачак.

Солтанов безнең баракка керде дә (без музыкантлар белән анда дүрт-биш кенә кеше идек): «Ну, нихәлләр, егетләр?»— диде. «Хәлләр шул — утырабыз менә, уйныйбыз...» «Менә нәрсә, Муса Гумеров капелла төзергә әйтте. Арагызда артистлар бармы?» Демблин крепостендә калган Гайнан Кормашев һәм башкалар кылт итеп исемә төште. «Артистлар монда бармы-юкмы, белмим,— мин әйтәм,— ә менә Демблинда алар бар». «Алайса шунда барабыз,— ди теге,— танышларыңны алып киләбез...»

Галимов белән икебезне алып киттеләр конвой белән. Солтанов үзе конвойсыз, немец офицерлары белән генә ашап-эчеп барды. Демблин крепостенда, хәтерем ялгышмаса, 13 кешене сайлап алдык. Араларында бер генә профессионал артист та юк иде, һәммәсе үзем белгән бик яхшы егетләр — Гайнан Кормашев, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Баттал, Сәйфелмөлеков... Гарәф Фәхретдиновны инде чын жырчы дип тәкъдим иттем: «Бу,— мин әйтәм,— Казан филармониясенең солисты». Соңыннан билгеле булды — Гарәфнең Казанда бер тапкыр да булганы юк икән. Карабашта туып үскән, үзенең табигый тавышы белән бик матур жырлый. Муса да белә иде аны. Демблин крепостенда нар өстендә утырып, бик моңлы итеп борынгы көйләрне жылый-жылый сузган вакытта: «Син болай ук жырлама инде, хәлне тагын да авырайтасың»,— дигәне исемдә калган. Зиннәт Хәсәнов — Татарстаннан, Сарман районыннан. Үзе әйтүе буенча, «СК-4» дигән Казан заводында эшләгән. Сугыш вакытында лейтенант булган, жәрәхәтләнеп, контузия алып, бик авыр хәлдә фашистлар кулына төшкән. Мин аны бик ярата идем, «Давай,— мин әйтәм,— Хәсәнов, капеллага, анда шартлар яхшырак булмасмы». «Әй, Рушад абый, мин бит артист түгел, жырлый да, бии дә белмим,

шигырь сөйләргә дә оста түгел. Шул фашистларның борынын каерыр идем, мөмкин булса, күрәлмыйм мин аларны! Сез мине капеллагызга язарсыз да, ә мин, уңае килгәндә, бирермен фашистларның кирәген, шуннан сезне бөтенегезне концлагерьга куарлар»,— ди.

Шул кешеләр барысы да капеллага керде. Әйткәнемчә, Муса мине шунда житәкче итеп куйды. Гайнан Кормаш художество житәкчесе булды. Үзе матур гына шигырьләр, кечкенә пьесалар яза иде. Гәрәев Нәжип — старшина булган ул — матур итеп аккордеонда уйный иде. Ул да оешма эшенә катнашты. Гарәф Фәхретдинов — бик ышанычлы кешеләрнең берсе — жырчы да, бик оста биюче дә иде. Фәрит Солтанбәков мандолинада уйный иде. Ул да яшерен оешма эшенә катнашты. Кәрим Ходжаев — иң ышанычлы егетләрнең берсе — скрипкада уйный. Сабитов биюче иде. Самирханов — бик чибәр, кара кашлы, кызларга охшап торган егет. Сабитов белән икесен кызлар ролендә биетә идек. Егетләр шаярталар иде, боларның ачулары чыга: «Уйнамыйбыз, кызлар булып, киенмибез!» — дип әйтәләр иде. Маликов Гариф (Мичурин дип йөри иде үзен) судья булган кеше. Коммунист. Бик ышанычлы иптәшләрнең берсе иде. Хөрмәт итә идем мин аны. Муса да ярата иде. Соңыннан, Франциядә чакта, француз коммунистлары белән бәйләнеш тотуда бик зур эш күрсәткән егетләрнең берсе. Ул — Мусаның якташы, Оренбург өлкәсеннән. Хәмиев — тыйнак, өндәми генә, төндәми генә серне бик саклый торган башкорт егете. Аның язмышы ничек булып беткәндер, бик ышанычлы, яхшы егетләрнең берсе иде. Оста рәссам иде ул. Шамбазов белән бергә бик матур итеп татар кызы портретын ясады. Татарстан күренешләре белән (Шамбазов яшерен оешмага катнашмады шикелле). Гәрәев аккордеонда, ә Хәмиев гармунда уйнаган вакытта күзгә яшьләр килә иде... Илне сагынган вакытта мин шуларның парлашып уйнавын тыңларга ярата идем. Үземнең туып-үскән якларны, Алма-Атаны, Казагыстанның киң җәйләүләрен, алма бакчаларын искә ала идем. Суликов бубенда уйный иде. Бик ышанычлы, сер саклый торган егет. Ибраһимов Рәшит — ударник, гитарист иде. Барабаннарын үзе булдырды. Ташкаев — Мәскәү-Горький тирәсеннән чыккан егет, скрипкада уйный иде. Фуат Сәйфелмөлеков минем якын дустым иде. Маликов белән икесен, Муса, ышанычлы, сәяси яктан грамоталы егетләр кирәк, дигәч, пропагандист роленә тәкъдим иттем. Икесе дә Совет армиясенең җиңеп чыгуына чын күңелдән ышаналар иде. Тагы Әхмәтов дигән егет бар иде. Хорда катнашып йөрди. Безгә Совинформбюро мәгълүматлары кирәк иде. Фашистларның ялганына каршы көрәшер өчен. Шул Әхмәтов белән Умаров кирәкле данныйларны табырга тиеш иделәр. Әхмәтовка фон Зиккендорфның денщигы булырга задание бирелде. Итекләр чистарткан булып, немецлар киткән арада радиоалгычлары белән файдалана бу. Аннан безгә сөйли. Менә шулай, тармактан тармакка китә инде яңалык — Берлин группасына чаклы. Николай Малышев дигән Горький егете бар иде. Бик сугышчан егет. Биергә оста иде үзе. Кызып китеп, бер немец офицерын сүгеп ташлаган. Шуның өчен аны, строй алдында чишендереп, концлагерьга озаттылар.

Тиздән безне Берлинга чакырдылар. Муса, күрәсең, капелла тирәсенә кирәкле кешеләр тупланууына шатланган. Күбесе Демблин крепостенда танышып белешкән кешеләр бит. Безне, капелла әгъзаларын, экскурсиягә алып киттеләр. Зоопаркка. Бик зур, бик бай бакча. Без Гайнан белән җәнлекләрне карап торганда, артыбыздан Муса Җәлил килеп, үзенә илтифат итмәскә кушты. «Күзләрегез теге маймылларда булсын, сүземне дикъкать белән тыңлагыз»,— диде. Ул фронт хәлләренә тукталды, Совет армиясе күп кенә шәһәрләрне азат иткән икән. Безгә көрәшне кичекмәстән көчәйтергә кирәклеген әйтте. Миңа кагылып: «Без ышанабыз сиңа, Рушад»,— диде. Мин чын күңелемнән: «Актык каныма чаен, актык тормышыма чаен кулымнан килгәнне Ватаныбыз өчен эшләрмен»,— дидем. «Мин ышанам, Рушад!» — әкрен генә әйтелгән шул җылы сүзләр әле дә күңелемдә. Шунда Муса, яшереп кенә, безгә листовкалар бирде.

Капелла бик зур эшләр башкарды. Ул бит легионның йөрәге кебек иде. Күбесе яшерен оешмада катнашкан кешеләр. Башлары киселгән иптәшләремнең яртысы шул капелла егетләре иде.

Шулай итеп, без күп кенә җирләргә — Демблин крепостена, Радом шәһәренә (анда эшче батальон бар иде), Крушино дигән җиргә, Дрезденга, ял йортына да концерт белән бардык. Барган бер җирдә Мусаның күп егетләр белән очрашканын белдем. Бөтен җирдә диярлек яшерен группалар бар иде. Шулар белән сөйләшеп, күрсәтмәләр биргәндер инде ул. Кемнәр белән сөйләшкәнен, кемнәр белән очрашканын Мусадан сорап торуның кирәге юк иде. Әнә, Ямалетдинов бик кызыксына, күп сораша иде, Берлинга да безгә ияреп барды — андыйлар күңелдә шик кенә тудыра. Беренче батальон Витебск тирәсендә безнең партизан-

нар ягына чыккач, немецлар легионда үз шымчыларын бөтен подразделениеләргә, батальоннарга тараткannar, күрәсең. Капеллага әллә кемнәр, без белмәгән кешеләр бер туктаусыз киләләр иде. Гайнан белән икәү киңәшеп, ничек тә боларны егетләр янына якын җибәрмәскә тырышабыз. Ямалетдиновтан да, фельдшер Исхаковтан да, шымчы икәнлекләрен ачык кына белмәсәк тә, барыбер шикләнә идек.

Абдулла Алиш, Гариф Шабаев, Фуат Булатов, Әхмәт Симаев һәм башка иптәшләр Берлин группасында яшерен оешманың төп үзәк эшен алып баралар иде.

Муса Берлиннан актык килүендә яшерен киңәшмә уздырды. Хәтерем ялгышмаса, 8 август булырга тиеш. Легионның немецларга каршы күтәрелеп чыгу мәсьәләсе каралды анда. Һәр адым бөртекләп хәл ителде: кайсы группа сакчыларны кырып салырга тиеш, кайсы — связьне, телефон һәм радиоузелны җимерүне, кайсы немец офицерларын юк итүне өстенә ала; минем группа исә атлар белән артиллерия коралларын алып чыгарга тиеш иде.

Яшерен оешмада татарлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә, Гаврилов, Скобелев кебек чуваш егетләре дә, башкорт егетләре дә шактый иде.

...Безне, кулга алып, Варшава төрмәсенә китергәч, шуны белдек: Мусаны төрмә капкасы төбендә бик каты кыйнаганнар икән, күн итек белән типкәләп. Без килгәндә Мусаны аннан этап белән Моабитка озатканнар иде инде. Капелладан биш кеше идек без монда: Гайнан Кормашев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Фәрит Солтанбәков һәм мин. Тагын Әмиров бар иде. Варшава төрмәсендә бик каты җәзаладылар, өзлексез сорау алулар, кыйнаулар, күзгә-күз шаһитлыклар булды. Бер айлар үткәч, прогулка вакытында искәрәбез: егетләрнең саны кими бара, кая алып китәләр — берни белмибез.

Егерме бишенче октябрьдан соң, безне, вагоннарга төяп, Берлинга алып киттеләр. Моабит төрмәсендә берничә сәгать утырганнан соң, конвой безне Тегель төрмәсенә чаклы озатып куйды. Адресы — Вильгельмштрассе, 39. Бая әйткәнемчә, бишәү без...

**Б. Урманче.** Шулай... Мусадан алгач, Тиммерманс «Моабит дәфтәрен»н үз әнисенә җибәрәме?

**Р. Хисаметдинов.** Әйе, әти-әнисенә сала. Шуннан барып әйтә СССР консулына: минем белән бергә татар совет язучысы утырды дип. Консул дәфтәрне сорый. Васыятына ул, Константин Симонов, Сергей Смирнов, Александр Фадеевка дип язган, ди Тиммерманс. Шуннан консул Симоновны чакыртып ала. Симонов, Тиммерманс яшәгән авылга барып, Җәлил блокнотын алып кайта. Консулга бирми бит Андрей Тиммерманс! Димәк, ул белгән инде мондагы хәл-әхвәлләрне...

Мусаның шигырьләре кулдан-кулга, төрмәдән-төрмәгә йөрде. Мин — Тегельдә, ул — Моабитта. Этап белән, бер төрмәдән икенчесенә күчерелгән кешеләр аркылы килә иде аның шигырьләре (кулдан кулга йөргән почтаны «ксио» дип атыйлар иде). Прогулкага чыккач, синең кулыңа кәгазь кисәге төртәләр. Немецча булса, ары җибәрәсең, русча яисә татарча булса инде, ачып укыйсың. Мусаның үз кулы белән язылган шигырьләре әнә шулай килеп керде кулга...

* * *

**Р. Хисаметдинов.** Муса Җәлилнең 70 еллыгында Мәскәүдә кызык хәл булды. Колонналы Союз йортында инде бу. Миңа сүз бирделәр. Чыгышымның азагында болай дим: «Татары, башкиры, марийцы, чуваши, удмурты! Вы — как орлы, можете достойно жить наравне с другими национальностями нашей великой Родины! Как орлы! Никто не смеет упрекнуть вас в предательстве, потому что Муса Джалиль и его подпольная организация добились того, чтобы ни один батальон, из четырех, не поднял оружие против Родины!» Шуннан мәрхүм Гази абый әйтә миңа: «Рушад, син артыграк мактанып җибәрдең»,— ди. «Соң дөресе дә шул бит, мин әйтәм. Курка торган җирем юк. Рус әйтмешли, кроме цепей, терять нечего». Кайткач, илдә, мине бик рәнҗеттеләр, күрмәгән калмады. Хәзер инде СССРның Хәрби коллегиясе аклады мине, так что, берәүнең дә теше үтми миңа. Тешләрен бик кайрап йөриләр, ләкин тешли алмыйлар! Ха-ха-ха! Немецлар күп утыртты — Варшава төрмәсе, Германиянең Тегель төрмәсе (анда мин сигез ай ярым утырдым). Франциядә Леон төрмәсенә тыгып куйдылар. Менә бу знагым минем — «Монлюк төрмәсе тоткынының Почет билгесе» дип атала. Леон төрмәсенең исеме ул. Знакның документы да бар миндә.

Исән калучылардан Котлы Бөкәштә тагы Гатин дигән кешебез бар. 23 ел буена мине эзләткән ул! Колхозларында борчак җире саклауны да ышанып тапшырмаганнар бичарага. Урта Азия буенча йөреп, төзелешләрдә эшләп көн күргән. Шабашник булып, мич чыгарган, йортлар салган. Күрешкәч, сорадым аннан: мине ничек таптың, дип. Көннәрнең бер көнендә Кыргызстанга барып чыккан бу. Сузак районында бер Камчыбеков дигән укытучыдан: «Сез Хисаметдинов дигән кешене беләсезме?» — дип сораган. «Рушад агамы?». «Әйе, исеме Рушад». «Ә сез аны каян беләсез?» «Франциядә без аның белән этап вакытында Леон төрмәсеннән бергә качкан идек. Мин бер якка йөгердем, ул — икенче якка. Шуннан бирле аны күргәнем юк, белмим, исән кала алды микән, юкмы?». «У-у, мин аның белән урман кисеп йөрдем, шахтада эшләдем»,— дигән укытучы. (И-и, Бакый абый! Күрмәгән газапларны күрдек инде без аның белән!). Шуннан хатынына әйткән Камчыбеков: «Бу кешегә пылау пешер. Ул безнең аяшата (кыргызларның кешене зурлап әйткән сүзе), Рушад әкә белән бергә йөргән!»

Әсирлеккә мин 1942 елда төштем. 1941 елны мин хезмәт иткән особый 79 нчы кавалерия дивизиясе августта сугышка керде. Беренче елны мин тулысынча сугышып йөрдем. Әсирлеккә төшкәч, башта Янки дигән лагерьга озаттылар. Анда бер кызыклы вакыйга булды, сөйлим әле сезгә...

**Б. Урманче.** Туктале, Рушад, башта минем соравыма җавап бир. Шуннан, син барганда Шәфи Алмазның оешмасы бар идеме инде?

**Р. Хисаметдинов.** Юк әле.

**Б. Урманче.** Ул кайчан оеша?

**Р. Хисаметдинов.** Менә шул 1942 елның ахырларында инде.

**Б. Урманче.** Муса ул вакытта анда инде? Ул да катнашамы?

**Р. Хисаметдинов.** Мусаны да чакырып алалар, өнди башлыйлар. Бу вакытта әсирләргә әйбәт ризык биреп, ныклап игътибар күрсәтәләр... Батальон, легионнар төзиләр немецлар. Җәлил күреп тора бит инде боларны. Ул гына да түгел, аның белән бергә шул Абдулла Алиш, Әхмәт Симаев, Шабаев, Кормаш, Сәйфелмөлеков, Хәсәновлар бар — алар күпләр. Анда тагын хәрби батальоннар — Таҗетдиновлар, Жуковлар...

**Б. Урманче.** Бәлки, башта германский бер оешма булып оешкандыр?

**Р. Хисаметдинов.** Юк, Муса Җәлил, Абдулла Алишлар баштан ук әзерлек лагерендә утыралар. Шуннан Җәлилне Розенбергка допроска чакырталар.

**Б. Урманче.** Ышанычка керү дигән нәрсә булган бит инде?

**Р. Хисаметдинов.** Һичшиксез! Башкача ничек итеп эшләргә була? Немецлар довериесенә кереп, эшне эчтән йөртергә кирәк иде. Шуны белмәгән кешеләр кинофильмнарда совет офицерларын, немец киеме киенеп, Гитлер янында ук йөргән итеп күрсәтәләр. Һәм аларга берни булмый моның өчен. Ә безнең бичара Мичуринны, унтерофицер формасын киеп йөргәне өчен, Бутырка төрмәсендә кыйнап допрослар алганнар. Ахырда паралич сугып Ташкентта үлде. Ә бит капелланы Муса нәкъ менә ышаныч тудыру өчен төзи. Андый мөмкинлек бер генә лагерьда була.

**Б. Урманче.** Шулайдыр, ләкин мин сораганга син җавап биреп бетермәдең әле. Шәфи Алмаз ул вакытта эшли инде?

**Р. Хисаметдинов.** Шәфи — эмигрант. Ул революциягә кадәр үк чыккан. Исеме Габдрахман аның.

**Б. Урманче.** Беләм, таныш кеше ул миңа.

**Р. Хисаметдинов.** Хатыны Хәдичәне дә беләсезме?

**Б. Урманче.** Әйе.

**Р. Хисаметдинов.** Ач яңаклы, арык кына, бик хәйләкәр күзле татар иде Шәфи. Оренбурныкы.

**Б. Урманче.** Мәскәүдә приказчик булып эшләгән кеше. Төрек илчелеге оешкач, шуларга эшкә керде. Шуннан төрекләрнең подданные булды ул.

**Р. Хисаметдинов.** Мин анысын белмәгән идем.

**Б. Урманче.** Мин анарда төрек дипломатлары белән кунакта булдым. Шуннан соң ул Берлинга күчте. Ул анда да төрек илханәсенең эшен алып бара. Муса, димәк, шул Шәфи Алмазның довериесенә керә?

**Р. Хисаметдинов.** Шәфи Алмаз Мусаны бик ярата иде, үзеннән бер дә калдырмый иде. Муса көндәм, юаш булып кына йөргән аның янында. Шәфи аңа ышана иде, чөнки Мусаның авторитеты зур, татар легионерларының күбесе белә иде аны.

**Б. Урманче.** Шәфи янында кемнәр бар иде тагы?

**Р. Хисаметдинов.** Иң ышанычлы кешесе — Гариф Солтанов. Ул хәзер дә Калифорния университетында чыгышлар ясый. Бик матур, кара чәчле, кылыч

борынлы кеше. Тагы Афзал Фәтхуллин дигән яшь кенә җырчы, бик чибәр егет. Шәфи Алмаз һәрчак җырлата иде аны. Хәдичә ханым да. Шәфи Алмазның Берлинда бик зур йорты, кунакханәсе була. Тагын Яушев Искәндәр дигән кеше яши Германиядә. Заводлар тоткан татар кешесе.

**Б. Урманче.** Анда безнең татар егетләрен коткара ул. Искәндәрне әйтәм. Ә үзе чыга алмый кала, тотыла.

**Р. Хисаметдинов.** Безнекеләр тотамы?

**Б. Урманче.** Әйе, чикне үткән вакытта.

**Р. Хисаметдинов.** Кара син, ә! Бик матур хатыны да бар иде аның. Галимҗан Идрисине дә ишетеп беләсендер?

**Б. Урманче.** Беләм.

**Р. Хисаметдинов.** Аның бер улы — Илдар — Муса янына килеп йөргән. Рафаэль Мостафин Германия Федератив республикасында эзләп тапкан аны соңгы вакытта. Бик яхшы фикере. Медицина журналы чыгара икән ул анда. Ә Шәфи Алмаз исән калды микән?

**Б. Урманче.** Әйе. Ул бит Төркия гражданы буларак, шунда кайткан булырга тиеш.

**Р. Хисаметдинов.** Монда Бидде дигән тәрҗемәче килгән икән, Мостафинга күп кенә истәлекләр сөйләгән ул. Леон Небенцаль белән бергәләп алар, ФРГга барып, татар әсирләренең документларын эзләп табалар. Бик кызыклы хәл: үз дәрәҗәсен күтәрер өчен сатлык җан үзен Гаяз Исхакый дип атый. Исхаков дигән бер фельдшер була ул, хаин.

**Б. Урманче.** Гаяз Исхакый ул вакытта Германиядә булмаган, дисең инде?

**Р. Хисаметдинов.** Юк. Безнең әти бик ярата иде аны. Китаплары да күп иде. Бер улына Гаяз исеме куйган,— язучы хөрмәтенә. Утыз җиденче елда, әти кулга алынгач, китапларын да юк иттеләр. Соңыннан акладылар үзен. Галим кеше иде безнең әти. Бакый ага, сезгә охшатам мин аны. Заманча карашлы иде. Совет властен төзүдә күп көч куйды. Беренче наркомобраз булды ул Алма-Атада (Верный шәһәре иде ул заманда). Фурманов килгәч, Шиһабетдинов, әти, тагын Җандосов дигән казакъ белән аралашып йөрде. Әти реввоенсовет члены иде. Приютлар оештыруны башлап җибәрде. Казакъ алфавитын язды. Гомер буе укытучы булып эшләде. Шиһабетдинов белән бергә трибунага чыгып басалар иде. Шиһабетдинов русча сөйли, әти аның сүзләрен казакъчага тәрҗемә итә иде. Басмачылар Шиһабетдиновны трибунада сөйләп торган вакытында атып үтерделәр.

**Б. Урманче.** Шиһабетдинов дигән фамилия таныш миңа.

**Р. Хисаметдинов.** Революция вакытында сез Казагыстанда идегезме?

**Б. Урманче.** Юк, революция вакытында мин февральдән майга кадәр өйдә — Кукандта. Аннан соң инде бу якларга кайттым.

**Р. Хисаметдинов.** Шамил Усманов гаскәрен күрмәдегез инде? Татбригада шунда бара бит. Татарлар йөргән бит анда, совет хөкүмәтен төзеп... Мостафа Ногманның шундый җыры да бар бит:

«...Фергана, Бохара — без йөргән ара...»

**Б. Урманче.** Мостафа белән икәү каберләрен эзләп йөрдек анда. Шул Татбригада белән совет хөкүмәтен төзеп йөргән картлар, инвалидлар Җәләлабад базарын тутырып утыралар. Аяксыз-кулсыз кешеләр әрҗә ясап көн күрәләр. Ә каберләре турысында әйтәсе дә юк. Әндиҗан янындагы каберлектә булдык. Бер дә каралмаган, ташландык хәлдә. Орск шәһәрендәге шикелле түгел. Дутовмы, Колчакмы Уралга килгәндә, татарлар бик каты сугышканнар акларга каршы. Форштадт дигән парк бар Орск янында. Шунда революционерларның каберләрен матур итеп бизәгәннәр, ташлар куйганнар, гөлләргә күмгәннәр! Ә Әндиҗан зиратында мондый таш куйганнар: «Здесь похоронены мусульмане, участники становления советской власти»,— дип. «Татарлар», «башкортлар»,— дигән бер сүз юк.

**Р. Хисаметдинов.** Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» клубында очрашу вакытында: «Гомер буе туган илдән читтә яшәгәнсез, ана теленә карашыгыз ничек?» — дип сораганнар иде. Мин әйттем: «Урта Азиядә казакълар, кыргызлар, үзбәкләр арасында үстем. Әти әйтә иде: «Син, улым, күп төрле милләтләр арасында яшисең, шулар белән тату бул, берәүне дә кимсетмә. Берәүне берәү рәнҗетсә, син ярдәм итәргә тырыш. Шунда гына тормыш юлың бәхетле булыр»,— дип. Төрле халыклар күрдем, телемә чит сүзләр кереп китүе дә мөмкин. Муса Җәлил һәм аның якын көрәштәшләре — соңыннан минем якын дусла-

рым — белән фашист лагерьларында, төрмәләрдә бергә булган вакытта татар телен һаман-һаман өйрәнергә тырыштым. Татар халкын чын күңелемнән яраттым мин. Кайда гына булсам да, ана теленә хыянәт иткәнем юк. Тел турында мин сезгә гыйбрәтле бер вакыйга сөйлим хәзер,— мин әйтәм...

Шулай Себердә җан асрап яткан вакытта этап белән лагерьга бер яшь егет килде. 19—20ләрдә генә әле. Руслар арасына кереп кысылган бу. Андый җирдә халык төркем-төркем булып, һәркем үз милләттәше тирәсендә булырга тырыша. Фамилиясе Хәбибуллин моның, үзе Харитонов булып йөри. Исеме Барый икән, ул үзен Борис дип атый. Рус егетләре әйткәннәр моңа: «Син болай үз милләтеңне сатып йөрисең бит, бер көн килеп, безне дә шулай сатарсың!» — дигәннәр моңа.— Син үз милләттәшләрең янына бар, мөселманнар янына, алар күп монда». Китә бу шуннан чеченнәр катына: «Здравствуйте, я мусульманин. Можно мне к вам?» — ди. «А почему по-мусульмански не здороваешься? Какой же ты мусульманин?» — диләр икән тегеләр. «Я татарин, татарин!» — ди бу. «Вон там ваши татары, к ним и иди»,— дип куып җибәргәннәр егетне. Күрсәткән якка китә мескен. Анда Барый Абдулла абый дигән кешегә туры килә, Себер татарына. «Вот, я татарин,— ди икән.— Меня вон те прогнали, и русские прогнали!» «Син кай якныкы?» — дип сорый карт. Теге лып-лып, күзен ача да йома, бер сүз аңламый. «Төшенмисеңме әллә син татарча?» «Я не знаю!» — ди теге. «Тогда, пшел вон отсюда! Какой ты татарин, языка матери своей не знаешь!» — дип, җилкәсеннән этеп җибәргән тегене. Чыгып, мескенләнеп тора инде. Яшь бит. Санчастьта минем Ремицан дигән латыш дустым бар иде. Ярата идем шул кешене, чөнки безнең җиңгиебез, әниемнең энесе — Әхәт абый хатыны Матильда исемле латышка иде. Шул хатыннан бер кызы, бер улы бар иде. Монда лагерьда берүзе каңгырап йөргән латышны (шул җиңгием хакына), дус итеп, үз янымда йөртәм инде. Ремицан әйтә моңа: «В санчасть иди, там у нас Рушад Билялыч, очень хороший человек. Он не обидит, к нему иди»,— дип алып килә теге малайны. Палаткада без. Шуннан, килү белән, исәнме юк, саумы юк, башын баганага орырга тотынмасмы егетем! «Я проклинаю своих — отца и мать, что родному языку не научили! Ненавижу их!» — дип кычкыра башлады. Нервысы тоткан, тавышы калтырый. Мин килдем дә: «Сынок, погоди, зачем ты так? Почему расстраиваешься?» — дим. Җылый теге: «Разве я виноват?! Это отец с матерью родному языку не научили! Как же мне жить?! — ди.— Русские прогнали меня, чеченцы прогнали и старик-татарин прогнал!» «Ну-ка, Ремицан, позови Абдуллу абый»,— дим. Карт килде дә күрә инде: мин малайны иңеннән кочып утырам. «И-и Рушад, бу сиңа нәрсәгә кирәк? Түргә утыртып куйгансың! Ана телен белми бит ул. Аннан куылган, моннан куылган! Чыгарып җибәр үзен!» (Абдулла абый мине ярата иде үзе.) «Юк,— мин әйтәм,— алай түгел. Ходай тәгалә бөтенебезне дә тигез яраткан, аның бәндәләре бит без. Ничек итеп моны куасың? Ата-анасы бернәрсәгә дә өйрәтмәгәннәр үзен. Әле бу яшь кеше, өйрәнер, гаепле булабыз бит, мин әйтәм, читкә каксак. Син куй ул сүзеңне, Абдулла абзый!».

Шулай итеп, малайны үз арабызга алып, башта исәнләшергә өйрәттек, кай яктан икәнен әйтергә һәм әкренләп башкасына... Ана теленең читтә дә кирәге чыга икән ул адәм баласына!

Шушыларны сөйләгәч, Түбән Кама кешеләре гөрләтеп кул чаптылар! Әйе, туган тел һәркемгә кадерле. Руслар әнә үз телләре белән горурлана беләләр...

Бер тапкыр, геология партиясендә эшләп йөргәндә, мине разведком председателе итеп сайладылар. (Профсоюз инде ул.) Шунда Войтенко дигән инженер-геолог миннән сорый: «Товарищ председатель, как ваше имя-отчество по-русски?» — дип. Мин әйтәм: «У нас не переводится. А как ваше по-татарски?» — дидем. Теге кычкырып көлә, ачуым чыкты: «Где вы воспитывались? Какой институт кончали?! Как смеете так унижать, смеяться над другим языком?!» Теге, чын күңелемнән рәнҗүемне күргәч, кочаклап алды мине. «Рушад Билялович, я нарочно задал вам этот вопрос, потому что многие татары меняют свои имена. Вот Тихоном зовется, а сам Талгат. (Геология партиясе начальнигы турында әйтә инде бу.) Спасибо вам,— ди,— кто любит свой народ, тот и Родину не предаст»,— ди.

Старший инженер иде. Шуннан теге Тәлгать дигәне килгән безгә бер көнне. «Рушад абый,— ди,— минем әти сезгә охшаган кеше булырга тиеш. Мин детдом малае бит. Войтенко сөйләгәч, аңыма килдем»,— ди. «Ата-ана биргән исемне алыштырырга ярамый шул»,— мин әйтәм. Күз яшьләре белән елап утырды. «Оялтты бит мине Войтенко!» — ди. Анысы ярдәмче генә, югыйсә, ә бу начальник инде. Ана теле кайда да кирәк шул...

* * *

Яшерен оешма эшләре буенча Муса Җәлил башка милләт кешеләре белән дә элемтәдә иде. Толымбәков дигән казакъ, Хәмзә Абдуллин дигән казакъ язучысы, тагын үзбәкләр дә бар иде, рус полковнигы Гушманов, Рыбальченко дигән украинлы — боларның барысы белән дә якыннан таныш иде ул. Михаил Иванович Иконников (аның белән төрмәдә бергә утырган идек) хәзер дә исән. Безгә Ош шәһәренә берничә тапкыр килеп китте. Мәскәүдә, Мусаның 80 еллыгыннан соң, хушлашканда, Таифә әйтә миңа: «Кара әле,— ди,— Михаил Иванович күз яшьләре белән елап тора». Мин дә елыйм инде. Ничек еламыйсың, дус бит, тормышның ачыларын бергә күргән кеше. Шулай итеп, елый-елый аерылышкан идек.

Әсирлектә чакта Персиков дигән рус егете мине үлемнән коткарып калды бит! Демблин лагеренда булды бу хәл. Этап белән салкыннан килеп кергәч, күрәм, әсирләр тезелешеп яталар. Кулымны берсенә куеп карыйм — җылы, тере, димәк; икенчесенә куям — җылы. Шуннан тегеләрне этеп, араларына кереп ятам.

Иртә белән уянып китсәм, тешем тешкә тими — шундый суык! Карасам, уң ягымдагысы үлгән, тәне суп-суык, сул яктагысы да үле. Аларның меңнәрчә бетләре миңа күчкәннәр! Колакка да, күзгә дә керәләр, борынга да. И-и, талыйлар үземне! — фашистлардан да яманрак икән бу хәшәрәтләр! Мин ничек тә булса торып санчастька киттем. «Послушайте, доктор, дайте что-нибудь: вши заели совсем!» — дим. «О, браток, нет у нас никаких лекарств. Ничего не дают фашисты. Мы тут, как мухи, мрем»,— ди. «Что же делать? Заели ведь, проклятые!» «А вон там, в углу, костер. Подержи одежду над огнем».

Учак янында минем шикелләләр утызлап кеше. Мин дә чишенеп, киемемне таякка алып ут өстенә китергән идем, чытыр-чатыр яна да башладылар теге хәшәрәтләр. Яңадан санчастька киттем. «Доктор, мне бы пристроиться где-нибудь, надо бы пользу какую-то приносить»,— дим.

Тик кенә йөреп үләсе килми бит инде. Чарасыз басып торам, шуннан врач, әллә инде кызганып, миңа якында гына дизентерия белән авыручылар ята торган барак барлыгын әйтте. Анда бер ярдәмсез хасталар үлем көтеп ята икән. Сак бул, ефрейтор-садист эләктермәсен үзеңне, кисәтү-нитүсез атып үтерәчәк. Анда ризык эзләп керүчеләрне чүпләп кенә тора ул. Обходтан соң гына керергә тырыш, диде.

Обход беткәч, баракның ишеген барып тарткан идем, галәмәт сасы ис борыныма килеп бәрелде. Нарларда йөзләгән авыру ята — арык дистрофиклар, коры сөяк белән тиредән генә! Кайсы киемнән, кайсы ялангач. Ыштаннары, күлмәкләре арт сөякләренә ябышкан — канлы кләй шикелле. Мине күрүгә: «Дай воды, воды»,— дип, туксан тугыз кул күтәрелә башлады.

Шулай ярдәм итеп йөрим, ара-тирә Валентин Персиков белән сөйләшеп тә алам. Күпмедер вакыт үтте. Теге ефрейторны гел күзәтеп торам, ул киткәч кенә авырулар янына керәм.

Дүртенче көннән соң микән, Валентин белән исәнләшеп тә өлгермәдем, ишек ачылып та китте, ике полицайны ияртеп, теге ефрейтор, явыз, килеп тә керде. «Вас махст ду hиер, ферфлюхтер ман?! — дип акыра бу.— Швайн райн!» — дип, сүгенә-сүгенә, билендәге парабеллумын чыгара башлады. Мин өнсез калдым. Шулвакыт теге Валентин — каян килгәндер көч аңа! — урыныннан кубып, миңа ташланды, мин — аңа. Кочаклап алды да Валентин, күз яшьләре белән елый-елый ялынырга тотынды: «Һер ефрейтор! Ниһт шиссен! — ди.— Дас ист майн брудер!..» («Атмагыз, зинһар, бу минем туган абыем! Ул эзләп тапкан мине!» — дигән сүзе инде.) Теге фашист карап тора. Мин дә зәңгәр күзле, аксыл чәчле, Валентин да шундый ук блондин. Теге садист карап-карап торды да — Валентинның күзеннән яшь ага, ышанмау мөмкин түгел — парабеллумын каешына кыстырып: «Бляйб hиер. Гут»,— дип («Ярый, кал шушында») — чыгып китте.

Менә бит, Валентин — рус, ә мин — татар. Икебезне дә атып үтерер иде, ләкин авыру кешенең елый-елый соравын аңлады бит немец! Каян килгән аңа мәрхәмәт?..

Шул көннән алып мин авырулар янында тора башладым. Үземә урын җайладым. Кухняга баргалыйм. Гайнан Кормаш белән шунда таныштым. Аннан җылы су ташыйм. Көн дә «капут команда» килеп, үлгәннәрне алып китеп тора. Бер чокырга гына да 95 мең мәет күмелгән!

Бер көнне Гайнан белән сөйләшеп торганда, әйтә бу: «Әнә, Рушад, күрәсеңме теге кешене?» «Күрәм. Кем ул?» — дим. «Безнең атаклы совет язучыбыз Муса Җәлил бит ул»,— ди. Мин әйтәм: «Кызганычка каршы, Муса Җәлилне белмим бит. Тукайны беләм, Галимҗан Ибраһимовны беләм, ә Җәлилне белмим.

Таныштыр безне»,— дим. «Әйдә, таныштырам»,— ди бу. Гайнанны күреп алгач, теге кеше безгә таба килә башлады. Аның кыяфәте йончыган булса да, янып торган күзеннән батыр кеше икәне күренеп тора иде. Мин: «Рушад Хисаметдинов»,— дип, аңа кул суздым. Ул: «Муса Гумеров»,— диде. Кайсы вакыттагы этап белән килүемне, кайчан әсирлеккә төшүемне, сугыш хәлләрен сораштырды.

Лагерь ишегалдында кечерәк бер чиркәү бар иде. Муса һаман шул тирәдә кайнашты. Аның янына гел кеше җыела — казагы да, татары да, чувашы да, урысы да, марие да. Һәркайсы аның шигырьләре белән кызыксына иде, шуннан үзенә дәрт, рухи көч, яшәү теләген алгандыр ул.

Озак та үтмәде, этаплар башланды. Мусаны каядыр алып киттеләр. Мине дә Ротвайль дигән лагерьга күчерделәр.

Бу вакытта Көнчыгыш фронтта безнең Совет Армиясе немецларга шактый каршылык күрсәтә башлый. Немецлар кырыла. Гитлерга яңа солдатлар, «пушечное мясо» кирәк була. Шуңа күрә алар элекке сәясәтен үзгәртәләр. Башта алар, «Майн кампф» дигән Гитлер китабы буенча, безнең совет халыкларын «унтерменш» дип юк итәргә хөкем иткәннәр. Ариецлар — ягъни, немецлар гына чын кеше, янәсе. Ә хәзер затлы расадан икәнлекләрен онытып, әсирләр лагерында төрле милләт кешеләрен ашата, эчертә башлыйлар. Әсирләрне милләтләргә бүләләр. Рус, украин, белорусларны бер җиргә җыялар; татар, башкорт, мари, удмурт, чувашларны икенче җиргә; грузиннарны әрмәннәрдән аералар; казакъ, таҗик, кыргыз, төрекмәннәрне үзаеры туплыйлар. Шулай итеп, үзләренә коралды көчләр әзерләмәкче булар.

Безне төрле лагерьлардан Польшага алып килеп, Едлино дигән җиргә тупладылар.

1943 елда безнең капеллабызның яртысын кулга алып, Варшава төрмәсенә яптылар.

Мусаны 10 августта алып китәләр, 11 августта — безне. Шунда ук безне саткан кеше дә билгеле булды. Ул — Ямалетдинов, Казагыстаннан. Без аңардан элек үк шикләнә идек.

Допрослар, күзгә-күз шаһитлык, кыйнаулар — һәммәсе шул Варшава төрмәсендә булды.

Ике айдан безне Берлинга алып киттеләр. Юлда конвоирлар үзара сөйләшеп, бутербродлар ашап бардылар. Күмәчкә май якканнар да, өстенә варенье сылаганнар. Бер-берсен кыстаган булалар, безгә илтифат итмиләр. Шунда Абдулла Батталдан: «Белмисеңме, Абдул, кем сатты икән безне?» — дип сорыйм. «Теге, күзлек кигәне, капеллага кереп йөри иде бит. Ямалетдинов. Мин аңа карата шигырь чыгардым»,— ди Баттал.

Их, Ямалетдин! Кызыл перчатканны
Юылмаслык канга мангансың.
Сузма кулың безнең күкрәкләргә!
Буең җитмәс, үсми калгансың».

Гази Кашшаф минем турыда «Комсомольская правда»да язып чыккан иде: «Мусаның якын көрәштәшләреннән Хисаметдинов дигән берәү булган. Аны 1944 елны Франциягә алып килгәннәр. Аягында да басып тора алмаслык хәлдә яткан Хисаметдиновны хастаханәдән немецлар төрмәгә илтеп япканнар. Шунда үлеп калган, имеш». Моны укыгач, үземнең тере икәнлегемне әйтеп, редакциягә хат яздым.

Шуннан озак та үтмәде, Гази Кашшаф безгә Ошка килеп төште. 1959 елда мине монда, Казанга чакырдылар. Язучылар клубына бөтен союз әгъзалары җыелган — руслары да, татарлары да. Халык бик күп. Кызык бит: Муса белән бергә булган кеше килгән! Шунда мин Абдулланың әлеге шигырен сөйләгән идем. Сөйләвен русча сөйләдем, ә шигырен татарча укыдым. Бервакыт залдан Салих Баттал — Абдулланың абыйсы, болай дип кычкыра: «Одну минуточку, товарищи! Это стихотворение я в 1929 году против Чемберлена написал. Вот теперь мне совершенно ясно, что Хисамутдинов был с моим братом. Брат воспользовался моими стихами против предателя».

Варшава төрмәсеннән соң немецларның атаклы зинданнары саналган Тегельгә эләктем. Шунда мин Александр Русанов дигән кеше белән таныштым. Ул Строкач дигән генерал-полковникның үз (личный) адъютанты була. Бу генерал — Украинадагы бөтен партизан хәрәкәтенең башлыгы. Соңыннан аны Советлар Союзындагы партизаннар хәрәкәте штабы начальнигы итеп билгеләгәннәр. Ә Русановны Брянск урманнарына Ковпак подразделениесенә 25 ел тулу уңаеннан җибәргән булганнар. Немецлар аның самолетын бәреп төшергәннәр. Дошман кулына ул шулай эләгә.

Тегель төрмәсенең һәр катына ятьмәләр сузылган. Югары каттан ташланасың икән, ятьмәгә килеп төшәсең. Шундый инде немец төрмәләре. Баскычлары буйлап әйләнәеп-әйләнеп менешле.

Шулай беркөн һава тревогасы башланды. Күктә — америка, инглизләрнең йөзләрчә самолеты. Берлин ут эчендә! 1944 ел бу. У-уу, күрсән... төрмә дер селкенә. Надзирательләр бомбадан саклану урынына качып беттеләр. Төн караңгылыгын кисеп, прожектор утлары айкала, реактив снарядлар атыла. Ул җәһәннәмне сөйләп кенә бетерерлек түгел. Әллә нинди төсләрдә аллы-гөлле утлар кабынып китә. Әгәр рәссам булсам, шул дәһшәтле манзараны ясар идем мин.

Шушындый һөҗүм вакытында төрмәдәге барлык тоткыннар берьюлы кычкыра башлый — инглиз, француз, рус, немец телләрендә. Чын кыямәт куба! Шул гауга эченнән ишетәм, берәү «Синенький скромный платочек» дигән җыр көенә сызгырына бит. Сызгыра да беразга туктала. Аннары кабат башлый. Мин дә бу җырны дәвам итеп киттем. Сызгырып та карадым. Шуннан аскы этаждан: «Кто поет?» — дип кычкыра берәү. Мин өченче катта. Аска карап: «Это я, Рушад Хисамутдинов!» — дип җавап бирдем. «А я — Александр Русанов!» — ди теге. Әнә шулай танышып киттек без. Көн дә бу миңа яңалыклар җиткерә. Мин дә кайчан әсир төшкәнемне, ни өчен төрмәгә утырткканнарын әйтәм. Әлбәттә, барысын да ачып ташлап булмый инде аңа. Ә ул болай дип кычкыра: «Я — партизан. Меня сбили. Со мной заигрывают тут. Если хочешь меня увидеть, нас с одним французским офицером на прогулку, примерно часа в три, выводят,— ди.— Я в погонах. Ты, наверное, еще не видел погонов?» «Нет, не видел»,— дим.

Сәгать өчләрдә (вакытны кояштан чамалыйсың) тәрәзәдән карасам, китеп бара бу. Башында полковник папахасы, плащтан, кара сакаллы чибәр егет. Янәшәсендә француз офицеры һәм немец фельдфебеле. Русанов нидер сөйли, минем тәрәзә ягына караштырып та ала. Кулын папахасы янына куеп, мин күрдем сине, дигән ишарә ясый. Мин дә аңа кульяулык болгыйм. Шулай итеп, безнең танышлык көннән-көн ныгый бара. Һава һөҗүме вакытында бөтен яңалыкларны бер-беребезгә җиткерәбез. Шушы вакытта Эрнст Тельман да Тегельда утырган икән.

Беркөнне минем камерага надзор прокуроры керде (Тегель — тикшерү төрмәсе бит). Немецчә белмим, дим моңа, миңа рус газетасы бирегез, дим. Бер-ике көннән алып киләләр миңа, онытылган инде, «Новое слово» мы, «Русское слово» мы, эмигрантлар газетасы. Беренче битендә үк зур итеп Русановның фоторәсемен биргәннәр. Күкрәгендә орденнар. Погоннардан. «Капитан госбезопасности Александр Дмитриевич Русанов» — дип язылган. Шунда ук Политбюро әгъзаларын мыскыл иткән төрле хәбәрләр...

Тревога вакытында «Синенький скромный платочек»ны җырлап, чакырам моны. «Что?» — ди. «Саша, мин әйтәм, передо мной газета «Русское слово». Здесь твоя фотография и показания капитана госбезопасности Советского Союза Русанова. Крупным жирным шрифтом». «Что пишут?» — ди. Мин әйтәм: «Чепуху всякую». «А ты веришь?» — ди. Мин, аны-моны уйламыйча, «не знаю»,— дип җавап бирдем. Шул сүзем өчен өзде бит бу араны! Тревогалар вакытында дәшми хәзер. Ярты ай вакыт узды, бер айга якынаеп килә — юк, теләми сөйләшергә, һаман үпкәләве бетми. Кычкырып та карыйм. «Платочек»ны да җырлап алам — юк, дәшми генә бит! Мин гаебемне аңлыйм: бергә төрмәдә утырган иптәшемне рәнҗеттем бит. Гафу үтенәсем килә. Нишләргә? Шуннан бер көнне «Дети капитана Гранта»дагы:

«Капитан, капитан улыбнитесь!..» —

дигән өлешен җырладым. Тавыш килә бит астан: «Что, Рушад?» — ди. Мин әйтәм: «Слушай, Саша, извини ты меня, дурака! — дим.— Как я мог, не подумав, ляпнуть такое — не знаю... Конечно же, они шельмуют тебя, поливают грязью. Я не верю ни единому их слову. Ты же многих здесь морально поддерживаешь, не только меня одного!..»

Шулай итеп, безнең дуслык алты ай дәвам итте. Ахыргы көннәре болай булды инде аның...

1944 елның февраль — март айларында мине, Шәриповны (ул шунда Муса Җәлилнең дәфтәрен алып чыккан), Солтанбәковны чыгаралар. Исән калуым белән мин Мусага, Гайнанга бурычлы. Алар мине сатмадылар. Ә мин үзем һаман бер сүзне кабатлап килдем: «Бернинди дә яшерен оешманы белмим. Гаебем шунда гына — мин сездән качмакчы идем».

Безне шуннан Франциягә алып киттеләр. Русанов Тегельда калды. Аның язмышын сугыштан соң, илгә кайткач, белдем. Фашистларның җәзалауларына

түзә алмыйча, кан тамырларын кисеп, һәлак булган. Ләкин соңгы хатын, тимер тартмага салып, җиргә күмеп өлгергән. Дошман ничек тырышса да, сындыра алмаган аны. 20 ел узгач, хатын табып, язучы Юрий Корольковка тапшырганнар. Ул анда миңа атап: «А ведь приятно, должно быть, Рушад, вновь встретиться с другом через столько лет!»,— дип язган.



**Рәсемдә:** Рушад ага (*сулдан икенче*) үзенең хәләл җефете Таифә ханым һәм көрәштәш дуслары Михаил Иконников (*Архангельск*), Фәрит Солтанбеков (*Үзбәкстан*) белән СССРның халык рәссамы, академик Харис Якупов остаханәсендә — Муса Җәлилгә багышланган картина янында (*1986 ел, февраль*)

Франциядә үзем белән бергә яшерен оешмада катнашучы Хәмиев, Гариф Маликов, Кәрим Ходжаев, Гарәф Фәхретдиновлар белән очраштым. Мин бик зәгыйфь идем, аягымда басып торырлык хәлем юк иде. Дүртенче батальонны шунда күчергәннәр икән, ә безнең капелла шул батальонның хозротасында иде.

Мине эшче команданың больницасына салдылар. Егетләр килеп ашаталар иде. Маликов ярдәме белән болар француз партизаннары, коммунистлар белән бәйләнешкә керә алганнар икән. Алар унсигезенче субдивизионның командиры капитан Сегельнең һәм штаб начальнигы подполковник Жевольд-Запольскийның заданиеларын үтиләр: ничә немец барын, кораллар күпме, кайчан җыелалар, кай җирдән чыгалар — барысын җиткереп торалар.

Бер көнне болар, унсигез егет, партизаннар ягына чыгарга булалар. Шуны белгәч, мине калдырмагыз, дип, бик үтенгән идем. Гарәф әйтте: «Сабыр ит, Рушад абый, без сине коткарырбыз, бераз көч җыеп ят»,— дип. Шул кичне алар — Гарәф Фәхретдинов, Әмир Үтәшев (ул хәзер Казанда яши), Гариф Маликов һәм башкалар — немец сакчыларын үтереп, коралларын алып, качалар. Иртәгесен мине, аларга җинаятьтәш дип, яңадан кулга алдылар да, шундагы Ле-Пюи төрмәсенә яптылар. Күпмедер вакыттан соң, машинага салып, кулларны арканнар белән бәйләп, этап белән атаклы Монлюк дигән Леон төрмәсенә алып киттеләр. Безне подвалда тоттылар. Һава җитми, тынчу. Судан чыгарып ташлаган балык кебек ятабыз! Шунда мин Зиннур Гатин дигән егет белән таныштым. Ул да качарга җыенган икән дә, немец складыннан мина алган вакытта, тотылган. Бер көнне меңнән артык француз партизаннарын һәм безне, кулларны бер-беребезгә богаулап, алып киттеләр Германиягә. Леон стансасында товар вагоннарына утырттылар. Утыз кешене — уң якка, утызын сул якка урнаштырдылар. Ә ишек төбендә ком тутырган капчыклар янында ике сакчы-автоматчы. Берсе — бер якка, икенчесе — икенче якка карап ята. Юлда, моментны туры

китереп, кечкенә генә кадак табып алдым (Минем яшьлегем, 1932 елдан алып сугыш башланганчы, чик буенда узды. Күптән түгел мине «Отличник-пограничник» дигән знак белән бүләкләделәр. Тагы «КППО» дигән бик кызыклы знагым бар — Краснознаменный панфиловский пограничный отряд» дигәне. Мин анда да хезмәт иткән идем). Элекке сәләтем ярады бит. Богауны ачтым мин, үземнекен дә, Гатинныкын да. Поезд бара инде. Менә ике шәһәр — Дижон белән Макон арасында, Турнус дигән разъезд янында эшелон кинәт туктый. Эшелон алдына, тимер юлга бомба ташлаганнар икән. Конвоирлар сикереп төшәләр дә тау яклап һөҗүм итеп маташкан партизаннарга каршы ут ачалар. Шундый атыш китә монда! Вагондагы сакчыларыбыз, кювет эченә яшеренеп: «фоейер! фойер!» — дип аталар, безгә карау да юк. Шул арада без дә сикереп төшәбез. Гатин бер якка йөгерә, мин — икенче якка. Йөзем бакчасына кереп чумабыз. Икәү генә түгел, безнең вагоннан гына да утызлап кеше коелышып шунда исән калдылар. Карыйм, янәшәмдә бер карт француз. Коммунист булып чыкты ул соңыннан... Аның белән бергә түгәрәк чокыр кырыена килеп туктадык та (французлар анда йөзем бакчасы өчен ашлама саклыйлар, күрәсең), шунда төштек. Тирә-юньдә туктаусыз атыш бара инде. Мин, бер тимер кисәге табып, сукыр тычкандай, җирне казый башладым, үземә ләхет алып, качарга урын әзерлим. Теге карт, әллә бу саташкан инде дигәндәй, куркынып тик карап тора. «Давай, капут, пух-пух!» — дим аңа, аңлатам инде. Шуннан ул да: «Уи, уи, мсье», — дип, казый башлады. Кереп посабыз йомшак җир астына. Атыш туктый — таудан һөҗүм иткән партизаннарны немецлар чигендергән, ахрысы. Конвой бик көчле бит. Йөземлектәге кешеләрне аулый башладылар бугай: «Хальт!» — дип кычкырган тавышлар, атышлар, ыңгырашулар... «Дук-дук-дук» — адымнары безгә ишетелеп тора. Сизәм, безнең чокыр кырыена ике немец килеп туктады. «Раус!» — дип кычкырдылар. Теге карт селкенергә азаплана. Котым очты! Куркып, чыга башлый инде бу, дип, муеныннан басып куйдым тегене. Немецлар аттылар-аттылар да китеп бардылар. Ярый әле, без яшеренгән яктан торып аттылар, каршыга чыгып атсалар — бетә идек. (Менә бит тагын бер үлемнән котылдым! Кайчандыр әниемнең әйткән сүзе һаман исемдә: «Унбер балам өчен дә бер Рушадым кулмәкчән туды, бәхетле булыр бу улым!» — дия иде. Ул күлмәкне әнием саклый иде, бер тартмага салып. Кибеп беткән иде...)

Тимер юлны рәтләгәннәр, ахрысы. Паровозның «ту-у-у» дип гудок биргәне ишетелде, менә «чух-чух-чух» итеп эшелон китеп барды. «Исән калдык», — дип күңел шатлана, йөрәк күкрәк эченә сыймый! Теге карт мине кочаклап маташа. Караңгы төшеп килә. Без ашыкмый гына чокырдан чыктык. Бакча кырыенда бер француз очрап, безгә өеннән су чыгарып бирде. Партизаннар югарыда, дип, кая барасын да күрсәтте.

Киттек без. Бервакыт «Атас!» дип, көтмәгәндә әрәмәлек арасыннан каршыбызга берәү килеп чыкты. Кулында җиңел инглиз автоматы. Кулларыбызны күтәрдек. Ул арада юлдаш картым сөйли башлады. Мине «рус, комрад», — ди. Шуннан теге автоматын муенына элде дә, юлны күрсәтте. Без тауга менеп киттек. Бара торгач, бер кечкенә генә йорт янына килеп җиттек. Эчендә — партизаннар. Бая немецлар белән атышканнар шулардыр инде. Араларында хатын-кызлары да бар. Бөтенесе кораллы. Шуннан безгә зур кружка белән — ике литр чамасы булыр — тутырып, коры шәраб салып бирделәр. Су урынына эчәм тегене, голт-голт итеп. Шәраблары тәмле шундый! Алар оста бит. Карт та калышмый миннән. Шуннан мин изрәп, ярым йокылы күземне ачып ятам, кешеләрнең башлары аста шикелле, аяклары югарыда. Хатын-кызларның юбкасы парашют булып күренә. Нишләп ачылмый икән болар, дип аптырыйм. Бераздан икебезне дә йөк машинасына утырттылар, бер сакчы — кузовта, икенчесе — кабинада. Алып киттеләр искиткеч матур Крузельский тауларына. Юлы, серпантин шикелле, уралып-уралып менә. Машина авырлык белән беренче тизлектә бара. Кузовтагы сакчыбыз җырлый (итальян булып чыкты ул). Тавышы матур. Шулай берничә сәгать узгандыр инде. Менә борынгы шато (замок) янына килеп туктадык. Бу кальга рыцарьлар заманында таш кыялар арасын уеп салынган. Капка янында — сакчы. Безне де Голль гаскәренең бригада штабына алып килгәннәр. Төшү белән теге картка җикеренә башладылар, җилкәсеннән тотып, тупас итеп этеп тә җибәрделәр. Минем белән дә шулай ук кыланалар. Фашистлар микән болар, партизаннар микән?.. Алып керделәр эчкә, картны — бер бүлмәгә, мине — икенчесенә. Допрос ала башладылар. Тәрҗемәчеләре бар, полякча сорый: «Яшермәгез, сез бит немец шпионы. Сезне махсус җибәргәннәр! Мин әйтәм: «Ничек махсус? Нәрсә, белмисезме әллә, меңләгән французны немецлар Германиягә алып бара иде бит. Турнус районында сезнең самолетлар тимер юлны бомбага

тотмады мени?!» Күп сорашып тормадылар, мине эткәли-төрткәли тимер ишекле подвалга кертеп яптылар. Анда юеш, тездән пычрак, лайлы идәннән лач-лач атлап кереп киттем. Карасам, анда немецлар утыра, арада — хатын-кызлар да бар. Мин стена буена барып бастым. Баягы шәрабның да көче бетте! Берме, икеме сәгать басып тора торгач, черем итеп тә алдым шикелле. Тан атты бер заман. Яктыда әйбәтләбрәк карыйм — чынлап та, хәрби киемле немецлар утыра. Шуны белүгә, үз-үземне кыздыра башладым: «Кая синең батырлыгын?! Син пограничник бит! Үлсәң дә егетләрчә үләргә кирәк!» Бардым да ишеккә гөрс-гөрс суга башладым. Аяк белән дә тибеп куям. Бар белгәнемне селкеп, русча да, үзебезчә дә сүгенәм! Бервакыт ишек артыннан: «Кес кесе сө?!» дип сорыйлар. «Я — русский офицер! — мин әйтәм.— Я — советский офицер! Вы не имеете права держать меня здесь! Идите и доложите, а не то я сейчас!..» Шуннан мине штабка алып киттеләр. Минем кан кызган, керү белән өстәлгә сугып: «Я — русский офицер! Я — советский офицер! — дип кычкырам.— Я у вас политического убежища требую! Вы прекрасно знаете, что я во время этапа бежал! Как смеете вы меня вместе с немцами в подвале держать?!» Тегеләр: «Вы — офицер, мсье, знаете, что мы обязаны проверять»,— диләр. Коль обязаны — так проверяйте! Я не возражаю, но с немцами не сажайте! Я у них в Берлине насиделся!»

Француз офицерының йокысы туйган, миңа көлемсерәп карап тора. «Ну ладно,— ди бу,— мы будем держать вас не в подвале, а на чердаке». Миңа бер фляга шәраб бирәләр (алар аны су урынына эчәләр), бер кисәк колбаса тоттыралар. Ашадым, эчтем, шуннан мине ат абзарының чарлагына алып менгереп яптылар. И — и! Үлектәй йоклаганмын шунда көне буе! Анда печән, салам — хуш ис, рәхәт. Төшләр күреп, изелеп йоклаганмын.

Кич белән уянып китсәм, чардак тулы кеше! Шау-шу! Үзебезнең татар егетләре — Закиров, Ризванов!.. Аннан Никитченко, Марченко дигән рус егетләре! Һәммәсе таныш. Алар да шул ук эшелоннан качканнар, тик французларга соңрак эләккәннәр. Туганнарча күрешәбез. «Сезне подвалда утыртмадылармы? Сезне алда шундый оҗмах көтә»,— дим.

Бер атна чамасы тикшерделәр безне. Аннан бригада комиссары мсье Дьюм: «Сезнең арада офицер бар бугай?» — дип, миңа ымлады. Бөтенесе: «Әйе, әйе, безнең командирыбыз ул булсын»,— диештеләр. Ни дисәң дә тикшерү вакытында җиде көн буена икмәген, шикәрен, ни бирсәләр — шуны мин өләштем. Һәммәсе миңа ышаналар иде. Яшем дә аларныкыннан олырак.

Шулай итеп, мсье Дьюм мине рус төркеменең командиры итеп куйды. Башта безне хуҗалык эшләренә куштылар. Соңрак сугыш операцияләренә катнаша башладык. Берәрегез кача калса, барыгызны да юк итәбез, дип кисәтеп куйдылар. (Теге подвалда утыручыларның барысын да аттылар.)

Сугышта без хәйран гына осталык күрсәттек.

«Французларның сәнгать җәүһәрләрен немецлар Германиягә алып китәләр!» — дигән хәбәр Парижның үзеннән килде. Менә ничек тә комачау итәргә кирәк иде.

Беркөнне безнең взвод, французлар ротасы белән бергә, төп автомагистральне контрольгә алды. Китәр алдыннан мин үзебезнекеләргә көрәкләр алырга куштым. «Нәрсәгә кирәк ул авыр көрәкләр?»,— дип французлар аптыраша. «Ничего, мин әйтәм, кирәге булыр әле!» Белеп торам: таулы җирдә немецның үз тактикасы бар — минометлардан аталар алар.

Барып житүгә, әрәмәлек арасында шахмат тәртибендә чокырлар казыдык. Җире йомшак иде. Командир килеп, колоннаның иң алгы машинасы якынаю белән аны атып яндырырга кушты. Егетләрнең һәркайсына задание билгеләнде. Марченко — пулеметчы. Аңа әйтеп куйдым: «Как только головная машина приблизится к кустарнику, стреляй, не дожидаясь команды. Старайся целиться в бензобак, чтобы поджечь машину».

Менә машиналар рәте күренә бер заман. Шундый күп — аргы очы күренми дә. Брезент бөркәвечле беренче машинаның якынаюы булды, Марченко ата да башлады. Утка чорналып шартлады бу машина. Туктады колонна. Китте ыгы-зыгы, шау-шу купты! Машиналарда хәзинә түгел, СС дивизиясе солдатлары булып чыкты! Франциядән Көнчыгыш фронтка барышлары икән. Безнекеләр анда фашистларны нык кына кыйнап яталар, күрәсең. Иң ышанычлы частьләрен Совет Армиясенә каршы җибәрәләр.

Французлар окоп казып мәшәкатьләнмәгән иделәр, берничәсе пуля тиеп егылды, калганнары чигенә-чигенә качып киттеләр. Без генә һаман атабыз. Немецлар ут көлтәсен безнең якка бордылар. Миналар оча башлады. Шуннан мин: «Прекратить огонь!» — дип команда бирәм. Безнең тарафтан атыш тынгач,

немецлар тауга менеп тормадылар, ашыгып, үз юлларына китеп бардылар. Бездән берәү дә үлмәде, барыбыз да исән-сау! Французларның үлгәннәрен бер җиргәрәк куйдык. Агач кисеп, носилка шикелле нәрсәләр ясап, яралыларны алып төшәргә тора идек, бая качып киткән французлар кире килделәр. Үлгән көрәштәшләрен күреп кычкырып елый башладылар. Бераздан казармабызга кайттык.

Ялдан соң мсье Дьюм чакыртты мине. Бөтен шартын китереп, строевой шаг белән каршына килеп: «Командир русской группы капитан Рушад Хисамутдинов по вашему приказанию прибыл!» — дип рапорт бирдем. Егетләргә дә әйтеп куйган идем: «Шалапайлык булмасын! Дисциплина армиядәге кебек булсын»,— дип. Француз партизаннарында бернинди тәртип юк — шәрәо эчеп алалар да, теләсә ничек болагайланып йөриләр шунда. «Сезнең группада үлгәннәр яисә яраланганнар бармы?» — ди мсье Дьюм. «Юк»,— мин әйтәм. «Французлар үлгән, сезнекеләр юк. Моны ничек аңларга?» «Без немецлар белән сугышкан кешеләр. 1941 елда ук мин хәтәр яуларны күрдем. Таулы урында немец һәрчак миномет куллана. Окоп — алардан бердәнбер котылу чарасы. Сезнең егетләрегез без окоп казыганда көлеп тордылар бит».

Берничә көннән болар безне бүләкләргә булдылар. «Сез орден телисезме, әллә кыйммәтле бүләк бирикме?» — диләр. Мин егетләр белән сөйләштем: «Ни эшлибез, орден йә кыйммәтле бүләк — кайсын сайлыйбыз?» — дим. «Әлбәттә, бүләк!» — диләр болар! — Нәрсәгә кирәк аларның орденнары!» Шулай итеп, миңа алтын сәгать бирделәр — хатын-кызныкы (Мин аны үзем белән өйгә алып кайттым, алтын түгел икән, йөгертелгән генә). Егетләрнең дә күбесенә сәгатьләр, портсигарлар бирделәр.

Французлар белән без берничә операциядә катнаштык. Фашистлар бәреп чыгарылды. Фронт линиясе Эльзас-Лотарингиягә — Германия ягына күчте. Генерал де Голль, партизан хәрәкәтен бетереп, француз регуляр армиясен төзи башлады. Мсье Дьюм безгә болай диде: «Макизарлар булмаячак хәзер, ә сезгә армиягә хезмәткә керү өчен француз гражданлыгын алырга кирәк. Уйлагыз да, иртәгә җавабыгызны әйтерсез». Егетләрнең барысын җыеп сөйләштек. Мин әйтәм: «Многих из вас я не знаю. Знаю только, что в бою были героями, сражались хорошо. В чем ваша вина перед Родиной, мне не известно. Подумайте хорошо, если решите принять подданство, навсегда лишитесь Родины»,— дим. «А как командир наш думает?» — диләр. Мин әйтәм: «У меня дома мать, сын, я к семье поеду. Большой вины перед Родиной я не чуствую, разве что себя застрелить не смог. В Германии я в тюрьмах сидел., только и всего. Для подпольной организации много сделал. Я вернусь, не стану принимать подданства». Шуннан бөтенесе дә кайтырга булдылар. Ростовцев дигән кеше генә калырга ниятләде. Шундый иде ул — ана туган ил дә, берни дә кирәкми иде.

Иртәгесен теләгебезне мсье Дьюмга җиткердем. СССР консулы Богомолов Парижга кайткан икән инде. Консул һәм хәрби миссиядән хәбәр килгәнче мине комендант итеп билгеләделәр. «Складта ни бар, азык-төлек тә, кием-салым да — бары да сезнеке!» — диде мсье Дьюм.

Калдык инде. Җәмгысы 21 кеше. (Миндә исемлектә бар. Соңыннан, партизан хәрәкәтенә катнашкан өчен, дип, безгә акча да бирделәр.) Арада 12 татар егете: Гайсин, Ходжаев... (Күбесе истән чыккан инде.) Парижга үзебезнең хәлне язып җибәрдем. 1944 елның декабре генә әле. Тиздән җавап килде: «Прибыть в Казанпардьюю»,— диелгән. Коралларыбыз белән шул Казанпардьюга киттек.

Анда бер департаменттан гына да җиде меңләп кеше җыелган. Барысы да безнекеләр. Егермеләп милләт кешесе бардыр. Һәммәсе Франциядә сугышып йөргән. Францияне азат итүдә зур хезмәт күрсәткәннәр. Бөтенебезне тезеп, генерал-майор Вихорев боерык бирә: «Командный состав, 15 шагов вперед! Младший командный состав — 10 шагов вперед! Рядовые — на месте!» Совет хөкүмәтенең өндәмәсен укыйлар безгә: «Родина-мать прощает даже тех, кто против нее с оружием выступал»,— дип. (Әгәр шулай димәсәләр, берәү дә илгә кайтмас иде!).

Миңа чират житте, сорашалар: «Где служил?» «С 1932 до начала войны служил в пограничных войсках — в Градовском 58-ом отряде, в маневренной группе, оперативном дивизионе». «А кто был командиром маневренной группы?» Мин әйтәм: «Майор Минкевич. Потом меня перевели на заставу Духовскую, а на место Минкевича какой-то с тремя шпалами красивый, чернявый небольшого роста полковник прибыл. Я его фамилии не знаю»,— дим. Теге кеше көлемсерәп куйды. «Вы останьтесь»,— ди. (Шул полковникның үзе булып чыкты бит бу! Әйтәм ич, бәхетем бар минем — күлмәктән туганмы.) «Я назначаю

вас комиссаром партизанского батальона, помощником командира по политпросветработе»,— ди бу. Меннән артык кеше бит анда! Тиз арада шул батальонның командиры да булып алдым. (Муса Җәлилнең 80 еллыгына чыккан альбомда ул чакның фоторәсемнәре бар.) 1944—45 елларда, сугыш беткәнче, партизаннарны Совет Армиясе уставы белән тәрбияләдек. Французженкаларга өйләнеп, шунда калмасыннар, илебезгә кайтсыннар, дип тырышкан булдык.

Сугыштан соң без, офицерларны, Мәскәү янындагы Невель дигән җиргә — фильтрацион пунктка алып кайттылар. Контрразведка, «Смерш» шунда баштанаяк тикшерде безне. Бер ай үткәч, мин унсигезенче артиллерия частеннән демобилизацияләндем.

Алма-Атага кайтып, әнием белән күрешеп, хәл-әхвәл белешкәч, гаиләм янына Ошка бардым. Анда ОПВК начальнигы, баш инспектор һәм баш ветврач булып ит комбинатында эшли башладым.

1949 елның ахырында, зәхмәтле Берия-Аббакумов заманында, әсирлектә булган офицерларны кулга алу башланды. Мин дә шул вакытта 58 нче статьяның 1Б пункты буенча (сугыш җинаяте), хөкем ителдем. Муса Җәлил белән бергә көрәшеп йөргәнем өчен (хәер, Мусаның үзенә дә ул заманда җинаятьче дип карадылар); фашист җәһәннәмендә — Варшава, Берлин, Леон төрмәләрендә газап чиккәнем өчен; партизаннар сафында Францияне фашистлардан азат итүдә катнашканым өчен биш елга түгел, егерме биш елга төрмәгә утыртсыннар әле! (Үлемгә хөкем иткәннәр иде, аннан «ввиду указа об отмене смертной казни» дип, егерме биш ел бирделәр.) Документлар, белешмә-кәгазьләрем булуга карамастан! Гомеремдә дә минем немец армиясенә ант биргәнем булмады! Берничә ай эчендә без, җәлилчеләр, шундый зур, мөһим эшләр күрсәттек! Фашистлар юкка гына кисмәделәр бит иптәшләремнең башларын!

Мин бик авыр шартларда эшләдем — Кыргызстан шахталарында, Кемерово өлкәсенең глубинкаларында урман кистем (бер кубометр киссәң — бу искиткеч зур норма! — 400 грамм икмәк бирәләр).

Татар бугазында Ванин дигән порт бар. Шунда меңнәрчә кешеләрне пароход трюмнарына тутырып, төньякка алып китәләр. Южный Сахалин, Петропавловск-Камчатский, Беринг диңгезе, Беринг бугазы, Чукотка ярымутравы, Төньяк Боз океаны, утраулар, Индигирка, ахырда — Яна тамагы. Юлда күп кеше һәлак булды. Ул трюмда күргән газаплар! Кысынкы, бөркү, сасы, пычрак, әсирләр дизентериядән кырыла торалар. Мәетләрне сугы ыргыта баралар! Врачыбыз бар иде, ул да үлде. Мин, ветврач буларак, уртак тел тапкан идем аның белән. Ул авыруларга ярдәм итә иде. Өскә чакыртып, дарулар, һәртөрле таблеткалар бирә иде. Ул үлде, сумкасы миндә калды. Пароход фельдшеры: «Врача на палубу!» — дип кычкыргач, әсирләр: «Ә врача уже подали наверх! Его, небось, уж акулы съели»,— дип җавап бирделәр. Мине чакырткач, әйттем: «Я — ветврач, эпизотолог. Сумка у меня вот, получите». «Нет уж, теперь давайте вы раздавайте лекарства»,— ди фельдшер.

Инде без Яна тамагында. Салкын кыш. Трюмнардан халыкны чыгаралар. Баржаларга төяп, елга буйлап бераз алып баралар да, ачык бер җирдә туктыйлар. Монда касетелит дигән руда бар икән. Бу руда аккургаш, кургашын һәм башка элементлардан тора. Ураны да бар. Якутиянең читe инде бу. Лагерь начальнигы, украинлы икән, речь тотты. Монда бер көн өч көнгә чутлана икән. Егерме биш еллыклар, әгәр намус белән эшләсәләр, сигез-тугыз елда котылырга мөмкин, имеш. Шуннан, арагызда медик бармы, дип сорый бу. Мина төртеп күрсәтәләр. «Вы шо, медик?» «Я — не медик, а ветврач. Был у нас врач, да умер. Сумка вот осталась». «Да, якая разница! Будешь у меня хвершалом. Набери себе двадать человек да органзуй санчасть».— Шулай фикер алышкач, латыш, татар, украин, руслардан эшчән кешеләрне җыйдым. Каракларны алмыйм: алар, билгеле инде, эшләргә яратмыйлар.

Амбулаторияне оештырабыз. Шулай итеп, биш-алты ел гомерем монда уза. Өйдән, туганнардан посылкалар килеп торды, шуңа күрә мин исән калдым.

Алты ай — көн, алты ай — төн. Өстебездә бушлат. Коточкыч суыклар! 50 градус салкында гына эшкә чыгармыйлар. Касетелит өстә генә ята. Бульдозер сыдырып китереп, тасмага төшерә дә, аннан, руда су белән аралашып, агып китә. Кешеләр бертуктаусыз үлеп торалар, көнгә биш-алты мәет. Караклар үзара сугышалар, авырып, өшеп калучылар да булды.

Таифә, хатыным: «Сиңа ничә ел срок бирделәр?» — дип, һаман сорап яза хатларында. Мин тикшерүчегә әйтеп куйдым: «Проявите хоть немного гуманности, не говорите матери, жене, моим близким правды. Скажите, что я осужден на 5 лет».

Себердә төрле хәлләр булды. Этап белән йөзәр чакрым ерaклыкка урман кисәргә куып баралар. Өстән яңгыр явып тора, үзебез ач-ялангач, бер адым уңга яисә сулга тайпылсаң — кисәтүсез аталар, приклад белән кыйныйлар! Авыр чакта таяныр кешең булсын — үзбәк, кыргыз, руслар арасыннан дусларым бар иде. Шул кешеләр әле дә исән. Хәзер дә туганнарча аралашып торабыз, бер-беребезгә ярдәм итеп.

1955 елның азагында (Хрущевка рәхмәт!) амнистия булды. «Со снятием судимости» дигән карар белән.

Өйгә кайттым, башта әнием янында Алма-Атада булдым.

Көннәрдән бер көнне (1957 ел) «Комсомольская правда» да мине үлгән дип язганнар. Франциядә мин, Гарәф Фәхретдиновка Мусаның төрмәдә язган шигырьләрен биргәндә: «Бәлки, мин исән калмам»,— дигән идем. Хәлем бик авыр иде ул чакта. Энем Габделхак, бу газетаны укыган да, миңа — Ошка шалтыратты. Шуннан мин үзем ул газетаны табып укыдым. Мәскәүгә, редакциягә хат яздым: «Мин исән, үлмәдем, дип. Әгәр кызыксынсагыз, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында, яшерен оешмаларның ничек барлыкка килүе турында бөтенесен сөйләп бирә алам»,— дип.

Шуннан күп тә үтми, Гази Кашшаф дигән язучы — Мусаның якын дусты икән — Ошка килеп төште. Фронтка киткәндә, Муса Җәлил аңа бөтен әсәрләрен, архивын васыять итеп калдырган булган. Таныштык. Унбиш көн бергә булдык. Мин зур гына хуҗалыкның рәис урынбасары идем ул вакытта. Бергә тауларга йөрдек, буш вакыт булган саен, барысын да сөйләдем аңа. Казанга кайткач, Гази Кашшаф КГБның бер таныш генералы белән сөйләшкән. Теге әйткән: «Хисаметдинов — единственный, кто рассказал всю правду о легионе, о подпольной борьбе. За это он и пострадал. Почему он на реабилитацию не подает? Мы ничего не имеем против»,— дигән. Гази Кашшаф миңа: «Син яз, Рушад. Болар тарих өчен әһәмиятле нәрсәләр. Син тарихта калырга тиеш»,— дип хат салды. Шуннан мин СССРның Генераль прокуроры Руденкога бөтен тормыш юлымны тасвирлап язып җибәрдем. Шуннан СССР Хәрби коллегиясенең махсус киңәшмәсе мине һәм Маликовны (аны үлгәннән соң) аклап чыкты. Бу хәл 1967 елда булды. Нигә күп еллар узгач кына диярсез, чөнки баштарак мондый мәшәкатьләр турында ишетәсем дә килми — хаксыз рәнҗетелүгә шул хәтле күнелем каткан иде.

Без, җәлилчеләр, бер-беребез каршында шундый васыять әйтешкән идек: кем дә кем исән калып, Илгә кайта икән, халыкка җәлилчеләрнең нинди авыр шартларда да көрәш рухын җуймаулары хакында сөйләргә тиеш. Менә мин исән. Шулай булгач, кая гына барсам да һәммә кешегә, бигрәк тә яшьләргә, бар белгәннәремне сөйләп калырга, васыятемне үтәргә тырышам!..

*Әлеге сәхифәдә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мидхәт Шакирҗанов фоторәсеме һәм Рушад аганың бертуганнары — Алматыда яшәүче Ибраһим ага Хисаметдиновта, Казанда гомер кичерүче Кәшифә ханым белән аның улы Әнвәр әфәнде Килеевларда, кызы — ошбу язманы журналга хәзерләп тапшыручы әдибә Азалия ханым Бадюгинада кадерләп сакланылган фоторәсемнәр файдаланылды.*



# ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ РЕАЛИЗМЫ

ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Билгеле булганча, зур һәм җитди сәнгать әсәрләрен тудыру ул алдан уйлаганча гына барып чыга торган нәрсә түгел. Ул — каршылыклы һәм газаплы, өзлексез үзгәрешләр кичереп бара торган процесс. Кайбер очракларда тәмамланып беткән әсәр белән художникның алдан уйланган фикере арасында шактый гына аерма да була. Лев Толстойның «Сугыш һәм дөнья» романын гына алып карыйк. Аның декабристлар турында язам дип керешкән әсәре эшләү дәверендә язучыга каттый рәвештә үзенең логикасын тага башлый, әдипне чирек гасырга чигендереп, тасвирлау өчен гасыр башланган елларны, аннан 1812 елгы Ватан сугышы чорын алырга мәҗбүр итә. Бу күренеш башка кайбер язучыларның әсәрләренә дә хас. Минем әти Таҗи Гыйззәт иҗатын да кырыйлатып узмаган ул.

Мәсәлән «Ташкыннар» трилогиясе. Әсәр башта таррак планда күздә тотыла. Моның турында әтинең шәхси архивындагы бер документ сөйли. Бу — аның Язучылар союзы идарәсенә 1936 елның 5 декабрендә ирештергән гаризасы. Анда түбәндәге сүзләр бар: «Мин хәзерге көндә «Семья фаҗигасе» исемле әсәр өстендә эшлим. Әсәремнең темасы: «1914—1917 еллар, империалистик сугыш нәтиҗәсендә урта хәлле крестьян семьясында туган Шәйморат абыйның семья фаҗигасе...» Авторның искәртүе буенча, ул әсәрне көчле драма итеп бирергә уйлый, әсәрен 1937 елның августына язып бетерәчәген белдерә...

Шушы документтан күренгәнчә, әсәр башта семья фаҗигасе планында уйланыла. Ләкин язылу процессында гаять зур үзгәрешләргә дучар була. Әлбәттә, ул үзгәрешләр төп персонаж дип күздә тотылган «Шәйморат абый»ның «Биктимер карт»ка әверелүенә генә кайтып калмый, үзгәреш шактый җитдирәк һәм аның социаль мәгънәсе, эчтәлеге дә башка. Моны исбатлау өчен әсәрне иҗат итү процессындагы кайбер этапларга күз ташлыйк.

1937 елның октябрендәге бер язмасында Таҗи Гыйззәт «Ташкыннар» әсәренең төп идеясе турында болай ди: «Авылның ярлы-батрак, урта хәлле крестьяннәренең империалистик сугыш, февраль буржуаз-демократик революциясе аша Бөек Октябрь социалистик революциясенә килүләрен художество образлары белән бирү...» (Т. Гыйззәт. Әсәрләр, 4 томда, 4 нче том.— Казан, 1978, 231 б.). Шушы ук фикер тагын бер документта, ул да булса «Ташкыннар»ның премьерасыннан кайткан кичне (1937 елның 5 ноябре) язып калдырган истәлегендә чагыла. Һәм ул бигрәк тә җыйнак, төгәл рәвештә 1938 елның 8 февралендә башкорт театры режиссеры Имашевка язган хатында ачыла (Имашев — «Ташкыннар»ны

Уфа сәхнәсендә куючы). «Кыскача әйткәндә,— дип яза Тажи Гыйззәт,— «Ташкыннар» әсәре крестьяннәрнең империалистик сугыш, буржуаз февраль революциясе аша Бөек Октябрь социалистик революциясенә килүләрен күрсәтә.» (Шунда ук, 234 б.)

Әсәр Татар Академия театры сәхнәсендә зур уңыш казана. Ләкин әти үзенең иҗат җимеше белән канәгатьләнми. Моның сәбәбен ул 1941 елның июнь аенда (сугыш башланганчы) түбәндәгечә билдерә: «...әсәр язылып беткәч тә, шушындый зур тарихи чорны крестьяннәрнең революциягә килүенең барлык этапларын бер генә әсәрдә күрсәтеп бетерү — алга куелган максатны тулысынча ачуда, бай, катлаулы вакыйгаларны киң яктыртуда, образларны, характерларны тулы итеп бирүдә бик зур кыенлыклар һәм чикләүләр тудырганы күренде. Нәтиҗәдә әсәр кирәгеннән артык тыгызландырылган булып чыккан иде. Мондый әсәрне сәхнәдә кую өчен театрга да, тулысынча тирәнлек белән аңлау-тәэсирләнү өчен тамашачыларга да җинел түгел иде.

Шул сәбәпле, әсәрнең беренче вариантын язып бетергәч тә, миндә аны соңра, югарыда күрсәтеп үтелгән һәрбер аерым чорны үз эчләренә алган өч пьеса — трилогия итеп эшләү фикере туды һәм бу эшкә мин керештем дә инде (шунда ук 240—241 б.). Билгеле булганча, Тажи Гыйззәт үзенең максатына ирешә: трилогиянең соңгы, өченче кисәге (беренче кисәге — «Шомлы көннәр», икенчесе «Даулы көннәр», өченчесе — «Данлы көннәр» — К. Г.) 1948 елны язылып бетә.

Документлардан (әлбәттә, беренче чиратта «Ташкыннар» трилогиясенең үзеннән) күренгәнчә, Тажи Гыйззәтнең иҗат ителгән әсәрне баштагы күзаллавы һәм аны язып бетергән реаль гәүдәләнеше арасында аерма чамасыз зур. Безнең өчен әсәрнең үзгәрү юнәлеше дә зур әһәмияткә ия: башта ул семья фаҗигасе планында күрелгән булса, язылу процессында киң полотнолы халык эпопеясын тәшкил иткән социаль драмага әверелә.

Мисал өчен Т. Гыйззәтнең тагын бер танылган әсәрен — «Наемщик» музыкаль драмасын алып карыйк. Бу әсәрен язу өчен әти кечкенә генә бер факттан файдалана. Ульяновск шәһәрендә яшәгәндә күршедәге бер ломовой извозчик аңа үзе белгән кызыклы гына вакыйганы сөйләп бирә. Нииндидер мулла, солдатка алынасы улы урынына бер егетне яллап, улын солдат хезмәтеннән йолып кала. Шушы фактны Т. Гыйззәт «эләктереп алып», «Наемщик» пьесасын иҗат итә.

Бу пьесаның да беренче варианты чагыштырмача тар темага, әнә шул Иманкол мулла белән наемник Батырҗан арасындагы мөнәсәбәткә корылган кечкенә генә әсәр булып чыга. Пьеса сәхнәдә уйнала, үзенә күрә азмы-күпме уңыш казана. Ләкин автор аның белән генә канәгатьләнергә теләми, әсәр өстендә эшләвен дәвам итә, аны социаль коллизияләр белән баета, геройларны, гомумән, бөтен сюжет линиясен конкрет тарихи шартларга, алар тудырган социаль экономик мөнәсәбәтләргә буйсындыра. Нәтиҗәдә, әсәрнең җирлеген Казан губернасында 1861 елдагы крестьян күтәрелешләре тәшкил итә башлый. Ә Иманкол мулла белән Батырҗан арасындагы мөнәсәбәт, әсәрнең исемен билгеләүдә роль уйнавын дәвам итсә дә, социаль әһәмияте ягыннан икенче рәткә чигенә, әсәрнең кызыклы бер коллизиясе булып кына кала. Мин биредә «Наемщик» пьесасының музыкаль драма итеп эшләнүенә кагылмыйм. Бу — бөтенләй башка һәм мөстәкыйль мәсьәлә.

Янсә тагын бер әсәрне искә төшерик. Тажи Гыйззәт аны язу өчен үзенең әтисе белән әнисенең тормышында булып узган кайбер вакыйгаларны файдалана. Шулай, 1922 елда «Талир тәңкә» пьесасы барлыкка килә. Әсәр сәхнәгә куела, авторга күпмедер куаныч китерә. Ләкин, «Наемщик»ның тәүге варианты кебек, бу да авторга зур канәгатьләнү бирми. Сәбәп шул ук: теманың тарлыгы, әсәрдәге коллизияләрнең, драматург тоя, аңлый башлаганча, социаль яңгыраш биреп бетерә алмавы. Моңа ул зур әһәмият бирә, аны үзе өчен принципиаль мәсьәлә дип саный. Бу турыда Т. Гыйззәтнең театрлар адресына юнәлдерелгән мөрәҗәгате сөйли. Аның эчтәлеге түбәндәгечә:

## Редакциягә ачык хат

Минем татар сәхнәсендә уйналып йөри торган «Талир тәңкә», «Наемщик» исемле әсәрләремне Главлит, Гублит, Улитләрдән моннан соң татар сәхнәсендә куйдырмауларын сорыйм. «Талир тәңкә» моннан сигез еллар элек язылып, нәфәсәт һәм сәяси яктан күп кенә кытыршылыклары бар иде. Бу кимчелекләр «Наемщик»та да күп иде. Әдәбият, сәхнә мәйданында эшләүче иптәшләрнең, шулай ук Мәскәү үзәк татар театры художественный советының күрсәткән

күзәтмәләре белән яңадан төзәтеп яздым. Моннан соң сәхнәгә куярга теләгән театрлар, труппалар һәм драмкружоклар кулымдагы яңа нөсхәләрен алып куюларын сорыйм.

Т. ГЫЙЗЗӘТОВ.
*«Кызыл Татарстан», 1929 ел, 9 май.*

Шунлыктан Тажи Гыйззәт 30 нчы еллар башында бу әсәренә яңадан кайта һәм аны, үзе өчен яңара, камилләшә барган принциплардан чыгып, үзгәртеп иҗат итә. Әсәр 1934 елда Татар Дәүләт академия театры сәхнәсендә «Чаткылар» драмасы рәвешендә үзенең яңа гәүдәләнешен таба.

Тажи Гыйззәтнең үз әсәрләре өстендә күп эшләгәнлеге, аларның күбесен кат-кат төзәтеп, яңабаштан язганлыгы турында аның белән бер заманда яшәгән артистлар һәм язучы халкы яхшы белә иде, бу турыда матбугатта да әйтелмәде түгел инде. Тажи Гыйззәтнең әлеге сыйфатын гадәттә аның тырышлыгы, үз хезмәтенә таләпчән каравы дип бәялиләр. Бу әлбәттә, хак сүз. Ләкин алай әйтү мәсьәләнең асылын ачып җиткерми әле. Нәрсәдә генә соң ул асылы?

Тажи Гыйззәт артист һәм драматург булып 20 нче еллар башында формалаша башлый. Аның иҗат юлындагы беренче адымнары татар драматургиясе һәм театры өлкәсендә аңа хәтле, шулай ук аның заманында яшәгән традицияләр җирлегендә башкарыла. Әлбәттә, милли традицияләр бер калыпта гына түгел, алар төрле. Бер төрләләре язучылык эшенә керешкән артистны сокландыра, ана ниндидер йогынты ясый, икенчеләре, киресенчә, аның тарафыннан кабул ителми, кире кагыла. 20 нче еллар азагы һәм 30 нчы еллар башында Т. Гыйззәт, кайбер тискәре традицияләрне тәнкыйтьләп, яңа эстетик программа сайларга керешә. Соңгысы исә язучының аңында билгеле бер установкалар рәвешендә яши башлый. Ул нинди булса да теоретик положениеләр формасында булмаска да мөмкин. Алар беренче чиратта язучының аңында, аның чынбарлыкны тоюы, аңа бәя бирү һәм шулай ук сәнгатьнең объектив функцияләрен, аның нинди булырга тиешлеген аңлау, бертөрле критерийлар рәвешендә яши. Тажи Гыйззәтнең художество эстетик критерийларын аңлауда аның түбәндәге сүзләре ярдәм итәргә тиеш. «Кайбер язучылар,— дип яза ул,— авыл тормышыннан алып язылган драма әсәрләрендә кыз белән егет арасындагы мәхәббәтне төп тема итеп алалар да, шул чорның политик, экономик шартларын томалап калдыралар...» (Т. Гыйззәт. Әсәрләр. 4 томда. 4 нче том, Казан, 1978, 230 б. Ассызык минеке — К. Г.).

Аңлашыла ки, шушы принципларны тәнкыйтъ күзлегеннән бәяләгән язучы үзе ниндидер башка кретирийлар белән эш итәргә омтыла. Һәм шушы яңа критерийлар, әйтергә мөмкин, язучының эстетик программасын билгели дә, аның иҗат процессы белән җитәкчелек итә. Ул язучының башта фәлән төрле итеп (өстәнрәк, тирәнгә кермичәнрәк) уйланылган темага, образларга, коллизияләргә төрле «төзәтмәләр» кертергә, аларны шактый үзгәртүдә роль уйнарга мөмкин. Т. Гыйззәтнең кайбер әсәрләре өстендә, югарыда әйтелгәнчә, кат-кат эшләвендә, аларны конкрет тарихи чорның социаль-экономик элементлары белән сугара баруында ул реализм методының логикасы, аның кушуы буенча эшләү нәтиҗәсе дип карарга кирәк.

Ф. Энгельс язучы Бальзак турында шундый сүзләр калдырган: «Мин,— дип әйтә ул,— Бальзакның «Кешеләр комедиясен» укып, хәтта экономик детальләр ягыннан да шушы чорның барлык экономистлары, тарихчылары, статистлары язганга караганда күбрәк белүгә ирештем.» (Әсәрләр, XXVII т. 29 бит). Бу — сәнгатьтә аналитик алым, ягъни реалистик метод кулланганда шулай була. Чын реализм әсәре башка методлар белән иҗат ителгән әсәрләрдән нәкъ шуның белән аерылып тора да: ул художество чаралары белән кокрет илнең, конкрет халыкның, конкрет чорда булган хәсиятләрен нәкъ чынбарлыкның үзендәгечә, конкрет рәвештә ачып сала. Тажи Гыйззәт үзенең югарыда аталган әсәрләре өстендә кат-кат эшләгәндә шушы әсәрләрнең геройлары хәрәкәт иткән чорларның конкрет шартларын, аерым кешеләр һәм социаль төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләрен ачуга басым ясый. Мәсәлән, «Чаткылар» да, «Талир тәнкә» дә яратышу гына түгел, бәлки дөнья хәтле социаль-политик проблемалар. Авыл халкы белән Сабир Ишбулдин арасындагы конфликт та абстракт (берәүләре — «ярлы», икенчеләре «бай») рәвештә генә түгел. Каршылык — заманча конкрет. Сабир бай, Столыпин реформасы ачкан мөмкинлекләрдән файдаланып, община җиренең иң яхшы өлешен үзенә умырып ала. Аннары крестьян халкын — кемне алдап, кемне куркытып, юмалап, кемнең кайчандыр алып торган бурычын түли алмавыннан файдаланып, юк бәягә генә аларның иманаларын үзләштерә. Шулай итеп, әсәрдә тимерче Гаязның юлына төшкән кондәше — традицион сюжетлардагы кебек

абстракт «бай малае» гына түгел, ул конкрет тарихи чынбарлыкның конкрет социаль-политик характеристикаларына ия булган конкрет «бай малае», конкрет фигура.

Бу — реализм. Шушы метод турында сүз йөрткәндә аны ялгыш аңлату да еш кына очрый. Янәсе, реализм ул чынбарлыкны «дөрес чагылдыру» методы. («Правдивое, объективное отражение действительности»). Болай әйтү фәнни яктан дөрес түгел. Әгәр дә без реализмның асылын «дөрес, объектив чагылдыру» дип бәялибез икән, ул вакытта башка методлар) әйтик, классицизм яисә романтизм) «дөрес, объектив чагылдырмый» дигән нәтиҗәгә урын калдырабыз. Чынлыкта исә реализм ул чынбарлыкны аналитик алым белән чагылдыру. Классицизмда да, шулай ук романтизмда да ул бик саран бирелә. Фонвизинның «житлекмәгән егет» пьесасында һәр персонаж ниндидер идея рупоры. Шуны персонажларның исемнәре генә дә әйтеп тора: Правдин, Софья, Милон Скотининнар, Вральман һ. б. Биредә персонажларның психологик кичерешләренә, шулай ук аларны чолгап алган экономик детальләргә (аналитикага) әллә ни урын юк. М. Горькийның «Давыл хәбәрчесе» шулай ук Такташның «Жир уллары» әсәрендә дә — шул ук хәл: аналитик алымга урын калмый. Әгәр дә реалистик әсәрләрдә дөреслек бар икән, ул беренче чиратта, нәкъ аналитик алымның нәтиҗәсе дип каралырга тиеш. Аналитик алым, Энгельс әйткәнчә, әсәрне экономик (һәм, әлбәттә, башка әһәмиятле) детальләргә бай итә дә.

Тасвирлана торган предметны аналитик алым белән, конкрет (мөһим) детальләр аша бирү өчен, әлбәттә, күпне белергә дә кирәк. Тажи Гыйззәт үзенең язмаларында нәкъ шуны игълан итә: «Ташкыннар» әсәре өстендә елга якын эшләргә туры килде. Чөнки авылның ярлы-батрак, урта хәлле крестьяннарының империалистик сугыш, февраль буржуаз-демократик революциясе аша Бөек Октябрь социалистик революциясенә килүләрен художество образлары белән бирү өчен бик күп укырга, шул заманны бик нык өйрәнергә... туры килде» (Шунда ук, 231 б.). Моның шулай икәнлегеН исбатлау читен түгел, Т. Гыйззәтнең шәхси китапханәсендәге тарихка багышланган китаплар аның төрле билгеләре, комментарийлары белән чуарланган.

Мәсәлән, ул мәзәк кенә башланган «Наемщик» әсәрен иҗат итүдә (ломовой грузчик Кәлимулланың наемщиклар турында сөйләве) Т. Гыйззәт күп этаплар кичерә. Югарыда әйтелгәнчә, әсәрнең уннан артык варианты яши. Бу турыда минем махсус язган зур мәкаләм басылып чыккан иде («Наемщик» музыкаль драмасының... драмасы». «Ватаным Татарстан», 1992 ел, 237—241 саннар). Либретто өстендә эшләү белән бергә ул, туктаусыз рәвештә әсәрнең социаль эчтәлеген тирәнәйтү, аның социаль мотивациясен тарихи чыганаклар белән генә чикләнмичә, өстәмә рәвештә эзләп, үзе тапкан фактлар белән ныгыту, гомумән әсәрдә барган вакыйгаларны һәр яктан дәлилләү белән шөгыльләнә.

Татар җирендә крепостной коллык булганмы, юкмы — бу мәсьәлә, минем уемча, ахырга хәтле тикшерелеп җитмәгән әле. Рәсми чыганаклар буенча Казан губернасында ул (крепостной коллык) рус авылларына гына кагылган. Болай әйтү өчен дәлил итеп шуны файдаланалар: тарихка Безднадагы восстание гына кереп калган. Билгеле булганча, анда рус крестьяннары күтәрелгән, ләкин җәзаланучылар исемлеге арасында берничә татар фамилиясе дә бар. Шуннан чыгып (?), безнең тарихчылар «татар җирендә крепостной коллык булмаган» дип баралар. Моны нигезгә салып, татарның милли характеры турында да нидер әйтергә телиләр әле. Ярый, бу мәсьәләне калдырып торыйк. Безне бу очракта кызыксындырганы башка нәрсә. Ул да булса, әтинең әлеге мәсьәлә буенча эзләнүләре, табышлары. Ул Казан губернасы тарихы буенча күп чыганакларны актара. Әлеге чыганаклар хәзер дә әтинең шәхси китапханә киштәләреннән төшкәне юк. Ләкин «Наемщик» әсәре өчен иң мөһим материалны ул шулай да үзенең күзәтүләре нигезендә табуга ирешә. Укучыны ялыктырудан берникадәр уңайсызланып, мин шулай да әтинең архивында табылган бер материалны китерер идем. Материал кульъязма рәвешендә. Ул аны «Тирсә хәбәрләре» дип атаган.

Әти үзенең язмасында:

«Тирсә» дигән сүзнең кайдан һәм нидән алынганын әйтүче кеше таба алмадым», — ди. — Асылда бу элекке алпавыт Котлыкай морзаның кол крестьяннары авылы.

Мин аларның «Мордыби» (дөресе Морза-би, булса кирәк) авылы белән ике арадагы утарларын һәм пыяла заводларын хәтерлим. Зур-зур йортлар, төрле каралтылар. Кара урмандай бакчалар, тегермәннәр бар иде. Хәзер аларның берсе дә юк, әлбәттә. Ләкин алардан калган паркларның күп кенә зифа буй агачлары хәзер дә үсеп утыралар. Күрәсең, бу алпавыт андый-мондыйлардан

гына булмаган. Парклар салып яшәрлек булгач, экономик, культура ягыннан да алдынгы аристократлар булганнар. Тирсәдә хәзер дә халык алар торган җирләрне «Бикә бакчасы», «Бикә тегермәне», «Бикә болыны», «Бикә басуы» дип йөртә. Чөнки бу алпавытлар нәселенең соңгы буыны Шәрифә бикә исемле бер алпавыт хатынының хакимлек итүенә бәйләнгән. Шәрифә бикә заманында үз утарында гына түгел, хәтта янәшә-тирәнә кулында биеткән гаярь хатын булган. Аның турында бик күп легендалар сөйлиләр. Бу тирәләрдә татар морзаларының утарлары күп иде. Мәсәлән: 1. Биектау. 2. Мордыби. 3. Тирсә. 4. Нажар. 5. Чишмә. 6. Шаршады. 7. Балтач. 8. Бакыр заводы. Бу авылларның барысы да татар морзаларының кол крестьяннәре булганнар.» (Татарстан Үзәк музее фондыннан. ТГ 13—6).

Мин үзем шуңа да игътибар иттем. Кайчандыр Кама буенда Мурзиха дигән пристань бар иде. (Алабуга районында шул исемле авыл бар.) Яңгырашы белән ул рус атамасы кебек. Ә яхшылап уйлап карасаң, ул да бит «морза» дигән сүздән барлыкка килгән. «Мурзиха» — димәк, морза хатыны. Ә нишләп шушы җирләрдә кайчандыр татар морзаларының утары булмаган дип уйларга кирәк икән?.. Тирсә җирләренең крепостной режимда булуы турында тагын бер момент әйтеп тора. Билгеле булганча, Пугачев Уралдан Казанны алырга килгәндә аның сафларына күп кенә татар крестьяннары да кушыла. Кемнәр иде соң алар? Пугачевың Казан губернасы җиреннән узган юлы күп нәрсә турында сөйли. Ул нәкъ Тирсә, Баржы пунктлары аша уза. Һәм шушы юлда үзенә гаскәр җыя. Әгәр крепостнойлык булмаса, иминлектә һәм изүдән азат халык «крестьян патшасы» сафларына басарга теләр иде микән?

Тажи Гыйззәт «Наемщик» әсәрен эшкәртү, камилләштерү процессында аны һаман шушы чорга хас социаль-экономик һәм политик «детальләр» белән баета бара. Вариантларның берсендә ул махсус рәвештә татар зыялыларының алдынгы вәкиле морза малае Зәкәрия персонажын кертә. Аның фикерләре («Россиядә крепостной режимны тизрәк юк итү, манифест кирәк, югыйсә аңа кара крестьян массасы үзе ирешәчәк») Шәрифә бикә, Бикташ һәм бигрәк тә бикәнең улы Аскарикларның фикерләвенә капма-каршы...

Ләкин безнең театрларыбыз сәхнәләрендә, бигрәк тә «Наемщик»ның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсендә соңгы куелышын алганда, бу нәрсәләрнең исе дә калмаган, әлбәттә. Билгеле, опера либреттосы шактый кысанрак була. Шулай да мин сүзне әсәрнең реалистик планда иҗат ителүе турында алып барам. Һәм сүз беренче чиратта шуның турында бара да.



Татар язучыларының Бөек Ватан сугышына каләр төшкән фоторәсемдә Тажи Гыйззәт беренче рәттә *(уңнан дүртенче)* утыра.

...«Ташкыннар» трилогиясе Тажи Гыйззәтнең иҗат юлында иң зур казанышы иде, әлбәттә. Бу әсәр, әйтергә мөмкин, бөтен татар драматургиясендә дә аерым урын алып тора. Аның Татар дәүләт академия театры сәхнәсендәге спектакле дә шундый ук зур дәрәҗәгә ирешә. Шушы театрның танылган артисты Хәким ага Сәлимҗанов болай дип язган иде: «Ташкыннар» спектакле театрда үзенә бер эпохаль төс алды. Ул авторның гына түгел, бәлки Татар академия театры

коллективының зур иҗат бәйрәме булды» (Х. Сәлимҗанов. Артист язмалары. Казан, 1966, 168 б.). Бу фикер бәхәссез кебек, ләкин хәзерге заманда күп нәрсәгә бәяләр үзгәреп бара бит инде. Шул исәптән Октябрь революциясенә дә. Шуңа күрә бәлки «Ташкыннар»га бирелгән бәя дә яңабаштан каралырга тиештер?. Мондый фикергә карата (әгәр дә ул туа калса) берничә сүз әйтми булмый.

Тажи Гыйззәт Октябрь революциясен чын күңеленнән куанып, зур өметләр белән каршы алган кеше. Моны аңлау читен түгел булса кирәк. Тормышның ачысын-төчесен татыган, дөньядагы гаделсезлекне үз җилкәсендә җитәрлек тойган ул. Аның күз алдында берәүләр балда-майда йөзеп, гел рәхәттә яшәсә, икенчеләр, киресенчә, гомерен газапта, михнәттә кичерә. Алар ничек кенә чиләнмәсен, юксызлыктан котыла алмый. Революциягә хәтле әтиләрнең гаиләсе нәкъ шулар рәтендә яшәгән дә. Аның атасы Кәлимулла һәм анасы Фатыйханың алты малае булган, һәм шул гаиләгә бер аршын җир юк. Чөнки Кәлимулла — башка авылдан, ул Фатыйхага йортка кергән кеше. Димәк, килмешәк. Ә иске авыл йолалары буенча, килмешәккә җир бирелми. Шуның өстенә Кәлимулланы авылның ниндидер куштанын кыйнаган өчен төрмәгә дә утыртып куялар. Хатыны Фатыйха 6 бала белән кала. Олысы Таҗетдингә 11 яшь. Кәлимулла срогын тутырып кайтса да, озак яши алмый: кара авырудан (рактан) үлеп китә. Менә шуннан барысы да аңлашыла инде. Әти үзенең «Тәрҗемәи хәлендә» болай язган:

«Әти төрмәгә алынгач, семьяда иң зур бала мин булганга, бөтен авырлык әнкәй-мәрхүмә белән минем җилкәдә иде. Баржы-Умга авылында (хәзерге Әгерҗе районы — К. Г.) мин ялланып урак урмаган, җир сөрмәгән, ашлык сукмаган, урман кисмәгән, йөз сулары түгеп ярдәм сорамаган йортлар бик сирәк. Бераз үсеп алгач, 1911 елдан башлап Гөлширмә, Иж, Бондюг, Воткинск заводларына эшкә йөри башладым. Ул заводларда грузчик, җир казу, утын кисү, таш вату кебек эшләрне тиеннәр бәрабәренә эшләргә туры килә иде. Ике-өч ел шулай, ярым батрак, ярым сезон эшчесе булып, шәһәр белән авыл арасында йөргәннән соң, 1913 елны Иж заводына эшкә кереп, тоташтан алты ел шул заводта эшләдем». Авылның кайбер кешеләре совет власте башлангач та Фатыйха карчык белән аның улларына җир бирмәү ягында торалар әле. Әтинең энесе Зыятдин абый әти үлгәннән соң инде миңа шуны сөйләгән иде. Боларны җирсез калдыру хәбәрен әтигә җиткергәннәр (ә ул бу вакытка инде авылдан аерылган «шәһәр кешесе» булып киткән). Зыятдин абыйның сөйләвенчә, әти авылга кайта да, власть башында утырган абзыйларга револьвер белән янап (!), гаиләсенә җир бирдертә. Шуннан соң авылда Кәлимулла токымына караш бөтенләй үзгәреп куя, боларны артык җәберләмиләр, ә Зыятдин абыйны хәтта сельсовет секретаре итеп тә сайлап куялар.

Революция әтигә күп нәрсә бирә. Ул совет заманында авылда алып барылган сәясәт белән канәгать булмаса да (әти һәрвакыт колхозчының кыерсытылуы турында ачынып сөйли торган иде), культура өлкәсендә барган сәясәтнең аңа артист һәм драматург булып үсәргә мөмкинлек ачканын яхшы аңлый, шуны тәкъдир итә иде. Хәзерге вакытта Октябрь революциясенең нәтиҗәләрен берьяклы гына (тискәре) бәяләү, аны гомумән «зур афәт» дип язулар ешайды, кайберәүләр революция адресына әрләү сүзләрен әйтми калуны үзләре өчен үкенечле була күрмәсен дигән кебек, «җае чыкканда» аны типми генә узалмыйлар. Берәүләр гомумән социаль революцияләрне бөтенләй «кирәкмәгән», җәмгыять үсешенә бөтенләй «чит нәрсә» дип әйтергә ашыгалар.

Моны ничек аңларга инде? Политик авантюристлар тарафыннан тудырылган конъюнктурага ярарга тырышумы? Бәлки. Ләкин ул гына түгел. Социаль революцияләрнең «законсызлыгы» турында сөйләнеп йөрүче адәмнәр — алар кем генә булмасын — үзләренең дуамаллыгын гына күрсәтәләр. Чөнки җәмгыятьтәге процесслар, табигатьтә кебек ук, һәм сан, һәм сыйфат үзгәрешләренә дучар. Җәмгыятьтә сыйфат үзгәрешләре (шул исәптән революцияләр) ешрак, чөнки биредә үзгәрешләргә субъектив фактор кушыла, һәм аның роле ифрат зур. Бу — диалектиканың төп законнарының берсе.

Ләкин моңа каршы болай әйтүләре дә бар. Әгәр дә инде социаль революцияләр котылгысыз икән, нишләп соң алар бездә, Россиядә генә? Нишләп алар башка илләрдә юк, башка илләрдәге кешеләр, революцияләрсез дә яши беләләр»?.. Сорау четерекле тоелса да, аңа җавап бирү читен түгел. Җәмгыять чыннан да, сыйфат үзгәрешләресез, революцияләрсез яши алмый. Алар барлык илләрдә дә бар. Ләкин социаль революциянең коралсыз, канлы бәрелешләрсез башкарылуы да мөмкин. Һәм билгеле очракларда ул шулай бара да. Коралсыз бәрелешләр, гражданнар сугышы — шул очракта туа: кайчан да ки искелек белән яңалык арасындагы каршылыклар тирәнгә җәелгән, ә социаль төркемнәр арасындагы

тартышулар һәр яктан да компромиссыз, килешмәүчелек характерында бара. Бу бигрәк тә Россия җирлегенә хас тенденция. Аның сәбәбе нәрсәдә? Беренче чиратта, Россия башында торучы идарә итүчеләрнең гасырдан гасырга килгән консервативлыгы, искегә ябышып ятулары. Моны бәлки рус милли характерының үзенчәлекле бер күрсәткече дип тә карарга кирәктер. Әйтик, империячел рухта фикер йөртү, ачы тәҗрибәләрнең булуына да карамастан, һаман халыкның күп кенә вәкилләре аңында тотрыклы рәвештә яшәп килә. Бу исә җәмгыять организмындагы каршылыкларны куертуга, төрле ризасызлыкларны көчәйтүгә китерә.

Әлеге мәсьәләгә килгәндә, А. С. Пушкинның түбәндәге сүзләрен искә төшерик: «Не приведи, господь, видеть русский бунт — бессмысленный, беспощадный». Бу сүзләрне ул рус алпавыты офицер Петр Гриневтан әйттерә. Аның күзлегеннән караганда, бунтлар чыннан да «мәгънәсез», чөнки Россия тарихында аларның берсенең дә куелган максатына ирешкәне юк — һәр кайсы бастырылу, тар-мар ителү белән тәмамланып килгән. Ә инде «беспощадный» икән — бу чыннан да шулай — ул рус чынбарлыгында изүнең рәхимсезлегеннән килеп чыккан нәрсә генә. Рәхимсезлек — һәр яктан да: моңа хәтле изелеп килүчеләрдән — каты үч алу рәвешендә, бунтны бастыручы хакимлек иткән сыйныфлардан — хәерче халык моннан соң артык баш күтәрергә базмасын өчен! Ә хәзер әйтегез инде: Европаның кайсы илендә бер социаль төркемнәрнең икенче төркемнәрне изеп яшәве Россиядагыга караганда артыграк һәм шәфкатьсезрәк булды икән?..

Моның сәбәбе бердәнбер түгел, әлбәттә. Ләкин төрле сәбәпләр арасында православие диненең үзенчәлекле роле турында әйтмичә булмый. Аның кануннары арасында бигрәк тә берсе калкып тора: «Бог терпел и нам велел». Әйе, рус халкы түземле булды. Ләкин аның бу сыйфаты ике яклы: һәм уңай, һәм тискәре. Уңай ягы бигрәк тә илебездә индустрияләштерү уздырган чорда, Ватан сугышы елларында чагылган булса, тискәре ягы — изүчеләрнең вәгъдәләренә ышанып, алардан шәфкатьлелекне, гаделлекне көтеп, үзләрен тагын да рәхимсезрәк изүләргә юл куюда. Шул ук үзенчәлекләр (йогынты рәвешендә) Россия җирлегендә яшәгән башка халыкларга да хас булды.

Ләкин яманлыкка түзү мәңге була алмый. Сан үзгәрешләре иртәме, соңмы, сыйфат үзгәрешләрен китереп чыгара. Бу хакыйкать шул ук «Ташкыннар»да Биктимер карт монологында чагыла. Авылда солдаткаларның бунтка күтәрелеше буенча барган допроста: «Аларны оештыручы синме?» дигән сорауга ул, яшеренеп торырга теләмичә, «әйе мин», дип җавап кайтара. «Җирсез-сусыз килеш, нужа белән карап үстергән балаларымны сугышка кудыгыз — түздем,— ди ул.— Актык атымны, бердәнбер сыерымны алып, тормышымны җимердегез — түздем. Алма чәчәгедәй кызымны алдап, намусымнан көлделәр — аңа да түздем. Улларымның берсен каторга, икенчесен кара кабергә тыктылар, Мирвәли бәбкәм әйтмешли — телемне аркылы тешләп булса да түздем. Ләкин авыл халкының еллар буенча түккән күз яшьләрен, ятим балаларның, карт-корыларның газап чигүләрен күреп чыдамадым... икмәкне халыкка өләшергә мин өйрәттем».

Шулай, түземлекнең чиге була. Изүгә түзү дә чиксез, чамасыз түгел. Бунт, революция — аның котылгысыз нәтиҗәсе. Шуннан чыгып, «безгә революцияләр кирәкми» дип шаулап йөрү ул — беркатлылык. Ат жиккәндә арбаны алга кую бу. «Революция безгә кирәкми» түгел (әгәр дә моның өчен социаль нигез туган икән, ул бездән сорап тормый инде, социаль төркемнәр үзләре, стихияле рәвештә хәрәкәткә киләләр), төрле изүгә, алдауга, илебезне һәлакәткә илтә торган башка кабахәтлекләргә каршы актив позициягә чакыру сорала.

Югарыда әйтелгәннәр «коры сәясәт» дип кенә кабул ителмәсен иде. Сүз һаман әле реалистик методның хасиятләре турында бара. Социаль-экономик шартлар... Тирән эчтәлекле, бигрәк тә халыкның яшәешен киң колач белән тасвирлауны «күздә тоткан» әсәр бары тик мәгьшуклар хиссияте яисә кызыклы мажаралардан торган «тукыма» белән генә чикләнә алмый. Ләкин әнә шул яшәү шартлары, әлеге дә баягы социаль-экономик «детальләр» художникны алдан уйланган геройларын, аларның кылган эшләрен, характерларын кинәт үзгәртеп куярга, башка төрле күрсәтә башларга мөмкин. Мәсәлән, А. С. Пушкин үзенең бер дустына «Евгений Онегин»ның финалы хакындагы фикерләре белән уртаклаша. «Ты знаешь, какую штуку выкинула Татьяна, она замуж выскочила», ди. Бер караганда берни түгел кебек. Кем өйләнмәгән дә, кем кияүгә чыкмаган?! Ләкин Татьянаның кемгә чыгуы бар бит әле. Ул югары чиндагы әфәндегә, генералга чыга. Шуның белән Татьяна кимсетелгән, юаш провинциаль барышнядан мәркәзнең күренекле дамасына әверелеп китә. Яңа шартларда аның холкы, характеры, үзен тотуы — барысы да үзгәрә. Ә Онегин? Тәкәббер җилкуар егет кичә генә мескен хәлендә булган хатынга үзенең йөрәгендә ялкынлы хисләр таба. Ләкин

аңардан тискәре җавап алып, җиңелгән хәлдә кала. Яхшы. Хәзер инде уйлап карыйк. Әгәр дә Татьяна үзе кебек бер провинциаль дворянга чыгып куйган булса, мондый метамарфозалар булыр идеме? Бик шикләнәм. Нәкъ менә шул кешеләр тормышының социаль-экономик шартлары соңгы нәтиҗәдә аларның ихтыяҗларын, максатларын, омтылышларын һәм, әлбәттә, әхлакый нормаларын, кыланышларын, характерларын билгели. Нәкъ реализм кануннары кушканча.

Шушы яктан караганда, Т. Гыйззәтнең «Алсу таң» әсәренең язылу тарихы, хәтта аның драматик язмышы — тагын бер җанлы мисал булып тора. Әти аны Татарстанның 30 еллык бәйрәменә туры китереп, ирешүләребезнең тантанасын гәүдәләндерү планында иҗат итәргә алына. Ләкин реаль чынбарлык, бигрәк тә авыл хуҗалыгы өлкәсендәге җитешсезлекләр һәм тирән каршылыклар, әсәрне бәйрәм төсендә күрсәтүдән бигрәк, еллар дәвамында колхозчы халкын азаплап килгән проблемалар чолганышында тасвир итүне ихтыяҗ итеп куя.

...«Алсу Таң» драмасы «алсу» төстә генә башланып китә. Баш герой колхоз председателе Мортазаның хатыны шәһәрдән кайтып төшә. Ир белән хатын бер-берсен сагынганнар. Мортаза — талантлы һәм көчле шәхес. Колхоз рәисе буларак, ул башка колхоз җитәкчеләре арасында беренче булып планнарны тутыра, дәүләткә вакытында ашлык тапшыра, колхозчыларга натуралата түләүне тизрәк өләшергә омтыла. Бу — начармы? Киресенчә, яхшы кебек чөнки Мортазаның бу карары популизм фәлән түгел. Ул практик максатларны алга куя: беренчедән, колхозның ашлыкны куярга урыны юк; икенчедән, ашлыкның тиешле шартлар булмау аркасында бозылуы бар; өченчедән, аны саклау өчен кемгәдер түләргә дә кирәк әле. Шуңа күрә иң яхшысы — колхозчыларга өләшергә. «Әйдә, үз икмәкләрен үзләре сакласыннар»... — ди ул. Мортазаның фикеренә парторг һәм кайбер колхозчылар каршы төшә. Алар бүленми торган фондны арттыру ягында. Бу очракта колхозчыга натуралата түләү өчен азрак кала. Аның урынына күмәк хуҗалыкның көче арта төшә. Бу да хаклы кебек. Каршылыкмы? Әлбәттә, каршылык, сугыштан соңгы чынбарлыгыбызның конкрет каршылыгы бу. Шушы ике якның кайсына күбрәк орынырга кирәк булгандыр язганда — белмәссең. Ләкин ул чынбарлыкның конкрет хасияте иде. Күмәк хуҗалыкларда бу экономик «детальләр» тирәсендә бәхәсләр (шуның өстенә югарыдан «өйрәтүләр») аз булмагандыр.

Әсәрдә күрсәтелгәнчә, Мортазаның тагын бер четерекле проблемасы бар — колхозның электр станциясе төзүе. Татарстан авылына электр уты 50 нче елларның уртасында гына килде. Аңа хәтле колхозлар — кем ничек булдыра — үзләре гидростанцияләр төзеп азапландылар. Һәр колхозның хәленнән килә торган нәрсә түгел иде бу. Шунлыктан андый 200—300 киловаттлык станцияләрне берничә авыл колхоз күмәкләп төзи торганнар иде.

Ә Мортаза исә янадан — үзенчә, янадан — берүзе: гидростанция бирәчәк җегәрлекне файдалануда нинди кечкенә генә өлешкә йөз тотып түгел, бәлки тулысынча үз авылы (колхозы) өчен алырга тели ул. Заманның принциплары буенча, бу — индивидуальлек психологиясенең гәүдәләнеше иде. Начар, әлбәттә. Ләкин мәсьәләгә икенче яктан да карап була бит. Мортазаның карашы буенча, гидростанцияне 4 колхоз бергәләп төзегән тәкъдирдә, бүрәнәнең юан башы янадан аңа — алдынгы колхоз башына төшәчәк. Мортаза алдан ук белә, күмәкләп файдаланылачак энергия өчен иң зур чыгым нәкъ аңардан соралачак. Ул болай ди: «Җитәр инде, күп булыштым. Ел саен орлык алып торалар. Ашлыкларын сугып бирәм. Корма җибәрәм...» Чыннан да, коллективизм шәп нәрсә булса да, ни кадәргә хәтле ялкау белән булдыксызларга (авылдашларының авызыннан өзеп) ярдәм итеп килергә?..

Әсәрдә барган вакыйгаларның коры схема түгеллеген мәхәббәт коллизияләре дә, төрле мәзәкле интригалар да исбатлый. Ләкин эш анда гына да түгел. Вакыйгалар монда конкрет социаль-экономик шартлар чолганышында, конкрет экономик «детальләр» сугарылышында бара. Конкрет детальләр аша (колхозның шушы конкрет чорда йөз баш ат өчен яңа абзарлар салуы, ике автомашина ала алуы, тимер ходлы арбалар булдыруы, клуб салуы, сокланырлык идарә йортын төзүе һ. б.) без 40 нчы еллар азагы — 50 нче еллар башы колхозларының хәлен, экономик мөмкинлекләрен, колхозчыларның шәхси хәятен, омтылышларын белүгә ирешә алдбыз. Бүленми торган фондның устав кушканча микъдары (кимендә 15 процент), колхозның ул вакытта әле шартнамәләр буенча, төрле предприятиеләргә акча күчерү актлары, ә бераүләрнең контроль системасы булуына карамастан, төрле законга каршы, шухыр-мухыр операцияләр яшый алулары һәм башка шушындый конкрет детальләр аша без 40—50 нче еллар авылын, аңа хас

булган проблемаларны аңлауда җыйган белемебезне тагын да арттыра, тирәнәйтә алабыз. Бу — художестволы тасвирлауда аналитик алымның нәтиҗәсе.

Әсәрдә Мортаза һәлак була. Геройның һәләкәте аның авантюр план белән эш итүенең нәтиҗәсе дип күрсәтелә («мин-минлек корбаны»). Ләкин аны символик ишарә рәвешендә, киңрәк планда — талантлы шәхеснең социаль каршылыклар чолганышындагы һәләкәте дип төшенергә дә була.

Әлбәттә, бу — Татарстанның юбилее өчен иҗат ителгән драматик әсәр — шушы тантаналы вакыйгага җавап бирерлек булмаган. Аны төрле яктан тәнкыйтьлиләр, чөнки ул драматургия өлкәсендә «конфликтсызлык теориясе» хакимлек иткән заманга туры килгән әсәр. Шулай итеп «Алсу таң» драмасы сәхнәгә куелмый кала.

Әти үзенең иң соңгы чыгышларының берсендә (1954 ел, 13 май) болай дип язган: «...безнең Татарстан шартларында... конфликтсызлык теориясенең әле һаман да яшәп килүен күрергә туры килә. Бу теорияләрнең колы булучы тәнкыйтьчеләр, әдәбият, сәнгать өлкәсендә эшләүче иптәшләр «бу — тормыштагыча түгел», «бу — характерлы түгел», «бу — типик түгел» дигән терминнар күзлегеннән, драма әсәрләрен тәнкыйть итеп килделәр. Күп вакытта аларның язмышларын да кире якка хәл кылдылар.

Шуның нәтиҗәсендә конфликтсыз, көрәшсез, фәкать уңай якларны гына чагылдыра торган кызыксыз, коры риторикадан торган әсәрләр тудылар.

Бу, әлбәттә, тормыш эчендә кайнаучы, һәрбер уңышыбызны зур көрәшләр белән җиңеп алырга өйрәнгән тамашачыларыбызны канәгатьләндерми иде...

Сәнгатьтән, әдәбияттан тормыштагы якты якларны гына күрсәтүне таләп итү — табигатьтә, җәмгыятьтә булган каршылыкны, яңалык белән искелек арасындагы көрәшне инкарь итүгә кайтып кала» (Т. Гыйззәт. Әсәрләр. 4 томда. 4 нче том, Казан, 1978, 391—392 б.)

Бу яктан караганда, әтинең иң соңгы (башланган, ләкин тәмамланмаган) «Туктаровлар язмышы» дигән әсәрен тагын да өметсезрәк финал көтәр иде дип саныйм мин. Югарыда китерелгән чыгышында әти: «Соңгы вакытта район үзәге работниклары тормышыннан зур күләмдәге «Туктаровлар язмышы» исемле әсәрем өстендә эшлим. Быел көзгә бетерергә тырышам» (шунда ук 393 б.) дигән иде. Анда (архивта бер пәрдәлек текст кына саклана) баш герой — райком секретаре. Яңадан шул авыл, колхоз крестьянының проблемалары. Беренче пәрдәдә үк баш герой Туктаров үзенең «кем икәнлеген» күрсәтә башлый. Яңадан шул югарыдан таләп ителгән центнерлар, литрлар, гектарлар, сөяк сындыргыч сәясәт, басымнар, куркытулар, җәзалаулар. Уйлыйм ки, мондый сюжетның барышы шактый зур конфликтларга китерергә тиеш иде... Чөнки әле пьеса башланган гына. Шигем юк, ул да тирән реалистик планда хәл ителәсе әсәр булган.

Кыз белән егет мәхәббәтен, Т. Гыйззәт әйткәнчә, «төп тема итеп алып», сурәтләү тукымасын җыр-бию, мәзәкле сүз ярышлары белән сугарып, шул ук вакытта чынбарлыкның «башка» (әмма мөһим!) якларын «читтә» калдырып иҗат ителгән драма әсәрләре дә реализм үзәнендә урын алалардыр, әлбәттә. Ләкин бу — көнкүреш реализмы (бытовой реализм) була.

Җәмгыятьнең тормышын конфликтсыз гына һәм уңай, берсеннән-берсе камилрәк геройлардан гына төзеп, әсәр тукымасына кешеләрнең, социаль төркемнәрнең бары тик идиллик мөнәсәбәтләрен генә сыйдырып язылган драма әсәрләре (әгәр алар сәнгать кануннары буенча, образлы итеп эшләнгән икән) шулай ук реализмга йөз тотучан булыр. Әмма бу инде тенденциоз реализм үрнәге.

Чынбарлыкны аналитик алым белән, димәк, аның бөтен катлаулыгы һәм барлык каршылыклары аша эмоциональ-образлы чагылдыру болар инде киң пландагы, сәнгатьнең югары таләпләренә җавап бирерлек, ташламасыз, чын реализмга хас сыйфатлар. Безнең татар драматургиясендә андый үрнәкләр аз түгел. Т. Гыйззәтнең мирасы да (һәрхәлдә аның күпчелек әсәрләре) шушы таләпләргә җавап бирерлек дип уйлыйм.

**Казбек ГЫЙЗЗӘТ,**
философия фәннәре докторы, профессор.

# ГАСЫРЛАР АВАЗЫ




**Бу елның язы безнең матбугат дөньясына тагын бер яңалык алып килде — республикабызда «Гасырлар авазы» дигән яңа журнал басыла башлады. Исеменнән үк күренгәнчә, ул — тарихи-документаль басма, татар һәм рус телләрендә нәшер ителә.**

**«Гасырлар авазы»н ачып җибәргән кереш сүздә мондый юллар бар:**

**«Безнең журналда Татарстанның һәм Россия Федерациясенең, шулай ук якын һәм ерак чит илләрнең — бигрәк тә Урта Азия республикалары һәм Төркия архивларында сакланган документлар, материаллар басылып барачак... Ул документларның күбесе, КГБ һәм парткомиссияләрнең тикшерү эше материаллары кебек үк «яшерен», «үтә яшерен» һәм «махсус папка» дигән урыннарда сакланган.**

**Хәзер ул документлар белән танышу Татарстанның һәм татар халкының үткәненә яңача карарга ярдәм итә, күренекле шәхесләрнең язмышларына ачыклык өсти. Байтак кына материаллар Россия тарихын объектив аңлауга да булышачак.**

**Яңа журналда республиканың күренекле галимнәре, язучылары, мәдәният эшлеклеләре, дәүләт һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләре актив катнашачак».**

**Кереш сүздән һәм беренче саннан күренгәнчә, яңа басма татар халкы тарихына кагылган материалларга аерым игътибар бирәчәк. Бирелә, мәсәлән, 1549 елны камалган Казан каласы эчендә язылган, үтә кызыклы бер хат китерелә. Бу факт һәм тагын шуның кебек башка материаллар үткәндәге трагик хәлләргә җиңүчеләр ноктасыннан гына түгел, ә бүтән яктан да карау мөмкинлеге бирә, тарихны чынрак итеп яктырта.**

**Садри Максудиның Дума делегациясе составында Англиягә баруы турындагы материаллар да бик кызыклы. Бирелә 1920 елны Татарстан республикасы җитәкчесенә ясалган һөҗүм һәм соңгы сугыш вакытында Казанда эшләгән атаклы авиаконструктор Петляковның һәлакәте дә языла.**

**Утызынчы елларда котырган репрессия корбаннары турында да «Гасырлар авазы» күп материал бирә.**

**Кыскасы, яңа журналның чыга башлавы тарихны объектив аңлауга, чынбарлыкны тулы яктыртуга ярдәм итәчәк. Бик кызганыч, ләкин бит әле шундый мисаллар да бар: күптән түгел Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган бер дәреслек дөнья күрде — анда акка кара белән «XVI гасырда татар милләте хәлсезләнгән, үсештән туктаган иде инде» дип языла!**

**Бу журналдагы фактлар моның ише бик күп уйдырмаларны юкка чыгара.**

**Яңа басманың «Гасырлар авазы» дигән исеме үзе үк бик тә мәгънәле, саллы ишетелә. Әйе, яңа басманың киләчәге зур. Ул халкыбыз тарихы белән кызыксынучы меңләгән укучыларның зиһеннәрен баетачак. Әмма яңа басма мәктәпләргә, гимназияләргә бигрәк тә кирәк. Ул һәр укытучының өстәл китабы булсын иде.**

**Хәерле юл сиңа, яңа журнал!**

**Ә без бу санда үз укучыларыбызга яңа журналдан алынган кайбер материалларны тәкъдим итәбез.**

***Журналны почта аша түләп алырга теләгән укучылар үз заказларын түбәндәге адрес буенча җибәрә ала: 420111, Казан, Ленин ур., 2/6. Телефон: 38-49-87.***

Мансуров Гасыйм Гата улы (1894—1955) Вятка губернасы, Әгерҗе өязенең (хәзер Татарстанның Әгерҗе районы) Тирсә авылында туган. Башта Иж-Буби мәдрәсәсен, соңыннан Ижауда 4 еллык училище тәмамлаган. Укытучы, совет чорында татар газеталарында мөхәррир, өяз идарәләрендә җаваплы хезмәткәр, ә 1920 елдан башлап Татарстан НКВДсы каршындагы Уголовный розыск идарәсе башлыгы. 1922 елда Г. Мансуров — «Коммунистический путь» журналы җитәкчесе, 1924 — Татарстан Халык комиссарлары Советы рәисе урынбасары. М. Солтангалиевне Сталин каршында яклаучы буларак, дәүләт хезмәтеннән читләштерелә. Үзәк нәшрияткә күчеп эшли. Биредә ул тулысынча фәнни-тикшеренү эшенә бирелә. Татарларның XX йөз милли һәм революцион хәрәкәтләренә багышланган «Татар провокаторлары» (1925), «Беренче революция елларында татарлар» (1926) дигән хезмәтләр яза.

1929 елның августында Г. Мансуров партиядән чыгарыла, 28 декабрьдә кулга алына һәм Соловки утравына 10 елга сөргенгә җибәрелә. Азат ителгәннән соң Муром шәһәрендә яши.

Укучыларыбыз игътибарына Г. Мансуровның лагерьдан гаиләсенә язган бер хатын тәкъдим итәбез. Хатының эчтәлегенә караганда, ул якынча 1932 елның май аенда язылган булырга тиеш.

*Разыя![1]*

*Сагынып күп **сәлам**. Лагерьга килгәч үзеңә өч хат язган идем, алгансыздыр дип уйлыйм. Үзеңнән **хат** алганым юк. Посылкаларың тапшырылды. Хат алсам, тагы да күңелле булыр иде. 17 апрельдә алган посылкада шушы әйберләр бар иде: күп кенә сухари, бер кадаклап[2] конфет, мятный лепешка, май, 3 кадаклап шикәр, бер кисәк сабын, 2 катушка җеп.*

*27 апрельдә алган посылкада сухари, бер кадаклап шикәр, бер банка шпрот, 2 кисәк бит сабыны, Арсланнан[3] кәгазьгә төргән ике конфет килде. Җаным, посылкаларың өчен сиңа зур рәхмәт. Посылкалардан исән икәнеңне һәм адресыңнан икенче фатирга күчкәнеңне аңладым[4]. Бу хатны яңа адрес белән язам. Адресыңны тулы итеп хатта язарсың. Апрель башында язган хатымны иске адрес белән җибәргән идем, бүлмә номерын 406 дип язган идем, тапшырылдымы? Әйтеп яз. Арсланнан күчтәнәч алгач тагын да күңелле булып китте. Шатлыгым эчемә сыеша алмады, күчтәнәчне иптәшләргә дә күрсәтеп, шатлыгымны алар белән бүлештем. Разыя, мин тагы бер кат синнән шуны үтенәм: миңа посылка җибәрәм дип, җан кисәгем, кысылып нужа күрмә, авызыңнан өзеп миңа җибәрмә, бигрәк тә кибет сухарие, конфет шикелле кыйбат нәрсәләр җибәреп расходланма. Айга бер мәртәбә аз-маз май, шикәр, йортта пешкән әйберләрдән ясалган сухарилар җибәреп торсаң, бик яхшы булыр. Өс-баш, күлмәк-ыштаннар җибәрә күрмә. Биредә һәммәсен дә бирәләр. Күрешкәндә үземнең күлмәк-ыштаннардан күбесен сиңа биреп җибәрергә туры килә. Апрель башында язган хатымда синнән берничә китап җибәрүне сораган идем. Хәзергә син шул китаплардан икесен-өчесен генә җибәр. Китаплар күп булса, аларны ташып йөрүе читен була дип уйлыйм. Миңа хәзергә Айхенвальд һәм Угримовның электричество турындагы дәреслекләрен, немесчә уку китаплары җибәрсәң җитәр. Хәзергә бүтән китаплар җибәрми тор. Китапларны кешедән алырга кара. Сатып алырга табып булмас, аннан соң кыйбат булыр.*

*Кыйбат булсалар, берәр генә китап җибәр. Күрешү сораганым юк әле. Күрешергә рөхсәт бирсәләр, хәбәр итәрмен. Миннән хәбәр алмыйча торып, килергә чыга күрмә. Минемчә, 2—3 сәгать кенә күрешү бирсәләр, юлда килеп расходланып йөрү файдасыз кебек тоела. Үзең уйлап карарсың тагы. Син Дьяковка кереп һәм башка кешеләр белән личный күрешү турында сөйләш. Әгәр лично күрешергә рөхсәт бирсәләр, миңа телеграмм сугарсың. Син кайчан отпуска аласың? Ни вакытта күрешергә килә аласың? Рөхсәт бирсәләр, Арсланны алып килә алырсыңмы? Аны алып килсәң, зур мәшәкать булмасмы? Юл мәшәкатьле булмасмы? Арсланны алып килүгә ничек карыйсың? Минем өчен, җаным, ватылма, минем тормышым начар түгел, эшли торган эшем җиңел вә үземә уңайлы эш. Эшләгәнемне башлыкларым яраталар. Кулымда 2—3 айлык акчам да бар. Бөтен кардәшләргә аеруча сәлам. Әнигә сагынып аеруча сәлам. Хат ешрак язып тор. Вера Николаевнага сәлам, аның кайгысын уртаклашам. Үзеңнең, Арсланның һәм әнинең карточкаларын җибәр. Арсланны яңадан төшерт. Әгәр җан кисәгем, үзеңнән матуррак берәр хат алсам, никадәр бәхетле булыр идем. Арсланны кысып үп, күңеленне төшермә, бәхетле яшә. Сау бул.*

*Үзеңне үбеп: Гасыйм МАНСУРОВ.*

*Адресым:*
*Станция Сорокская, Муром ж. д.*
*7-е отд. СЛАГ*
*заключенному*
*Гасыму Гатаевичу Мансурову.*

**Искәрмәләр:**

1. Разыя Галиәскәр кызы Сәгыйтова (1900—1993) — Г. Мансуровның хатыны. Мәскәүдә В. И. Ленин исемендәге үзәк китапханәдә фәнни хезмәткәр булып эшләгән.
2. Кадак — үлчәү берәмлеге — 400 гр.
3. Арслан — 1923 елда туган, Г. Мансуровның бердәнбер улы. 1943 елның 12 гыйнварендә Сталинград сугышында батырларча һәлак булган.
4. Г. Мансуров, кулга алынганчы, гаиләсе белән, дәүләт идарәсе системасында эшләүче фатирсыз башка хезмәткәрләр кебек үк, «Националь» кунакханәсенең бер бүлмәсендә яшәгән.

## Якташыбыз — казакъ акыны

Соңгы вакытта татар-казакъ дөньясындагы үзара бәйләнешләрне чагылдырган мәкаләләрнең вакытлы матбугатта, басма китапларда шактый еш күренүе матур төс алды. Без казакъ, татар галимнәреннән Чокан Вәлихановлар һәм Хөсәен Фәезхановларның эшлекле элемтәләре, Мифтахетдин Акмулла, Галимҗан Ибраһимов, Зариф Бәшири һ. б. әдипләрнең казакълар арасындагы эшчәнлекләре хакында тегә яки бу дәрәҗәдә хәбәрдар инде.

Бүген сүз казакъ халкы арасында яшәгән зыялы якташыбыз Кәшафетдин Шаһмәрдән углы әл-Минзәләви әс-Сөлеки әл-Каркаралы турында барачак.

«Казан утлары» журналының 1975 елгы унынчы санында филология фәннәре докторы, профессор Габдрахман Таһирҗановның «Әдәби бәйләнешләр һәм аларның нәтиҗәләре» дигән күләмле хезмәтендә әлеге шәхескә бәйле шундый юллар бар иде:

«...Татар укымышлылары казакълар арасына барып бер «мулдакәлек» белән генә шөгыльләнеп йөрмәгәннәр. Балаларны грамотага өйрәтүдән тыш, алар казакълар арасында язма әдәбият үрнәкләре таратуга да хезмәт иткәннәр. Шиһап Мәрҗани шәкертләреннән Кәшафетдин Минзәләвинең эшчәнлеге аерата игътибарга лаек. Каркаралы шәһәрендә мөдәррис булып торган чакта ул йөзгә якын казакъча әсәр язган. Шуларның күпчелеген төрле әдәби кыйссалар, тарихи поэмалар, дәреслекләр тәшкил итүе үзе күп нәрсә турында сөйли».

Якташыбыз турында серле йомгакның очын менә шушы җептән сүтә башлагач, шактый нәрсә ачыкларга мөмкин булды.

Кәшафетдин 1864 елда элеккe Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Нәркәй волосте, Сөлек авылында дөньяга килгән. Әтисе Шаһмәрдән Гыйбадулла улы авылның шактый нык хәлле крестьяны булган, алар бабалары Фәтхулла заманыннан ук умартачылык белән шөгыльләнгәннәр һәм бал белән сәүдә иткәннәр. Әтисен авылда «башкорт Мәрди» дип йөрткәннәр.

Шаһмәрдән белән Шәмсениса 10 бала үстерәләр, баш балалары Кәшафетдин кечкенәдән үк өлгер табигатьле, укуга махир булган. Казанда 1870 елларда ук Шиһап Мәрҗанидә белем алган авыл имамы Ризатдин Сиражетдин углының тәкъдиме белән 19 яшьлек Кәшафетдин дә Казанга юнәлә. Ул Шиһап Мәрҗани мәдрәсәсендә 9 ел укый, 1892 елда Уфага барып диния нәзарәтендә имтихан тота һәм мөдәррислеккә указ ала. Шушы елдан аның гомер юлы Казахстанның Семипалатинск өлкәсе, Каркаралы шәһәре белән бәйле.

Семипалатинск (казахча Семей) өлкәсе ул чакта Семей, Каркаралы, Павлодар, Өскемен, Зәйсан өязләренә бүленгән була. Мәдрәсә һәм мәктәпләр юк дәрәҗәсендә. Мәсәлән, 1884 елда бөтен өлкәгә 10 мәктәп һәм мәдрәсә булып, аларда 615 бала укыган («Казакъ халкының XX гасыр башындагы демократик җазушылары». Алматы, 1958. 10 б.). Шуны да әйтергә кирәк, Каркаралы шәһәрендә мәчетне казакъ халкының бөек шагыйре Абайның атасы Конанбай салдыра; соңыннан мәчет янына мәдрәсә өстәлә. Шәкертләрнең күбесе мәдрәсәдә торып укый торган була. Кәшафетдин әнә шул мәдрәсәдә сабак укыта. 1897 елда чыккан «Кыйссаи Бәдәр» дигән китабының ахырында ул болай ди:

> Яранлар! Моны язган Кәшафетдин,
> Каркаралының мөгаллиме иҗтиһаддин.

Нисбәтендә әйтсә дә Сөлеки дип,
Остазы — Мәржани Шиһабетдин.

1899 елда басылган Җамасый Хәким кыйссасы ахырында Кәшафетдин үз әсәрләренең исемлеген бирә. Анда 80 гә якын әсәр телгә алына. Ул үзе хакында: «Җәдид ысулы белән сабак укытам, балалар күп нәрсә беләбез дип шатланалар»,— дигән. Хәзер дә Каркаралы шәһәрендә яшәүче пенсионер Хафиз ага Вәлитов үзенең бер хатында менә нәрсәләр яза: «Мин Кәшафетдин мулладан 1912—1915 елларны укыдым. Ул кеше, онытмасам, сары төсле, күк күзле (зәңгәр), уртадан югары буйлы, сары сакаллы иде. Мин укыган вакытта яше 47—50 тирәсендә булырга мөмкин. Аның хатыны Хәсәнә төскә кара иде. Кызы Мәсхүдә (казакълар Мәстәкәй дип әйтәләр иде) 1916—1919 елларда рус мәктәбендә мөгаллимә булып эшләде. Мин 1—3 классларны шул Мәстәкәйдән укыдым. Яше чама белән әйткәндә 24—26 тирәләрендә булырга тиеш. Кәшафетдин мулланың Мансур һәм Мәмдүх исемле уллары бар иде. Мәмдүх белән Мәсхүдә әтиләре шикелле сары төсле, күк (зәңгәр) күзле, ә Мансур әнисе кебек кара тутлы иде. Мәмдүхны, онытмасам, 1916—1917 елларда солдатка озаттылар.

Мин 1920 елдан башлап Кәшафетдиннең һәм аның хатын-балаларының кая киткәннәрен, нинди хәлдә булганнарын белмим.»

Кәшафетдин күпчелек әсәрләрендә бу әсәрнең язылу вакытын һәм үзенең яшен күрсәтә барган. Мәсәлән, 1987 елда язган бер әсәрендә ул: «утыз өчкә килде яшем», дип белдерә.

Казакъ совет энциклопедиясенең бишенче томында (314 бит) Кәшафетдин турында мәгълүмат бирелгән. «Кәшафетдин Шаһмәрдән углы — казкъ акыны. Яшь чагыннан мөселманча язу танып, шәрык әдәбиятын күп укыды. Шәрык әдәбиятындагы сюжетларны казакъча жырлап күп кыйсса-дастаннар язды»,— дигелгән һәм егермеләп әсәрнең исеме китерелгән.

Шунда ук аның, үзе язган һәм тәрҗемәләренә кушып, казакъның үз галимнәреннән Ибрай Алтынсарин, Абай әсәрләрен дә халыкка аңлатуы әйтелгән, «яшьләрне укырга, һөнәргә, гадел, кешелекле булуга чакырды»,— дип язылган.

Әмма шуны әйтеп үтәргә кирәк, энциклопедиядә Кәшафетдиннең якынча туган елы итеп 1840 ел күрсәтелгән. Бу дөрес түгел. Инде ачыклаганыбызча, ул 1864 елда туган. Үлү елы итеп 1910 ел куелган. Бу урында да хата киткән, истәлекләрдән күренгәнче, ул әле революция елларында, ягъни 1919—1920 елларда да исән булган.

Кәшафетдин Шаһмәрдән углының әсәрләре белән өстән-өстән генә танышканда да, аны тормыштагы күренешләрне пассив күзәтүче итеп кенә түгел, ә бәлки кешеләргә аң-белем бирергә тырышучы, мәгърифәтчелек карашларын алга сөрүче итеп тә сиземлисең, аның күп өлкәдән мәгълүматлы кеше булуына шигең калмый. Тәрҗемә әсәрләренең ахырларына ул «җир хакында», «кеше тәне хакында» һ. б. исемдәге кушымталар өстәгән. Болар барысы да аның астрономиядән, анатомиядән дә шактый хәбәрдар булуы турында сөйли. «Кыйссаи Гали» әсәренең соңында ул ачык төрки телдә 8 битлек «Әл-гыйбад» исемле мөселман дөньясында мәшһүр кешеләрнең үлгән елларын күрсәткән библиографик белешмә бирә.

Кәшафетдин Шаһмәрдән улы әл-Минзәләви татар һәм казакъ халыкларының рухи хәзинәсе чыганаклары башланган чишмәләрдән һәрдаим иҗади көч алган, алар аның каләменә бетмәс-төкәнмәс сюжетлар, эчтәлекләр биргәннәр.


Менә шуның өчен дә казакъ халкы аны үз акыны итеп хөрмәт иткән, бөек шагыйрь Кунанбаев та аның турында югары фикердә булган. Казакъ галиме Бөркет Исхаков аның исеме белән «китапчы акыннар» сафын башлап җибәрә.

Аның әсәрләре үз чорының мәгълүм истәлекләре булып бүген дә тарихи әһәмияткә ия. Ул казакълар арасында ислам динен таратуга һәм аны ныгытуга да тырышлык куя. Без аның эшчәнлеген өйрәнергә, тугандаш халыклар арасындагы әдәби һәм рухи бәйләнешләр сәхифәсендә аның урынын ачыкларга тиешбез.

**Дамир ГАРИФУЛЛИН.**

# Мөселманнарның «изге урыннары» исемлеге

| №№ | Табыну объекты | Адрес |
|---|---|---|
| 1. | **«Изге» кабер** | Әгерже районы, Иж-Буби авылы |
| 2. | **Чишмә** | Әгерже районы, Салагыш авылы |
| 3. | **Чишмә, «изге» кабер** | Аксубай районы, Яңа Мукшы авылы |
| 4. | **Хажи Мәһдүм-задә Керкания кабере** | Аксубай районы, Иске Киязле авылы |
| 5. | **Хужалар тавы, чишмә** | Алексеевск районы, Биләр авылы |
| 6. | **Чишмә, шәһәр калдыклары** | Әтнә районы, Әйшияз авылы |
| 7. | **Чишмә, зират калдыклары** | Арча районы, Иске Кишет авылы |
| 8. | **Зират калдыклары** | Арча районы, Яңа Мәңгәр авылы |
| 9. | **Зират калдыклары** | Апас р., Калганы, Каштаулы авыллары |
| 10. | **«Изге» кабер** | Балтач районы, Карадуган авылы |
| 11. | **Зират калдыклары** | Биектау районы, Калинино авылы |
| 12. | **Мулла Хажи кабере, чишмә, Айшәбикә кабере** | Биектау районы, Татар Әйшәсе авылы |
| 13. | **Кече манара, «изгеләр» Солтан-әл-Әрәфин, шәех Хәсән Басрый, шәех Шибли, мулла Хәсәнетдин каберләре, Рабига күле** | Спасс районы, Болгар авылы |
| 14. | **«Таш билге» зираты** | Спасс районы, Иске Рәҗәп авылы |
| 15. | **Чишмә** | Кукмара районы, Адай авылы |
| 16. | **«Изге» кабер** | Мөслим районы, Уразмәт авылы |
| 17. | **Голяма Дувания кабере** | Яңа Чишмә районы, Бакташ авылы |
| 18. | **Зират калдыклары** | Питрәч районы, Чыты авылы |
| 19. | **Хажи Хабибулла кабере** | Балык Бистәсе р., Бирдебәк авылы |
| 20. | **Нияз Чокмаков кабере** | Балык Бистәсе Р., Котлы Бөкәш авылы |
| 21. | **Кабер ташлары** | Балык Бистәсе р., Казаклар авылы |
| 22. | **Идрис Мөхәммәт** | Балык Бистәсе р., Табердино Чаллысы авылы |
| 23. | **Чишмә** | Теләче районы, Олы Нырсы авылы |
| 24. | **Зират калдыклары** | Теләче районы, Иске Җөри авылы |
| 25. | **«Изге» таш** | Теләче авылы |
| 26. | **Зират калдыклары** | Казан шәһәре, Архирей дачасы |
| 27. | **«Изге» нарат агачы** | Сарман районы, Каташ-Каран авылы |
| 28. | **«Изге» таш (әүлия ташы), «Изге әүлияләр» чишмәсе** | Сарман р., Иске Минзәләбаш авылы |
| 29. | **«Калабаш» шәһәр калдыклары** | Лаеш районы, Ташкирмән авылы |



# Җәнгиз Дагҗыга 75 яшь




Җәнгиз (Чыңгыз) Дагҗы — күренекле кырым татар язучысы. Ләкин анын исемен һәм иҗатын без генә түгел, элекке СССРда яшәгән газиз халкы да әле һаман белми диярлек. Ул фашистлар Германиясенә каршы сугышка китә һәм дошман кулына әсир төшә, сугыштан соңгы гомере туган иленнән читтә уза. Кырым татар халкы исә 1944 елда ватаныннан тулаем сөргенгә сөрелә һәм 1967 елга кадәр СССРдагы әсирлектә яши. Аклангач та ватанына кайту хокукыннан мәхрүм ителә һәм бары сиксәненче еллар азагында гына күпләп Кырымга кайта башлый.

Журналыбыз кырым татар әдәбияты үрнәкләрен кардәшләребез өчен иң авыр дәвердә дә биреп барырга тырышты. Сатлык исемен нахак күтәргән язучыларның әсәрләре белән укучыларыбызны таныштыру редакциябезгә җиңел генә бирелмәде, ләкин безнең бу каһарман халыкка, якын кардәшебез, гасырлар буе безгә ярдәм итеп, аралашып яшәгән кавемгә мәхәббәтебезне белдерәсебез килә иде. Ләкин без һәрвакыт шигъри әсәрләр бастыру белән генә чикләнергә мәҗбүр булдык.

Проза — кырым татар әдәбиятында яшьрәк жанр. Кырымда Ватандашлар сугышының озакка сузылуы, аннары ярымутрауның Гитлерчылар тарафыннан басып алынуы, шуннан соң бөтен кырым татар халкының иленнән куылуы һәм илле елга якын ватансыз, йорт-җирсез, типкедә яшәве, байтак каләм ияләренең сугышта һәм сөргендә һәлак булуы яки сәламәтлеген югалтуы аркасында, кырым татар прозасы бүтән кардәш төрки халыклар әдәбияты дәрәҗәсендә үсә алмады. Кырым татар әдипләренә «Кырым» сүзен телгә дә алырга ярамаган дәвердә, чынбарлыкны дөрес, табигый гәүдәләндерү тыелган заманда нинди әйбәт әсәрләр язылырга мөмкин иде соң? Алар кайда басылырга мөмкин иде? Хакыйкатьне, милләт язмышын, фаҗигале көрәшләрне кырым татар совет язучысы әйтә ала идеме соң? Әлбәттә, юк. Ихтимал, менә шуңа күрә дә без укучыларыбызны сәнгатьчә югары сыйфатлы кырым татар чәчмә әсәрләре белән таныштыра алмаганбыздыр.

Ярый әле дөньяга Җәнгиз Дагҗы килгән һәм ул, дошманга әсир төшеп, ватанындагы җәбер-золымнардан котылып калган, мөһаҗирлектә зур әдип булып житешкән, ватаны һәм газиз милләте башына төшкәннәрне үзе теләгәнчә яктырту ирегенә ия булган, дистәгә якын романында ватанында калган барлык каләмдәшләре бергәләшеп тә әйтә алмаган хакыйкатьләрне бөтен дөньяга ачып салган. Сәнгатьчә камил дәрәҗәдә!

Җ. Дагҗы Кырымның Ялта районы Кызылташ авылында 1920 елның 9 мартында туган. Башлангыч белемне Кызылташта, урта белемне Акмәчеттә (Симферопольдә) алганнан соң, 1938 елда ул Кырым педагогия институтына укырга кергән. Монда ике курсны бетергәннән соң, аны Одесса офицерлар училищесенә җибәргәннәр. Сугыш башлангач, ул Украина фронтында танк взводы командиры буларак сугышка кергән, 1941 елда әсир төшеп, лагерь михнәтләрен кичергән. 1946 елда Лондонга килеп урнашуга ирешкәч, тыныч тормышын шушында көйләп җибәргән. Бераз аякка баскач, кибет ачкан, шуның килеренә яшәп, бөтен буш вакытын иҗатка багышлаган. Монда инде ул иҗатын төрек телендә дәвам итәргә мәҗбүр булган.

Бер-бер артлы дөнья күргән романнарында ул 1932—1940 еллардагы Кырым тормышын, Икенче Дөнья сугышында катнашырга мәҗбүр булган аз санлы халыкның фаҗигасен гәүдәләндерә. Аның түбәндәге романнары: «Куркыныч еллар» (1956), «Ватанын югалткан адәм» (1957), «Алар да кеше иде» (1958), «Үлем һәм курку көннәре» (1962), «Ул җирләр безнеке иде» (1966), «Кайту» (1968), «Яшь Тимучин» (1969), «Бадәм ботагына асылган бәбиләр» (1970), «Туңган урам» (1972) Төркиядә кат-кат басылып, Төркиядән тышта төрек телендә язылган әсәрләрнең иң яхшылары төсендә танытылып килене.

Аның тормышы һәм иҗаты хакында тулырак мәгълүматлар кулыбызда юк. Без аны бүген дә исәндер һәм иҗаты дәвам итәдер, дип уйлыйбыз, югарыда саналган романнарыннан һичьюгы берсе киләчәктә Татарстанда да басылыр әле, дигән өмет белдерәбез.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

БИГИЕВ МУСА ЯРУЛЛА улы (1875—1949) — дин галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Заһир Бигиевнең бертуган энесе. Ростов-Дон шәһәрендә туа.

1909—1910 елларда Оренбургта яши, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта, аннары янадан Петербургка кайта, төпләнеп кала. Татар вакытлы матбугаты туган көннән башлап, дини, әхлакый, иҗтимагый мәсьәләләргә кагылышлы полемик мәкаләләре белән исеме таныла. Ислам диненә реформа ясау, аны җанландыру, заманның иҗтимагый тормышы, фәне таләпләренә җайлаштыру идеясен алга сөргән дини-фәлсәфи хезмәтләрен бастыра.

Басылган әсәрләренең кайберләре: «Кавагыйде фикъһийә» («Ислам дине нигезләре»), Казан, 1910; «Инсанларың гакыйдәи илаһийәләренә бер нәзар» («Кешеләрнең дини ышануларына бер караш»), Оренбург, 1911; «Озын көннәрдә руза», Казан, 1911; «Рәхмәте илаһийә борһанлары» («Аллаһының рәхмәтлелегенә дәлилләр»), Оренбург, 1911; «Халык нәзарына бер мәсьәлә», Казан, 1913. (Бу китаптан Россия шартларында Ислам диненең киләчәк язмышы турында сөйләнгән бүлеге русчага тәрҗемә ителеп, «Мир ислама» журналында да басылып чыга.)

## ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗДӘ — БӘЙРӘМ ТАНТАНАЛАРЫ

Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүгә 5 ел тулуга багышлап, җөмһүриятебез шәһәр-авылларында бәйрәм тантаналары булып үтте. 29 августта исә Казанда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында тантаналы утырыш булды. Анда республикабызның күп кенә шәһәр-районнарыннан килгән делегацияләр, Татарстан һәм Россия Федерациясе халык депутатлары, әдәбият-сәнгать әһелләре, Россия Федерациясе, Башкортстан, Чувашия, Удмуртия һәм Мари-Эл республикаларыннан дәрәҗәле кунаклар катнашты. Тантаналы җыелышны татар һәм рус телләрендә кереш сүз белән Татарстан Президенты М. Шәймиев ачты.

Татарстанның Дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул итүнең 5 еллыгына багышланган доклад белән ТР Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев чыкты.

Аннары тантаналы җыелыш мөнбәреннән Россия Федерациясе Премьер-министры В. Черномырдин чыгыш ясады. Ул Татарстан халкына, шушы зур бәйрәм уңаеннан, Россия Президенты Б. Ельцинның котлавын тапшырды һәм, федераль үзәкнең Татарстанга карата игътибарлы һәм дустанә мөнәсәбәттә булуын әйтеп, Мәскәү Кремле сурәте төшерелгән картина бүләк итте.

Тантанага җыелган кунакларны һәм бөтен Татарстан халкын аннары Азнакай шәһәр һәм район хакимияте башлыгы Ә. Исхаков, Башкортстан Республикасы Президенты М. Рәхимов, Татарстан халык язучысы Г. Ахунов, Чувашия вице-президенты, хөкүмәт Рәисе Ә. Әбләкимов, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, академик И. Таһиров, Мари-Эл Республикасының Дәүләт секретаре Н. Рыбаков, Чаллыдан рус теле укытучысы Л. Михейкина, Удмуртия хөкүмәте Рәисе урынбасары В. Гусев кайнар котладылар.

Соңыннан тантаналы җыелышта катнашучылар Дәүләт Декларациясе кабул ителүнең 5 еллыгына багышланган резолюция кабул иттеләр.

Тәнәфестән соң Татарстан сәнгать осталарының зур бәйрәм концерты булды.

30 август көнне исә бәйрәм тантаналары Казан урамнарында, ипподромда, Үзәк стадионда дәвам итте. Кабан күле яныннан алып стадионга кадәр сузылган урамнар халык ташкынына күмелде. Ул җырлы-биюле, уен-көлкеле, сый-хөрмәтле тоташ бер бәйрәм мәйданына әверелде. Халыкның күңел ачу тамашаларында Татарстан җитәкчеләре М. Шәймиев, В. Лихачев һәм Ф. Мөхәммәтшин катнашты.

## ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — КАЗАГЫСТАНДА

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе 8—11 августта, Казагыстан Президенты Н. Назарбаев чакыруы буенча, Казагыстан Республикасында булды. Алар анда Көнчыгышның күренекле акыны, мәшһүр шагыйре, фикер иясе Абай Конанбаевның тууына 150 ел тулу юбилеен бәйрәм итүдә катнаштылар.

Алматы, Симәй (Семипалатинск), шәһәрләрендә һәм Абайның туган ягы Җидебайда ЮНЕСКО кысаларында үткәрелгән юбилей тантаналарында 27 илнең, шул исәптән — Россия, Франция, Англия, Кытай, Мисыр, Төркия, Пакыстан, Һиндстан һәм күп кенә халыкара оешмаларның рәсми делегацияләре катнашты.

9 августта Алматы шәһәрендәге тантаналы җыелышта Татарстан Президенты М. Шәймиев нотык тотты. Җөмһүриятебез Илбашы казах һәм татар халыкларының, аларның әдәбиятының, күренекле шагыйрьләре Абай белән Тукайның рухи туганлыгы һәм якынлыгына аерата басым ясап сөйләде һәм, ахырдан, татар халкы исеменнән казах дусларга атаклы рәссамебез Б. Урманченың «Абай тирмәдә» картинасын бүләк итте.

Туганлаш Казагыстанда булу көннәрендә Татарстан Президенты М. Шәймиев Казагыстан Президенты Н. Назарбаев, Әзербайҗан Президенты Г. Алиев, Кыргызстан Президенты Ә. Акаев, Үзбәкстан Премьер-министры А. Муталов, Грузия һәм Төркмәнстан парламентлары спикерлары В. Гагуадзе, С. Мурадов белән очрашты. Бу очрашулар вакытында дәүләтара икътисадый, сәүдә, фәнни, мәдәни бәйләнешләр урнаштыру һәм тирәнәйтү проблемалары тикшерелде. Алматыда Татарстан вәкиллеген ачу турындагы килешүгә ирешелде. Президентлар Г. Алиев һәм Ә. Акаев М. Шәймиевны үз республикаларына рәсми визит белән килергә чакырдылар.

Татарстан Президенты М. Шәймиев ЮНЕСКО Генераль директоры Ф. Майор әфәнде белән дә очрашып сөйләште.

Татарстан делегациясе әгъзалары (алар арасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, республика халык депутаты Р. Мөхәммәдиев, язучы-академик Ф. Мусин да бар иде) Казагыстанда булу вакытында Абай мавзолеена һәм һәйкәленә чәчәкләр куйдылар, Симәйдә Абай музее комплексын, Җидебайда шагыйрьнең музей-мемориалын ачу тантаналарында, Абай районы үзәге Караултүбәдә акыннар фестивалендә катнашты.

Казагыстан җирендә шулай ук татар диаспорасы вәкилләре һәм татар-башкорт мәдәни үзәге әгъзалары белән дә очрашулар булды.

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ — «МАНАС» ЮБИЛЕЕНДА

Кыргыз халкының бөек эпосы — «Манас»ның 1000 еллыгы уңае белән, Кыргызстан башкаласы Бишкек шәһәре дөньяның 33 иленнән мәртәбәле делегацияләр кабул итте. Төркия Президенты С. Дәмирал, Пакистан Ислам Республикасы Премьер-министры Б. Бхутто, Әзербайҗан, Казагыстан, Үзбәкстан, Төркмәнстан Президентлары Г. Алиев, Н. Назарбаев, И. Каримов, С. Ниязов һәм башка күренекле дәүләт эшлеклеләренең килүе тантананың әһәмиятен аеруча күтәреп җибәрде.

Бирегә Татарстан делегациясенең килүе дә нур өстенә нур булды. Аны ТР Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары, язучы Р. Харисов җитәкләде. Делегация әгъзасы — язучы-галим Ф. Галимуллин «Манас» эпосы һәм дөнья халыкларының эпик мирасы» дигән халыкара симпозиумда катнашып, доклад белән чыгыш ясады.

## ПРЕЗИДЕНТЫБЫЗ ТУРЫНДА КИТАП

Казанда «Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев» дигән китап басылып чыкты. Китап авторлары — Рафаэль Мостафин белән Әнәс Хәсәнов Җөмһүриятебез Илбашының тәрҗемәи хәлен тәфсилле, республикабызның мөстәкыйльлеккә бару юлын шактый тулы чагылдырганнар.

## ЖЫРЧЫНЫ КАБУЛ ИТҮ

Татарстан Президенты М. Шәймиев Казан Кремлендәге үз резиденциясендә СССРның һәм Татарстанның халык артисты, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты, җырчы А. Аббасовны кабул итте. Дустанә җылы әңгәмә вакытында тамаша учреждениеләренең иҗади хәлен яхшырту, бүгенге кыен чорда әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренә матди һәм рухи ярдәм күрсәтү турында да сүз булды.

## МӘСКӘҮНЕҢ ПОКЛОН ТАВЫНДА МӘЧЕТ ТӨЗЕЛӘ

Бөек Ватан сугышында җиңүебезнең 50 еллыгы уңаеннан Мәскәүнең Поклон тавында Мемориал комплекс ачылган иде. Шәһит киткәннәр рухына анда чиркәү дә күтәрелде. Хәзер исә, архитектор Ильяс Ибраһим улы Тажиев эшләгән проект нигезендә (аны Мәскәү шәһәр төзелеше советы раслады), биредә мәһабәт мәчет төзелә. Борынгы Болгар җирендәге кебек, ул — сигез кырлы, гомуми мәйданы — 1200 квадрат метр. Әлеге Аллаһ йорты 1996 елның май аенда үзенең беренче дога кылучыларын кабул итәргә тиеш.

## ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Күренекле драматург — Татарстанның Г. Тукай исемендәге, РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Татарстанның һәм РФның атказанган сәнгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның тууына 60 ел тулу юбилее республикабызда һәм чит төбәкләрдә дә зурлап бәйрәм ителәчәк. Аның пьесалары буенча куелган спектакльләр сәхнәләрдә зур уңыш белән барды. Радио-телевидение тапшырулары аша миллионлаган тамашачылар Т. Миңнуллин иҗаты белән тагын да якыннрак таныштылар. Юбилярның туган ягы — Кама Тамагы районында да аңа багышлап күп кенә кызыклы очрашулар үткәрелде инде.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Казандагы театр училищесе директоры — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор һәм җырчы Мәсгут Имашевның тууына — 65, иҗат эшчәнлегенә 40 ел тулды. Шул уңайдан, аның туган ягында — Пермь өлкәсенең Барда районында иҗат кичәләре булып узды. Шундый кичәләр хәзер Казандагы Мәдәният сарайларында да дәвам итә.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Казанда хәтер көне. 1990 ел.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим.

Д. БУНТУКОВ фотосурәте.

# ХӨРМӘТЛЕ ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕЛӘР!

Инде Сезгә мәгълүмдер дип уйлыйбыз: быелның 1 сентябреннән 1996 ел өчен газета-журналларга язылу башланды. Ә «Казан утлары»н алдырырга теләүчеләргә мона өстәп шуны гына әйтәбез: иң беренче эш итеп, журналның шушы битенә урнаштырылган әбүнә кәгазен пөхтә генә итеп кисеп аласың да, тәртип белән генә — күрсәтелгәнчә — кирәкле графа-бүлемтәләрне тутырганнан соң, почта бүлекчәсенә йөгерәсең һәм кассага 24.000 (нибары егерме дүрт мең!) сум акча түләгәч — ел буена берсеннән-берсе кызыклырак, берсеннән-берсе мавыктыргычрак роман-повестьлар, хикәя-новеллалар, шигырь һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре,

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
"Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету / журнал 73210 (индекс издания)

Казан утлары (наименование издания) — Количество комплектов:

на 1996 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

---

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на газету / журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Кол-во комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | |

на 1996 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

халык тарихына һәм мәдәниятенә караган язмалар белән танышып куанып яши башлыйсың.

Ә тагын да кызыксынучанрак укучылар өчен тагын шунысы да мәгълүм булсын:

— журналның индексы — 73210;

— ул Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән һәм элеккеге «союз» каталогына кертелгән.

Хәерле сәгатьтә, «Казан утлары»н яратып укучылар!

Уңышлар Сезгә!!

**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

**ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!**

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

---

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки "ПВ-МЕСТО" производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Татарское отделение "Росбланкиздат". 1/24/112/. 02.95 г. т. 350000 Асбест. тип. З. 641.

# ЯҢА КИТАПЛАР




РАДИК САЛИХОВ, РАМИЛ ХАЙРУТДИНОВ. **Памятники истории и культуры Татарского народа.** Казан: Тат. кит. нәшр., 1995, 280 б. Тиражы — 5000 данә.


Китап — хәзерге Татарстан Республикасы территориясендә сакланып калган тарихи һәйкәлләр турында. Бу нәүбәттән караганда, бу җитди хезмәтнең басылып чыгуы икеләтә әһәмияткә ия: чөнки тарихи ядкарьләребез еллар үткән саен югала, сирәгәя бара. Китапка, күренекле шәхесләрнең кабер ташлары фотокүчермәләрен дә исәпләп, биш йөздән артык һәйкәл берәмлеге теркәлгән хезмәтнең беренче бүлеге Казандагы тарихи һәйкәлләр турында булса, икенче бүлеге Татарстан районнарындагы истәлекле объектларга багышланган. Халык тарихы белән кызыксынган һәркем өчен бу хезмәт үзе зур бүләк. Китап татар, рус телләрендә басылган.

**Сембер язлары.** *Коллектив җыентык.* Ульяновск: «Симбирская книга» нәшр., 1995, 280 б. Тиражы — 1000 данә.

Гасыр башында Рәсәйнең төрле төбәкләрендә татарча басма китаплар нәшер итү табигый хәл булган. Әмма соңгы еллар эчендә татар китаплары нигездә Казанда гына басылып килде. Ниһаять, заманалар үзгәреп, милли хәрәкәт көчәя төшкәч, милләттәшләребез күпләп яшәгән үзәкләрдә дә — әлегә сирәк кенә булса да — туган телебездә китаплар чыга башлады. Ульяновскида басылып чыккан бу китап шушы күркәм башлангычның бер мисалы. Полиграфик яктан камил эшләнгән бу китапка Ульяновск өлкәсендә яшәүче Иделбикә (Л. Садыйкова), Котдус Сафиуллин, Рифкат Хисмәт, Флорис Галимҗанов, Иркәм Хәйретдиннәрнең шигырьләре тупланган.



Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог